ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

8. 1998



# JAZUCЬLARЬBЬZ CIT ILLƏRDƏ



Şaƣir һəm çəməƣət eşleklese **Renat Xaris** BMOnьꞑ Millətlər sarajь konferenciələr zalьnda *(Ƶeneva, mart, 1998 jьl).*



Tatar PEN–yzəge əƣzalarь **Rafajel Mostafin, Əxət Muşinskij, Waxit Junьsof, Razil Wəlief** xalьqara PEN–klub kongressьnьꞑ utьrьşlar zalьnda *(Meksika, Gvadalaxara şəһəre, nojəber, 1996 jьl).*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1998

**8**

**(910)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Нажар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхмәт РӘШИТ. Сөйлә җиргә милләт хакыйкатен. *Шигырьләр* ..... 5
Ләбибә ИХСАНОВА. Кемгә сөйлим серләремне? *Автобиографик повесть* ..... 11
Гәрәй РӘХИМ. Аулак. *Шигырьләр* ..... 95
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Горур ялгызлык. *Шигырьләр* ..... 99
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Кечкенә кешеләр. *Хикәяләр* ..... 102
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Кайту ..... 124
Мөдәррис ВӘЛИЕВ. *Шигырьләр* ..... 126

**ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА**

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Һуннар- болгарлар, кыпчаклар һәм татар халкы ..... 134

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Сәгыйть ХАФИЗОВ. Әдәбиятта базар заманы ..... 148
Флера ГАНИЕВА. Шагыйрь гомере — аккошлар юлы. *(Роберт Миңнуллинга 50 яшь тулу уңаеннан)* ..... 163

**АКАДЕМИК МИРФАТИХ ЗӘКИЕВКӘ 70 ЯШЬ**

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Остазыбыз, дустыбыз ..... 171

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Хәмзә ЗАРИПОВ. Сабан туйларында — халкыбыз асылы ..... 175
Латин имласында уку күнекмәләре ..... 185

**ӘЙ, ГОМЕР АГЫШЛАРЫ...**

Мәңгеләшкән мизгелләр. *Фоторепортаж* ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": автобиографическая повесть Л. ИХСАНОВОЙ "Кому излить душу?", рассказы Р. ЗАЙДУЛЛИНА "Маленькие люди", стихи А. РАШИТОВА, Г. РАХИМА, Х. МУДАРРИСОВОЙ, а также цикл стихов Муд. ВАЛЕЕВА с предисловием Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
"К истории народа": статья М. ХАБИБУЛЛИНА "Гунны- булгары, кипчаки и татарский народ".
"Литературная критика": статья С. ХАФИЗОВА "Рыночные отношения в литературе ", к 50 — летию Р. Миңнуллина статья Ф. ГАНЕЕВОЙ.
"К 70 — летию академика М. Закеева": "статья А. АХМАДУЛЛИНА "Наставник, друг".
"Книжное обозрение": "Сабантуй — душа народа".
"Навыки чтения на основе латинской графики".
Фоторепортаж из коллекции М. Шакирзянова.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: тугра — родовой знак Президента Республики М. Ш. Шаймиева — работа художника-каллиграфа Н. Наккаша; писатель Султан Шамси.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

" Prose and poetry ": the autobiography story of L. IKHSANOVA " Whom can i open my soul?", the stories of R. ZAIDULLIN " The small people "; the verses of A. RASHITOV, G.RAHIM, KH. MUDARRISOVA and also the verses of M. VALIEV with preface of R. FAIZULLIN.
"To the people history": M. KHABIBULLIN'S article.
" Literary criticism ": S. KHAFISOV'S article " Marketing relations in literature",commemorating the 50th anniversary R. Minnullin F. GANIEVA'S article.
"Commemorating the 70th anniversary academician M. Zakeev", A. AHMADULLIN'S article "The teacher and the friend".
" Book's review ": Sabantuy - the soul of people.
Skills of reading on the basis of Latin script.
Fotoproduction from the M. Shakirzanov's collectuon.
The diary of social and cultural life.
In our covers: the wirk of N. Nakkash, the writer Sultan Shamsi.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.07.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108[1]/[16].
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 11500. Заказ Я-320
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Əxmət Rəşit

SƟJLƏ ÇIRGƏ MILLƏT XAQIQƏTEN...

### Məjdan kɵtə

Səƣədətlek ɵcen jodrьq bulьp
Tɵjnəlergə tieş zamanda
Ike tatar ɵc partiə bulьp
Tartqalaşa əle һaman da.

Berqatlь da inde bezneꞑ xalьq –
Jaular caqta daulap, davajlap,
Suverenlьq qajcan birələr, dip
Sorьj minnən qajber aƣajlar.

Tot qapcьgьꞑ – birdelər, di, siꞑa –
Et awьzьnnan səjək al, jylər!
Xəjer genə sorap alьp bula,
Azatlьqnь sorap birmilər.

Əle caq bulьr ul – çan talaşьp,
Qorban birə–birə alsaq ta;
Şuꞑa kyrə kiler kɵneꞑ ɵcen
Məjdanƣa cьq forsat bar caqta.

Ə utьrsaq şɵker itep kenə
Bəleş aşap tujƣac kikerep,
Suverenьn tygel, xətta suьn
Birməs bezgə berkem kiterep.

* * *

Qajsь bajƣa barьp başьm iim –
Kem aꞑlar da mine, ni diər?!
Ɵstəlemdə, dɵnja kyrergə, dip
Tilmereşep jata şiƣerlər.

Kemder, әnә, sponsorlar tabьp
Һәm çajlaşьp qьsьr jьllarƣa,
Өc tiengә tormas taqmaƣьn da
Zatlь kitap itep cьƣara.

Min әjtәse oluƣ xaqiqәtlәr,
Min sәjlise xalqьm ytkәne
Mie tәmam tyngәn adәmnәrgә
Inde kirәk tygel mikәnni?!

Mәnfәƣәte fani bu dәnjanьn̡
Biegәndә qьrƣьj "tamtam"ƣa,
Kyrce, kypme asьl şaƣirlәrnen̡
Jәrәgennәn sarqьp qan tama.

Әrәm bit, dip, kyn̡el çimeşlәrem,
Jalƣьz janьp şiƣer utьnnan,
Kyktәn sәrelgәn qart pәjƣәmbәrdәj
Awьr ujlar ujlap utьram.

## Qolşәrif mәcete

Qolşәrifkә atap mәcet saldьq —
Manaralar başь altьn aj;
Tәqdirlәrgә nilәr jazьlƣandьr —
Jazmьşlarnь belә ber Xodaj.

Biek—biek manaraƣa menep
Jan̡ƣьratьjq mon̡lь azannь!
Qolşәrif lә digәn i izge zat
Şәhit kitte jaqlap Qazannь.

Ƣasьr artь ƣasьr kicә tordь —
Zilzilәlәr, çillәr ujnadь;
Әmma xәter ilnen̡ asьl ire
Qolşәrifne onьttьrmadь.

Ul bygen dә әle beznen̡ belәn —
Sәjeklese izge zatlarnьn̡;
Kyn̡ellәrgә jaqtь ujlar salьp
Kilәcәkkә әjdi tatarnь.

## Sinen̡ jьlmajuьn̡

Kyn̡elen̡dә әllә nilәr bardьr,
Kyn̡elen̡dә çil wә dawьllardьr,
Parә-parә kilgәn jәrәk belәn
Kәlep kenә jәşәy, әje, awьr.

Lәkin kyn̡elen̡ azat qara şomnan,
Jәzlәren̡ә һәrcaq qojaş qunƣan —
Tirә-jyndәgelәr bojьq caqta
Şifa taba sinen̡ jьlmajudan.

Ecenƣə ut jansa, əjdə, jansьn,
Irenŋərdən ħaman nurlar tamsьn —
Ytkəndəge tik ytkəndə qalsьn —
Yz-yzenŋe çiŋep gel jьlmaj sin.

Sin jьlmajsaŋ, çanƣa rəxət bula,
Sin jьlmajsaŋ, çanƣa şatlьq tula;
Juƣisə bit kyŋel baqcasьna
Bəxet qoşь, aj-ħaj, sirək quna.

Dənja qьrьs. Əmma jəşise bar,
Jəşəy təmen tatьp jəşnise bar —
Bojьƣudan, kyqel təşylərdən
Qotqara tik kersez jьlmajular.

## Ber ujlap qarasaŋ...

*(Ekzjuperinьŋ "Bələkəj prins"ьn uqьƣac)*

Sin, səjeklem, aculanma miŋa —
Min tormьşta "şyrəle kyk nadan";
Başqa planetadan, diseŋ mine —
Əje, əje, min cit planetadan.

Min jьraqtan kildem, çildəj çilep,
Al taŋnarьn Çirneŋ kyrer əcen,
Tuzƣanaq ta tygel, ameba da...
Adəm bulьp Çirdə jərer əcen.

Min məŋgelek illərennən kildem —
Anda ƣəmer ciklənməgən ide.
Min qoş bulьp tygel, keşe bulьp
Beraz jəşəp qarau əcen kildem.

Min jьraqtan kildem, ƣələm gizep,
Kəc wə qyət çiьp bar joldьzdan;
Inde sentavrьnьŋ al'fasьnnan
Kitkəngə də million ƣəmer uzƣan.

Min onьttьm inde cьn isemem —
Bez səjləşə idek bytən teldə;
Tik nigə soŋ Bəjek Təzyce Zat
Olaqtьrdь mine şuşь ilgə?

Sez başqaca ikən, sez başqaca,
Sezneŋ dənjaƣьznь aŋlau qьjьn;
Ə nişləp soŋ jaqьn itte kyŋel
Jat dənjanьŋ səjer ƣəməl—ujьn?

Ħəm... nişləpter Kordiljerlar tawь...
Amazonka mine caqьrmadь...
Ħəm... cit kyrde, qabul italmadь
Gobi cyle... Tibet taqьrlarь...

Aq qajьnlь, sajrar sanduƣaclь
Şuşь təşkə kilep təşkənmen min,

Əmma jəşəjeşnen anlajьşsьz
Tuqsan tuǥьz seren cişkənmen min.

Jazmьşьma şulaj jazьlǥanmь —
Eləkkənmen nigə nəq bu ilgə?
Min bəxetsez tygel — şulaj ikən,
"Nigə?" digən sorau biry nigə?

Balalarьm, əje, çir ullarь —
Adəm belən Xəywa nəselennən;
Ə şulaj da kynel qəǥbəsendə
Taǥьn əllə nilər jəşerelgən.

Һər tan sajьn sorau birə mina
Əkiətle wə kompjuterlь zaman.
Min kyptənge çismi tormьşьmnan
Һaman əle, һaman ajьrlmaǥan.

* * *

*Sabaqtaşьm akademik Foat Ǥarifullinǥa*

Bu garmunnьn ni tьlsьmь bardьr? —
Ujnaǥanda Foat, ber tьnьp,
Şuşь tellərenə bas sin, diep,
Barmaqlarь tora ьmsьnьp.

Jərəgenen qajsь qьllarьnnan
Əzelep tama ikən bu monnar?
Ujnьj garmun, ujnьj, ul ujnasa,
Tьnьc qьna anь kem tьnlar?!

Bez jəşəgən ǥəmer, ni ǥəçəpter,
Şuşь garmun monь şikelle,
Cьnlap quja, inde jьraq qalǥan
Jəş caqlarnьn sonь şikelle.

* * *

Jaz inde bu. Jaz uramda —
Cəcne nazlь çil tarьj.
Dərte quzǥalǥan qьzьjlar
Məlderəp kyzgə qarьj.

Qaraşlardan baş əjlənə —
Jaz başь şul, jaz başь...
Jəşlekkə qajtьp, janadan
Jəşise kilə başlьj.

## Jьlama!

Jьlama, kimsenmә, ɡorur bul —
Kyp alar rәnçergә sәbәplәr.
Sin ьşan — barьber bar alda
Sәɡәdәt kiterer sәɡәtlәr.

Ɡөmer bit! — dinɡezlәr kicәse,
Daru da, aɡu da ecәse.
Kөn ytәr — ә ɡөmer sonьnda
Xәterdә qalьr son nicәse?!

Sin bәlki... keşelәr yzen kyk
Riasьz һәm ixlas, disender,
Bu qьrьs dөnjada ɡazap kyp,
Ә sin yz—yzenne ysender.

Jөrәkkә uq bulьp qadalɡan
Ɡәmәllәr kyp bulьr, lәkin tyz —
Bu minem sina cьn kynеldәn,
Duslarca juatьp әjtkәn syz.

Çanьnda izgelek utlarьn
Synderә almasьn jьllar da.
Jәşise ɡөmerlәr bar әle —
Ɡorur bul, kimsenmә, jьlama!

## Illәr gizep...

*Tatarstan çьr һәm biy ansamblenә*

Beznen awaz qajda janɡьramas —
Sibelmәɡәn tatar qajda ɡьna;
Kaja barsan, şunda millәttәşlәr,
Jәşәmider tatar ajda ɡьna.

Tik tarixьn barьber onьtmaɡan,
Onьtmaɡan monьn, tuɡan telen;
In qәderle qunaq itep kөtә
Beznen çьr һәm biy ansamblen.

Beznen xalьq, acsan kynеllәren
Jөrәk saɡьşlarьn tьrnьj—tьrnьj,
Rәxәtlәnep kөlә—kөlәr çirdә,
Jьlьj-jьlьj tьnlьj monlь çьrnь.

I bu beznen jazmьş, mөһаçirlek
Qaj çirlәrgә bezne taşlamaɡan!
Tuɡan ilne saɡьnьp һәm monajьp
Qajsьbьznьn kyze jәşlәnmәɡәn!

Çьrlarьbьz beznen tatlь aһәn —
Anlьj anь һәrber ixlas kynеl,
Biyebez beznen zatlь, nәfis —
"Tudьj-sudьj bugi-vugi" tygel.

Aŋlьj anь japon, qьtaj, alman... —
Şuŋa kyrә meskenlәny nigә?!
Negr bulьp xәtta negrть da
Bietkәn bar yzebeznen kәjgә.

Tatarstan danьn jaŋqьratьp,
Ilce bulьp bytәn xalьqlarqa,
Qajda qьna alkьş işetmәde
Tatar çьrь һәm biye anda.

I ansambel, giz sin ildәn ilgә,
Sajlamьjca julnьŋ çiŋellәren,
Sәjlә çirgә millәt xaqiqәten,
Ujat, ujat xalьq kyŋellәren.

## Mәһaçirlәr

Kirәk cakta gel—gel soŋqa qaldьq,
Kirәkmәgәn caqta aşьqtьq;
Tәqdirlәrgә nilәr jazьlsa da,
Bez tormьşqa mәŋge qaşьjqtьr.

Gyzәllegen, kamillegen ezlәp
Kamillege qackan dәnjanьŋ,
Qajsь qьjtqasьna suqьlmadьq,
Urьj—urьj anьŋ bar jaqьn.

Ingә sarqan Gobi tuzannarь,
Savannalar kergәn jәrәkkә,
"Sibelә cәcәk" çьrьn kәjli—kәjli
Sibelgәnbez jьraq—jьraqqa.

Mәһaçirlek mәllә qanqa seŋgәn,
Rizьq mәllә şulaj jәretә?!
Ata—baba qәberlәren saqьnьp
Uftanabьz lәkin kic—irtә.

Jat itsә dә qajcaq tuqan tufraq,
Jat itmәdek tatar ujlarьn —
Amazonka jarlarьna barьp
Bәjrәm ittek Saban tujlarьn.

Qajsь qьjtqalarqa kyz salsaŋ da,
Moŋajьp һәm jәşerep jarasьn,
Kypme cit—jat qawem arasьnnan
Qarap torьr tatar balasь.

Kaja barsaŋ da ber qojaş tygel,
Cәcәk ysmәsә dә julьnda,
Soltan bulmasa da, oltan bulmas —
Tatar әcen qanun şul qьna.

Kojaşlardan arь qojaşlar bar,
Tuqan ildәn arь illәr bar,
Jazmьşlarnь suqbaj dyŋgәlәktәj
Tәgәrәtep jәrtkәn çillәr bar.

# Чәчмә әсәрләр



**Ләбибә Ихсанова**

## КЕМГӘ СӨЙЛИМ СЕРЛӘРЕМНЕ?..

ИСТӘЛЕК – ПОВЕСТЬ

### Туган өй җылысы.

**Безнең авыл заманында базарлы авыл иде. Һәр атнаның җомга иртәсендә югары очтагы кибет мәйданына печән, юкә кабыгы, нарат сагызы, җитен сүсе, утын, җиләк-җимеш кебек табигать хәзинәләре, тире-яры, чабата, балта-көрәк сабы ише кирәк-ярак, кәҗә, сарык сыман вак мал, тагын шундый нәрсәләрне сатарга һәм сатып алырга дип, тирә-як авыллардан күп кенә кеше җыела. Түбән очтагы өебез турыннан да базарчылар үтеп йөри, барганда да, кайтканда да аларның бер генә минутка булса да тукталып, өй түрендәге бакчабызга сокланып карап торуларын күрәм. Сугыш елларында һәм сугыштан соң, сатарлык әйбер булмагач, үзеннән үзе бетте ул базар. Авыл урамы бушап, сүлпәнләнеп калды. Шулай да Идел аша кичү юлы өстендә утырган авыл бөтенләй үк кешесез дә түгел иде. Үтеп-сүтеп йөрүчеләрнең әле берсе, әле икенчесе бакчабызга күз төшерми китмиләр. Гөлләр, чәчәкләр үстерергә ярата шул безнең әниебез. Ул аларны сайлап кына, әле авылда күренмәгән затлыларын гына табып үстерә.**

**Мин әле хәзер дә далияләр, кашкарыйлар, үрмәле гөлләр шау чәчәк аткан бакчада, августның саран кояшында җылынган койма тактасына арка терәп, җәйге практикада язып барган дәфтәремне актаргалап утырам. Ашык-пошык сызгалаган юллар аша ташларга бәрелеп аккан елга тавышын, җирдә чайкалган агачларның шомлы шаулавын, тымызык кичләрдә черки күченең җанга тиеп безелдәвен ишеткән кебек булам. Ике-өч кешелек кенә отрядыбыз башлыгы Пипин агайның, билдән үлән ерып, юлсыз җилдән юл салып барган армас-талмас тынгысыз җанның кояшта, җилдә агарып беткән плащ аркасын күрәм.**

**Шулай истәлекләргә бирелеп утыруым эш юктан эш табып вакыт үткәрү өчен генә түгел, диплом эше тора минем алда. Шуны яклаганда көймән комга терәлсә, биш ел укып йөргәнең җилгә очты дигән сүз, диплом урынына "программаны үтте" дигән язу гына аласың. Андый хурлыкны теләмәсәң, алдан ук баш ватасың булыр.**

Мин бу сәяхәткә рухланып, китаплардан укыган кебек күңелле мажаралар көтеп чыктым. Төшкә дә кермәгән ят җирләрдә йөрү, бигрәк тә кыз бала өчен шактый җайсыз булган эш шартларына күнегә алу шатлыгы, үтә игътибарлы юлдашларымның адым саен ярдәм итәргә торулары ошый иде миңа. Романтик хисләрнең тора-бара сүрелеп киткән, мәшәкатьләрнең туйдырган, ардырган чаклары да булды булуын. Әмма барыбер канәгать идем. Өйгә кайткач, чегән кебек каралган, чат сөяккә калган кызын күргәч, әниемнең күзенә яшь килсә дә, минем күңелем күтәренке иде. Табигать матурлыгын күреп, тоеп үскән кыз лабаса мин, яшел чирәмгә яланаяк басуның рәхәтен дә белмәгән шәһәр баласы түгелмен. Якты дөньяның йомшак җилләренә йөзем куеп иркәләнүдән, салкын чишмә суларын ләззәтләнеп эчүдән, саф һавасын кинәнеп сулаудан туймас, ахры, минем җаным.

Авылыбыз да бик матур җирдә, Шөн елгасының Иделгә койган җирендә урнашкан. Бер яктан Толлы, икенче ягыннан Ярмәкәй таулары усал җилләрдән ышыклап тора. Элек заманнарда бу җирләрне үтеп чыга алмаслык калын кара урман баскан булган, диләр. Шулайдыр, безнең заманнарга ук килеп житкән Аю күле, Бүре базы дигән атамалар бар. Хәзер монда бодай басуы. Без шуннан үтеп, Ярмәкәй тау башына чикләвек, шомырт, балан, миләш җыярга йөрибез. Ә Идел аръягында печәне билгә җиткән болыннар, көмеш чабаклы күлләр җәелеп ята. Аларны да узгач, кара җиләкле, кура җиләкле карурман китә. Әле генә мин йөреп кайткан Урал тауларына барып терәлә ул нарат урманы. Шәһәргә укырга киткәнче Фәрхинурлар белән шунда җиләккә йөри идек. Өч-дүрт кыз кичтән сөйләшеп куябыз да, берәр карчыкка ияреп, иртән бик иртә чыгып китәбез. Әле кояш күтәрелеп кенә килә, үлән өстендә әле көмеш төсле салкын чык, ышык җирләрдә мамык кебек куе ак томан. Күбебезнең йокысы да ачылып җитмәгән, иртәнге салкынга чыерап, авызыбызны зур ачып, тәмле итеп иснәп барабыз. Без күбрәк түбән очның Мортый карчыгы белән йөрергә яратабыз. Ул урманны әйбәт белә, күзен бәйләп җибәрсәң дә җиләкле урынны таба, дип әйтәләр аның турында. Мортый карчыгына ияреп барган кызларның ярты потлы су чиләген тутырмыйча кайтканнары юк әле.

Мин үзем җиләк җыярга алай маһир түгел, җиләк пешкән җирләрне үзем эзләп таба белмим, күбрәк Фәрхинурлар артыннан йөрим. Алар, курадан курага очып кунган төклетура кебек, эреләрен генә сайлап җыялар да икенчесен эзләп китәләр. Мин шул алардан калганны чүпләп вакыт үткәрәм. Печән чүмәләсе кебек кырмыска оясына килеп төртелсәм, анысын җыярга да онытам. Кара инде бу нечкәбилләрне! Мең генә түгел, миллиондыр үзләре, бертуктаусыз чабышалар, эшем кешеседәй ашыгалар, ник шунда берсенең юлына берсе аркылы төшсен, ник кенә дип берсе икенчесенә килеп бәрелсен, һәркайсының үз юлы, үз сукмагы бармы икән әллә аларның? Кешеләр, мондый ыгы-зыгыга тарсалар, авызборыннарын канатып бетерү генә түгел, бер-берсен таптап, изеп үтеп китәрләр иде. Нинди кодрәт белән шулай камил булып яратылды икән бу дөньядагы табигать дигән могҗиза? Кеше акылы житмәгән тагын нинди серләре бар икән? Без дә йөргән булабыз бит синең кыргый көчеңне буйсындырабыз дип. Уйлап карасаң бер дә кыргый түгел, бик тә акыллы, мәрхәмәтле көч икәнсең бит син. Минем әтием —биология укытучысы дәрес биргән саен әйткәне бар: табигать ул мәрхәмәтле, игелекле, ул кешене тынычландыра, сафландыра, ул кешегә иҗади көч, акыл бирә, киң күңелле итә, урманда, кырда йөрергә яраткан кешенең эчендә явызлык булмый, дип әйтә иде.

Бервакыт җиләккә баргач, үземнең дә шундый хәлне кичергәнем булды. Иптәшләрдән калып йөри торгач, куе наратлыкка барып кергәнмен. Ә наратлар шундый төз, шундый биек, башлары белән зәңгәр күкне терәп торган кебек. Ак каурый болытлар агач башларын сыйпап үтә сыман. Мин аларга кое төбеннән карагандай карап торам, ә үзем сәер

бер хис кичерәм, озын буйларын тота алмагандай әллә агачлар чайкала, әллә минем башым әйләнә, әллә аяк астымда әкрен генә җир тирбәлә, мәгәр бик рәхәт миңа. Бишектә тирбәлгән сабый бала гына тойса тоядыр мондый рәхәтлекне. Күңелем ашкына, канатланып очасым, шул ак болытлар янына очып менәсем килә. Иптәшләремнең чакыру авазы гына айныта мине бу халәттән:

— Лә-би-бәү-ү-ү!

Инде менә Уралның таулы-ташлы урманнарын да күреп кайтырга насыйп булды. Урал табигате икенче төрлерәк шул. Ул кыргый, караңгы чырайлы булып тоелды миңа. Авыз ачып йөреп булмыйдыр анда, ваемсызлыктан бигрәк сак булырга кирәк.

Бу ел безгә — Казан Дәүләт университетының география факультеты студентларына шактый җитди эш йөкләтелгән иде. Сугыш беткән генә еллар, бөтен җирдә төзелеш бара, электр энергиясе бик кирәк. Зур куәтле станцияләр салырга әле илнең көче юк, вакытлыча вак елгаларның көченнән файдалану көн тәртибенә куелган чак. Без дә, ике-өч кешелек отрядларга бүленеп, Свердлов өлкәсенең төрле районнарына таралыштык. Безнең отряд Молотов өлкәсе (хәзерге Пермь) белән чиктәш төньяк районда эшләргә тиеш булды. Бик гадел рәвештә, елганың агып чыккан чишмәсеннән башлап койган җиренә кадәр, йөзләрчә чакрым җирне җәяүләп үтеп, аның киңлеген, тирәнлеген, агым тизлеген, елга төбенең һәм ярларының характерын торымнан торымга үлчәп, дәфтәрләребезгә теркәп бардык. Соңыннан шул мәгълүматларга таянып, белгечләр бу елгада электр станциясе салырга мөмкинме-юкмы икәнен тәгаенләр, ә без үзебезнең диплом эшебезне язарбыз.

Көннәр җылы, матур тора, ачык һавада учак ягып пешергән ашны яшел үләнгә кырын ятып ашау, авылларга барып җитә алмаган көннәрдә, черкиләр белән сугыша-сугыша, урманда төн үткәрү кызык тоелды. Тирә ягымда әле мин күрмәгән, күз алдыма китереп карамаган, урманлы-чытырманлы, ят, күңелгә шом салып торган кыргый табигать. Үземне романтик китаплардагы геройларның берсе кебек хис иткән чакларым. Түзмәдем, ял итәргә утырган бер кечне шигырь сыман нәрсә дә язып куйдым.

Мана-мана калын чыршыларның
Ботакларын алтын төсенә,
Кояш байый, шәфәкъ нурын сибеп
Күкселләнгән урман өстенә.
Чурлап аккан көмеш чишмәләргә,
Аланнарга, агач башына
Акрын гына килеп канат яба
Караңгы төн шунда барсына.
Зур ташларга бәрелеп шаулап аккан
Салкын сулы елга ярында
Гидрологлар туктап ут яктылар,
Ял итәргә учак янында.
Коры чыбык яна дөрли-дөрли,
Ялкыннары күккә үрелә,
Елга өсте, яшел киң аланнар
Кичке томан белән күмелә.

Ә бер көнне елга буенда ялгыз утырганда сәер дә, сөенечле дә уй килде күңелемә. Сәерлеге шунда — проза язып карарга булдым. Барып чыгарына ышанып та җитмим үзе, әмма гел үртәп, кытыклап тора башлады бу уй мине. Шулкадәр матурлыкны, җәй буе күргәннәремне шигырь юлына сыйдырып буламыни? Шигырьгә түгел, күңелгә генә дә сыйдырып булмый аны. Авылдагы туганнарым, тулай торактагы сабакташларым белән генә булса да бүлешәсем килә. Моның өчен киңрәк мәйдан кирәклеген күңелем сизә, ритмнар, рифмалар белән талашмыйча гына, кәгазь битен

тутырып язасың да язасың инде. Исеме дә телдән сикереп төшәргә тора бит хәерсезнең: Көмеш елга! Шулай дип атармын, шушы елга буенда йөрибез ләбаса.

Эшебез төгәлләнеп килә иде инде. Елга тамагына килеп җитәргә, калса, чама белән ике көнлек юл калды. Үзәк базага кайтып сабакташлар белән очрашыр, малахит валчыклары сибелгән яшел калкулыкта, базаның ишек алдында, баштан үткәннәрне бер-беребезгә сөйләп утырыр чаклар да җитә. Аннан һәркайсыбыз туган өйләргә таралып, октябрьга хәтле ял итәрбез. Ләкин бу татлы уйларны ямьсезләгән бер нәрсә бар — менә ничә көн инде ачлы-туклы йөрибез. Елап сорасаң да, акчага берни бирмиләр. Ипине әйтәсе дә юк, авыллардан бәрәңге дә табып булмый, искесе беткән, яңасы җитмәгән чак шул. Пипин агай белән икәү киңәштек тә, өченче кешебезне кайтарып җибәрергә булдык. Бәхетсезлеккә, ул, әллә белеп, әллә белмичә, соңгы консервыларыбызны да алып киткән булып чыкты. Бу хәлгә күпне күргән Пипин агай да югалып калды. Әле ярый, без кунып калган өйнең хуҗасы мәрхәмәтле кеше булды, кызганып, яңа сауган җылы сөт салып бирде. Рәхмәт әйтеп һәм тияр хакын түләп, кырга чыгып киттек. Ләкин эчкән сөтебез нихәтле куе һәм туклыклы булса да, буш карынны озак майлап тора алмады, төш җиткәндә тәмам хәлдән тайган идем инде. Башым әйләнеп, күз алларым караңгыланып китә башлады. Ахырдан, тигез җирдә сөртенеп егыла язуымны күргәч, Пипин агай бер карарга килеп:

— Болай булмый, сеңлем, мин менә бу авылга барып кайтыйм әле, — дип, эре масштаблы картадан бер ноктага төртеп күрсәтте. — Базарлы авыл дигән. Базары таралса, кибете булыр, кулга бирәр нәрсә төшереп булмасмы.

Шулай итеп, ул китеп барды. Ә мин эшсезлек рәхәтенә куанып, кыл да кыймылдатасы килмичә, каен күләгәсендә утырып калдым. Баштарак ялгызлыкны сизмәдем. Пипин агай да ерак китмәгәндер, чыршы ботаклары арасыннан килеп чыгар да янымa утырыр кебек иде. Тәкатьне корытырлык шомлы тынлык та сизмим. Ташлар арасыннан бәреп чыккан чишмәнең, җырлый-җырлый, Көмеш елга тарафына чабуын ишетеп торам. Үлән арасындагы чикерткәнең кыштырдавы колак төбендә. Аяк очымдагы чәчәк тирәсендә пар күбәләк әйләнүен карап утырам. Берсен-берсе куышып югарыга очып киттеләр дә күздән югалдылар, озак та тормыйча тагын әйләнеп килделәр, ак канатлары белән ак чәчәккә орыныр-орынмас тирбәлеп торгач, әйләнә-әйләнә, әбәкле уйнаган сабыйлар кебек, тагын куыша башладылар. Каен ботагындагы борындык, бу нинди ят кунак тагын дигәндәй, чем кара күзләрен җемелдәтеп, миңа таба карап торды да, ялт итеп, яфраклар арасына кереп югалды. Кара буйлы сырты гына күренеп калды. Әлләни ерак та түгел, кайдадыр агач башында тукран тукылдый: тук-тук-тук...

Син тук булганнан безгә ни файда, безнең хәлләр яман бит, дигән шаян уй башыма килә дә үз алдыма елмаеп куям. Мин шулай гамьсез бер тынлыкка тарып утырган да утырган булыр идем, кинәт, көтмәгәндә бер ямьсез уй күңелемә килеп керде дә сискәнеп киттем. Кырын яткан җиремнән торып утырдым, шөбһәләнеп, як-ягыма каранып алдым, йөрәгем дөп-дөп кагарга, колагым шауларга тотынды. Мине курку биләп алган иде. Әллә кайда, җәһәннәм читендә, туган җиремнән мең чакрым еракта, авыллар да анда бер, монда бер генә булган урында кара урман уртасында бер ялгызым утырам лабаса! Бүре-мазар килеп чыкса, ни эшләрмен? Мондый җирдә аюлар да ерак йөрмидер. Айба елгасы башына килгәч, монда аюлар тыюлыгы, аучылар да өчәр-дүртәр кеше йөри, куркыныч, дип борып кайтарганнар иде үзебезне. Агач башына менеп тә, елгага төшеп тә котылып булмас аннан. Пипин агай кайтуга шушы каен төбендә канлы сөякләрең генә таралып ятса!

Үзем дә сизмичә урынымнан сикереп торган идем, әллә аякка басуым соңгы көчемне бетерде, әллә куркуым котымны алды, әллә

ачлыктан күз алдым караңгылана башлавын тойдым. Агачлар, чәчәкләр, пар күбәләкләр аяк астымнан шуып чыккандай бер якка агыла башлады һәм шул ук мизгелдә кара кәеп юк та булды. Мин үзем дә шул караңгылыкка чумып эреп беттем кебек.

Шуннан соң күпме вакыт үткәндер, битемә салкын тиюдән күзләремне ачсам, каен төбенә чалкан төшеп ятуымны күрдем. Пипин агай кульяулыгын чишмә суында чылатып, битемне, чигәләремне сөртеп тора. Уңайсыз булып китте. Күлмәк итәгемне тарткалап торып утырдым.

— Хәлең ничек? — диде ул, гаять борчылып.

— Әйбәт, — дидем мин, аны тынычландырырга теләп. Хәер, ялгыз түгеллегемне күргәч, үзем дә бик шатланган идем. — Сез кайчан кайттыгыз соң?

— Әле янарак кына. Менә, күрәсеңме нәрсә алып кайттым? — Зур тантана белән алдыма бер бөтен кирпеч ипи китереп куйды.

— Яшибез икән болай булгач, — дип әйтеп тә бетермәдем, сораулы күзләремне аңар төбәп калдым. Отряд башлыгының иртән дә, кичен дә өстеннән төшмәгән, җилдән, яңгырдан, кояштан, черкидән бик әйбәт саклый торган плащы өстендә юк иде.

— Акчага берни дә бирмиләр, — диде ул, сүзсез соравыма җавап итеп. — Баш исән булса, мал табылыр. Менә хәзер чәй куеп җибәрәбез...

— Ләбибә апа, сине бер абый эзләп килгән!

Венера сеңлемнең тавышы мине Көмеш елга буеннан үзебезнең чәчәк бакчасына кайтарып утыртты. Чандыр гәүдәле, җаныңны иркәләп карый торган чем кара күзле, чәчен ике кыска толымга аерып үргән сеңлемә беренче кат күргәндәй текәлеп карап алдым. Хикмәт шунда, әле кичә генә шушы сөйкемле кызыйны эт итеп тиргәп ташлаган идем бит. Ул минем кешелеккә генә тота торган бердәнбер күлмәгемне киеп урамга чыккан. Иптәшләре янында матур күренәсе килгәндер инде. Рәтләп кия белсә икән әле. Билен пута белән буган да аннан-моннан кыстыргалап, үзенә таман иткән, янәсе. Җитмәсә, яшел чирәмгә утырып, итәгенә тап төшергән. Ул кичне без Фәрхинур белән клубка чыгабыз диеп сөйләшкән идек. Болай булгач чыктың сиңа, менә, бар!

Шушы кичтән соң Венера минем белән сөйләшмәс тә дип уйлаган идем, таң алдыннан яныма килеп ятты да нәзек, кайнар беләкләре белән муенымнан кочып алды:

— Мин сине төшемдә күрдем, Ләбибә апа. Казанга киткәнеңне. Бөтенләй кайтмыйм, дип әйттең.

— Төшкә киресе керә.

— Син китмә, апа, өйдә генә тор.

— Минем өчен кем укыр, Пушкинмы? Мин сиңа ачуланам да әле...

— Ачулансаң ни...

— Үпкәләмисеңме?

— Үпкәләмим, — диде сеңлем, яныма сыена төшеп, аннан соң балаларча беркатлылык белән, — син өйдә булгач, әни тәмле әйберләр дә пешерә, — дип куйды.

— Мин югында бик эләкмимени?

— Кая ул, бәрәңге дә бәрәңге...

— Келәттә оныгыз бар бит.

— Син кайтуга дип, әни Җөридән китертте. Чана шәленә алыштырып.

— Ул шәл дә очтымыни инде?

Әнинең бик зур, үзе җылы, үзе җиңел шәле иде ул. Үсмер чакта юрган урынына аны мин ябынып яттым, миннән соң Венера сеңлемә калды. Ерак юлга чыкканда әни үзе дә чанада толып урынына шул шәлне бөркәнеп утыра иде. Сугыш башланганнан бирле безнең өйдәге затлырак әйберләр шулай берәм-берәм йә онга, йә бәрәңгегә алышып, тамакка кереп беткән иде инде. Хәзер шәлгә дә чират җиткән икән.

Әнә шундый моңсу һәм туганнарча эчкерсез сөйләшү булып алган иде безнең арада. Сеңлемнең күзләре элеккечә нур чәчә, үпкәләүнең эзе

дә юк, кичәге күңелсез хәл бөтенләй булмаган дип әйтерсең. Мин генә үкенүдән, уңайсызланудан айнып җитә алмыйм.

— Тор инде, кереп җитә бит ул, — дип пышылдады Венера, бакчага кердә торган җил капкага ишарәләп...

Башымны күтәреп карасам, бакча рәшәткәсенә таянып Шәрәф басып тора! Әнекәйгенәм! Күзләремне бер ачам, бер йомам, кояшта җебеп утыра торгач, йоклап киткәнменме әллә? Төш күрәмме? Казанда булырга тиеш кеше нигә монда басып тора ул? Ә сеңлем кулымнан тартыпмы тарта. Димәк, төш түгел, димәк, өнем бу. Ышанырга да ышанмаска да белмичә, әкрен генә аңа якынлашам.

— Әллә кертмисең дәме? — ди Шәрәф, үзенең авызы колагына җиткән, кычкырып кына көлми.

— Ничек килдең?

— Толлыга хәтле машина белән, Толлыдан соң җәяү, — ди ул мине үртәп.

Мәгънәсез соравымны ачыграк әйтергә тырышам.

— Килергә ничек уйладың дип әйтүем.

— Гәзиттән Тәкәнеш районына командировка бирделәр. Колхозларда йөри торгач, сезнең күрше авылга да килеп чыктым, — диде ул җитдиләнеп. — Җәләй аганың шәкертләре шунда икән. Безнең янда кал да кал, диләр.

— Әллә Җәләй ага үзе дә андамы?

— Үзе юк. Егетләрне аспиранты алып килгән. Нократ диалектын өйрәнәләр.

— Алар белән каласыңмы соң?

— Командировкамның вакыты бетте. Сезнең авылны тау артында гына дип ишеткәч, барып килим әле, дидем. Безнең сәяхәтче кыз ничек ял итә икән, белеп кайтыйм, дим.

— Әйбәт иткәнсең...

Без әле һаман икебез рәшәткәнең ике ягында басып тора идек.

— Кара инде, кунакны капка төбендә тоталармыни? Әйдәгез, өйгә керегез, — дип, сөйләшкән тавышыбызга әни килеп чыкты да өйгә кыстый башлады. — Венера кызым, син самовар куеп җибәр.

— Әни, шагыйрь Шәрәф Мөдәррис була бу, — дидем кунак егет белән таныштырып.

— Бигрәк зур кунак икән. Исәнмесез.

— Исәнмесез, Гыйлембану апа. Анда, Казанда Ләбибә гел сезнең турыда сөйләп тора.

— Сагынадыр шул.

Шәрәфне шагыйрь дип таныштырсам да, бу егетнең минем өчен гади бер кеше генә булмавын әнием сизенә иде, билгеле. Шуны белүдән безгә дә уңайсыз, барыбыз да тартынабыз, чәй янында сөйләшүебезнең дә рәте-чираты булмады. Ярый әле эти белән Ренат гөмбәдән кайтып керде. Кунакны күргәч, Ренат кыю гына килеп кулын бирде:

— Исәнмесез, Шәрәф абый!

Яз көне Казанда күрешкәч алар шактый дуслашып киткән иде. Мин лекциядә чагында Шәрәф энемне киногa йөрткән, кичләрен бергәләп театрга, циркка бардык. Болай да кешегә тиз ияләнүчән, ышанучан энем аны үз итеп бетергән иде инде. Алар кайтып кергәч сүз үзеннән-үзе җанланып китте. Эшләпәсе аш тәлинкәсе хәтле каен гөмбәләрен, симез тәпиле ак гөмбәләрне тотып-тотып карагач, Шәрәф:

— Мондыйларны күргәнем юк иде әле, — диде.

— Сезнең Идел буйларын да күргәнегез юктыр әле, — диде Ренат, — әйдәгез, күрсәтеп меним.

— Кичке ашка хәтле әйләнеп кайтыгыз шул, — дип, әни дә хуплагач, без өчәүләп су буена төшеп киттек.

— Бәләкин утравына барабыз. Анда көймә алып була, — диде энем, "дилбегәне үз кулына алып", без аңар сүзсез буйсындык.

Ярмәкәй тау башына менеп житкәч, алдыбызда гаҗәп матур манзара ачылды. Ялгыш төшеп калган көмеш пута кебек Идел бормаланып ята, елга аръягындагы тигезлекне калын карурман каплап тора, Идел уртасында, олы кара үрмәкүчкә охшап, ком юдыручы машина-кораб утыра. Шуларның барысы өстендә рәшә сыман дерелдәп кояш нуры уйный. Күргән саен күрәсене китереп торган бу күренештән күңелгә аңлап булмый торган әллә нинди бер шатлык тула. Без барыр жиребездән туктап, тын да алмыйча, хозурланып карап торабыз. Ахырдан Шәрәф, бу мөкаддәс тынлыкны бозып:

— Шушы кадәр матур җирдә яшәгән кешенең шагыйрь булмавы мөмкин түгел, — дип куйды.

Бу сүзләрне мин үземә генә күпсендем. Минем йомшак күңелле, шагыйрь җанлы, ярдәмчел авылдашларым да бар бит әле. Шуларны истә тотып:

— Шагыйрь җанлы дип әйтү дөресерәк булыр, — дидем.

Кыска гына арада Шәрәф белән күрешеп калу күңелемне кузгатты. Әти-әни янында яшәү никадәр җайлы һәм рәхәт булса да, Казанга кайтасым килә башлады. Ачлы-туклы студент тормышын, Рәмзияләрне, Җәмиләләрне сагындым. Шулай да, болын чишмәсенә хәтле озатып куйган кичтә Шәрәфкә биргән вәгъдәм булса да, авылдан тиз генә чыгып китә алмадым. Берсе арты берсе тезелеп торган эшләр кулны тотты. Иң элек, көзге салкыннар башланганчы, сарыкларның йонын кыркып аласы булды. Җенем сөймәгән эчпошыргыч эш инде ул. Мәңге бетмәс кебек тоелган эш. Шунда әниемнең үгет-нәсихәтләрен тыңлап утыру да рәхәт түгел. Мине бәхетле итәсе килеп сөйләгән сүзләр, югыйсә, күңелгә сеңдереп кенә барырлык та бит... Юк шул, бердән, яшьлек карыша моңар, икенчедән, оялчанлык комачаулый. Безнең татар кызлары йөрәк серләре турында әниләре белән сөйләшеп утырырга күнекмәгән бит. Әниемнең кактырып-суктырып әйткән сүзләрен тыңлаганда, яман эш өстендә тотылган кешедәй, гаепле сизәм мин үземне. Сәгатьләр буена сузылган "тәрбия дәресенең" тәнәфесе дә юк бит аның. Сарык башын ташлап китеп булмый, кулыңның аз гына бушавын сизсә дә, сикереп торырга гына карый. Бу юлы бигрәк җай килде әнигә. Җайлап-җайлап кына, сүз уңае туры китереп, Шәрәф турында сораша: "Мишәр малае икән, сөйләшүеннән күренеп тора, кайсы якныкы соң? Әти-әнисе исәнме, туганнары бармы? Кайда укыган?" Каян белим соң мин боларны? Анкета тутырып алмадым бит. Әниемнең төпченүенә эчем пошып, ачуым килеп утырсам да, бер сүзе колагыма эленеп калды тагын.

— Әниемнең әйткәне бар иде (минем әби турында әйтүедер инде): бөтен теләгем шул сиңа, кызым, киявең эчкече булмасын, ялганчы булмасын, карак булмасын. Шул теләгем кабул булса — бәхетең булыр, дигән иде. Аның теләге кабул булды. Үзең дә күреп торасың, әтиеңдә ул начар гадәтләрнең берсе дә юк. Сиңа да шуны телим, балам.

— Кияүгә чыгарга җыенмыйм бит әле, — дидем, үзем кып-кызыл булдым, ахры, ике колагым ут булып яна башлады.

Эшләр житәрлек иде ул көннәрдә. Бу эштән соң, олы бакчаның бәрәңгесен казып алыр вакыт житте. Ул гына беткән иде, тәрәзәләрнең яздан алып куйган эчке катларын юып урнаштырасы, тагын...

Казанга көз кергәч кенә чыгып китә алдым.

## Көзге ачы җилләрдә

Казанга ни кадәр ашкынып килсәм дә, күрешү шатлыгы мин көткәнчә үк булмады. Озак килми торганга үпкәләгән сыман, шәһәр мине чытык йөз белән каршы алды. Көзге җил коелган яфракларны урам буйлап куып йөри, стеналардагы ертык афишаларны йолкып, пыскаклап салкын яңгыр ява. Куе, кара болытлар шул кадәр түбән йөзә, башыңны

күтәребрәк атласаң, башыңа тиеп үтәр кебек. Көн туып өлгерми, дөньяны кичке караңгылык баса. Студентлар килеп житмәгәнгәме, торакка да жылы бирмәгәннәр әле. Ишекне ачып керүгә йөзгә таш салкыны бәрә. Килеремне көтеп торган кешем булмаса, күңелсезләнер идем.

Күрешкән кичебездә үк Шәрәф мине язучыларның Кремльдә булган жыелышына чакырды. Минем инде андый утырышларда булганым бар, тик алар Матбугат йортының бишенче катындагы Тукай клубында үтә иде. "Ни өчен бу юлы Кремльдә?" — дип соравыма каршы Шәрәф:

— Гафаров үзе үткәрә, — диде. — Син авылда ишетми дә калгансындыр. Үзәк Комитетның идеясезлеккә каршы көрәш турында карары чыкты бит. Татар язучыларыннан да зарарлы әсәрләр эзлиләр.

— Табалармы соң?

— Эзләсәң, тырнак астыннан да кер табыла.

Авылда ятып белми калганмын икән: күптән түгел генә Ленинград өлкә комитеты секретаре А. А. Жданов "Ленинград" һәм "Звезда" журналларында басылган кайбер әсәрләрне бик каты тәнкыйтьләп чыккан. Сатирик язучы М. М. Зощенконың "Маймыл мажаралары" дигән хикәясенә һәм "Кояш чыгар алдыннан" дигән повестена, шулай ук Анна Ахматова ижатына бик каты эләккән. Шуннан соң ВКП(б) Үзәк Комитетының "Звезда" һәм "Ленинград журналлары турында" дигән карары басылган. Бу ике язучыны Язучылар союзыннан чыгарганнар. Хәзер бөтен ил буйлап шул карарны өйрәнәләр ди. Шаукымы безгә дә килеп житкән. Өлкә комитетының идеология секретаре Гафаров кичә бик усал доклад ясаган. Бүген шул жыелышның дәвамы булачак икән.

Кремльнең Спас капкасына житәрәк безне погонсыз шинель якасын күтәреп куйган, хәрби фуражкасын батырып кигән берәү куып житте дә: "Исәнме, Шәрәф", — дип, узып та китте.

— Бу кем инде?

— Шәйхи Маннур. Кичәге докладта бик каты эләкте аңар.

— Орденлы язучы бит ул. Нишләп идеясез әсәрләр язсын?

— Язган, диләр шул. "Казан кызы" дигән поэмасын докладчы эттән алып эткә салды.

Сугышка хәтле үк Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән шагыйрьне "безнең як кешесе" дип, горурланып йөри идем. Ул туган төбәк Тәкәнеш авылыбыздан ерак түгел, мәктәп өчен кирәк булган китапларны шуннан алабыз, урыслар арасында яшәгән татарларны Татарстан белән тоташтыручы бер күпер сыман ул район. Казан безгә ерак, ә Тәкәнеш — менә генә. Шуның өчен Тәкәнеш үзе дә, анда туып үскән шагыйрь дә күңелемә бик якын. Әллә кайлардан эзләп табып укый торган идем мин аның язганнарын. "Совет әдәбияты"ның март санында басылган "Казан кызы" поэмасын бик яратып, күңелем сыкранып, жаным сулкылдап укыган идем. Дилбәр исемле Казан кызының фронттагы батырлыгын, үзен намуслы, әдәпле тотуы өчен солдатларның аны ятратулары, якын итеп, "Кызым" дип дәшүләре һәм шул гүзәл кызның Мамай курганындагы сугышта батырларча һәлак булуын сурәтләгән поэма иде ул. Аннан да гаеп тапкач инде! Булмас. Булса да, Шәйхи абый аны начарлык уйлап язмагандыр, кая борсаң булмый сүзне. Кулга тотып, капшап карый торган әйбер түгел бит. Бәлки әле көндәшләре юри уйлап тапкандыр. Фәрештә кебек изге дип уйлаган язучылар арасында да төрле кешеләр булуын әзрәк сизенә башлаган идем инде. Студентның күзе күрә, колагы үткен бит аның.

Кремль урамына кереп бераз баргач, Министрлар Советының ике катлы ак бинасы янында туктадык. Ишек янында зур бер төркем тәмәке тартып тора. Барысы да ирләр, ярымхәрби киемлеләре дә бар. Йөзләре житди, сөйләшүләре кырыс, ирләр жыелган жирдә була торган гадәттәге жорлыкның эзе дә юк. Шәрәф чакырганга жиңел генә ияреп китеп барсам да, биредә уңайсыз хәлгә калдым. Үзем кебек яшь язучыларның берсе дә юк, барысы да өлкәннәр, без китаплардан гына укып белгән

тере классиклар да бар арада. Әдәбият түгәрәгенә йөрүчеләрнең берәрсен очратсам, янына барып сыенып идем, булмады. Әллә килеп житмәгәннәр, әллә чакыручы булмаган үзләрен. Шәрәф янында күзле бүкән кебек басып тору да читен. Язучыларның берничәсе аның белән килеп күреште, кайберләренә үзе барып кул бирде. Сөйләшеп тордылар. Аларның сынап, мина карап алганнарын күреп торам. Шәрәф шуны сизенепме: "Яшь шагыйрә", — дип, минем белән таныштыра, берәүләр кул биреп бер-ике жылы сүз әйтеп куя, икенчеләре илтифатсыз гына баш кагып, стенадагы рәсемгә карагандай, күз төшереп алалар да шунда ук барлыгымны онышалар. Шәрәфнең иптәшләре белән сөйләшеп торасы килүен аңлыйм, сүзгә мавыгып, мине онытмасын дип тә хафаланам. Бәхетемә, хәлемне аңлады тагын. "Әйдә, мин сине кертеп утыртыйм әле", — дип эчкә уздырды.

Авыр имән ишекне ачып керүгә андагы яктылыктан күзем чагылды. Биек түшәмнән асылынып төшкән зур бәллүр люстраның дистәләгән лампочкалары, һәркайсы үзе бер кечкенә кояш кебек, көчле нур чәчә. Мәрмәр баскычның фигуралы тоткалары, тәрәзәләрне каплап торган парчалы калын пәрдәләр, түшәмгә тигән зиннәтле көзге киноларда күргән патша сарайларын хәтерләтте. Мин кинәт каушап, югалып калдым. Гозер белән килгән кешеләрнең бәләкәйлеген, бөжәклеген, мескенлеген, кимлеген исенә төшереп, күзенә төртеп әйтеп торсын дип шундый зур итеп, зиннәтләп салганнармы әллә мондый биналарны? Шулайдыр, күрәсең. Мин дә туган ягымның Идел буйларында, урманнарында йөргәндә генә патшабикә булуымны аңладым, мондый жирдә тузан бөртеге кебек кенә бер зат икәнемне тойдым. Ләкин шул ук вакытта, мизгел эчендә туган тойгыларыма каршы килеп, күңел төпкеленнән икенче бер хис баш күтәрде. Тузан бөртеге булып калырга ярамый, тузан бөртеген теләсә кем таптап китә, жилләр дә аны кая теләсә шунда илтеп ташлый. Бу дөньяга кеше булып тугансың икән, кеше булып яши дә бел, дип әйтә йөрәк.

Өсне чишенеп, жыелышлар бүлмәсенә кереп утыргач, Шәрәф, кулындагы гәзитне янымдагы буш урынга куйды да:

— Бу урынны бирмә, мин тартып керәм, — дип, яңадан чыгып китте.

Мин инде тынычланган идем. Ишектән кергән кешеләрне игътибар белән күзәтерлек хәлгә килгән идем. Аларның кайберләрен күреп беләм, Тукай клубындагы әдәби кичәләрдә шигырь укыганнарын да, безнең әдәби түгәрәккә килеп йөргәннәрен дә таныйм. Әхмәт Фәйзи дә еш килә безгә. Әнә ул, көнбагыш кабыгын төкереп ташлаган кебек, калын иреннәрен кыймылдатып ишек төбендә туктап калды да, кара кысалы күзлек пыялалары аша бүлмәне сөзеп чыккач, Афзал Шамов янына барып утырды. Афзал абый да таныш миңа. Беренче кат күргәндә, белер-белмәс көе, Жәмилә аны "Мостафа Ногман ул" дип әйткән иде. Безнең әдәбият түгәрәгенә килгәч "Рәүфә" повестеның авторы Афзал Шамов икәнен белдем. Елый-елый укырлык кызганыч әсәрләр язса да, шаяртырга ярата икән үзе. Бер килүендә: "Шәрәф монда ни эшләп йөри, дисәм, кызлар янына килә икән, әнә нинди чибәр кызлар бар", — дип, көлдереп алды. Яшькелт китель, галифе чалбар белән хром күнитек кигән таза гәүдәле, шадра йөзле язучы килеп керде. Аны да беләм. Кави Нәжми ул. Сигезенче класста укыган чагымда бу язучыны мәңге истә калдырырлык бер хәл булды. Тәнәфес арасында аның хикәяләр китабын укып утыра идем. "Миңлебикәнең кайгысы" дигән хикәянең нәкъ уртасына житкәндә кулымнан китапны тартып алдылар. "Халык дошманы язган аны, укырга ярамый", — диде әдәбият укытучысы. Ул чагында ук актив комсомол булсам да, ике көннең берендә халык дошманнарының этлеге турында ишетеп, нәфрәтләнергә өйрәнсәм дә, ни өчендер, бу юлы андый дошманлыкны тоймадым, хикәяне укып бетерә алмавыма үкенү хисе генә калды. Соңыннан мин аны барыбер эзләп-табып укыдым. Казанга килгәч, үзен күрергә дә насыйп булды. Артыннан ияреп кергән карсак буйлы кешегә Кави Нәжми кырыс кына нәрсәдер әйтте дә, аны тыңлап та тормыйча, алдагы рәтләргә узды. Ә

тегесе әрсез елмаеп, кире чыгып китте. Бу кешенең нәзек иреннәре чалшайган зур авызы, чыраена чыккан явызлык таң калдырды мине. “Нәкъ шундый кешеләр тырнак астыннан кер эзлиләрдер әле”, — дип уйлап куйдым. Ул арада кыңгырау шалтырады. Язучылар ашыгып утырыша башладылар. Шәрәф тә “Беломор” исен аңкытып яныма килеп утырды. Бүлмәгә язгы ташудагы кебек гөрелте тулды.

Минем әле мондый да гаугалы җыелышны ишеткәнем дә күргәнем дә юк иде. Чыгып сөйләүчеләр рәхимсез бер-берсен тәнкыйтьлиләр, сүзләрне сайлап тормыйлар, хәтер калдырам дип уйламыйлар. Никадәр катырак итеп әйтсәм, шул кадәр акыллырак булып күренәм дип уйлыйлар-мы? Кайсы вакыт әйткән сүзләренә үзләре дә ышанмыйлар, президиум өстәле артында утыручыларга ошарга тырышалар, дигән тәэсир дә кала. Чөнки алар залга түгел, ярты гәүдәләре белән президиумга таба борылып сөйлиләр. Тешләре японнарныкы кебек калкып торган базык гәүдәле берәү барысыннан да уздырырга тырышты бугай. Каршысында бер полк дошман солдаты тора дип белерсең, сүз кылычын әле уңга, әле сулга селтәп Нәкый Исәнбәтне тәнкыйтьли. Артык тырышудан тыны кысылып, тавышы чыжлый башлый. Әз генә тын алып тора да яңа көч белән “селтәнергә” тотына. Ул тетеп салган “Идегәй” спектакленең кырык дүртенче елны ук сәхнәдән алынганын белә идем. Ә менә “Җирән чәчән” әсәре барын беренче ишетүем. Ораторның сүзләренә ышансаң, аннан да зарарлы, партия политикасына каршы килгән, милләтчеләр җырын җырлаган әсәр дөньяда юктыр кебек.

Икенче берәү “Казан кызын” сүтеп ташлады. Имеш, автор совет сугышчыларын тотнаксыз, фахиш итеп сурәтләгән. Гомумән, Шәйхи Маннур иҗатына төшенкелек хас. Ул яшьләрдә оптимистик хисләр тәрбияләми, аларны пассивлыкка, битарафлыкка өнди. Сөйләүче үзе авызыннан утлар чәчми, йомшак, тигез тавыш белән сөйли. Ә сүзләре йөрәккә ук булып кадалырлык. Аларны тыңлый-тыңлый тәмам башым катты. Кемгә ышанырга? Биредәге чыгышларгамы? Әллә төн йокыларымны калдырып укыган китапларгамы? Әле генә фронтлардан кайткан, күкрәкләре тулы орден-медаль булган язучыларны дошман тегермәненә су коюда гаеплиләр. Тукта! Шәрәфнең дә исемен атадылар түгелме? Колакларыма ышанмыйм. “Эх, шул килеш...” дигән шигырьне сүтә берәү. Мин аны яттан беләм:

Ташты ташкын, басты ташлы тауны,
Барды сугыш дулап, ыжгырып.
Кырып, сытып фашист-шакшыларны
Штурм полкы чапты ыргылып.
Кышкы кичтә, җилдә, кар-буранда
Ярсып-шашып сугыш шаулады.
Байрак тотып, кинәт калку тауга
Менеп басты татар солдаты.
Җәйде байрак алтын канатларын,
Нурга бизәп поход юлларын,
Ашкындырып совет каһарманын,
Дистәләрчә милләт улларын.
Торды басып, бомба-миналардан
Көл булса да бөтен тау башы,
Бабайлардан үлмәс мирас алган
Ашкын җанлы татар солдаты.
Торды батыр, тауга тамырланып,
Байрак белән нурга өртелеп.
Полкы чапты күкрәп, давылланып,
Көнбатышка ялкын өрдереп.
Эх, шул килеш кинәт җизгә катып
Һәйкәл булып басып калсачы

Туган җирен канга, тиргә батып
Яклый алган татар солдаты!

Олы корсагын каеш белән буган гимнастеркалы бер агайга шигырь ошамаган. “Ни өчен татар солдатына гына һәйкәл куелырга тиеш? “Совет солдаты” дип әйтергә кирәк иде, бу сүз сугышта катнашкан һәр милләтне эченә алыр иде. Аннан килеп, нинди бабайлардан мирас алган ул? Татар-монгол яуларыннан түгелме? Ике төрле уйларлык урын бар монда. Теләсәгез ни әйтегез, җәмәгать, милләтчелек исен сизәм мин бу шигырьдән”, — кебек сүзләрне ычкындыра башлагач, аптырап Шәрәфкә карадым. Ул бертуктаусыз аскы иренен чәйнәп утыра, йөзе бер агара, бер кызарып китә. Аның бар гәүдәсе, бар күзәнәкләре кысылган пружина хәленә килгән дә менә-менә атылып китәр сыман. Шулай булып чыкты да. Әлеге кеше:

— Телен генә карагыз сез аның, кәнинә бит бу, кәнинә, —дип, шигырьне сүтүен дәвам иткәндә Шәрәф сикереп торды да:

— Алдыйсың, сволочь! — дип, ярсып кычкырды.

Сөйләүче авызын ачкан көе калды, тыңлаучылар ягында шау-шу булып алды, урындыклар шыгырдады, безнең якка борылып-борылып карый башладылар. Җыелышны алып баручы ачу белән кыңгырау какты.

— Утыр, Шәрәф! — дип боерды ул. — Үзеңә сүз биргәч сөйләрсең.

Шәрәф сүз алса, кызып китеп, әллә ниләр әйтеп ташлар дип, шүрләп утыра идем, акланырга, нәрсәдер аңлатырга теләмәдеме, әллә әзерләнеп килеп, иртәгә чыгарга ниятләдеме — урынына утырган җирдән башын күтәрмәде. Иртәгә ниләр булып бетәр инде, Ходаем? Әле җыелыш тәмамланмады бит, аның дәвамымы, ахырымы булачак. Тагын күпме кешенең төн йокыларын калдырасы, газаплы уйлар эчендә бәргәләнеп ятасы бар икән... Шәрәфнең дә эчендә утлар янганын беләм, милләтчелектә гаепләнү уен эш түгел, әгәр теге кешенең сүзен күтәреп алсалар... Ой, уйларга да куркыныч! Бу хәлләрне бер кат башыннан кичергән бит инде ул. Комсомол өлкә комитетының беренче секретаре Галим Мөхәммәтҗановны, японнар файдасына шпионлык иткән дип, кулга алгач Шәрәфкә дә жиле тигән. Халык дошманының туганы дип, аны педагогия институтыннан куганнар. Шәрәф:

— Туганлыгы да шул кадәр генә иде инде, әти ягыннан чыбык очы кардәш. Бервакыт, бик ачыккач, әзрәк акча сорап торырмын дип, фатирларына барган идем. Асраулары: “Өйдә юк”, — дип, ишек төбеннән борып җибәрде, — дип сөйләгән иде. Әллә шул хәлләр тагын әйләнеп кайтамы? Кешеләр яңадан бер-берсен батырырга тотыналармы? Сугыштан соң тормыш бик матур булыр, исән-имин калганнар яшәүнең кадерен белеп, бер-берсенә дус, ярдәмчел, мәрхәмәтле булып гомер итәрләр, дип хыяллана идек бит. Әнә аның иҗат планнары зурдан. Очрашкан саен дәртләнеп “Полк байрагы” дигән трагик поэмасы турында сөйли. Язып бетерә аламы инде ул аны, болай булгач? Бервакыт шулай бәхәсләшкән идек.

— Кинода фашистларны адәм көлкесе итеп сурәтлиләр. Шундый ахмак булгач, ни өчен дүрт ел сугыштык соң без алар белән?

— Бөтен Европаның байлыгын җыйган иде бит.

— Чепуха! Безнең илебез үзе биш Европага тора. Хикмәт шунда — алар да, безнең кебек үк, какшамас идея солдатлары иде. Ил белән ил түгел, ике идея сугышты монда. Ницше дигән кешене ишеткәнең бармы?

— Философияне өйрәнгән идек бераз. Көчне, хакимияткә омтылуны тормышның мәгънәсе дип өйрәтә. Аныңча, бары тик сайланган, көчле раса гына дөньяга баш булырга тиеш.

— Менә, менә, фашистлар шуның өчен байрак итеп алдылар да инде аны. Алма-Ата йә Ташкентта ятып кына төшерелгән фильмнар сугышның чын асылын күрсәтә алмый.

— Халыкка ошый бит. Яшьләр яратып карый. Сугыш дәһшәтләреннән болай да туйган инде. Беләсеңме, бервакыт академия театрында

Таһирә Тәминдарова дигән студентка белән Нәкый Исәнбәтнең "Мәрьям" спектаклен карадык. Фашистлар Мәрьямне асып куйгач: "Нигә инде бу натурализм?" — диде Таһирә.

— Сугышны күргәнме ул!

— Күргән шул менә. Ул үзе фронтта булган.

— Шулай да тарихка дөресне язарга кирәк.

— Дөресен әйтә аласыңмы соң?

— "Полк байрагы" дигән трагедиямда әйтәчәкмен мин аны. Фашист акыллы да, ерткыч та, мәкерле дә һәм шул ук вакытта европа культурасын бик яхшы үзләштергән зат та ул. Бик куркыныч дошман белән сугыштык без аңда. Немец генералы белән әсир төшкән совет офицеры арасындагы бәхәстә бик көчле итеп күрсәтергә кирәк шуны. Аларның сүзләре кылыч чапкан кебек ялтырап торсын.

Хәзер менә шул сөйләшүне уйлап барам. Шул буламы инде фашист тегерменәнә су коючы, дим!

Шәрәфнең тавышын ишетәсем, ниләр уйлавын беләсем килә иде. Черек күл буена җитәрәк, сүз башлар өчен генә:

— "Кәнинә" нәрсә дигән сүз ул? Берәр әдәби терминмы? —дип сорадым.

Ул күтәрелеп карады, туктап кесәсеннән тәмәке алды, җилгә арты белән борылып кабыза башлады. Бер шырпыны сындырды, икенчесе кабынмыйча интектерде, өченчесенең яктысында мин аның куллары калтыравын күрдем. Соравымны аңламады дип уйлаган идем, аңлаган икән, бер тирән итеп суыргач:

— "Ат ите" дигән сүз. Конина. Үзенчә образлы итеп әйтүе инде. Авыл хуҗалыгы журналының җаваплы сәркәтибе ул. Сүзеннән тирес исе килә, — диде, эчке бер рәнҗү белән.

— Ул да сугышта булганмы?

— Булды. Фронт газитенең корреспонденты иде.

— Татар егетләренең батырлыгын күрмәдеме икәнни?

Шәрәф җавап бирмәде. Ул тагын уйларына батты, ахры. Бераз баргач кына:

— Менә күрдеңме инде. Матур кызлар алдында шигырь уку гына түгел ул әдәби процесс, — диде. — Чынлап торып язучы булам дисәң, алдыңны-артыңны карап тотын. Бер башлагач чигенү юк. Китми торган чир кебек. Авыз-борыныңны канатсаң канатасың, ә барыбер язарга тырышасың.

— Бүгенге кебекме?

— "Монысы әле баласы, алда тора анасы", дип әйткән ди бер бабай.

Мин аның өчен сөенеп куйдым. Болай булгач, язылып бетә икән әле "Полк байрагы".

## Эч пошулы төн

Тулай торакка кайтып җиткәч, саубуллашып бүлмәгә үтим дигәндә:

— Әйдә безгә, чәй эчәрбез, — дип, Әхмәт Юныс үзләренә чакырды. Мин дә артык кыстатып тормадым, бу вакытта кухня барыбер ябык инде, калган ашны җылытып алырлык та, чәй кайнатырлык та җай юк хәзер, "Хлеб да вода — студенческая еда", — дип әйтәләр дә әйтүен, салкын су белән ипи капкалап ятуга караганда кайнар чәй эчеп алсак, зыян итмәс, билгеле. Карточкага тигән ипием дә үзем белән, кеше өлешенә керерлек түгел. Шуның өстенә Гөлсемне күрмәгәнгә дә биш былтыр диярлек. Безнең бүлмәдәш кыз иде ул. Барыбызны да шаккатырып, Әхмәткә кияүгә чыгып куйды да, тулай торакның беренче катында кечкенә генә бүлмә алып, шунда яши башладылар. Бер үк факультетта укымагач, хәзер мин аны атнага бер тапкыр гына очратам.

Әхмәтләрдә кунак бар икән. Зифа буйлы, яшь, чибәр капитан урыннан торып каршыбызга килгәч, Әхмәт Юныс аны кочаклап ук алды:

— О-о, Гали дус! Килеп, прусты әйбәт иткәнсең.

— Исәнме, Әхмәт, — диде кунак, аның кочагыннан ычкынгач, оялчан кыз балалар кебек тыйнак елмаеп кулын бирде. — Сәгать сигездән бирле көтеп утырам инде. Менә, Гөлсем ханым белән дә таныштык. Котлыйм үзегезне!

— Һе-һе-һе-... — дип, йомшак кына көлеп куйды кияү кеше, — өйләндерде дә куйды шул үзенә, сизми дә калдым.

— Утырмасана кыланып! — диде Гөлсем, кулындагы тастымалы белән иренең аркасына йомшак кына сугып куйды.

Шушы ыгы-зыгыдан файдаланып, чыгып китим дип, ишек тоткасына ябышкан идем, өлгерми калдым, Әхмәт кулымнан тотып алды.

— Менә шагыйрь дустым белән таныштырыйм әле үзегезне. Гали Хужи абыең була бу. Һе-һе-һе... Егет кеше дип уйлама тагын. Буада Гайшә исемле бик чибәр хатыны бар.

— Җә инде, Әхмәт, — диде кунак, уңайсызланып елмайды, кызарып та китте бугай әле, артык тыйнак кеше, ахры, ул кичне күзен күтәреп караган чагын күрмәдем. Миңа да читен булды. Гали Хужиев дигән шагыйрьнең исеме күземә чалынган булса да, шигырьләре истә калмаган. Хәзер сүз шул якка борылмаса ярар иде дип утырам. Укыганым юк дисәм, авторның күңеленә авыр булыр, белгәнгә салынсам, үзем ялганга батармын. Бәхеткә, уен сүзне туктатып, Гали абый әле генә без булып кайткан әдәбият түгәрәге турында сораштыра башлады.

Безнең андагы очрашулар күңелле генә үтә иде болай. Ишәеп тә киттек. Вакыты белән егермегә якын җыелабыз. Чөнки быел педагогия институтыннан да җилле генә егетләр килеп кушылды. Хәтта Нәби Хәмидуллин белән Үлмәс ханым кебек, бүген булмаса иртәгә кандидатлык диссертациясе якларга торучылар да йөри. Театр училищесы белән авыл хуҗалыгы институтыннан да бер-ике студент күренгәли. Безнең инде "Ленинчы" дигән газитебез бар. Университет типографиясендә басылган чын газит. Аның һәр санында шигырьләребез, хикәяләребез күренә. Утырышларга зур язучылар килми калганда да сөйләшүләр бик кызык үтә, кайнар-кайнар бәхәсләр дә булып ала торган иде. Ә бүген алай ук булмады, юкны чәйнәп вакыт үткәрдек шунда. Миңа гына шулай тоелганмы дип уйлаган идем, Әхмәт тә кулын гына селтәде:

— Юкка вакыт үткәрү кебегрәк булды бүген. Бер егетнең хикәясен укыган идек. Прусты примитив. Авыл хуҗалыгы институтында укыгач, "материалны беләм" дип бәхәсләшә. Әдәби осталык турында сөйләгәнне ишетергә дә теләми...

Бик озак утырдык без әдәбият турында сөйләшеп. Кайтып урыныма яткач та, йокыга китә алмыйча, шул турыда озак уйланып яттым. Бигрәк тә Әхмәтнең сәер фикере сагайтты. Белеп торам, минем бакчага таш атуы иде. Бер гаиләдә, аныңча, ике шагыйрь йә ике язучы булса, шуның тик берсе иркенләп иҗат итәргә тиеш. Ә икенчесе, Әхмәтнең уенча, — билгеле инде, ул аның хатыны, — иренә бөтен мөмкинлекләрне тудырып, булышып яшәсен. Сүзе ышанычлырак булсын өчендер, Сибгат Хәким белән аның хатыны Мөршидәне телгә алды.

Әйбәт кенә шагыйрә буласы иде Мөршидә. Сугышка хәтле "Чиккән яулык" дигән матур китабы да чыкты. Сибгат хакына язуын ташлады бит әнә.

"Алай-болай Шәрәф белән кушыла калсаң, син дә аңар юл куй: синнән әле язучы чыгармы-юкмы, ә ул инде шактый танылган шагыйрь", — дип, төртеп кенә әйтмәде. Ә Шәрәф бервакыт кайнарланып китеп миңа: "Яртысын үзем язып булса да, исемеңне әдәбиятка чыгарам", — дигән иде. Шул чагында мин аңа үпкәләдем. "Алай булса бөтенләй язудан туктыйм, йә прозага күчәм", — дип әйттем. Вот феодаллар! Язучы бит үзләре, югыйсә! "Кеше җанының инженерлары" дип әйтәләрме әле?

Тукта, инженер сүзе бик тә туры килә түгелме соң боларга. Инженер ул салкын акыл белән, коры формулалар һәм тимер-томыр белән эш итә ләбаса. Әхмәт, мәсәлән, хатын-кыз хисләрен җинел генә кухня плитәсенә бәйләп куярга маташа. Шәрәф исә мине ирексезләп ят һәм анлаешсыз дөньяга кертеп адаштырырга тели. Икесе ике юлдан килсәләр дә, хатын-кызның тиз җәрәхәтләнүчән, зәгыйфь, моңлы җанын үзләренчә үзгәртеп корырга маташучы инженерлар бит болар. Икесе дә миңа ышанмыйлар, миңа гына түгел, хатын-кызлардан язучы чыгарына ышанмыйлар. Әхмәт таләп иткән игътибарны безгә бирсәләрме, өй эше мәшәкатьләрен әз генә булса да кулыбыздан алсалармы? Мөршидә дә, бәлки, язуын ташламас иде. Шәрәфнең исәбе — мине язучы итү. Минем үземнең дә язасым килә. Ләкин кеше ярдәме белән түгел, үз көчем белән әдәбиятка чыгасым килә минем. Әллә чыннан да прозага күчәргә инде. Язарга теләгән әйберем дә бар бит... "Көмеш елга" һаман үзенә чакырып тора, шуларны уйлап ята-ята йоклап киткәнемне сизми калганмын. Төш күрәм, имеш. Төшемдә үзебезнең әдәби түгәрәккә йөргән бер егет белән сөйләшеп утырабыз. "Бер теория уйлап таптым әле, — ди ул миңа. — Божралар теориясе". "Геометрия белән мавыгуыңны белми идем". "Геометриягә кагылмый. Психологик теория". "Ничек була инде ул?". "Ничекме? Менә бер олы божра..." Студентлар тузаны коелып калган өстәлдә олы бер түгәрәк хасил булды. "Бу мәйданга бик күп кеше сыя, — ди егетем. — Әйтик, безнең әдәбият түгәрәгенә йөрүчеләрнең барысы да. Ничә кеше булса, шул кадәр үк төрлелек. Матур әдәбиятка мәхәббәт кенә берләштерә аларны". Шуннан соң нәзек озын бармаклар икенче бер кечерәк түгәрәк сызып куйды. "Бу божрага сайланган төркем генә керә". "Син дә мин, Мөхәммәт Әминме?" — дип, шаярган булам. "Ашыкмый тор, хәзер әйтәм, — диде ул йомшак тавыш белән. — Якын дуслар, сердәшләр, бер үк идеаллар, омтылышлар, теләкләр белән яшәүчеләр алар. Инде менә бик бәләкәй бу божрада..." Шулай диде дә ул, сүзен әйтеп бетермичә, күзләремә карады, тик карашымны күтәрә алмады, башын түбән иде. Мин аның ни әйтергә теләвен, шуңа бик нык дулкынлануын сизеп утырам һәм үзем бу акыллы, итәгатьле егетнең күңелен рәнҗетмәслек җавапны эзләп азапланам. Йә, раббем! "Юктырсың ла, Алла!" дип Мәҗит Гафури белеп әйтмәгәндер ул. Бар икән бит син, Ходаем! Ишектән үк ни турындадыр бәхәсләшеп кергән Әхмәт Юныс белән Гали Хуҗи абый четерекле хәлдән коткарды бит безне, әй. "Кара боларны, икәүдән икәү сөйләшеп утыралар", — диде Әхмәт, ни өчендер киная белән. ""Ярамыймы әллә?" — дидем анар, үчләнеп. "Ярый да... Шәрәф ни әйтер?". "Причем монда Шәрәф", — диде минем белән утырган егет. "При том шул..."

Шул вакыт, кабыргама төртеп уяткандай, күзләремне ачып җибәрдем.

Өнем булдымы соң бу, әллә төшемме? Шул хәтле дә дөреслеккә туры килер икән. Төш кенә икәнен белгәч, рәхәтләнеп көлеп җибәрдем. Кызлар берәм-берәм башларын күтәреп карадылар.

— Әллә алышындыңмы? — диде Җәмилә, авызын зур ачып иснәде дә, баштанаяк бөркәнеп ятты, шунда ук төш тә күрә башлады бугай әле.

Мин генә инде йоклый алмый идем. Әле генә күргәннәремне тагын бер кат күз алдыма китереп яттым. Беләм бит мин ул егетне. Төшемдә башка кеше кыяфәтендә күренсә дә, өнемдә бик әйбәт беләм мин аны. Соңгы вакытта игътибарын сизеп, җылы карашын тоеп йөрим. Беренче тапкыр университет китапханәсенең уку залында утырганда аңладым. Инглиз теле укытучыбыз Стрижакның грамматика кагыйдәләрен ятлатып үзәккә үтә торган гадәте бар. Өйгә дә күнекмәләрне күп итеп бирә. Эшләп килмәсәң, иптәшләрең алдында хур итеп, тиргәүдән дә тартынмый. Шунлыктан, үзен яратмасак та, җен урнына күрсәк тә, җеннән курыккандай куркабыз, башка берәр семинарга әзерләнеп өлгермәгәндә дә ул биргәнне эшләп килергә тырышабыз. Өйгә биргән күнекмәләрне эшлим дип, уку залына кергән идем. Буш өстәлгә кәгазьләремне таратып куярга өлгермәдем, бер кочак китап күтәреп кергән егетне күрдем. (Бүген төшемә

кергән егет үзе иде ул.) Ерактан баш кагып кына сәлам бирдем дә дөньямны онытып эшкә тотындым. Мин дә бер шаккатырыйм әле шул Стрижакны, өлгермәүчеләр рәтендә йөртмәсен, житәр. Без дә алланың кашка тәкәсе була алабыз. Ләкин ни гажәп, бер заман әллә нинди, аңлатып булмый торган тынычсызлану белән алды күңелемне. Күзләрем перфект, постперфектларны күреп тора, мәгънәләре аңлашылмый, миемнең күзәнәкләренә барып житкәннәре дә, тишек чиләккә салган су кебек, коела да бетә. Бер ара башымны күтәрсәм — күрәм: егетнең күзләре миңа төбәлгән. Эчкә баткан яңакларына ике учын куйган да үзенә тартып китерергә теләгәндәй томырылып карап тора. Аның күз карашы һавадагы магнит дулкыннары сыман миңа килеп бәрелә, жанымны борчый, уйларымны чуалта. Күз карашларыбыз очрашкач, ул тиз генә китабына иелде. Әйтерсең лә аның миндә эше юк, үз кирәген уйлап утыра дип белерсең. Шулайдыр әле, укыганын күңеленә сеңдереп утыруыдыр, нәрсәгә юраган булам тагын мин — юләр. Шулай да сынамак өчен тагын бер карап алдым мин аңар. Тагын шул ук күзләр... Берничә рәт кабатланды бу сәер уен. Миңа кызык булып китте. Егет кешенең игътибарын нинди кыз яратмас та, кайсының йөрәк тибешен тизләтмәс икән? Өйгә биргән эш онытылды болай булгач, Стрижакның ут чәчеп торган ачулы карашы онытылды, мыскыллы чәрелдек тавышы да онытылды. Кинәт, кылт итеп, Шәрәф искә төште. Аңар хыянәт итү була түгелме соң? Дөрес, Шәрәф белән хисләребез турында ачылып, тирәнгә китеп сөйләшкәнебез дә юк, мөнәсәбәтләребезне егет белән кыз арасындагы самими дуслык кына дип әйтергә дә була. Әмма аның яратуын, киләчәккә өмет баглавын күңелем сизә. Үзем дә шул көннең бер киләсенә ышанып, сөенеч белән көтеп йөрим түгелме соң мин? Юк, бу егетне болай үртәп утыру килешмәс, чынга алуы бар. Эшне дә эшләп булмас инде. Әйдә, иртәгә семинарга кереп тормам, икенче юлы яхшы итеп әзерләнеп килермен. Бүгенгә шуның белән вәссәләм, димәк. Кәгазьләремне жыеп алдым да һавага чыктым. Ут булып янган йөземне салкын һавага куеп, бераз хәл алып тордым. Тиз генә кузгалып китәргә дә урам шау-шуына кушылырга, кешеләр арасына кереп югалырга кирәк булган икән. Аны көтеп торган кебек булды бит әле бу. Әнә, инде чыгып та килә. Ашыгудан пальтосын да төймәләмәгән, бүрегенең алдын артка кигән.

— Кайтасың дамыни?

— Эшем бетте, — дигән булам, мөмкин кадәр битараф тавыш белән. — Ә син яңарак кергән идең, нигә бераз утырмадың?

— Кирәгемне эзләп кергән идем, таптым инде.

— Шулай тиз табылырлык булгач, эзләп тә тормыйлар аны.

— Алай димәс идем...

Шул көннән соң бу егет гел юлымда очрый торган булды. Сәбәбен беләм бит. Аның урынында икенче берәү булса, ачуым да килер иде. Аңар ачулана алмыйм, аның белән сөйләшүе рәхәт, аның янында үземне иркен тотам. Тартынмыйм, чөнки уйларында, сүзләрендә, хәрәкәтләрендә бозыклык күрмим. Аның күп белүе, акыллы фикер йөртүе ошый. Шәрәф тә шулай. Ни турында сорасаң да, уйлап та тормый, җавап бирә. Иптәшләре "аяклы энциклопедия" дип йөртәләр икән үзен. Менә шулай, берсе якын дустым, икенчесе сөйгәнем булып калса икән алар. Серемне сөйлисе килгәндә, эчкә йотып калган чакларым була. Иптәш кызларыңа әйтәсе килмәгән эшләр дә була бит. Менә, мәсәлән, минем Шәрәфкә үпкәләп йөргән көннәрем ул. Шуны Җәмиләгә сиздерсәм, белеп торам, авыз ерып көләр генә:

— Исең киткән иске чикмәнгә. Менә күрерсең, итекләрен шакылдатып килеп житәр әле, — дип әйтер.

Бөтен нәрсәгә төкереп карый ул Җәмилә. Хәтта мәхәббәткә дә. Тарих факультетында укучы бер егеткә күзе төшеп йөри үзенең. Җәмиләнең мәхәббәтен студент егет белми. Ә Җәмилә аны күргән саен: "Әнә минем пәрием!" — дип сөенә. Шәрәф белән үпкәләшүемне Рәмзиягә әйтсәм,

минем үземнән дә ныграк кайгырыр иде, ә үзе бер акыллы киңәш бирә алмас. Ни эшләргә соң миңа? Шәрәфне эзләп үзем барыргамы, әллә сер бирмәскә, үзенең килгәнен көтеп торыргамы? Әгәр килмәсә? Араның өзелүе шул булса... Егетләр хәлен бары егетләр генә аңлый ала, дөрес киңәшне дустым дип йөргән егетем генә бирә алыр кебек.

Кайчаннан бирле инде бер йолдыз тәрәзәдән карап тора. Кулларымны баш астына куйган көе мин дә аңа карап ятам. Ничәмә-ничә гасырлар буе минем кебек гашыйклар аңа серләрен сөйләгәндер. Аңа ышанып була. Ул тыңлый гына белә. Синең уйларыңны башка йолдызларга да, айга да сөйләми. Шуңа күрә аны сердәш итәләр, күңелләре тулганда аңа карап юаналар һәм:

Ай янында якты йолдыз, минем йолдызым гына,
Таң алдыннан ул да сүнә, калам ялгызым гына, —

дип офтаналар. Мин дә сиңа карыйм, Тимер Казык. Син дәшмисең. Бүлмәдә дә авыр тынлык, йокы тынлыгы, тын алулары да ишетелми кызларның. Мин аларның шулай рәхәтләнеп йоклап ятуларына кызыгам, ә үзем керфегемне йома алмыйм. Әллә нинди кич, әллә нинди төн булды ла бу! Әхмәтләрдәге әңгәмә җан тынычлыгымны алып, йокымны качырган иде. Инде менә бу төш бөтен күңелемне айкап ташлады. Гел чын булып, өндәге кебек булып күренде бит. Тукта әле, шул кадәр пошынырлык ни булды соң әле? Бер кыз янына егете килми башлаган, имеш. Харап икән! Дөнья җимерелгәнме шуннан? Мин бит үземне гаепле санамыйм.

Ул кичне Мөслихә янында, китапханәдә сөйләшеп утырдык та кайтырга кузгалгач, Шәрәф:

— Әйдә, бер кешегә кереп чыгабыз, ерак түгел, чатка гына борыласы, — диде.



*Ләбибә Ихсанова, Шәрәф Мөдәррис. 1947 ел.*

Кремльдә үткәрелгән җыелыштан соң шактый көннәр күңелсезләнеп йөргән иде ул. Нәшриятка "Җыр үткән юл" дигән шигырьләр җыентыгын биргән. "Шуны тоткарласалар, йә бөтенләй кире борсалар,

ни эшләрмен?" — дип борчылды, җыелышта сөйләгән сүзләргә матур әдәбият бүлегенең башлыгы А. Гомәрнең борыны бик сизгер. Ул болай да шигырь китапларын кире борырга гына тора. "Проза китерсәгез, пожалуста, шигырьне кеше укымый", — дип кенә җибәрә икән. Ләкин Шәрәфнең бәхетенәме, әллә башлыкның бераз фронтовиклардан шүрләве булдымы, китап планга кергән, тиздән аны редакторга бирергә торалар икән. Шуны белгәч Шәрәф, авырудан терелгән кеше кебек, дәртләнеп йөри башлады. Бүген дә шатлыгын уртаклашыр кеше эзләп баруын күреп торам, теләгенә каршы килмәдем. Болай да караңгы, шыксыз бүлмәгә кайтып утырасым килми иде. Электр энергиясе житмәгәнгә тулай торакка утны чиратлап бирәләр. Торакның бер башында ике сәгать янганнан соң икенче башын бәхетле итәләр. Төнге сәгать икеләргә кадәр шулай кабатлана да, аннан соң ут бөтенләй күзен йома. Студентларның иренмәгән-нәре, китап-дәфтәрләрен алып бер баштан бер башка, танышлары бүлмәсенә йөриләр. Ә кайберләре шул арада ятып йокы симертү ягын карый. Мина тегесе дә, монысы да тансык түгел.

Өч катлы яшел йорттагы кара дерматин белән тышланган ишек төбенә килгәч, Шәрәф кыңгырау төймәсенә баскан арада, җиз пластинкадан "Писатель Асгат Айдар" дигән сүзләрне укып өлгердем. Менә кемгә килгәнбез икән бит. Бәләкәй чагымда йотлыгып укыган "Ташбай" авторына. Үксез казакъ малае, батыр чик сакчылары, кытай хунхузлары... Куркыныч та, күңелле дә маҗаралары тулы китапның авторы.

Әле дә онытмыйм, шул китапны укып утырганда әнием бәрәңге чүбе утарга кушты. "Үз өлешеңне утап бетерсәң, кич белән киногә барырсың", — диде. Башлаган битемне генә укып бетерим дә эшкә тотынырмын дип, китабымны да алдым. Карлыган төбенә утырып бер бит укыдым, икенчесен башладым, өченчесенә күчтем. Тагын ни булыр, нәрсә булыр дип, укый торгач, дөньямны онытканмын.

— Кара син бу ялкауны! Әле булса тотынмаган. Мин аңар булышырга дип чыгам тагын!

Әниемнең ачулы тавышына сискәнеп киттем. Китабымны карлыган куагы арасына шудырып төшерергә өлгерми калдым, кулымнан тартып алды да:

— Эшеңне бетермичә күземә күренәсе булма! — дип, өйгә кереп китте.

Киногә чыгу бетте инде болай булгач дип, гарьлегемнән күземә килгән яшьләрне сыпырып алдым да, үҗәтләнеп, эшкә тотындым. Менә шул китапның авторын кайчан да бер күрермен дип кем уйлаган ул чагында. Әле узган ел гына "Кызыл Татарстан" газетыннан шул повестьның яңа бүлекләрен укыган идем.

Ишекне зәңгәр майкалы, какча гәүдәле бер кеше ачты. Әле генә йокыдан торганмы, таушалган йөз, шешенке күз кабаклары, тузган чәч, яшүсмерләрнеке кебек мускулсыз нәзек беләкләр аны бик үк сөйкемле итеп күрсәтмиләр иде. Шәрәфнең ят кыз белән басып торуын күргәч, үзе дә уңайсызланды, ахры:

— Бер генә минутка, — диде дә ишекне кире япты.

— Вакытсыз килдек, ахры, — дидем мин, борылып китәргә әзер булып.

— Юк, юк, ул бик гади кеше. Менә күрерсең.

Шул арада ишек яңадан ачылды. Хуҗаның өстендә берничә орден һәм медальләр, яраларының билгесе булган сары һәм кызыл тасмалар таккан гимнастерка иде инде.

— Узыгыз, рәхим итегез, — диде ул, чәчләрен сыпыргалап.

Кара күзләренең җанны эретерлек елмаюы күңелне күтәреп җибәрде.

Ишеге кебек үк затлы фатирга керермен дип уйлаган идем, болын хәтле иркен, шыр ялангач бүлмәне күреп, сәерсенеп калдым. Шәрәф тә ни әйтергә белмичәрәк тора иде.

— Хатын ташлап китте әле, парин, — диде хуҗа, гафу үтенгән

сыман мескен тавыш белән. Әйтерсең, шундый хәлдә каршылавына безнең алда бик зур гаепле ул. Аның казакъныкы кебек кысынкы күзләрендәге елмаюны сөйләп бетермәслек газап алыштырган иде. Шәрәф түргә узып, бүлмәне аркылы-буйга әйләнеп чыкты да:

— Кайда йоклыйсың соң син? — дип сорады.

Әсгать Айдар тәрәзә төбендәге кызыл кирпечне күрсәтеп, әллә чынлап, әллә шаярып:

— Менә шуны баш астына салам да ятам. Солдат кеше бит мин, — диде.

Кирпеч яткан тәрәзә төбендә язучының кәгазьләре, берничә китап, яртылаш ашалган ипи кыерчыгы, буш стакан тора. Художник өчен менә дигән натюрморт. Иясенең хәсрәтле дөньясын ача торган күренеш. Үзе дә Әсгать Айдар хәленә калган останың гына кулы барыр мондый рәсемне ясарга. Ә мин аны натурада күреп торам һәм күңелемне гаҗизлек, өметсезлек, чарасызлык кебек кара уйлар урый башлавын сизәм. Бер йотым салкынча саф һавага тилмергән кешедәй, амбар ишеге хәтле зур тәрәзәгә тартылам. Юл артындагы борынгы матур йортка карыйм, бозланып каткан тротуардан тая-шуа үтеп йөргән кешеләрне күзәтәм. Анда, саф һавада, тын алуы рәхәттер. Минем шунда чыгасым, бу хәсрәт дөньясыннан котыласым килә. Ләкин нидер тота үземне. Бу бәхетсезнең язмышын беләсе килүме, әллә язучы исемен йөрткән кешедән уңайсызлануммы? Үзем дә белмим. Күзем тәрәзәдә, колагымда аларның сүзләре:

— Хәзер ни эшләргә уйлыйсың инде?

— Белгән юк әле. Азиягә китәрмен, ахры. Ни әйтсәң дә таныш җирләр бит.

— Үзебезнең әдәби мохит түгел инде. Кыйналсаң да, тиргәлсәң дә, үз ишләрең арасында булу кирәк. Язарга да язарга иде сиңа хәзер.

— Үзем дә шулай дип кайткан идем дә...

Әсгать абый мине кәгазьләре белән кызыксына дип уйлады, ахры:

— Эш өстәлем дә, аш өстәлем дә шушы инде, — дип, аларны бер читкә җыйды һәм, көтмәгәндә, кайдандыр алып, башланган бер шешә аракы китереп куйды.

Шешә күргәч, болай да төшенке күңелемне ничек юатырга белмәдем, әшәке, кыргый җиргә килеп эләккәндәй, гаҗиз булып Шәрәфкә карадым. Юк, айдан төшкән кыз түгел идем мин, дөнья хәлен беләм, аракы эчкәннәрен дә күргәнем бар, исереп, урамда аунап яткан мескен бәндәләрне дә очратам, әтәчләнеп бер-берсенең якасына ябышкан камыр батырларны да беләм. Тик алар миңа чит-ят кешеләр, якыннарым, кардәшләрем түгел, алар күрсәткән хәсрәт миңа кагылмый, аларның килбәтсезлеге мине оялтмый. Ул нәрсә белән минем әтием дә шаярмады. шушы яшемә җитеп бары бер тапкыр күрдем мин аның кызмача кайтканын. Күзләре сәер ялтыраудан шикләнеп әнием:

— Әллә эчкән инде? — диде.

— Булмаганны...

— Йә, тыныңны өр әле!

Әтием, шаярып, сулышын эчкә тартты. Ләкин ис тоюга бик сизгер әниемнең кашлары җыерылганны күргәч, тизрәк акланырга ашыкты:

— Жож грамм гына ла! Кибетче Габделхак сыйлады.

— Ай-һай шәп сый! Укучыларыңның ата-аналары алдында авыз күтәреп эчеп торырга оялмадыңмы?

— Кибетнең арткы бүлмәсенә алып керде, берәү дә күрмәде.

— Ни өчен кергәнеңне сизмәделәр, дисеңме. Аңгырага санама кешене. — Булмаганны...

Шул көннән соң әтиемнең андый чагын күрмәдем, ләкин җае чыкканда “жож грамм” дип әни аны үртәп алгалый торган иде. Эчми эчкән кешегә шул да җиткәндер инде, “йөз” урнына “жож” булып чыкты шул сүзе. Ә бүген менә бу шып-шыр бүлмә, юылмаган бердәнбер стакан, кукыраеп утырган аракы шешәсе өнемне алгандай итте. Шәрәф кенә бу эшкә риза кебек иде, хуҗаның тәрәзә тирәсендә кыбырсып йөрүен елмаеп

карап торды. Китик, дигәнне аңлатып ишеккә ым каксам да исе китмәде, хәзер дигәндәй, баш кагып кына куйды.

— Каласың килсә — кал, мин китәм, — дидем аңа үпкәләп.

Шәрәф яртылаш аракы салган стаканны тәрәзә төбенә куярга ашыгып, нидер әйтмәкче булды, ләкин Айдар каршыма төшеп өлгерде.

— Син гаеп итмә инде, сеңелкәш. Ике фронтовик очрашканда әзрәк була инде ул.

— Хушыгыз!

Менә шул көннән башлап Шәрәф мине, мин Шәрәфне күргәнем юк.

Мин киткәч, Әсгать Айдар:

— Бик усал кыз икән, башыңны бәйләмә, — дигәндер Шәрәфкә. Аны аңлап була. Баш астына салырлык мендәрен дә калдырмыйча, барысын җыеп чыгып киткән хатыннан соң шулай дип әйтүе табигый аның. Ә Шәрәф мине белә бит. Урамга чыккач та көтеп тордым әле мин аны. Артымнан килеп җитәр дип ышандым. Килмәде. Гарьлегемнән күземә яшь бәреп чыкты.

Уйнап кына әйткән идем:

"Синең белән кайтмыйм", — дип.

Салкын гына әйтеп куйды:

"Кайтмасаң, сүз әйтмим", — дип.

Шушы сүзләр күңелемә килде дә кычкырып елап җибәрмәс өчен иренемне тешләдем. Ләкин күз яшемне тыя алмадым, янагым буйлап тәгәрәп төште.

## Хәсрәт арты хәсрәт

Үтерә инде бу Стрижак. Инглиз телен генә дөньяның тоткасы дип белә инде әллә? Тагын тастымал хәтле текстны тәрҗемә итәргә биреп җибәрде. Башка фәннәрне өйрәнәсебез барлыгын уйлап та карамый.

— Интегеп утырма юкка, — дип, киңәш бирә Җәмилә. —Сажидә ападан Джек Лондон китабын сорап ал да, күчер шуннан. Зачет алсаң җитә бит сиңа.

Сажидә апа Сатыева, Үзәк көтепханәнең татар бүлегендә эшли. Сорасаң, үзендә булмаган китапны да табып бирә. Тик Җәмилә Белла Абрамовнаның явызлыгын белми шул. Тәрҗемәнне укып күрсәтү генә җитми аңа, студентларның этлегеннән сизеп тора һәм аерым сүзнең инглизчә мәгънәләрен сорап теңкәгә тия. Үзең сүзлек актарып, баш ватып эшләгән эш булмагач, барыбер тотыласың.

Җитмәсә, бүген безгә Гөлсем кергән. Башка вакыттагы кебек ут капкандай чыгып йөгерми, иркенләп утыра. Бүлмәдәге кызлар Җәмилә караваты янына җыелганнар да көлә-көлә сөйләшәләр.

Тыңламыйм дисәң дә колакка керә бит:

— Гөлсем, әйт әле, кияүгә чыгу рәхәтме? — ди Җәмилә. Әйләнеп карамасам да, аның астыртын елмаюын сизеп торам.

— Үзең чыгып кара, белерсең, — ди Гөлсем, шул чагында ап-ак тешләрен ялтыратып зур авызын ера инде ул.

— Чыгар идем дә, алучы юк бит.

— Кара пәриең бар ла! — монысын Зәмзәмия әйтте, ашаганда да кулыннан китабын төшерми торган бу кыз да килеп кушылган икән.

— Һы... Безнең авылда бер егет барие, күршеләрендәге кыз кияүгә киткәч, мин аның белән биш ел йөрдем, үзе генә белмәде, дип әйткән, ди.

— Син дә шуның кук...

Бигайбә, миссис Стрижак, утырмадым түгел, бик тырышып утырдым. Үзеңне шаккатырырга иде исәбем. Тел бистәләре янында эшли генә алмадым, ачуланма. Җәмиләнең киңәшен тотармын, ахры, мин, ни әйтсәң

дә, буш кул белән баргандай булмас. Текстны сүзлек эченә кыстырып куйдым да Гөлсем янына утырып, муенынннан кочып алдым.

— Әхмәтең өйдә юкмы әллә? Болай утырырга ирек бирмәс иде.

— Өйдә. Үзе куып чыгарды. "Дусларыңның хәлен белеп төш", — диде.

— Каян килгән мәрхәмәт!

— Язарга утырды. Күптән тотына алмый йөри иде. Теге көнне син чыгып киткәч, Гали абый белән төне буе сөйләшеп яттылар. Шуның файдасы тидеме?

Әхмәт үзенә күрә түгел, дворян баласы кебек, язар өчен аерым бүлмә, үзенең эш өстәле, өстәлдә кайнар кофемы-чәйме булырга тиешлеген алга сөрә. "Артында хатының табак-савыт шалтыратып йөргәндә ничек язасың инде?" — ди. Җитмәсә: "Әйбәт шигырь язу өчен айлар кирәк, поэма кебек зур күләмле әсәрләр унар ел сорый", — дип тә куя. Әгәр аның сүзендә хаклык булса, бөтен иҗат гомере ун елга да тулмаган Тукай шулхәтле күп әсәрләрен ничек язды икән?

Гали Хуҗи абыйдан уңайсызланмасам, мин шулай дип әйткән булыр идем, әлеге дә баягы кыюсызлык уйлаганымны күп вакыт эчемдә калдыра шул. Ярый, кунак үзе дә минем кебегрәк фикердә икән әле.

— Фронтта планшет өстенә куеп язганыңны оныттыңмыни? —дип каршы төште.

— Онытуын онытмадым, адәм рәтле әйбер генә яза алмадым.

— Әнә, Фатих Кәримне кара син!

Фатих Кәрим турында сүз чыккач, Гали абыйга ялгап ук Әхмәт:

— Без җыелдык,
Шагыйрь дустыбызны
Озатырга сугыш кырына;
Берәм-берәм кысып кочты безне
Һәм баласын алып кулына
Ул ант итте... — дип сөйли башлаган иде, кунакка бу ошамады.

— Сүз минем поэма турында бармый, Әхмәт, куй әле! Фатихны әйтәм мин, — дип бүлдерде. — Аның "Моң һәм көч", "Мәхәббәт һәм нәфрәт" китаплары сугышның иң кайнар җирендә язылмадымыни? "Разведчик язмалары!" Сугышның алгы сызыгындагы Сибгат, Нур Баян, Маннур, Кутуй, Мөдәррис... Тагын кирәкме?

Кара син бу кешене! Кызып та китә белән икән. Ул инде утырып кына тора алмый, кысан бүлмәне ишекле-түрле әйләнеп тә килде.

— Син прусты кызып киттең, дустым, — диде Әхмәт, килешү эзләп. — Алар турында бер сүз әйтә алмыйм. Мин бит үзем хакында гына сөйлим.

Ул кичне шундый бәхәс булып алган иде шул. Җиңенә тигән икән Гали абый, Әхмәтне дә язарга утырткач инде.

Тәмләп кенә сөйләшеп утырганда ишек шакып, безгә таныш булмаган бер егет белән Шәрәф килеп кермәсенме!

— Бу өйдә аулак өй дип әйткәннәр иде, егетләр килде, кызлар, кертәсезме?

— Кәнфит, прәннек алып килсәгез, кертәбез.

— Кәнфите дә, прәнниге дә менә шунда, — дип, каршына килгән Җәмиләгә Шәрәф бер төенчек тоттырды.

Гөлсем белән мин урыннан купмадык, Зәмзәмияләр, Рәмзияләр өстәл тирәсенә елышты, мин Шәрәфне шаярта дип уйлаган идем, төргәгеннән кәгазь-мазар гына чыгар дип юрадым. Әмма барыбызны да шаккатырып өстәл өстенә майда кыздырган бавырсак, тәбикмәк, төче күмәч, сумса, банкалы бал кебек авыз суларын китерерлек тәм-томнар таралып китте.

— Әттә-тә-тә!

— Мондый егетләрне кертмәсәң, Алла орыр!

— Әллә үзең пешердеңме боларны?

— Кызлар, туктагыз әле, күчтәнәчнең кемгә икәнен беләсезме?
— Әллә үзе генә сыйланыр идеме?
— Безгә дә түгелмени?
— Барыгызга да, кызлар, барыгызга да, йә чәй куеп җибәрегез инде, туй күчтәнәчләре белән сыйланып алыйк.
— Өйләндеңме әллә?

Эчемдә нидер кылт итеп өзелгәндәй булды. Башыма кан бәреп, колагым томаланды, бүлмәдәге ыгы-зыгыны томан аша күргәндәй карап торам. Ярый әле күчтәнәч белән мавыккан кызлар игътибар итмәде, Гөлсем генә сынап йөземә карап алды.

— Өйләнмәдем, сеңелне кияүгә биреп килдем.
— Әллә шушы егеткәме?
— Юк, аңа түгел. Таныштырмадым да бит әле мин сезне. Бу минем күптәнге дустым — Шәрәф Ибәтов була. Сугышка хәтле рабфакта бергә укыган идек, хәзер педагогия институтының студенты. Немецча бик шәп белә, чит телләр факультетында укый.
— Йә, барын да сөйләп бетермә инде, дустым, — диде кунак, оялчан елмаеп.

Мин Әсгать Айдарлардан дулап чыгып киткән кичне өенә кайтса, Шәрәфне телеграмма көтеп тора икән: "Немедленно приезжай Салиса замуж выходит". Немедленно булгач, немедленно. Чүпрәлегә кайту Мәскәүгә барудан да мәшәкатьлерәк. Поездлан төшүгә машина туры китерә алмыйча, Буада өч көн ятканнан соң, кире борылып кайтканы да булган Шәрәфнең. Төнге сәгать уникеләрдәге поездга, чак-чак булса да, өлгерә алган тагын үзе. Кияү дигәне Салисәдән унбиш яшькә олы, хатыны үлгән бер кеше икән. Мәскәү янындагы шахталарның кайсындадыр күмер чаба. Тагын шунда китәсе, ди. Күрешеп сөйләшкәч, ипле кешегә ошата аны Шәрәф. Ләкин Салисәнең әнисе белән туганнары каравыл гына кычкырмыйлар. "Дөньяда булмаган хәл... Татар гадәтен бозып... Әбзәң белән апаңны калдырып... әтәң күк кешегә... Бер белмәгән чит-ятка... ягада ташлап калдырса... Уби базарыннан башка җиргә чыкканың бармыни... Ә кызның үз туксаны туксан: "Чыгам булгач чыгам, әбзәй каршы әтсә дә, чыгам!" Әбзәй кеше каршы килү түгел, өстәл сугып бер генә әйтә өйдәгеләргә: "Җитте сезгә, акыш-макышлар! Бу заманда кызыгызга кияү чыкканга рәхмәт әйтегез".

Шулай итеп туй ясый болар. Махсус өйләнергә кайтуы булгач, кияү дә сынатмаган. Туй кирәкләрен алып кайткан.

Боларны Шәрәф чәй янында кызык итеп сөйләсә дә, кызлардан бигрәк минем өчен әйткәнен аңлап торам. Шулай да ачык чырай күрсәтергә бик җиенмыйм. Күкрәгемдә төер булып торган ачуым, теге вакытта ялгыз башым кайтып китүдән гарьләнүем ирек бирми. Ярый әле, бераз утыргач, Гөлсем үзләренә төшәргә җыена башлады. Җай табылды.

— Озатып куям, — дип, мин дә кузгалдым.

Шәрәф: "Инде бер чыгып киткәч, кире әйләнеп кермәс бу", — дип уйлады, ахры:

— Без дә кайтабыз, хәзер бергә чыгарбыз, — дип, Гөлсемне туктатты.

Егетләр ашык-пошык кына саубуллаштылар да безгә ияреп чыгып киттеләр. Беренче катка төшеп җитәрәк Шәрәф кулымнан тотып арткарак калдырды:

— Сөйләшәсе бар иде, кайчан күрешәбез? — диде.
— Моңарчы алдан сөйләшеп очрашканыбыз юк иде әле.
— Бик зур сүз ул, җитди сүз...
— Белмим шул. Бу арада зачетлар бик күп. Вакыт юк.

Инде аска төшеп җиткән Гөлсем белән Ибәтов башларын күтәреп, безгә карап торалар иде.

— Әнә иптәшең көтә, бар инде, — дидем, егеткә ачык бер җавап бирмичә.

— Иртәгә укуың бетүгә килермен, — диде Шәрәф, хушлашканда.

Иртәгәсен таң атар-атмастан ук бүлмәбезгә кайгылы хәбәр керде. Рәмзияне алырга килгәннәр, әнисе үлгән. Ишектән кергән сеңлесен күрүгә дустым барысын да аңлап, сеңелесен кочаклап үкси башлады. Мин дә аларга барып сарылдым, тыела алмыйча елап җибәрдем. Юынырга әзерләнеп йөрүче Җәмилә дә, табак-савытларын шалтырата башлаган Зәмзәмия дә катып калды. Рәмзиянең көн дә дип әйтерлек кайтып йөрүенә ияләнеп беткән идек инде, чөнки әнисенең урын хастасы икәнен беләбез. Утын кискәсе кебек, кузгала алмыйча, еллар буе түшәмгә карап ятуның нинди авыр газап булуын уйлый гына алмаганбыз. Гомерлек чир түгел, узгынчы сырхауның да ни икәнен белмәгән яшь, таза чак бит. Кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәсә, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул.

Бер елга түгел, ун елга торырлык озын, авыр, хәсрәтле көн булды бу. Иң авыры мәетне алып чыккач, керләрен юып элгәч, өйне җыештырып алгач, бөтен мәшәкатьләрдән арынып эшсез калгач икән ул. Юеш кердән, юеш идәннән су салкыны түгел, гүр салкыны килгән кебек, бушап калган өйдә кабер тынлыгы. Мәрхүмәнең рухын рәнҗетмик дип, аяк очына гына басып йөрибез, пышылдап сөйләшәбез. Ялгыз бүлмәдә өч кыз туган бер-берсенә сыенып елап утыра, икенчесендә гомер иткән карчыгының рухына багышлап әтиләре намаз укый. Ә мин ни эшләргә, кая барып бәрелергә белмичә, урамга чыктым, ишек яңагына сөялеп, каршыдагы нарат башына төшкән кичке кояшның алтынсу нурына карап тора башладым.

Сәгать алтыларда безне күршеләр чәйгә чакырып алдылар. Кичә кичтән бирле авызыма ризык кергәне юк иде, шулай да табак тутырып китергән кайнар бәрәңгегә, кемдер кертеп биргән тозлы кәбестәгә карыйсым да килмәде. Әтеп-төртеп дигәндәй, бер бәрәңгене йотып җибәрдем дә, кишер чәен эчеп куйгач, рәхмәт әйтеп табыннан кузгалдым. Буыннарның гына хәлсезләнүе түгел, җанымның да талчыгуы җиткән икән. Башым таш тутырган чүлмәк кебек авыр. Кинәт үтереп йокым килә башлады! Рәмзия белән икебезгә әнисе авырып яткан караватта урын җәйгәннәр икән, тартынып, шикләнеп тору кая, башым мендәргә тияргә дә өлгермәде, “Нәүм базары”на китеп тә барганмын. Ләкин озак йокламадым, төш тә күреп өлгермәдем, ахры, Рәмзиянең сулкылдап елап ятуына уянып киттем. Дустымны юатырлык сүзләр көчсез, сүзләр артык икәнен беләм. Хәсрәтенең беразын гына булса да үз йөрәгемә алырга теләгәндәй, вак калтырау алган ябык тәнен кысып кочакладым.

Шуннан соң күземә йокы кермәде. Таң атканчы әллә ниләр уйлап бетердем. Әниемне исемә төшердем. Мондый ачы язмыш минем үземнең дә баш очымда канат җәя язып калган иде бит. Узган елгы кышкы сессия вакытында әниемнең бөер зәхмәте белән авырып китүен хәбәр иттеләр. Юк-бар чиргә генә бирешә торган кеше түгел иде ул. Башы авыртып урынга яткан чагын хәтерләмим. Маңгаен ак яулык белән кысып бәйләр иде дә, һич бетәсе булмаган өй эшләрен тавышсыз-тынсыз гына эшләп йөрер иде. Без бала-чагага бик күңелсез булыр иде шул чагында. Сулып киткән йөзеннән, эчкә баткан күзләреннән кәефе шәп түгеллеген аңлый идек.

Инде район больницасына ук килеп ятарлык булгач, авыруының көчле икәнен белергә була иде. Ә мин, мәнсез, сынаулар беткәч кайтырмын дип, вакыт үткәрдем. Әйтерсең лә, эшең беткәнне көтеп тора ала инде авыруның хәле. Йә, шунда бер-ике сынауны бирми калганнан дөнья җимерелә ме? Күп булса, стипендиядән мәхрүм итәрләр иде. Әнием хәле авырында кайтып килмәвемә үпкәләмәде тагын. “Сынауларыңны вакытында биреп бетергәнсең икән, рәхмәт, кызым”, — дип, хәлсез кулын күтәреп башымнан сөйде. Әниләр күңеле даладай киң, яз кояшыдай җылы була шул. Ул минутларда без икебез дә бәхетле идек. Әле хәзер уйлап ятам, кеше шулай ялгыша-ялгыша сабак ала, үкенечләр аша акылга килә, күрәсең.

Мәрхүмәнең өчесен үткәргәнче китмә дип кыстасалар да, Казанга кайтасы иттем.

Исәннәргә яшәргә дә яшәргә, дөнья мәшәкатьләрен чигәргә дә чигәргә икән шул.

Профессор Чернышевның лекциясенә йөрергә яратмыйбыз. Алдындагы кәгазьдән башын күтәрмичә, йокыны китереп торган төссез тавыш белән борын астыннан мыгырдаганын язып бару кыен. Тарихтан башка кеше укытсын, Чернышевны теләмибез дип, деканатка шикаять белән кергән идек. "Аның кебек галимнән лекция тыңлавыгыз белән горурланырга тиеш әле сез", — дип чыгардылар. Имеш, ул дөньяга мәшһүр галим, имеш, аның чит илләргә мәгълүм хезмәтләре бар. Булса соң! Шуларның меңнән бер өлешен генә булса да студентларына бирә белмәгән галимнән ни файда? Йокымсырап йөргән кешедәй авыр хәрәкәтле, бернәрсәгә дә исе китмичә караган бу карт галим кыяфәте белән үк гайрәтебезне чигергән иде. Шуның өстенә талымсыз да үзе. Деканатка нинди үтенеч белән керүебезне әйткәннәрдер аңа, әйтмичә калмаслар. Ләкин ул ни күз карашы белән, ни сүз белән үпкәләвен белдермәде. Әшендә дә үзгәреш күренмәде. Үзе турындагы фикергә битараф иде бугай ул. Каршында өч-дүрт студент утырса, шул житкән аңа, башкалар кебек, деканатка кереп әләкләп йөрми. Шуның өчен лекциясенә чиратлап йөрибез. Ни белән генә шөгыльләнми профессор каршында утырганнар, кайсысы хат яза, кайберләре калган лекцияләрне күчереп утыра, зачетка әзерләнүчеләр дә була. Профессорның эч пошыргыч тавышына колак салучы да юк. Лекцияне "тозлаучы"га да рәхәт. Берәр төрле эшең булмаса, шул арада киногa кереп чыга аласың.

Бүген мин дә чират үткәреп утырырга тиешмен. Өйгә күптән хат язганым юк иде. Туйганчы укырлык итеп язармын дип, иртән үк уйлап куйдым. Кич булдымы, әниемнең капка төбенә чыгып, почта йөртүче Халисәне өмет белән каршы алганын беләм бит. "Юк шул әле, Гыйлем апа", — дигән сүздән соң боегып калган йөзен күз алдына китерү кыен түгел.

Студентларның кайсы-кая таралып бетеп, өч-дүрт кеше бүлмәдә утырып калган идек, мин дә, хат язарга гына тотыла торган дәфтәремнең уртадагы куш битен ертып алып, әлегә хәтле кулым житмәгәннән генә көн дә кичереп килгән эшкә тотыныйм гына дигәндә, ишектән:

— Ихсанова, тебя зовут, — дип кычкырдылар.

Кем булыр икән? Сабакташлардан берәрсе чакырып тормас, аудиториягә үк килеп керер, әллә авылдан килгәннәрме? Менә шәп булыр иде, дигән куанычлы өмет белән канатланып чыксам, баскыч култыксасына таянып Шәрәф басып тора.

— Син?!

— Килдем әле менә.

Йөзем кинәт караңгыланып китте, ахры. Бирегә килүенә үкенгән кебек егетнең тавышы кыюсыз, төшенке булып ишетелде. Мин дә аның белән очрашуга атлыгып тормый идем. Шулай да үпкәләп йөрүемнең мәгънәсезлегенә үз-үземне ышандырган идем инде. Теге вакытта Шәрәфнең Әсгать Айдар бүлмәсендә утырып калуын да, хәбәр бирмичә авылга китеп баруын да үземчә аклаган, хәтта ки, эгоистлыкта гаепләп, үз-үземне тиргәп тә алган идем. Ләкин аның тулай тораклан китеп барганда: "Иртәгә киләм әле, житди эш турында сөйләшәсе бар", — дигән сүзләре сагайткан иде мине. Рәмзия әнисенең вафаты бу очрашуны кичектереп килсә дә, вакыт-вакыт исемә төшеп, тынычсызланып йөргән чагым иде. Сүзнең нәрсә турында буласын сизенәм, гипнозланган кеше кебек күнелем белән шуңа тартылам, бу хәлнең шулай ук тиз якынлашып килүенә пошамангa калганымны да сизәм. Шуңа күрә бик ачылып китмичә генә:

— Хәзер лекция башлана, — дип, вакытым юклыгын белдердем.

— Лекцияне тыңлау миңа да зыян итмәс иде.

— "Ихтыярың — бәрәңге, тәгәрәсен дә черсен", — дип әйтәләр иде безнең авыл кызлары.

— Сезнең авыл кызлары назландырырга ярата инде ул.

Җавап биреп өлгермәдем, авыр атлап, баскычтан менеп килүче профессорга күзем төште. Култык астына язмаларын кыстырган, уң кулы белән баскыч култыксасына тотынып, вакыт-вакыт туктап хәл алып торган карт галимгә карап торуы авыр иде. "Әллә авырыймы икән ул", — дигән уй күңелемә килеп, кызгануга охшаш хис кичердем. Карт кешегә күп кирәкмени? Авырмаса да, сугыш елларының михнәте, кайчандыр зифа булган гәүдәнең тураеп басарлыгын калдырмавы бик ихтимал. Без бөтенебез дә сугыш михнәтләрен бер төрле кичерәбез. Сынауларын да вакытында биреп өлгермәгән студент кисәге дә, дөнья серләрен ачарга тырышкан галим дә тәүлегенә 500 грамм икмәк ала. Билгеле, байлар тормышы дип булмый моны, алай да җан сакларга мөмкин. Ач студентның ләкин бер өстенлеге бар, тыныч, матур тормышны күрер әле ул, бөтен гомере алда. Ә бу галимнең?..

Арган карт профессорга нәрсә аңа, ник шунда алдына аю китереп утыртмыйлар. Шәрәфкә игътибар итүче дә булмады. Сима белән Катя гына борылып карадылар. Катя баш бармагын күрсәтеп, мәгънәле генә елмаеп куйды. Мин исә, хат язарга әзерләгән дәфтәр битенә кагылмадым. Беренче тапкыр игътибар белән Чернышевның сүзләренә колак салдым. Тыңласаң, тыңларлыгы бар икән бит ул сөйләгәннәрнең. Дөрес, аның тавышы әкрен, хәлсез. Дөрес, сөйләвенең эффектын белергә теләп, кайбер яшь галимнәр кебек, күзе белән аудиторияне ашамый, агарып беткән юка чәчле башын игән дә, бер көйгә салып, сөйли дә сөйли. Дөрес, лекцияне язып баруы кыен, әмма, игътибар белән тыңласаң, истә калырлык күп нәрсәләрне беләсең. Шушы сәгать ярым вакыт эчендә моңа кадәр бу картның лекциясен "тозлап" йөрүемә үкенеп утырдым. Шәрәф тә урамга чыккач:

— Нинди акыллы кеше, — дип куйды.

Белми бит ул безнең шикаять белән деканатка кереп йөргәнне.

— Сиңа бер яңалык әйтәм, — диде Шәрәф, бераз сүзсез баргач, — "Җыр үткән юл"ны редакцияли башладылар.

— Менә шәп булган. Ә син куркып йөрдең. Редакторың кем?

— Шәйхи Маннур. Юкка булмаган ул курку. Китапның чыкмый калуы да бар.

— Ничек инде?

— Эш болай да авыр бара иде. Бер шигырьгә килеп җиткәч, икебез дә терәлеп каттык.

— Кайсы шигырь соң ул?

— Сиңа атап язган шигырьгә каршы килә.

— Ошатмыймыни?

— "Сөйгән кызыңа багышланган альбом шигыре белән китапның ямен җибәрмик әле", — ди. Шигырь кермәсә, китапны чыгармыйм гына.

— Нишләгән ул Шәйхи абый? Үзенең дә укып туймаслык лирик шигырьләре күп бит. "Тартай арбасы"ның тәэсиреме әллә?

— Аңа гына бирешә торган түгел ул. Карт солдат нindидер кризис кичерә. Фронтта ук күңел төшенкелегенә бирелгән хатларын ала идем. Аңламыйм мин аны.

— Шәйхи абыйны гына түгел, дөньяны аңлавы да читен әле монда.

Әдәби мохиткә керә барган саен зиһенем чуалып, күп нәрсәне аңламас булган идем шул. Нәрсә уйласам, шуның турында шигырь язып, бүлмәдәшләремне "шаккатырган" чакларым кая китте соң? Бер-беребезне сүзсез хуплап утырган вакытлар булмаган да кебек. Онытылды. Студентлар арасында әдәбият турында тыныч кына сөйләшкән кешеләр аз хәзер. Без инде башлап язучы күлмәгеннән үсеп чыккан, университеттагы әдәби түгәрәк белән генә канәгатьләнмичә, Язучылар союзы секцияләрен дә калдырмыйча йөрибез. Әдәби җомгаларда, дәрәҗәле җыелышларда Тукай клубының арттагы урыннарын тутырып утырабыз. Фронтовикларча кыю

сөйләшүләр, бер-берсен үпкәләтер дәрәҗәгә житкереп әйткән ачы сүзләр безнең болай да уйнап торган яшь каныбызны кыздыра. Зурлар сөйләшкәндә тынлап кына утырсак та, үз арабызда алардан калышмаска тырышабыз. Әле күптән түгел генә Мәхмүт Хөсәен яна шигырьләрен укыды. Яшь кешенең тойгыларын белдергән, беренче заттан язылган шигырьләр, Мәхмүтчә бераз гына күпертеп, һаваланып әйтелгән юллары да бар. Бәйләнделәр бит шуңа. "Мин" дип, халык исеменнән сөйләргә үзеңне кем дип беләсең, имеш. Шау-шу купты. Шуңа охшашлырак бәхәс аннан элегрәк проза секциясендә дә булып алган иде. Сәмигуллин дигән бик чибәр бер егет үзенең фронтовик язмаларын укыды. Бер-ике рус солдатын кире яктан сурәтләгән. Ябырылдылар егеткә: "Башка милләт кешесен тәнкыйтьләү яхшы түгел. Бигрәк тә бөек милләт вәкилен. Алайга китсә, безнең үзебездә дә житәрлек андый мөртәтләр"... "Мин булганны яздым, үзем күргәнне", — дип аклану да ярдәм итмәде егеткә. "Булган эшләр дөньяда күп ул, әдәби дөреслек дигән нәрсәне онытмаска кирәк, социалистик реализм кануннарын", — дип, авызын томаладылар.

Иптәшләрем кызып-кызып бәхәсләшкәндә авыз йомып утырам. Мин бернәрсә дә белмим, алар янында шыр надан мин. Шундый чакта үземне карурман авызында басып торган ялгыз юлчыдай сизәм. Керергә, үтәргә кирәк миңа аны, әмма таныш түгел урман юлы шикләндерә, шомландыра да үземне. Кая китте минем бөтен нәрсә гади һәм анлаешлы булып тоелган самими чакларым. Мин инде: "География факультетында калып, дөрес эшләдемме икән?" — дип шикләнә дә башладым. Чөнки татар әдәбияты бүлеге ачылгач, Җәмиләләр чакырганнар иде бит. "Күч безнең янга, география түгел, әдәбият белеме кирәк сиңа", — дип әйткәннәр иде. Ул чакта мин, эре генә итеп; "Максим Горький югары уку йортларында белем алмаган, тормыш университетын үткән", — дип җавап бирдем. Күчмәвемнең сәбәбе бик гади иде, югыйсә. Яңабаштан, беренче курстан тотынырга кирәк иде. Ә бу инде бер ел укуым җилгә очты дигән сүз. Берне ташлап, икенчесен башлап йөрсәм, әтием белән әниемә авыр йөк булырмын дип уйладым, тәвәккәллек житмәде. Әдәбият дигән сихерле дөнья үзенә әсир итеп, суырып алыр дип тә уйламаган идем ул вакытта. Терсәк якын да, тешләп кенә булмый, диләр бит.

Шәрәф белән икебез бер үк нәрсә турында уйланып, сөйләшмичә генә, урамнардан күп үткәнебез бар. Мин аның холкын бераз беләм кебек. Шәйхи абый шигырен калдырырга аяк терәп каршы торса, китабының чыкмый калуы да бар. Шәрәфнең дә кирелеге житәрлек. Бу китап турында күпме кайгырып, борчылып йөрде бит ул, әле планга кергәнче үк... Ул китапны минем дә бик күрәсем килә. Шигырьнең кермәве дә кызганыч. Мин әле дә аны күңелдән кабатлап барам:

"Килер" дип, сагынып көтеп торасың,
"Килде" дип, ашкынып каршы чыгасың.
Күрмичә сөйгәнең, бәгърем Ләбибә,
Ялкынлы яшь йөрәк ничек чыдасын?
Кыймыйча, ятсынып яныма киләсең,
Бит алмаң кызарып кулыңны бирәсең,
Карамыйм текәлеп, бәгърем Ләбибә —
Тукта, дим, зифама күзем тимәсен.
Синдә — хис, омтылыш, уйлар пакьлеге,
Эчкерсез садәлек, намус сафлыгы.
Син — чәчәк дөньяда, бәгърем Ләбибә,
Табигать-анамның бөтен шатлыгы.
Яшьлегем чәчәген ямьгә төрәсең,
Кояштай жемелдәп төшкә керәсең.
Көнләшәм, гүзәлем, бәгърем Ләбибә,
Бәхетле сабый күк сөелә беләсең,
Кулга көч, йөрәккә илһам саласың,

Сихерле, серле нур — синең карашың.
"Гүзәлем син", — дисәм, бәгърем Ләбибә,
Син тагын кызарып, тынып каласың,
Пакъ теләк, изгелек, саф уй нишләтә?
Мәхәббәт бәхетен шулар тизләтә.
Ялкынлы уртак хис, бәгърем Ләбибә,
Арттыра көч-сәләт бездә бишләтә!

Минем өчен үтә кадерле шигырь иде ул. Кат-кат укып ятлап бетердем. Шәрәф белән сөйләшми йөргән көннәрдә бигрәк еш исемә төшә торган иде. Күңелемнән шуны кабатлыйм да күземә яшь килә. Минем аны ялгышып та, берәү белән дә уртаклашасым килми. Бары тик миңа, минем өчен генә әйтелгән сүзләр икәнен беләм. Хәтта бүлмәдәш кызларым да белми ул шигырь турында. Бары тик Рәмзия генә укыды. Бу Шәйхи абый да юкка бәйләнә. Ниткән альбом шигыре булсын ул. Егетләр аны үз сөйгәннәренең исемен атап укыр иде. Әгәр...

— Шәрәф, Ләбибә урынына Рәмзия дип куйсаң, Шәйхи абый риза булырмы икән? — дидем мин бераз икеләнебрәк.

— Мин аны Рәмзия өчен дип язмадым.

— Үз кулың белән биргән шигырең миндә, йөрәгемдә. Аны бер кем дә ала алмас. Шәйхи абый да. Рәмзия, минем иң якын дустым. Шигырьне үзенә аталган дип кабул итмәс. Миңа язганыңны белә. Китап укучы өчен Ләбибә ни дә, Рәмзия ни...

Бу сүзләрем башта Шәрәфнең хәтерен калдырган кебек булган иде. Шактый гына уйланып сүзсез барды. Шулай да дәлилләрем белән килеште, ахры, тавышы йомшара төште. Кистереп үк әйтмәсә дә: "Уйлап карарга кирәк булыр", — дигән сүзеннән эчкә җылы керде.

## Авырткан башка тимер тарак

Кассаның бүрек хәтле генә тәрәзәсеннән сузылган ведомостька кул куеп, стипендия акчасын алдым да, бирәчәк бурычларым турында уйлый-уйлый, татар теле кафедрасына таба киттем. Барыннан да элек Зәмзәмия белән араны өзәргә кирәк иде. Кайтуымны көтеп торадыр. Болай да ыңгыраша-сыкрана гына биргән иде. Акчасы барлыгын тәгаен белгәнгә күрә генә. Профсоюз белән партия взносларын түләргә дә түләргә инде. Анысын кичектерү турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Аннан соң... Аннан соң Шәрәфкә дигәнен. Узган ел энем каникулга килгәч алган акчаны әле дә кайтарганым юк. Муеннан бурычка батма икән ул. Стипендия алган саен биш-ун сумын илтеп бирәм югыйсә. Атна-ун көн дә үтми, кесәмнең такыр икәнен әллә күземә карап белә инде, ул тагын акча суза.

— Бүген гонорар алдым. Бераз синдә торып торсын әле. Миндә тиз бетә, — ди.

— Ә мин тотсам?

— Әкренләп түләрсең.

— Тегесен дә биреп бетерә алганым юк.

— Бурычыңны түләмәсәң, үзеңне алырмын.

— Йә жаның, йә малың дип әйтәсең инде.

— Шулай шул, — ди Шәрәф, көлә.

Алсам да вай, алмасам да вай, ул акчаны. Чөнки иртәгә ипи алырлык та рәтем юк. Кеше саен теләнеп йөрү дә туйдыра. Иптәшләрнең күбесе минем кебек хәерче бит. Зәмзәмия кебек акчалы кызлар аз безнең тирәдә. Зәмзәмия ул артык сак яши, булганын тиенләп тота. Безнең кебек, ике көннең берендә йә киного, йә театрга чыгып йөгерми, шуңа күрә генә маядан өзелми. Ә без бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй шул. Безнең кебек гамьсез җан булгандыр инде, бер студент, акчасын тотып

бетергәч, өенә телеграмма суккан, ди. "Здравствуйте, родители, денег не дадите ли?"- дип. Аңа каршы: "Здравствуй, Никодим, денег не дадим" дигән җавап килгән. "Шундый-шундый эшләр, тора-бара нишләр?" — дип әйткән, ди, берәү.

Беренче каттагы озын, тар һәм караңгы коридордан килә-килә, әле генә алган стипендиямне күнелемнән бүлгәләп бетергәч һәм кесәдә бик аз калачагын да белгәч, әзрәк эчне тырнап куйды да онытылды. Әй, җан биргәнгә җүн бирер әле. Бу — әниемнең сүзе. Авыр чакларда шулай дип юана ул. Көтмәгәндә бер җае чыгып куя тагын. Әйдә, мин дә хәзер Җәмиләне эзләп табыйм да киногa кереп чыгыйк. Кызыграк картина булса, тамак кайгысы да онытыла. Кайтасын да урынына авасын. Бер ашавың янга кала.

Авыр имән ишекне ачып вестибюльгә кергәч тә уңга борылсаң, беренче ишек Җәмиләләрнеке. Урамга караган бер тәрәзәле. Ул тәрәзәне дә фасадтагы юан ак колонналарның берсе каплап торганга, көн яктысы бик саран төшкән бүлмәнең түшәмендә иртәдән кичкә кадәр электр лампасы яна. Тарих-филология факультетының татар теле бүлегендә укучыларның бөтен гомере шунда үтә дип әйтерлек. Уку сәгатьләре беткәч тә бирсдән кеше өзелми. Эше булганы да, булмаганы да шушы җылы почмакка сыена. Студентларның сүз куешып очрашу урыннары да шушында, лекцияләргә генә сыеп бетмәгән фикерләрен дәвам иткән Җәләй аганы да, Рабига Афзаловнаны да, башка остазларны да шушында очратырга була. Рабига Афзаловна — көньяк хатын-кызларына хас калын кара кашлы, кара тут йөзле, гаиләсез, ялгыз хатын — кирәгеннән ешрак та була торгандыр әле. Бүлекнең житәкчесе һәм остаз булудан бигрәк, яшь, дәртле, туймас тамак студентлар янына күңел бушлыгыннан котылу, ялгыз җанына юаныч табу өчен дә киләдер кебек тоела ул миңа. Читтән караганда кырыс чырайлы, каты табигатьле булып күренгән бу ханымда аналарча кайгырту сизәләрме, студентлар хөрмәт итә үзен. Әле күптән түгел генә тулай торакка килеп тә безнең бүлмәдәге кызлар белән бик озак сөйләшеп утырган иде.

Җәмиләне шушы бүлмәдә очратырмын дип нык ышанып килгән идем. Чыннан да, анда кешеләр барлыгы ябык ишек аркылы да сизелеп тора. Берәүнең тоңык тавышы колакка керә, сүзләрен генә аерып булмый. Ишекне сак кына ача төшеп, ярыкка колагымны куям. Әхәт икән. Тынкышрак тавыш белән нәрсәдер укый. Урындык шыгырдап куйды. Кемдер тамак кырды. Кызыксынып, ишекне киңрәк ачтым да ярты гәүдәм белән эчкә тыгылдым. Әхәт артлы урындыкка атланып утырган. Кулында калын гына китап дип әйтимме, журналмы. Бүлмәдәгеләр егетнең һәр сүзен йотардай булып, тын да алмыйча тыңлыйлар.

— Мәхмүт Хөсәен иптәшкә нык өйрәнергә, тырышып эшләргә кирәк әле...

Нәрсә укый соң бу Әхәт? Нәрсәне шулай тын да алмыйча тыңлыйлар? Мәхмүт шигырьләренә язылган рецензияме? Кайда басылган? Кем язган? Минут эчендә башымнан шул сораулар үтеп китте.

— Ул ашыга, кабатлый, сюжетны эшләүгә игътибар итми...

Шулай авыз ачып тыңлап торганда, Җәмилә күреп алды да үз янына чакырды. Аяк очларыма гына басып буш урындыкка килеп утырдым.

— Вакыт-вакыт ялтыравыклы, ләкин буш сүзләр белән декламация сөйләргә тотына...

Җәмиләнең колагына пышылдап:

— Ул нәрсә укый? — дип сорадым.

— Ибрай Газиның яшь язучылар турындагы мәкаләсе. Пешергән, малай, үзегезне!

— Мәхмүт турында гына түгелмени?

— Ибраһим белән Сафа Сабиров хикәяләре турында да бар.

— Кайда басылган соң ул?

— “Совет әдәбияты”ның унберенче санында.

Пышылдауыбыз янибызда утырган Әхмәт Юнысның эчен пошырды.

— Тыңларга прусты ирек бирмисез, — дип, канәгатьсезлек күрсәткәч, Җәмилә белән күзгә-күз карап елмаешып алдык. Әхмәт Юнысның керпе кебек тырпайган җирән чәченә, кәефе кырылудан кызарып чыккан колак яфракларына каравы кызык булса да, Әхмәт авызыннан чыккан сүзләр сагайтып, игътибарымны тупларга мәҗбүр итте.

— Безнең кайбер яшь шагыйрь һәм шагыйрәләребез, күбесенчә, табигать турында, табигатьнең матур күренешләре турында йә исә шагыйрьнең үз эчке кичерешләре турында гына язалар. Ул шигырьләрнең чыганагы шагыйрьнең үз башыннан кичкән истәлекләр булу сәбәпле, шагыйрь күңеле өчен кадерле дә булалардыр, ләкин гадәттә андый шигырьләрнең социаль кыйммәте бик кечкенә була.

Авторның “шагыйрәләр” дип тә әйтүенә эчке бер сизенү белән тынычсызлануым юкка булмаган икән. Мәкалә авторы нәкъ миңа төбәп әйткән ул сүзләрен.

— Мәсәлән, Ләбибә Ихсанова иптәш үзенең “Зәңгәр чәчәк” исемле шигырендә яза:

Яшел хәтфә төсле яшел үлән
Арасыннан башын калкытып...

Бүлмәдәгеләр, әле син үзең дә мондамыни, дигән кебек миңа таба борылып караганда аяк буыннарым йомшап, битемне ут капкандай кайнарлык өтеп алган иде. Бик авырттырып, күкрәкне нәрсәдер кысты, тын алуы кыен булып китте. Җитмәсә, Җәмилә кабыргама төртеп утыра, әйтерсең, шатлыклы хәбәр ишеткән дә шуны минем белән уртаклашырга ашыга.

— Кайбер яшь шагыйрьләр, Ләбибә иптәш Ихсанова кебек, табигатьне, аның матурлыгын җырлау белән генә, берьяклылык белән генә мавыгып китәләр дә аларның шигырьләрендә гадәттә фикер дә, тирән тойгы да булмый.

Яратып язган шигырем иде ул “Зәңгәр чәчәк”. Мин аны әле дә әйбәт шигырь дип уйлый идем. Кадерле иде ул миңа. Шәрәф белән танышуга сәбәп булганы өчен генә түгел. Көмеш елга буенда йөргәндә бер аланга килеп чыктык без. Яр буйлатып бардык-бардык та, сазламыкка очрап, аны әйләнеп үтәргә булып, яр өстенә күтәрелдек. Куе таллыкны ерып ачык җиргә чыгуыбыз булды, күз алдыбызда гаҗәп манзара ачылып туктап калдык. Зәп-зәңгәр алан. Тоташ зәңгәр чәчәк. Орлыгын кулдан сибеп үстергәннәр дип әйтерсең. Күзгә күренмәс һава агымында сизелер-сизелмәс кенә чайкалып, кояш нурларында җемелдәгән тыныч диңгез өсте кебек күзнең явын алып утыра. Шул зәңгәр кыңгырауларның сихри чылтеравы дә ишетелмәдеме икән әле колагыма. Әгәр ул аланны камап торган агачлар кысасы булмаса, әгәр ул күз күреме җиргә кадәр үк сузылган булса, шушы зәңгәр матурлык чат аяз күк йөзе белән тоташыр иде дә кайда җир, ә кайда галәм икәнен дә аерып булмас иде.

Бу хозурга исе китеп карап торган мин генә түгел икән лә. Отряд башлыгы Пепин агай да хискә бирелеп:

— О! Божественная муза! — дип куйды.

Әйе, төсләр белән язылган моң, сүзсез җыр иде бу күренеш. Арабызда рәссам булса, һичшиксез, бер-ике этюд язмыйча түзә алмас иде.

Ул көнне юлыбызда йә сазламык, яки ерып чыга алмаслык куе таллык, аны ерып үттем инде дигәндә, су өстенә ишелеп төшәргә торган биек калкулыклар очрап кына торды. Аның шулай буласын кулыбыздагы карта бик ачык күрсәткән иде күрсәтүен, бу кадәренә үк очрарбыз дип кенә уйламаган идек. Әйләнеч юллардан йөреп бер чакрымны ике итсәк тә күңел төшенкелеген сизмәдек. Әллә инде теге зәңгәр аланның күз алдыннан китмәве сәбәп булды, әллә тагын шундый матур җирләр очравына ымсынып атладык, кичке ялга туктаганда, башка көннәрдәге

кебек, жиргә тәгәрәп китеп, аяк-кулларны ял иттереп алу турында уйламадык та.

Кайчагында бер дә көтелмәгән уйлар, йә берәр җыр исенә төшә дә, бәйләнчек чебен кебек, кусан да китмичә, көне буе күңелендә йөри. Алҗытып бетерә. Ул чагында да мин:

... Зәңгәр һава
Зәңгәрләтә дингезне.
Зәңгәр дингезләрдән эзлим
Бик сагынсам мин сезне, —

дип, күңелемнән озак кабатлап йөрдем. Бер ара кычкырып җырлап җибәрәсем дә килгән иде, иптәшләремнән оялдым. Ә бәлки тирә-юньдәге илаһи тынлыкны бозарга базмагандырмын. Шунысы гаҗәп, бераздан җырны башка сүзләр, үз күңелемдә туган, үз хисләремнең авазы булган, шуңа күрә бик тә кадерле сүзләр кысрыклый башлады. Минем аларны югалтасым, чәчеп-сибеп калдырасым килми, берсен икенчесенә тоташтырасым, бер мәгънәгә буйсындырасым, матурлыйсым, җанга ятышлы итәсем килде. Күңелемдә шигырь туа башлады. Кичке ялга туктар чакны түземсезлек белән көттем, шигыремне кәгазьгә күчереп, ләззәтләнеп эшлисе, кешегә күрсәтерлек хәлгә китерәсе сәгатьләрне көттем. Һәм менә ул вакыт килеп тә житте. Иптәшләрем учак ягып, макарон һәм консервыдан кичке аш әмәлләгән арада, бер читкә утырып үз эшемә тотындым.

Нарат агачына арка терәп, тез өстенә куйган дәфтәргә бер язып, аннан сызып, тагын язып байтак утырганмын, ахры. Кичке эңгер-меңгерне сизми калганмын.

— Караңгыда күзегезне бетерәсез, учак янынарак күчегез, —дип, отряд башлыгы яныма килеп басты.

— Зыян юк. Инде күчереп тә бетердем.

— Шигырь язасыз дип әйтимме?

— Әйе, о божественной музе, — дип, чытлыкланып, аның үз сүзләре белән җавап бирдем дә ирексездән мактанып куюымнан оялып киттем. — Шаярып әйтәм. Көндез күргән зәңгәр алан турында язып карамакчы булган идем.

— Бик дөрес эшлисез. Андый матурлыкның җырга әйләнми калуы мөмкин түгел.

— Кая инде миңа андый җыр язу!

— Мөмкин булса, укып күрсәтегез әле.

— Мин татарча гына язам шул.

— Бик әйбәт. Һәр халыкның үз теле, ул телнең үзенә генә хас моңы, матурлыгы була. Тыңлый белергә генә кирәк. Беломорканал төзелешендә бик күп милләт кешеләрен очраттым мин. Анда татарлар да бар иде. Араларында бик укымышлылары булды. Сөйләшеп утыруы рәхәт иде. Ә гомумән, эшчән халык ул —сезнең татарлар. Моңлы да. Җырларга яраталар. Сүзләрен аңламыйм, ә менә сагышлы көйләре күздән яшь китерә.

Шулай диде дә ул кичке шәфәкъ белән алсуланган нарат башларына карап тынып калды. Кара төк баскан ябык йөзенә әллә кичке күләгә төшкән иде, әллә инде авыр истәлекләрдән тагын да караңгыланып китте. Ул кинәт картаеп, кечерәеп калган кебек тоелды миңа.

Әй, Пепин агай, Пепин агай! Саф күңелле кеше шул сез, нечкә күңелле. Таулы-ташлы җирләрдә, су буйларында эшләп гомерегез үткәнгә сизгер җанлы булгансыздыр. Утыз җиденче елның гарасаты да читләтеп үтмәгән икән бит үзегезне. Табигать гармониясенә, далалар иркенлегенә күнеккән җаныгызга ай-һай кысан булгандыр анда. Шулай да урман шавының телен, чишмәләр җырының серен онытмагансыз. Ул кичтә, учак янында, табигать матурлыгы турында дулкынланып сөйләвегез әле дә исемдә. Шул вакытта яттан бик күп шигырьләр укыдыгыз.

Что ты клонишь над водами,
Ива, макушку свою?
И дрожащими листами,
Словно жадными устами,
Ловишь беглую струю...

Тютчевның шушы шигырен үзебез яшел чирәмле ярында ял итеп утырган Көмеш елга турында язылган кебек итеп тыңладык бит.

Менә шундый хозурлыкны башкалар белән дә бүлешәсем килгән өчен хәзер нинди сүзләр ишетеп утыруымны белсәгез икән, Пепин агай!

Ибрай Гази табигать матурлыгын язу беркемгә дә кирәкми дип әйтә. "Алар битараф шигырьләр, ләкин алар, күбәеп китсәләр, зарарлы шигырьгә әйләнәләр. Укучыны чын тормыштан читкә өстериләр, пассивлыкка, битарафлыкка алып китәләр" икән бит. Бу сүзләрне ул Жданов докладыннан күчереп алган дип әйтерсең. Анда да бит "Анна Ахматова шигырьләре яшьләрне боеклык һәм үз эшенә ышанмау рухында тәрбияли" дип әйтелгән иде.

Әллә нинди ел булды ла бу! Октябрь башында Казан Кремлендә узган зур җыелышның шаукымы әле дә бара кебек. Кайсы гына газетны алма, нинди генә журналны ачма, ачы тәнкыйть мәкаләсенә очрамый калмыйсың. Әйтерсең лә, безнең язучылар Мәскәүдән фәрман гына көтеп торганнар. Шул фәрман Жданов докладу сыйфатында килеп җитүгә, берсеннән-берсе уздырып уяулык күрсәтергә тотынганнар. "Совет әдәбияты"ның соңгы ике-өч санында гына да Әхмәт Юныс белән Әхмәт Фәйзине дә, Сәхаб Урайский белән Таҗи Гыйззәтне дә "тешләгән" усал-усал мәкаләләр басылган иде. Инде менә яшьләргә дә чират җиткән икән. Үземә кагылган җире дә булгач, "Яшь язучылар, аларның иҗатлары һәм бурычлары" дигән мәкалә канатларымны каергандай итте.

Мин бит әле юлның башында гына, шигырь язам дип йөрүем, бәлки, язучылар тирәсендә чуалуымның тәэсире генәдер. Менә укып бетерермен, эшкә китәрмен, шигырь язуым да яшьлек мавыгуы гына булып калыр. Шушы вакытларны күңелле итеп искә алып сөйләрмен. Ә менә гомерләрен әдәбиятка багышлаган кешеләргә бик авырдыр бу көннәрдә. Шәрәфтән беләм. Шагыйрьләр секциясе үткән көннәрдән соң күзгә күренми йөри. Ялгыш очрашып куйсак, чытык йөзен күрәм. Сүзенең рәтен тапмыйм, үпкәләшеп аерылышабыз. Бер көнне секциядә аның шигырьләрен тикшергәннәр. Тәнкыйтьчеләрдән берәү, дәлиле саллырак булсын диптер инде, "иптәш Батыев шулай әйткән" дип, ул вакыттагы партия өлкә комитетының культура бүлеге башлыгы сүзләрен искә ала. Шәрәф кызу канлы, теленә килгәнне йотып җибәрә белми, ул вакытта да:

— Батыйлар килер дә китәр, Мөдәррисләр калыр, — дип кычкырган.

Сөйләшү каты булгандыр шул, юкса алай ук тузынмас иде. Партия җитәкчеләренә тел озайтуның арты яман икәнен белә бит. Секциядәге кайберәүләрнең шул сүзләрне тынлап утырулары өчен генә дә котлары очкандыр әле.

Ә мин "Совет Әдәбияты"ның теге санын табып, Ибрай Гази мәкаләсен баштанаяк укып чыктым. Газет-журналларда исемнәре күренә башлаган күп кенә яшь язучыларның иҗатына анализ ясаган. Бер карасаң, дөрес тә әйткән кебек үзе. Дәлилләре дә ышандыра сыман. Ул бит тәҗрибәле, олы язучы. Университеттагы әдәби түгәрәккә килгәндә дә шундыйрак сүзләр сөйли иде бит ул безгә. Ләкин анда кара-каршы бәхәсләшергә, тарткалашырга, үз фикереңне якларга була. Хәзер менә йөр инде дөреслекне эзләп. Ни генә уйласам да, ничек кенә ышанырга тырышсам да, аның табигать турындагы фикерләрен аңлый да, яклый да алмадым. Үземә кагылганы өчен генә түгелме, дип тә уйлыйм. Өлкән язучының абруйлы сүзенә ышанасы да килә. Ләкин колак төбендә кемдер берәү үҗәтләнеп "алай түгел, алай түгел" дип пышылдап тора сыман. Шулай зарарлы

булгач, классикларның табигать турындагы шигырьләре ничек безнең заманнарга хәтле килеп җиткән соң? Тукайның "Галибанә яктырып ал таң ата" дип башланган шигыреннән кайсы бала зыян күргән?

Алар шул классиклар. Алар яза белгән. Бөтен хикмәт минем үземдә. Шагыйрь булам дип йөреп тә бернәрсә дә чыгара алмавымда. Ибрай Газины да әйтер идем, нигә шулай дип туп-туры язмаска инде. Бөтенесе дә аңлашылыр иде. Башта авыр булыр иде, кызлар алдында оят булыр иде. "Автор тәҗрибәсез, әдәби зәвыгы юк, аңа әле өйрәнергә дә өйрәнергә кирәк" дип әйтсә дә, түзәр идем. "Сүнмәс утлар булмас әле, сүнәр әле бер вакыт" дип җырлыйлар бит...

## Ике аккош күлләрдә

Яз башларында әти белән әнинең фатихасын сорап авылга хат яздык та, көннәрне генә түгел, сәгатьләрне-минутларны санап дигәндәй, җавап көтә башладык. Миннән бигрәк тәкатьсез булып Шәрәф көтә. Сүзсезләнде, яңаклары суырылып калгандай булды, авызыннан тәмәкесен төшерми.

— Берәр районга командировкага барып кайт, вакытың тиз үтәр, — дим, аны кызганып.

— Командировка кайгысы түгел әле, — ди ул, кулын селтәп.

Каникулга кайткан чакларымдагы сүзләреннән, язган хатларыннан әнинең тел төбен бераз белгәнгә, мин алай ук борчылмыйм. Әти дә, әни дә теләгебезгә каршы килмәсләр кебек. Ләкин минем дә тынычлыгым югалды, төн йокыларымны йокламыйча уйланып ятам. Күңелгә әллә нинди уйлар килә. Алдагы язмышымның билгесезлеге пошындыра да, кызыктырып, ымсындырып та тора. Су коенырга килгән кызның, чиркангчык алудан куркып, яр буенда басып торганы кебек. Сикереп төшеп чумасы, колач салып йөзеп китәсе дә килә, шул ук вакытта нәрсәдер тота, басып торган урыныннан кузгалырга ирек бирми.

Бөтен тормышың, өйрәнгән гадәтләрең, корган планнарың үзгәрү дигән сүз бит бу. Кыз чагындагы бәйсезлегеңне югалту, яшьлегең белән хушлашу дигән сүз. Әле мин үземә үзем хуҗа, теләгән җиремә теләсә кайчан бара алам, уйлаганымны эшлим, күңелем кушканнар белән дуслашам, җаным теләмәгәннәрдән ерак йөрим. Хәзер менә шуларның барысын сызып ташларга да аның тормышы белән яшәргә, аның кәефенә яраклашырга, аның теләге белән хисаплашырга туры киләчәк. Ни өчендер, тормышның матди ягы турында уйланылмады. Әллә инде дөньяның кырыслыгы чыныктырган, куркытмый. Икәү бергә булгач, студент тормышыннан да авыррак булмас әле дигән инстинктив тойгы көчле булдымы әллә, белмәссең. Ул турыда элегрәк сүз чыкканда да уенга борып җибәрә идем. Бервакыт, сүз иярә сүз китеп Шәрәф:

— Әгәр гаиләм булса, җирдә күтәреп яткан кадакны да өйгә алып кайтыр идем, — диде.

Ә мин шаркылдап көлдем дә:

— Борын заманның рыцарьлары сөйгәненең аяк астына бөтен бер дөньяны китереп салган, аннан соңгыраклары ярты дәүләтен бирерлек булган. Хәзерге заман егетләре күтәргән кадак белән кызыктыралармы? — дидем.

— Елына күрә жылы шурпа инде, — диде ул, аптырап тормады. — Оҗмах вәгъдә итә алмыйм шул. Гап-гади, хыянәтсез, гөнаһсыз тормыш төзи алуыма ышанам. Оҗмахтан күңеллерәк булыр, борчылма.

Шундый борчулар белән хат көтеп йөргән көннәрдә Казанга әни үзе килеп төшмәсенме! Озакка түгел, мәктәптә укулар вакыты бит. Якшәмбегә туры китереп, көнен килеп, көнен китәргә планлаштырган. Әни, Шәрәф, мин — өчәү Горький урамындагы Кекин йорты ашханәсенә кереп утырдык. Кияү буласы кеше сынатмаган, өстәл тулы ризык. Тик без беребез дә аш-суга кагылмадык. Әни белән Шәрәф гомерлек танышлар

кебек тыныч кына сөйләшәләр. Кайбер мизгелләрдә мин аларны суд тикшерүчесе белән гаепләнүчегә охшатам. Әни бер дә көтелмәгән сораулар бирә, ә Шәрәф, ничек әйтсәм ялгышмам икән дигәндәй, уйланып кына җавап кайтара. Андый чакта түбән иелгән башымны күтәреп әнигә карыйм, күз карашым белән "җитәр инде, әни, артык төпченмә" дигәнне аңлатмак булам. Кая ул!

Озатканда, поездга кереп утырыр алдыннан, "тартып килим әле" дип, Шәрәф безнең яннан китеп торды. Шул арада әни башымны күкрәгенә кысып аркамнан сөйде дә:

— Язучы — әшәке кеше булмас. Яратсаң чык, кызым. Әтиең дә шулай дип әйтергә кушты, — диде. Үзенең күзендә яшь. —Менә җәй көне, укуың беткәч, бергәләп авылга кайтырсыз. Матур итеп туй ясарбыз.

Минем дә елыйсым килә. Шулай да үзем үскән җылы оядан, туганнарымнан, ел да кайтып йөргән авылымнан аерылуыма ышанмыйм, йөрәгем кабул итми. Бөтенесе дә болай гынадыр, миңа кагылмыйдыр, менә әни утырып китәр дә барысы да элеккечә калыр кебек.

Шул арада ниндидер төргәкләр тотып янибызга Шәрәф килеп басты.

— Әтигә әзрәк кучтәнәч алдым әле, — диде ул, кулындагы әйберләргә күрсәтеп.

Инде бөтенесе дә хәл кылынгандай итеп, "әти" дип әйтүе мине чынбарлыкка кайтарды.

Әни китте...

Бераздан без дә Зәйнәп исемле укытучы хатынның подвалдагы бер бүлмәле фатирында ишек төбеннән почмак алып яши башладык. Әни, киткәндә, әти ягыннан туган тиешле Хәят апаларда бер чемодан калдыруын әйткән иде. Икәүләп шуны барып алдык. Кияүгә чыгасы кыз балага кирәк булган барлык нәрсәне таптым мин анда: урын җәймәләре, мендәр тышлары, карават кашагасы, сөлге-тастымаллар... Әнинең бу нәрсәләрне еллар буе, әкрен-әкрен әзерләп, сандыкка сала барганын сизенә идем. Үзем шуның бервакыт кирәк булырын төшенмим, әнинең, укытучы кешенең, шулай юк-бар белән шөгыльләнүеннән эчтән генә көлеп тә йөрим. Хәзер менә шуларны карап утырганда гына аңладым мин әниемне. Минем өчен иң гаҗәбе тагын шул булды: бу авыр елларда ничек саклап калган ул аларны? Әле соңгы кайтуымда гына да өйдәге затлырак әйберләрнең азык-төлеккә алышынып беткәнен күреп килгән идем бит. И әни, әни... Ничекләр кайтарып бетерермен икән бу кадәр яхшылыкларыңны?!

Ата-ана фатихасы булгандыр шул, кеше ишек төбендә булса да бик матур яшәп киттек. Безнең дуслыкка Зәйнәп апаның үз карашы бар: "Минем әни әйтә торган иде" "ир кеше татлы дошман ул, ике бөтен ипиең булса, берсен куйныңа яшер" дип әйтә торган иде", — ди. Олы кеше булса да, аның сүзләренә ышанасым килми. Үзең теләп, яратып чыккан кеше дошман була димени? Яратмаса, ул да минем белән кушылмас иде, малай-шалай түгел. Яше дә мәхәббәт уены уйнаудан узган. Зәйнәп апа үзе үк әйтеп тора бит: "Шәрәф бер чиләк су да алып керми иде, син килгәч йөгереп кенә йөри", — ди. Дошман кеше шулай була димени?

Мин үзем дә сәер бер үзгәреш сизәм. Йөгерә-йөгерә кайтып мичкә ягып җибәрү, Шәрәф белән бергә утырып ашыйсы кичке ашны әзерләү көтеп алган күңелле мәшәкать миңа. Элегрәк, лекциядән чыктыммы, йә кинога, йә матбугат йортына, бер дә булмаса китапханәнең уку залына кереп утыра идем. Караңгы төшмичә тулай торакка кайту искә дә керми. Хәзер менә шушы салкын һәм караңгы бүлмәгә дә кайтасы гына килеп тора. Югыйсә, Шәрәф тә әле редакциядә, Зәйнәп апа да кичсез өйдә булмый.

Баштагы шикләнүләрем, икеләнүләрем дә онытылды. Әле кайчан гына ирегемне югалтам дип кайгырып йөргән кеше бу төшенчәнең берәр максатың булганда гына кадерле икәнен аңлады. Изге максатсыз ирек

мәгънәсез, кирәкмәгән буш нәрсә икән ул. Мин ирекле, мин жаным теләгәнне эшли алам, дип, үзең дә сизмичә, тайгак юлга кереп китүең, хыянәткә, җинаятькә дә тартылуың бар, аллам сакласын! Болай гына башка килгән уй инде монысы. Хәзер ул мине борчымый, инде жан тынычлыгымны таптым. Ышанычлы кешемнең канаты астында яшәвемне тою белән бәхетле мин.

Шулай бер көнне бәрәнге әрчеп утыра идем, ят бер кеше килеп керде. Өстендә куксел төстәге язгы-көзге пальто, башында бүрек. Озын гына буйлы, сөйкемле кеше. Борыныннан һава өреп чыгарган кебек йомшак тавыш белән көлеп куйды да:

— Яшь киленне күрергә килдем. Шәрәф үзе таныштыра белмәде. Хатип Госман булам мин, — диде.

Өстемдә Шәрәфнең таушалган кара кителе, аягымда анын олы киез итеге иде. Шушы кыяфәтемдә ят кешене каршы алуыма уңайсызландым, югалып калдым, ни әйтергә белмичә торганнан соң кабаланып, аңа урындык тәкъдим иттем.

— Утырыгыз, Хатип абый.

Ул башымнан аягыма кадәр сынап караган кебек булгач, тәмам коелып төштем. Эчемнән: "Ат базарындагы чегән кебек, авызымны ачып тешемне генә санымйсың калды инде!" — дип уйладым.

— Шәрәфне әйтәм әле, "гомеремдә өйләнәсем юк" дигән кеше, нинди сөйкемле кызны каптырган.

— Балык түгел лә мин... кабарга.

— Кызлар алар балыктан да шома. Кулга керде дигәндә генә шуалар да төшәләр.

Аның шулай беренче күргәндә ук тәкәллефсез кылануы ошамады миңа. Шәрәф белән дус булгач та... Мине белми бит әле ул. Бала-чага белән сөйләшкән кук утыра. Күрешкәннән бирле күңелемдә җыела килгән ризасызлыгым, ниһаять, кыюлык бирдеме, бу юлы мин дә аптырап тормадым:

— Сез күпне күргән кешедер. Тәҗрибәгез дә бардыр. Беләсездер, — дип әйтергә батырчылык иттем.

— Тәҗрибә кая инде ул? Бер кылчыклы балык эләкте шунда.

Мин җавап кайтарып тормадым. Ул да җитди төс алды.

— Син ачуланма инде, шаярып кына сөйләшүем. Мин сезне кунакка чакырырга кергән идем бит әле. Кичке җиделәргә котәбез.

— Рәхмәт. Кайткач, Шәрәфкә әйтермен, — дидем, салкын гына.

Бу кешене Шәрәф сөйләве буенча әйбәт белә дип уйлый идем. Күп яхшылыклар эшләгән ул яшь шагыйрьгә. Педагогия институтында аларга чит ил әдәбиятын укыткан. Шул вакытта ук шигырьләр язучы егеткә игътибар иткән. Сугышта икесе бер ук фронтта булсалар да, берберләрен белешмәгәннәр. Соңыннан Хатип абыйны фронт газетына эшкә алганнар, ә редакциягә минометчы Шәрәф Мөдәррис шигырьләр җибәреп ята икән. Хатип абый, билгеле, аны редакциягә кайтару чарасын күргән. Кыр почтасы номеры белән үзе барып, алгы сызыктан, ут эченнән эзләп тапкан. Шуннан башлап алар гел бергә булганнар.

"За родину" газетының редакциясе дә, типографиясе дә Валдай урманы наратлыгына ышыкланып торган. Соңыннан фронт алга барган саен, кучә-кучә, зур шәһәрләрдә дә яши башлаганнар. Ә башта бу газетның казакъчасы да, татарчасы да, үзбәкчәсе дә, литва телендә чыга торганы да шунда бер поездда булган.

— Кайчагында командировкадан кайтып керәсең, эт булып арылган, бүре булып ачыккан чагың. Җитмәсә шунда ук утырып иртәнге санга материал эшләргә кирәк. Ә купеда — пәри туе. Кайсы язу машинкасын шыкылдата, кайсы нәрсәдер эшли, алла белсен, — дип сөйләгән иде бер кичтә Шәрәф — Бервакыт Хатип белән чүт сугышмый калдык. Тик торганда сикереп торды да бу, теше сызлаган кеше кебек, ишекле-түрле

*Борис Изакович Исбах — урыс язучысы, галим.

йөри башлады. "Ай, Марфам, ай Марсым!" Бик сагынса, йөрәген шулай баса торган гадәте бар аның. Без моңа иялэнеп беткән идек инде. Шулай да ачу килә. Театр уйнауның кемгә кирәге бар? Безнең кайсыбыз сагынмый да, кемнең йөрәге янмый. Беребез дә каравыл кычкырмыйбыз. Үземне кая куярга белми йөргән көннәрем иде. "Җитәр сиңа! Шыңшыма. Колакны тондырып бетердең", — дип акырдым. "Син нәрсә беләсең соң, молокосос! Менә өйлән әле, балаларың булсын..." "Син дуракның өйләнгәне дә җитәр! Хатын-кызның янына да барасым юк..." "Ялынырлар дип беләсеңме?" Үтерде шул сүзе белән. Авырткан җиремә кагылды. Ботарлады. Сикереп торуымны сизми дә калдым. Шак итеп өстәге урынга башым бәрелде, күземнән утлар чәчрәде. Өстә Әхмәди йоклап ята иде, ул сикереп торды...

Шәрәф исенә, аңына килгәнче Хатип абый купедан чыгып сызган. Егетнең дуамаллыгын белгәндер, арттырып җибәрүен дә шәйләгәндер.

Кичкә таба, берни булмагандай кайтып керә ул. Беркемгә берни әйтмичә, биштәрендә актарына башлый. Хәер, кемгә сүз катсын. Шәрәф, тәмәке төтененә күмелеп эшләп утыра, Әхмәди әле булса йокы симертә, Сагынгали каядыр чыгып киткән.

— Бирергә онытканмын, Борис Изакович* сиңа күчтәнәч җибәрде, — дип, берәздән Шәрәфкә тәмәке пачкасы суза.

Бу тәмәкенең биштәрдән чыгып кесәгә кергәнен егетнең яшертен генә карап торуын сизми кала ул.

— Күчтәнәчкә каршы күчтәнәч булсын, бу шикәрне Исбахка бирерсең, — дип, Шәрәф тә кичә алган паегын Хатип янына куя.

— Алган шикәрләрен җыеп Казанга җибәргәли иде. Шул көннән соң мин аңа үземнекен дә бирә башладым. Ә аннан "Исбах күчтәнәчләрен" алып тордым. Рәхәтләндем тәмәкегә, —дип сөйләгән иде Шәрәф, тулай торак бүлмәсендә икәүдән-икәү генә сөйләшеп утырганда.

— Шикәр урынына тәмәке суыргансың икән, — дип көлгән идем шул чагында.

Озакламый, бер кочак газет күтәреп, Шәрәф кайтып керде. Ул юынган арада өстәл әзерләп өлгердем. Ит белән томалап пешергән бәрәңгене өлеш тәлинкәләренә салдым, куе итеп чәй ясадым. Өйгә ямь кереп китте. Хатип абый артыннан калган аңлашылмаучылык эреп югалгандай булды, онытылды.

— Хатип Госман кереп чыкты, — дидем, өстәл янына утырышкач, күршедән кергән кеше турында гына әйткәндәй итеп. — Безне кунакка чакырды.

— Кайчанга?

— Бүген, сәгать җиделәргә диде.

— Җиденче киткән бит инде, — диде Шәрәф, сәгатенә карап. — Кунакка барасы булгач, ни эшләп утырабыз соң? Әйдә, җыен.

— Туйга барсаң, туеп бар, диләр бит.

— Хатиплар үз кеше, гаеп итмиләр.

— Ошамады ул миңа. Барасым да килми.

— Барабы-ыз!

— Беренче күргән кешегә хатынын яманлый башлады.

— Марфанымы? Уйнап кына әйткәндер. Алар хәтле матур торган...

— Аның хатыны маржамыни?

— Керәшен кызы. Чаллыныкы.

— Эшлиме соң ул?

— Укытучылар институты бетергән. Әлегә эшләми. Хатип укыта бит, үзе аспирантурада укый да. Балалары да бар.

— Ни өчен ул сине, гомердә дә өйләнмәскә ант итте, дип әйтте?

— Аны озак сөйләргә кирәк. Бер сөйләрмен әле, йә, барабызмы-юкмы?

Минем ничек тә вакытны уздырып, бармый калу ягын каеруым иде. Бердән, Хатип абыйдан соң калган сәер тойгы янарды, икенчедән,

шушы жылы почмагыбызда, Зәйнәп апа да өйдә юк чакта, Шәрәфкә ошасын дип тырышып пешергән аш янында икәүдән-икәү генә сөйләшеп утырыр сәгатьләрне көтеп алам бит мин.

— Сөйлә инд-е-е, — дидем, балаларча ялынган кебек итеп.

— Ярый. Кыскасы шул. Педагогия институтында укыганда бер кыз белән яратышып йөрдек дип сөйләгән идем бит. Көтәргә вәгъдә бирсә дә, сүзендә тормады. Кияүгә чыктым дип хаты килде. Мине беләсең, дуамаллыкны. Язган хатларын, аңа багышланган шигырьләремне җыеп яндырдым да көлен Валдай туфрагына сиптем. Һич югы, үләннәргә азык булсын дип. Шул чагында "гомерем булып, сугыштан исән кайтсам, бер кызга да карамам" дигән идем. Антымны син боздырдың.

— Сине институттан чыгарганда берүзе яклаган кызмы ул?

— Шул инде. Ул чагында курыкмаган иде.

Шул мизгелдә мин Шәрәфнең күзләрендә Валдай учагының сүнеп бетмәгән очкынын күргән кебек булдым. Яшь кешенең, өйләнмәгән егетнең мәхәббәт шигырьләре бик аз булуына сәерсенеп йөри идем. "Әллә йөрәге ташмы икән, бер дә җылы хисләре юкмы икәнни?" — дип уйлаган чакларым булды. Андый тирән яралар тиз генә төзәлми икән шул, йомылса да эзе кала. Хәсрәт белән үткән көннәрне искә төшереп, гомер буена кызыл җөй булып тора. Шәрәф күзендәге сагышны күргәч, тыныч калдым дип әйтә алмыйм. Үтеп киткән давылның сүнә барган хәлсез җиле күзгә ком сипкәндәй итте. Ни генә дисәң дә, мин аның бердәнбере түгел шул инде. Әмма вакыты житкәч, учак урынына да үлән үсә бит. Безнең гаилә көлдән яралган феникс кошы кебек. Ә яшь үлән һәм кояшлы җирдә бәхет булмый калмый, тик менә шигырьләре кызганыч.

## Тирән сулар тын агалар

Ниһаять, Шәрәфнең "Җыр үткән юл" дигән китабы басылып чыкты. Уч төбенә сыярлык кечкенә форматлы, аксыл тышлы китапны ни ашкынып көткән идек. Мин тиз генә эчтәлегенә күз йөртеп чыктым. Бар, "Рәмзия" дигән шигырь дә бар. Үз исеме белән чыкса, куанычы тагын да күбрәк булыр иде дә, "ярамый" диләр бит. Шәйхи абый сүзендә торган. "Исемен алыштырганнан шигырьнең исеме үзгәрми", — дип, редактор буларак китапка кул куюдан баш тарткан. Шуннан соң кульязманы Әхмәт Исхакка биргәннәр, китап "Редакторы Әхмәт Исхак" дигән сүзләр белән басылып чыккан. Хәзер шигырьне "Мин" диеп, үз шәхесеңне белдереп язуны да яратмыйлар. "Без" кирәк. "Без". Бөтен халык фикере булсын. Газетлар да лирик шигырьләргә караганда публицистиканы күбрәк басалар. Шәрәфкә атна саен дип әйтерлек шундый бер шигырь язарга туры килә. Газетта эшләгәч, бүлек башлыгы Мөсәгыйть кушып кына тора. Летучкада бүлекне мактыйлар. Мөсәгыйтьнең күкрәк киерелгән. Хәзер мин аны таныйм инде. Кырык алтының көзендә, Министрлар Советы бинасында булган зур җыелышта иң хәтәр сөйләүчеләрнең берсе шул иде бит.

Бик яхшы күреп, сизеп торам: газетта эшләү дә, заказ шигырьләр язу да Шәрәфкә шатлык китерми. Аның "Идел-Сылу" дигән дастан язасы килә, чибәр болгар кызы турында башлап куйган поэмасы бар. Ләкин ул аларга тотына алмый. Язылса да, басмаслар дип уйлый. Партия өлкә комитетының "Идегәй" эпосы турында карары чыккач һәм Нәкый Исәнбәт либреттосы буенча куелган "Түләк" операсы сәхнәдән алынгач, борынгы тарихны хәтерләткән һәрнәрсәгә, хәтта шигырь калыбына да шикләнеп караучылар күбәеп китте. Шәрәфкә дә "көнчыгыш поэзиясенә тартым озын юллар белән яза" дип тел тидерүчеләр бар. Эчтәлеге заманча булганга күрә генә ачыктан-ачык бәйләнә алмыйлар. Ә шәрекъ стиле — Шәрәфнең яраткан алымы. "Күкрәкне тутырып тын алган кебек булам, борынгы Иделнең ярларына тулып аккан көмеш суын, кыпчак далаларының

карап күзең җитмәс киңлеген тойгандай булам бу алым белән язганда", — ди ул. "Үлемсезлек" поэмасын да унике-уникеле иҗек белән эшләп утыра.

Ни генә булмасын, гомер елгасы ага да ага. Мин хәзер университетка йөрмим. Биш еллык студент гомере, ачлы-туклы яшәп тә уен-көлкедән арынмаган, юк хәсрәтне бар итеп бәләкәй генә куанычларны да тау итеп, хыял диңгезендә бата-калка йөзгән елларны артта калдырып, диплом язарга таралыштык. Минем темам — "Юрмыч бассейнының геоморфологик үзенчәлеге". Сәяхәтләр көндәлеген карап утырганда Урал буенда йөргән көннәр кабат искә төшеп, мине тагын Көмеш елга ярларына алып килде. Бер кечкенә повесть язарга хыялланып та һаман тотына алмавыма эчем пошып куйды. Соңгы вакытта Шәрәф тә җанга тия:

— Кияүгә чыккач иҗатын ташлаган хатыннар бездә болай да бар. Син дә шулар күк булма инде. Яз! — ди.

Бер көнне балалар өчен иң яхшы әсәрләргә конкурс игълан ителүен кайтып әйтте.

— Синең темаң кызыклы. Материалың яңа, тапталмаган. Көчеңне сынап кара, — дигәч, миндә язучылык шаукымы кузгалып китте.

Өйдә көнозын бер үзем. Бер төркем мәктәп балаларын алып, Зәйнәп апа Мәскәүгә китте. Язгы каникул вакытында башкаланы күрсәтеп кайтырга. Ул яшәгән якның өстәлен зурайтып куйдым да бер башына Юрмыч елгасыннан алып кайткан сызымнарны, диаграммаларны, язмаларны җәеп салдым. Икенче башында "Көмеш елга" көндәлекләре. Иртән Шәрәфне эшкә озатам да өстәл каршына килеп басам: кайсына тотыныйм икән? Йөрәгем, билгеле, соңгысы ягында. Ә акыл әйтә: "Зәйнәп апаң Мәскәүгә гомергә китмәгән, санаулы көннәр тиз үтә, ул кайтканчы, шушы зур өстәл өстендә һич югы сызымнарыңны сызып куй, язуын үз ягыңдагы бәләкәй өстәлдә дә язарсың, диплом яклау көннәрең борын төбендә бит", — ди.

Айба, Юрмыч, Серебрянка елгалары моннан күп гасырлар элек Дон казагы атаман Ермак атлары таптап үткән татар җирләреннән аккан. Биредә атлар кешнәп күкрәккә күкрәк килгән, уклар сызгырган, ачы төтен бөркеп мылтыклар аткан, хисапсыз кан коелган. Бер көнне елга буенда ял итеп утырганда, күп мәгълүматлы Пепин агай шул замандагы фаҗиганың бер мисалы итеп гыйбрәтле риваять сөйләгән иде.

— Менә хәзер без утырып торган җирдән көньяк-көнчыгышка карап китсәң, түбәсендә ак әремнәр генә үсеп утырган калкулыкка юлыгасың, — дип башлады ул сүзен.

Караңгы чырайлы чыршы, нарат агачлары башыннан шул тауны шәйләгәндәй, барыбыз да ул күрсәткән якка борылып карадык. Инде урман артына төшә башлаган кояшның алтынсыман шәүләсе зәңгәрлегән җуйган күк йөзендә, рәссам пумаласыннан төшкән сары тап кебек, кичке сәгатьләргә серлелек катыш моңсулык биреп тора. Без дәшми генә җитәкчебезнең хикәятен тыңларга җыендык.

— Руслар аны Лысая гора дип йөртәләр, — дип сүзен дәвам итте Пепин агай, учакка чыбык-чабык ташлап, ялкынланып янып китүен көтеп торды да тузанлы учларын бер-берсенә ышкып алды. — Җирле халык Сөзгә тау дип әйтә. Моннан бик күп еллар элек тау башында имәннәр шаулаган, киек кошлар оя ясаган, аю, төлке, бүре ауга йөргән. Ә калкулыкның иң биек җирендә аз санлы гаскәре, хатыннары, балачагалары белән яшәп яткан татар ханының кальгасы булган. Җәен-кышын төрле яктан килгән сәүдәгәрләр белән гөрләп торган ул җир. Су юллары белән Бохара сәүдәгәрләре килгән, кара урманнар аша Болгар осталары юл сапкан. Алар олау-олау мал китергәннәр. Шуның бәрабәренә кеш тиреләре, эрбет чикләвеге, кисмәк-кисмәк бал, тайга урманының башка байлыкларын төяп киткәннәр. Шулай матур гына аралашып яшәгәндә сәүдәгәрләрнең бу якларга таба юлы киселә. Россиянең Себер җирләрен яулап алу еллары башлана. Үз мәшәкатьләре белән бер төрле яшәп яткан

авыллар-шәһәрләр берәм-берәм ятлар кулына керә бара. Озакламый тау башындагы кальгага да чират житә. Көннәрдән бер көнне дошман аны камап ала. Кара яу булып килгән чиругә каршы тора алмый Күчүм хан. Дошманда утлы корал бит, ә анда бары тик уклар гына. Мәргәннәр төз аталар атуын, соңгы чиктә дә бирешмәсләр. Ләкин соңгы чик дигәне яман булыр. Андый хикмәтләрне ишетеп тә, күреп тә беләләр инде камалудагылар.

Менә бервакыт хан янына кече хатыны Сөзгә килә.

— Ханым-солтаным, тыңлар булсаң, сиңа киңәшем бар, — ди ул. — Яшерен юлдан халкыңны алып чык. Гаскәрнең беразы белән мин калып торыйм. Дошман күзен буар өчен. Үзеңнән хәбәр килүгә без дә сиңа кушылырбыз.

Күчүм бу хатынын яшьлеге, чибәрлеге өчен генә түгел, акылы, тапкырлыгына күрә дә барысыннан да артык ярата икән. Бу юлы да Сөзгәнең киңәше ошый аңа, ләкин жанын-тәнең белән сөйгән кешене ничекләр итеп дошман камалышында калдырмак кирәк? Бик озак уйлана морза, озак икеләнә, әмма хатыны киңәшеннән башка чара таба алмый. Кальгадагы барча халыкның олысын-кечесен алып, яшерен юллардан үтеп, Иртеш буена чыга һәм елганың түбән агымындагы остяк кабиләсенә таба китә.

Сөзгә белән калган аз санлы гаскәр, ни тырышса да, көчле дошманга каршы тора алмый. Ханнан чапкын килеп житәргә өлгерми, урыслар кальганы басып алалар. Батыр йөрәкле ханбикәне гаскәре белән бергә әсир итәләр. Менә шул чакны, үкенечкәме-бәхеткәме, әле мыек та чыгып өлгермәгән яшь бер казак, үләр дәрәжәгә житеп, чибәр ханбикәгә гашыйк була.

— Аллаһы тәгаләнең әмере шулай икән, берни эшләр хәл юк. Мин сиңа буйсынам, егет. Тик бер шартым бар, — дигән аңа Сөзгә.

Мәхәббәттән күзе тонган егет хатын ни әйтсә шуны эшләргә риза икән.

— Боер гына, барысын да үтим, — дигән.

— Гаскәремне азат итеп кальгадан озат. Шуннан соң мин синеке булырмын.

Гашыйк егет яшь, чибәр, гайрәтле булу өстенә хәйләдән, тапкырлыктан да мәхрүм калмаган. Күк йөзен кара болыт баскан караңгы төндә Сөзгә гаскәренең барлык сугышчысын кальгадан чыгарып жибәрә ул. Әмма моны адәми затлар түгел, киек-жәнлекләр дә сизми кала. Һәм егет татлы хыялдан исереп, сөйгәне янына ашыга.

Бу минутларда ханбикә ботакларында кошлар йоклаган юкә агачы төбендә ачы күз яшьләре белән елап утыра икән. Елга булып аккан тозлы күз яшеннән саргаеп үләннәр кибә, агачлар корый. Әле генә урман шаулап үскән тау башы пеләшләнеп кала. Казакмы? Йөгереп килеп житкәндә үткен хәнжәрен йөрәгенә кадаган ханбикәнең салкын гәүдәсен генә күрә ул...

Экспедициядән алып кайткан язмаларны карап утырганда шул риваять искә төште дә моңа кадәр кулны тотып торган әчке пружина ычкынып киткәндәй булды. Диплом эшен ничек башларга белмичә аптырап йөри идем. Кулыма серле бинаның ачкычын бирделәрмени! Әйе, менә шул риваятьтән башлап китсәм, фикеремне соңгы сугышның афәтләренә китереп ялгасам, вак елгаларның көчен барлау мәшәкатен акларга юл ачыла түгелме соң?

Язмамның кереш өлешен Шәрәфкә укып күрсәткәч, аңа да ошады.

— Яз әйдә, беренче вариантны ничек телисең шулай яз, үзеңне чикләмә. Житәкчең белән киңәшкәч, кирәген сайлап алырсың, — диде.

"Сайлап алырсың" дигәне генә бераз сагайтты. Димәк, янадан эшләргә дә кирәк булуы ихтимал. Ә бер эзгә салынган әйберне сүтеп эшләүнең авырлыгын беләм. Шәрәф тә, шигыренең бер юлын үзгәртсәләр дә, тузына. "Совет әдәбияты"нда басылган бер шигырен укыгач, сүгенеп үк куйганы исемә төште. Шигырьнең бер юлын бик мәгънәсез сүзләр

белән алыштырганнар иде. "Шагыйрьнең җанын башта редактор талый, аннан калганнарын обллит* йолкый, язучылар каләменнән төшкәнен укучы күрә алмый", — дип зарланды Шәрәф. Шигырьләренә кемнендер кул тыгуын бер дә яратмый иде ул. Хәтта бер җыентыгын наборга бирер алдыннан кире алган. 1940 елны чыгачак бу китапны башта Хәсән Туфан редакцияләгән. Инде эш бетте дигәндә генә, көтмәгәндә, Туфан кулга алына һәм, яңадан карап чыгарга дип, кульязманы Хәсән Хәйригә бирәләр. "Халык дошманы" дип кулга алынган шагыйрь редакцияләгән эшкә редактор бик "җаваплы" килә һәм берничә шигырьне басарга яраксыз дип таба. Шәрәфнең баш бирмәс яшь чагы, артык бәхәсләшеп тормый, хәер, мәгънәсе булмасын белгәндер, кульязманы кире ала. Шулай итеп, китап басылмый кала. Хәзер андый дуамаллыгы кими төшкән. Теш кысып булса да, әйткән сүзгә колак салырга тырыша. Ольгаюмы бу, әллә гаиләсе алдындагы җаваплылык мәҗбүр итәме? Ни генә әйтсәң дә, көн итәсе дә бар бит әле. Ләкин ул чакта бик рәнҗегән иде журналда эшләүчеләргә:

— Тырнак астыннан кер эзләүчеләргә ул юллар ошамасын да, ди. Тик мин исән бит әле, көн дә яннарына кереп йөрим. Үземә әйтсәләр ни була?

Шикләнүем юкка булмаган шул. Профессор Ступишин эшемне шактый җыйнакландырырга киңәш итте. Баштагы лирик өлешен суеп, бассейнның гео-геоморфологик үзенчәлеген коры фән теле белән сурәтләп бирергә мәҗбүр булдым. Менә шунда аңладым инде мин Шәрәфнең янып-көюләрен. Ләкин мин алай ук пошынмадым. Язылачак "Көмеш елга"ны уйлап тынычландым. Диплом эшеннән тизрәк котылу һәм инде тәмам өлгереп җиткән, кәгазьгә өзелеп төшәсе калган повестьны башлап җибәрү теләге бик көчле булса да, үз-үземне ирексезләп диярлек диплом эшенә яңадан тотындым. Иң элек миңа сызым эшләрен бетереп куярга кирәк. Шәрәф фронттан бик әйбәт, ап-ак, шоп-шома немец кәгазьләре алып кайткан булган. "Кирәк эшеңә тотарсың", — дигән иде. Шул иskә төшеп, караватасты ндагы чемоданнарны тартып чыгардым да пыр тузып кәгазь эзли башладым. Ходаем! Нәрсәләр генә юк бу иске чемодандагы кәгазьләр арасында? Язылып бетмәгән шигырь юллары, аркылы-торкылы сызылган язмалар, газеттан кисеп алган хәбәрләр, кыр почтасына Шәрәф исеменә килгән хатлар, СССР Верховный Советының Мактау кәгазьләре... Барысы да сыер тагарагына салган башак кебек буталып беткән. Ни эшләп элегрәк ачып карамадым икән, буш вакытларым бар иде, рәтләп куйган булыр идем бит. Мин әле һаман да үземне чын хуҗа итеп сизмим, ахры. Яңа тормышка, яңа шартларга ияләнүе читен. Үзем теләп кушылган кешем булмаса, ике дә уйлап тормыйча, Җәмиләләр, Рәмзияләр янына кире кайтып китәр идем кебек. Кеше өстендә, бигрәк тә аның ишек төбендәге караңгы почмакта яшәү дә күңелне күтәрмидер.

Актарына торгач, калын гына бер дәфтәр табып алдым. Шәрәфнең 1944 елда яза башлап ташлаган көндәлеге икән. Болай гына укый башлаган идем, бу чемодан янына ни өчен килеп утыруым да онытылды. Бит артыннан битен ачтым. Солдатның үз күзе белән күргән хәлләр, вакыйгалар үз эченә суырып алды.

"... Яңадан 1326 нчы полкка киттем. Кая карама — шунда сазлык. Кыргый урман. Аяк астында миналар ауный. Снаряд төшмәгән урын юк. Үзеңне тудырган, үзеңә ризык биреп үстергән газиз әнкә — кара җир өстенә ышанып аяк басып булмый — минага очравың мөмкин".

"... Алгы кырый. Беркем дә йокламый. Атулар. Ләкин немецлар ерак. Ара биш чакрым. Чөнки сазлык. Кереп булмый. Бөтен тирә-як якты. Теге якта бер өй яна".

"... Көндез Вильнода торучы поляк мөселманнар янына киттек. Кечкенә генә бер мәктәп янына җиттек. Без барганда мөселман ирләр һәм хатыннар мәчетне чистарта, юа һәм себерә иделәр. Безне бик яхшы каршы алдылар. Татарча бөтенләй белмиләр".

---

*Обллит — кульязманы басарга рөхсәт бирүче цензура оешмасы.

"... Элек немецлар, тирә якта яхшы, уңайлы сарайлар булуга карамастан, мәчетне ат абзары итеп тотканнар. Манарасын снаряд тишеп чыккан. Шулай да мәчет эшкә ярарлык, стеналарына матур итеп, коръәннән төрле аятьләр язып куелган"...

Шулай дөньямны онытып укып утырганда Шәрәф үзе кайтып керде. Пальтосын җилбәгәй җибәргән. Фуражкасы маңгае артында, чәчләре чәбәләнеп төшкән. Мин аны көтми идем әле. Эш сәгате бетәргә шактый вакыт бар. Андый-мондый хәл булмагандыр ла? Алай дисәң, авызы колагына җиткән, күзләре көлә.

Өс-башын да салмыйча, алдыма бик күп акча чәчеп ташлады. Пальто кесәсеннән дә, костюм кесәсеннән дә коела, чалбар кесәсеннән дә чыга акчалар. Көзге яфрак шикелле әкрен генә тирбәлеп, тезләрем өстенә җай гына ятуларын, фокусчы хикмәтен күргәндәй, авыз ачып карап утырам. Ходаем, бу хәтлене гомеремдә түгел, төшемдә дә күргәнем юк бит минем.

Ниһаять, кесәләр бушады, ахры, Шәрәф учын-учка ышкып, йә нәрсә әйтәсең, дигәндәй елмаеп карап тора башлады.

— Каян алдың бу хәтлене?

— Алдым инде...

Иремнең көр күңеле миңа да күчте бугай:

— Банк бастыңмы әллә? — дип елмайдым.

— Әйе, Кузьма Яковлевич белән.

Кузьма Яковлевич китап нәшриятының баш бухалтеры. Олы яшьтәге чуаш. Китабы чыгып килүче язучылар ничек тә аның күңелен күрергә тырышалар. Гонорар буласы көннәрдә Кузьма Яковлевичның дәрәҗәсе нәшрият директорыныкыннан да югары буладыр, мөгаен. Баш бухгалтер үз дәрәҗәсен яхшы белә. Кешесенә карап кына үзенә сыендыра. Бигрәк тә фронтовикларны якын итә бугай. Бүген иртәнге якта Шәрәф эшләп утырган җиргә шалтыратып:

— Минем янга менеп төш әле, — дигән.

Баш бухгалтер үз янына кешене юкка чакырмый. Сулуы кабып килеп кергән Шәрәфкә дә "Җыр үткән юл" китабы өчен тиеш булган гонорарны тулысы белән язып биргән.

— Акча күп түгел, кассирның банктан кайтканын саклап тор, авызыңны ачып калма, — дигән.

Бу елларда нәшриятның акча яклары хөрти икән. Китап бәяләре арзан булса да, чыгу белән сатылып бетми. Банкка акча аз килә, булганын да бармак арасыннан сыгып кына чыгаралар. Китапларын кулларына алган авторлар айлар буе әҗерен күрмичә йөдиләр. Әллә нидә бер гонорар биреп куйсалар, нәшрият коридоры корт оясы кебек гөҗләп тора.

— Әзрәк сыйларга туры килде инде картлачны, — диде Шәрәф.

— Үзең дә ярыйсы гына сыйлангансың, — дидем, канәгатьсез булып, аның сәеррәк ялтыраган күзләренә карап алдым.

— Ансыз булмый инде, — диде ул, яныма чүгәләп, әле булса чәчелеп яткан акчаларны учына җыя башлады һәм, — ямьсезгә китәсе сүзне башка якка борасы килепме: — Бу әллә ни күп түгел. Дүрт ел буе землянкада, сукыр лампа яктысында язылган шигырьләр өчен күпмени бу? Үз гомеремдә бер генә тапкыр алдым мин үземчә күп акчаны. "Яшь ленинчы"га шигырьләр язган малай чагымда. Иң элек туйганчы кызыл су белән ак күмәч ашадым. Аннары әнигә чәчәкле шәлъяулык, Сания белән Салисәгә ефәк пионер галстугы сатып алдым. Вот акча иде ул!

Бу вакыйганы беләм. Узган ел мин акча югалтып кергәч сөйләгән иде аны. Соңыннан:

Мең тугыз йөз утыз бишенче...
Сентябрьнең тәүге атнасы...
Басулардан килгән малайга,
Казан, Казан! Ишек ачсанчы! —

дип шигырь дә язган ул.

Җиденче классны тәмамлагач Шәрәф Казанга укырга килә. Бауман урамындагы Матбугат йортын эзләп таба. Шигырьләрен бастырган "Яшь ленинчы" редакциясенең ишеген ачып керә. Өстәл артында эшләп утырган матур апа аны күргәч:

— Сиңа кем кирәк, энем? — дип сорый.

— Шигырь апкилгәнием...

— Бездә басылганың бармы соң? Исемең ничек?

— Шәрәф Мөдәррис...

— И-и... Шәрәф син буласыңмыни? — ди дә матур апа, кинәт урыныннан кубып, "әйдә"әле", дип, бүлмәдән алып чыга һәм озын коридор буйлап баргач, бер кечкенә тәрәзә каршына китереп бастыра.

— Шунда тор әле. Мин хәзер... — дип, аны-моны аңлатмыйча, бүлмәгә кереп китә.

Тәрәзәчек өстендәге "Касса" дигән язуны күргәч, малай коелып төшә. Газетта шигырь бастырган өчен акча түләтәләр икән дип уйлый. Аның бит кире кайтырлык та акчасы юк. Яхшы чакта таяргамы әллә, дип уйлап куя. Тик ул бер карарга килергә өлгерми кала, каршындагы тәрәзәчекнең капкачы ачыла да:

— Менә шунда кулыңны куй, энем, — дип, Шәрәфкә кәгазь белән каләм сузалар.

Малай калтырый-каушый кулын куйгач, күп итеп акча бирәләр.

— Ал-ал, шигырьләрең өчен гонорар ул, — ди янына килеп баскан матур апа. — Син бит бер дә адресыңны язмадың. Шигырьләрең астына "Мөчали мәктәбе" дип кенә куя идең. Кая җибәрергә белмәдек. Менә хәзер танышыйк инде. Мин Мәрьям Дибаева булам.

Бу акча авыл малае өчен бик күп булып күренә. Әнисе, налог түләр өчен акча кирәк булганда, Баеш базарында күкәй сатып кайта торган була. Анда да бу хәтле күп акча керми иде кулына. Әнисен, сеңелләрен сөендерер өчен беренче гонорар акчасына сатып алган бүләкләре булган икән ул яулык белән галстуклар.

— Йә, бу акчаны ни эшләтәбез? — диде Шәрәф, житди тонга күчеп. — Өс-башны карыйбызмы, әллә өй сатып алабызмы?

Бирде бу миңа мәсьәләне! Чишә алсаң, чиш, булдырмасаң... Әгәр дә мин Пушкин әкиятендәге балыкчы картның хатыны булсам, аяк тибеп бер кычкырыр идем дә... әй, юк, аяк тибеп түгел, иркәләнеп-җайлап кына: "Минем өйле дә буласым килә, матур киенеп йөрергә дә телим", — дип әйтер идем. Алтын балык, күз ачып йомганчы, безнең икебезне патша сарайларына тиң өйгә кертеп утыртыр иде. Ләкин без әкият геройлары түгел шул. Җирнең гап-гади кешеләре генә. Алдымда чәчелеп яткан акчалар да ике хыялның берсен генә чынга ашырырлык.

Бу караңгы баздан котылу чарасын эзли идек без. Ял саен шәһәргә чыгып, корырак, яктырак бүлмәгә фатир кертүче булмасмы дип белешеп йөрибез. Ләкин берәү дә парлы кешеләрне сыйдырырга теләми. Барысы да ялгызларны, бигрәк тә студентларны алу ягын карый. Аларның мәшәкате аз. Бүген монда, иртәгә әллә кайда алар. Гаиләле кешеләр төпләнеп калыр да ахырдан чыгарып булмас дип куркалар. Җитмәсә без бит әле бәби дә көтәбез. Кемнең соң инде яшь бала тавышын тыңлап, тыныч башын тынычсызлыйсы килсен?

Ул елларда шәһәр читендәге урамнардан ике-өч меңгә ярыйсы генә өй алып була дип сөйлиләр иде. Бәләкәй генә булса да үз куышыбызга тиенәсе, аяк атлауларыңа кадәр санап кемнендер карап торуыннан, урынсыз кинәшләреннән, туктаусыз акыл өйрәтүеннән башны котылдырасы иде. Дөресен генә әйткәндә, һәр почмагыннан җылы бөркелеп торган якты, чиста, тыныч өйдә яшәве кызыктыра. Туган өемнән чыгып киткәннән бирле чит кешеләр белән — башта тулай торакта, инде менә кеше фатирында көн үтә.

Өс-башны да карыйсы килә. Курсташ кызларның сынаулы-сораулы карашларын тоеп йөрим. Аларча, шагыйрьгә кияүгә чыккан кеше чук

кебек киенергә тиештер инде. Шагыйрьләр акчаны күрәп ала дип уйлыйлармы? Шулай да, "киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар", дип тә әйтәләр бит әле. Кешенең күзе иң элек киемгә төшә. Сугыш беткәнгә инде өченче ел китте. Халыкның өс-башы күзгә күренеп үзгәрә башлады. Кибетләрдә матур киемнәр бик күп. Фронтовиклар өстеннән погонсыз шинельләр, юа-юа уңып беткән гинастеркалар төшкәнгә дә байтак. Яшь кызлар көязләнеп, биек үкчәле туфлиләрдән йөриләр.

Яшь чак бит. Кичләрен өйдә утырасы килми.

Бер көнне кинәт кенә уйладык та театрга киттек. Тажи Гыйззәтнең күп сүзгә сәбәп булган "Изге әманәтен" карамаган идек әле. Бу спектакльне кайсылары мактап сөйли, бөтенләй бетереп ташлаучылар да бар. Шәрәф эштән кайтып өстен дә алыштырып тормады:

— Мин капкалап алганчы җыен. Театрга барабыз, — диде. — Редакциягә төрлечә язалар. Материал эшләгәнче үзем карамыйча ярамый.

Без килеп кергәндә фойэда халык күп иде инде. Чишенеп, икенче катка менәбез дигәндә Шәрәфне Гамир Насрый чакырып алды. Пөхтә киенгән чибәр генә кеше белән сөйләшеп тора иде, Шәрәфнең кулыннан тартып алды да әлеге кешегә мөрәҗәгать итеп:

— Таныш бул әле. Татарның даһи шагыйре Шәрәф Мөдәррис шушы була инде, — диде һәм тиле кеше кебек шаркылдап көлә башлады.

Гамирның үзенә генә хас көлүе бар. Китапларда аны "иблис көлүе" диләр. Кешене ярсыта, тәнгә каз тиресе чыгара торган шашкын көлү. Көтмәгәндә яңгырап китә дә секундның бер мәлендә шартлап өзелә. Нәзек иреннәр кысылып ябыла, күзләрендә салкын битарафлык кала. Шәрәф аны "Гамирический хохот" дип йөри. Атаклы Гомерның "Илиада" поэмасындагы аллалар көлүе, янәсе. Баштарак миңа Гамирның көлүе сәер, шаярып әйткән сүзләре ачуны китерә торган кебек иде. Күп аралаша торгач, әлләияләндем, әһәмият бирми башладым. Дуслары арасында Шәрәф белән бары тик ул гына шулай тәкәллефсез сөйләшә иде. Мин моңа аларның бик озак бергә фронт газетында эшләүләре, сугыш елларының авырлыгын бергә үтүләре нәтиҗәсе дип карыйм һәм шундый мөгамәләгә азмы-күпме хакы бар дип уйлыйм. Шәрәф үзе дә кимен куймый бит, аның турында ни уйласа, шуны яра да сала. Үпкәләшмиләр тагын үзләре.

— Ринат Ибәтуллин, — диде пөхтә кеше, Гамирга игътибар итмичә, Шәрәфкә кулын сузып. — Шигырьләрегез белән таныш. Ләкин үзегезне башкачарак күз алдына китергән идем.

Шәрәфнең өс-башы бу кешегә фәкыйрь күренгәндер шул. Эштән кайтышлый гына кергән кебек идек бит, шулай да аның тел төбендә кимсетү дигән нәрсә сизелмәде. Бер катлы эчкерсез кешенең, балаларча, уйлаганын туп-туры әйтеп салуы гына булды, ахры. Шуңадырмы, Гамирның тагын авыз ера башлавы урынсыз тоелды. Моны ул үзе дә чамалады, гадәтенчә, шып туктады да бер сүз дә әйтмичә китеп тә барды.

— Гаҗәп түгел, — диде Шәрәф Ибәтуллинның сүзенә каршы. — Сандугачны да бәләкәй соры кош дип уйламыйбыз бит.

Театрдан чыкканнан бирле хиссият дөньясында йөзә идем. Кичен өйгә кайткач шул турыда сөйләшербез, фикерләрне уртаклашырбыз дип уйлаган идем. Тик Шәрәф нигәдер уйчанланды. Сөйләшергә атлыгып тормавын күреп мин дә сүз башламадым. Алдындагы чәен ашык-пошык эчте дә, чемоданга ук салып куйган поэмасын алып караштыра башлады. Сәхнәдә барган хәлләр, сугышта яза башлап та, әлегә кадәр кул тимәгән эшен исенә төшерде, ахры. Мин дә өстәлне җыеп алгач, урын җәясе иттем, караватыбыз янына ук терәп куйган кечкенә өстәлдәге лампаның абажуры газета белән капланса да, күзгә якты төшеп тора. Әллә шуннан, әллә спектакльдә күргәннәремне хәтерләүдән, күзгә йокы керми. Сөйгәне Әсфанны фашистлар аскач, Нажиянең акылдан язган йөзе күз алдыннан китми. Бигрәк тә ышандырырлык итеп уйнады шул аны Зифа Басыйрова. Минем кырыйдагы апа гел елап утырды.

Боргаланып ятуым Шәрәфкә эшләргә комачаулый иде. Әледән-әле

башын күтәреп миңа карап ала. Шунда Әхмәт Юнисның сүзен искә төшердем. Теге вакытны Гали абыйлар белән сөйләшеп утырганда: "Артында табак-савыт шалтыратып торсалар, эшләп булмый шул инде", — дигән иде. Шәрәфнең дә иҗат дәрте сүрелде, ахры, утны сүндерде дә:

— Йокла, — дип, тәмәке-шырпысын алып, ишек алдына чыгып китте. Озак торды ул анда. Мин инде әкрен генә оеп бара идем, салкын куллары белән орынуына йокым тагын ачылды.

— Фатир мәсьәләсен хәл итәргә кирәк, — диде ул каттый итеп, — болай язып булмый. Син дә эшли алмыйсың. Гомер буе кеше почмагында тормабыз бит инде. Кошның да үз оясы була, —диде.

Ибәтуллинның театр рәссамы булуын икенче көнне шул Гамирдан белдем. Кичке чәйне эчеп утырганда килеп керде, Шәрәф караватка күчеп утырды, урындыгын аңа бирде.

— Гамир, кем булды инде ул Ибәтуллин? — дип сорадым, алдына чәй ясап куйгач.

— Театр рәссамы. Декорацияләре шәп, — диде һәм, гадәтенчә көлеп туйгач, Шәрәфкә борылды. — Кара әле, дустым! Театрга да шул хәлләң белән килмә инде. Җүнлерәк кәчтүмең юкмыни соң? Театр бит ул, Казан вокзалы түгел.

— Шулаймыни? Белмәдем, — дигән булды Шәрәф. — Ләбибә, син теге, Англия королевасы янына баргандагы смокингны алып куй әле.

— Букенгем дворецына якынрак күчәргә кирәк сиңа, — диде Гамир, шаяруны дәвам итеп. — Караңгы юллардан үтә-үтә, янына кереп җиткәнче маңгайлар күбеп бетә. Берәр фонарь да элдерә белмисең шунда.

— Сугыш вакытында гына торак итеп җайланган подвал бит бу, электр чыбыгын ишеккә хәтле сузарга онытканнар, — диде Шәрәф җитди тонга күчеп. Әлерәк кенә гонорар алуын, дворец ук булмаса да, кечерәк бер өйгә тиенергә теләвен әйтте.

Гамир безне бер маклер белән таныштырырга булды. Бишбалтада абыйларының күршесендә тора икән, Казанны уч төбендәге кебек белә, ди. Кайда нинди йорт сатыла, күпме сорый, күпмегә бирергә исәбе бар икәнен, төнлә йокысыннан уятып сорасаң да, әйтеп бирә, ди.

Гамирның үзенең торыр урыны бар. Радиокомитет йортының аскы катында шактый зур бүлмәдә яшиләр, хатыны Васфикамал Саттарова диктор булып эшли, шуңа биргәннәр. Тәрәзәләре төньякка карап тора, кояш төшми. Ул ягы белән безнең подвалдан әлләни артык җире юк. Әмма җылы һәм коры. Мичкә ягып азапланырга, утын эзләп йөрергә кирәкми, йортның үзәктән җылыту системасы аларга да керә. Гамирның эш өстәле аерым. Шунысы безне бик кызыктыра. Ашарга утыргын саен кәгазьләреңне өстәл почмагына җыеп куясы юк.

## Мин сине беләм...

Булса да була бит үзәккә үтә торган шыксыз көннәр. Тышта пыскаклап көзге яңгыр ява. Тизләми дә, әкренләми дә, теш сызлаган кебек җанга тиеп, туктаусыз сибәли дә сибәли. Тәрәзәгә карасаң, юеш, салкын, авыр һава басымыннан юл читендәге юкәләрнең башлары иелгәнен, яфракларын койган шәрә ботакларның яңгыр тамчыларын күтәрә алмыйча салынып төшүләрен күрәсең. Йорт түбәләренә орынып, әкрен генә агып барган кара болытлардан бүлмәгә иңгән шыксыз караңгылык эчне пошыра. Түшәмдәге берданбер лампочканың боек кына януы бу хәлне көчәйтә генә. Эшкә кул бармый, җанны ялкаулык баскан.

Яшьләр газетының бер бүлмәсендә без өчәү эшлибез. Тәрәзә янындагы өстәл шагыйрь Сәхаб Урайскийныкы. Аңа каршы сәясәт бүлегенә җаваплы Идият Абдулов утыра. Иң җайсыз урында, ишек төбендә — минем өстәл. Төньякка караган, ничә еллардан бирле юылмаган, рамнары буяу күрмәгән тәрәзәнең яктысы аяз көнне дә минем өстәлгә килеп

житми. Әледән-әле ачылып-ябылып торган ишек тавышына да иләнеп бетә алмыйм. Ходаем, минем урыным гел шулай ишек төбендә булырмы икәнни инде? Түгәрәк узар көннәрне күрерменме берәр вакыт?

Туры килсә дә килә бит. Үскән чакта йоклый торган урыным да ишек янында иде: әтинең үзе ясап куйган агач караваты. Шәрәф белән кушылгач та тормышыбыз кеше ишек төбендә башланып китте. Инде менә беренче эш урыным да шуннан узмады. Алдан килгән урын өчен, диләр. Әле ике генә ай эшләгән кешегә жайлы урын әзерләп куймаганнар шул. Урайскийның кул астында, әдәби бүлеккә килгән чиле-пешле әйберләргә үзем белгәнчә җавап язып утырам. Тешем үтмәстәйләрен шефка бирәм. Сәхаб абыйның эше болай да күп. Язучылардан килгән кульязмалар аның кулыннан үтә. Алар белән сөйләшү бик үк жиңел түгел. Какча гәүдәле, пөхтә кеше ул. Миңа аның мөлдерәп торган кара күзләре, озын кара керфекләре ошый. Бер карасаң шаян очкыннар чәчә, бер карасаң, үзәкләрне өзәрлек моң була аларда. Урайскийның тирән, кара шадраларын да оныттыралар ул күзләр.

Идият Абдулов белән икәү гел әйткәләшеп утыралар. Дөресрәге, Идият бәйләнә. Икесе дә Хода бәндәсе, югыйсә, икесенә дә бер үк кояш карый, бүлешер әйберләре дә юк кебек. Урайский унлап китап чыгарган шагыйрь. Бик матур жырлары бар. "Син кайтмадың"ы гына да ни тора. Татарстанда аны белмәгән, жырламаган кеше бар микән ул?

"Кошлар күптән кайтты, син кайтмадың..."

Идият тә язып маташа. Ниндидер бер пәрдәлек пьесасы авыл сәхнәләрендә уйнала, ди. Тагын язып караган да, анысы барып чыкмаган, ахры. Культура министрлыгында да, драматурглар белән дә ачуланышып беткән. Ул әйберен безгә дә күтәреп килгән иде.

— Синнән язучы чыкмый, журналистикага ныклап ябыш, — дип, Шәрәф аңа мишәрчә, турысын әйтте.

Ул хәзер безнең гаилә турында тузга язмаган сүзләр сөйләп йөри. Мин дә аны яратмыйм. Кремльдә үткән зур жыелышта күргә үк өнәмәгән идем. Миңа аның, карсак кешеләргә хас булганча, борын чөеп йөрүе ошамый. Шул сөйкемсез борынын теләсә кая тыгып, иснәнеп йөрүен дә яратмыйм. Сугышта аны разведчик булган, диләр. Бу гадәте бәлки шуннан калгандыр. Пинжәгендәге Кызыл Байрак орденын юкка бирмәгәннәрдер. Дөрес булса, ул аны мунчага да тагып бара, диләр.

Урайский да сугышта булган. Ләкин ул бер вакытта да башыннан үткәннәрне искә төшерергә яратмый. Аны тормыш баскан. Бишме-алтымы баласы бар бугай. Шуларның мәшәкәте башыннан ашкан. Бүген дә:

— Ботинкам авызын ачып бара, — дип, үз алдына сөйләнеп утыра. — Төзәтергә бирсәң, "яңасы арзанрак" дип әйтерләр инде.

Талчук базарында бераз киелгән ярыйсы гына әйберләр сатылганын белгәнгә, үземчә киңәш бирәсе иттем:

— Базарда әйбәт кенә әйберләр була, чыгып карагыз.

— Базарга әниеңне алып чыксаң, әти дә табып кайтырга була анысы, — диде ул, яза торган кәгазен бер читкә алып куйды да тәмәке төрә башлады.

Юеш һава тәмәке төтенен бүлмәгә кире куды, борынга ачы ис бәрелде.

— Сәхаб абый, чыгып тартыгыз әле, тын алып булмый бит.

Ул чыгып тормады, учы белән төтенен куа-куа, бер-ике суырды да, төпчеген сүндереп, сугышларда йөреп кайткан алюмин тәмәке савытына салып куйды.

— Ирләр исе чыксын дип әйткән идем.

— Андый истән болай да гарык.

— Да, тәмәкене ашый инде ул Шәрәф.

Кайдадыр йөреп кергән Идият урынына утырырга өлгермәде, колагына Шәрәф исеме керүгә:

— Карале, аны чирли диләр, дөресме? — диде.

Хәл белергә теләп, яхшы ният белән сорау түгел иде бу. Әгәр

шулай булса, мин Шәрәфнең бер атнага ял алып, "Биш минут" дигән поэмасын машинкада басып утыруын әйткән булыр идем. Ә болай:

— Юк, авырмый, — дип кенә җавап бирдем.

— Яшермә инде, ирләр чиредер әле.

— Үз хәленнән чыгып әйтәсеңме?

— Да, Идияттә андый чиргә иммунитет юк инде ул, — дип, Сәхаб абый да сүзгә кушылды.

— Кем әйтте? — диде Идият, кабынып китеп, Урайскийның күзенә керерлек булып алдына килеп басты.

— Сүз иясе белән йөрми, — диде тегесе тыныч кына. —Сәлимә апаң бик тәмле бәрәңге пәрәмәче төреп җибәргән, әйдә, кил, тамак ялгап алыйк.

Ул, өстәлгә газет җәеп, кара икмәк телеме, кабыксыз бер-ике бәрәңге, шырпы кабы белән тоз чыгарып куйды. Бәләкәй термостан стаканга чәй агызды. Аның шундый да житди кыяфәт белән табын әзерләвен Идият сүзсез генә карап торды да, төкереп чыгып китте. Мин дә буфетка төшеп менәсе иттем.

Әйләнеп килүемә "сәгать бишкә — редакторга!" дигән хәбәр ишеттем. Редакциянең эше турында җыелып сөйләшүләрне ярата идем мин. Йомшак кына, елмаеп кына сөйләшә торган, Шәрәфнең беренче шигырьләрен газетта бастырган Мәрьям Дибаева, матур киенеп йөрергә яраткан Суфия Әхмәтова, кулыннан тәмәкесен төшермәгән Мәгъмүрә Бибарсова, бөдрә чәчле Хәбиб Гобәйдуллиннар эшли монда. Әле күптән түгел генә җаваплы секретарь булып Зәки Нури килде. Барысы да аяклы тарих дип әйтерлек кешеләр. Сөйләгәннәре гыйбрәтле дә, кызык та. Алар сүзенә һәрвакыт колак салалар. Ләкин бүгенге җыелышның тизрәк бетүе хәерле иде. Бүген тимер юлчылар клубында Шәрәф белән очрашу булачак. Поэманы укырга Хәким ага Сәлимҗанов ризалык биргән. Эшем бетүгә мин дә шунда барырга тиеш идем. Бәлки, әле редактор Гали Хуҗи иртәрәк тә җибәрер дигән өметем бар. Газет чыгасы көн түгел бит. Ә мин, энә өстендә утыргандай булсам да, җыелышның ахырын көтәргә мәҗбүрмен. Чөнки сүз әдәбият бүлеге турында бара. Алдагы ел башларына яшь язучылар конференциясе булачак икән.

— Сәхаб, соңгы елларда әдәбиятка килгән өметле яшьләрнең исемлеген барла әле. Кем ул, кайда яши, эшлиме, укыймы? — диде редактор, Урайскийга карап. — Редакция каршында иҗат түгәрәге оештырырбыз, бәлки.

— Уйлап карарга була.

— Уйлау гына житми, эшләргә кирәк.

Андый чакта киңәш бирүче күп була бит, бигрәк тә үзләре эшлисе эш булмаганда. Бу җыелышта сүз алып сөйләмәгән кешеләрдән мин генә калам бугай инде. Түзмәдем, алданрак җибәрүен үтенеп, редакторга язу язып җибәрдем. Укыды да бер читкә алып куйды, күтәрелеп тә карамады.

Ниһаять, утырыш тәмамланды. Очып чыгардай булып ишеккә ташлануыма:

— Ләбибә, сабыр ит, машина белән илтеп куярбыз, — дип, Гали абый туктатты.

Тышта яңгыр басылган иде инде. Фаралар яктысында күлдәвекләр ялтырап-ялтырап китә, алардан машина тәрәзәсенә ныграк су чәчри. Бертуктаусыз "машинаның дворнигы" эшләп тора.

Тимер юл идарәсенең вокзал янындагы яшел буяулы, зур, мәһабәт бинасы янына житәрәк Гали Хуҗи белән Зәки Нури:

— Әллә кереп тыңлыйбызмы? — дип киңәшеп алдылар.

— Вакытыгыз булса... — дип, аларны кыюсыз гына хупладым.

— Вакыт үзебезнеке. Сатып аласы түгел, — диде Зәки, гадәтенчә авыз ерып.

Кызыл почмак бүлмәсендә халык күп иде. Барысы да дип әйтерлек ирләр. Кайсылары киемен дә салмаган. Изүләрен генә чишеп җибәргәннәр. Аларга карагач, бераз утырырмын да, чыгып китәрмен дип кергәннәр дә, инде менә дөньяларын онытып, артистны тыңлыйлар, дигән тәэсир кала.

Машинистлар, поезд төзүчеләр, диспетчерлар арасыннан, тиз генә күз йөртеп, Галимҗан абыйны эзлим. Ул күренми.

Хәким ага шәп укый поэманы!

Әхтәм Мусин китте конторага —
"Борчалары"н басып килергә.
Ялкин дигән ошбу мошенникка
Әлифбадан сабак бирергә.

Әхмәт Мусин дигәне — Галимҗан абый ул, Юдино депосының машинисты. Моннан берничә ел элек, үзебез өй сатып алганчы, без аларда фатирда торган идек. Нарат урманына караган ике тәрәзәле, кояшлы бүлмәбезне әле булса сагынам мин. Кызыбыз Әлфия шунда туды, ерак дип тормадылар, Казаннан кунаклар килеп йөрде.

Йорт хуҗабыз Галимҗан абый сүзгә юмарт кеше. Әзрәк төшереп тә алса, мәзәк сөйләргә ярата. Чын итеп, үзе күргән хәл итеп сөйли ул.

— Бер көнне получка алдык та бик әйбәтләп юдык моны. Минем иптәш кәйрәк нәрсә, артыграк та киткән моңа. Тыңламый гына бит аяклары. Бара торгач, "бух" сулы чокырга. Ә анда бер ана дуңгыз аунап ята икән. Шинель сәдәпләре кебек ике рәт тезелгән дуңгыз имчәкләренә кулы тиеп китте дә: "Үзебезнең брат икән әле", — дип, дуңгызны кочаклап та алды. Көчкә иллеалла өстерәп чыгардым үзен.

— Иптәш дип утырмасаң, үзең булгансыңдыр әле, — дип, хатыны Сәрби апа җиңелчә генә әрләп ала.

— Тик тор, карчык! Характерымны беләсең, — дип көлә Галимҗан абый.

Болай ул үзе ипле кеше. Шәрәф белән төннәр буе гәпләшеп утыралар. Шушы поэманы язарга ниятләве дә шуннан булды бугай Шәрәфнең. Кызганыч, бүген Галимҗан абый үзе юк, рейска киткәндер, күрәсең. Уйларымны дөресләгәндәй:

Минем герой бүген поезд белән
Китеп барды рельс буйлата... —

дигән сүзләр колакка керә.

Кичә тәмамланып, халык таралгач, Шәрәф кунакларны вокзал ресторанына чакырды. Вакыт әллә ни соң булмаса да, кеше аз күренә. Аяк өсте капкалап алырга кергән юлчылар, ялгыз башы салып утырган бер-ике сәрхүш һәм шау-шулы яшьләр төркеменнән башка кеше күренми. Юан биленә таплы чүпрәк бәйләгән (ак алъяпкыч димәсәң, хәтере калыр) официант ханым күрше өстәлдә утыручылардан ашау хакы алып тора.

— Ханым, безнең янга да сугылсагыз икән, — диде Шәрәф, мөмкин кадәр ягымлы булырга тырышып.

— Минем биш кулым юк, — дигән дорфа тавыш ишетелде.

— Безгә ике кулыгыз да бик җиткән, — диде Зәки, аңа каршы.

— Йә инде, ачуландырма, йә бөтенләй килмәс, — диде Гали абый, гадәтенчә тынычлык сакларга теләп.

Официант меню язылган дәфтәрне "шап" итеп өстәлгә ташлагач, Шәрәф ачып карады һәм сызгырып җибәрде:

— Рәттән сызганнар монда.

— Кабарлык бер әйбер дә юкмыни?

— Лангет дигәне бар, ашарлык булса...

Шәһәр үзәгендәге затлы ресторан түгел шул инде бу. Шәрәф әйткәндәй — забегаловка. Дөнья рәхәтенә чумып утырып булмый монда. Шулай да Шәрәф белән Зәки администраторга кереп сөйләшкәч, таплы эскәтерне чистарагына алыштырдылар. Өстәлгә затлы балык, кыздырган тавык, әле генә ясалган яшелчә салаты килде.

— Эш беткәч, уйнарга ярый, — дип, Зәки учын-учка ышкып алды да коньяк шешәсенә үрелде. Рюмкаларга затлы эчемлек салынган арада Гали абый:

— Мөхәммәт белән Прага ресторанында утырган идек, — дип, сугыш елларында Мөхәммәт Садри белән үтеп барышлый гына тамак ялгап чыгуын хәтерләп алды. Андагы тәртипне, затлылыкны, матурлыкны сөйли башлагач, күпне күргән Сәлимҗанов:

— Әкренрәк, Гали, урман — колак, кыр — күз, диләр. Мондый җирдә кем булмас та, кем тыңлап тормас, — диде.

Гали абый, кызлар кебек кызарынып, күзләрен түбән төшерде. Артистның сүзен Зәки җөпләп куйды:

— Бер абзый "шундый хуш исле, бер төтәтсәң, артыңнан кызлар калмый" дип, немец сигаретын мактап утыра икән. Икенче көнне килеп алып киткәннәр үзен.

Сүзнең кирәксез якка борылуын сизеп, Шәрәф:

— Очрашуга соңга калдыгыз, — дип куйды.

— Шулай туры килде инде. Алданрак белмәдек бит, үзең әйтмәдең, — диде Гали абый. Бокалларга коньяк коеп мәшәкатьләнгән секретаренә карап алгач: — Редакциядә әдәбият түгәрәге оештырабыз. Алып бар әле шуны, Шәрәф. Яшьләр иҗатын күзәтеп барасың бит, — диде.

— Йә, монда эш турында сөйләшмик әле, Шәрәфнең уңышы өчен күтәрик, — диде Зәки.

— Минем уңыш турында сөйләргә иртәрәк әле. Мин бу тостны Хәким ага сәламәтлеге өчен күтәрәм. Радиокомитетта очрашып сөйләшкәндә бик үк ышанып бетмәгән идем. Вәгъдәсендә торды. Олы башын кече итеп килде, үтенечемне кире какмады. Поэманың әйбәт кабул ителүе Хәким аганың артистларча шәп итеп укуыннан булды. Рәхмәт, Хәким ага! — диде Шәрәф.

— Килде-китте әйберне шәп итеп укып булмый ул, — диде Хәким ага, аңгәмәне дәвам итеп.

— Язганыңны тәнкыйтьчеләрдән алда халыкка уку гыйбрәтле икән. Чын бәяне алар бирә инде, бик акыллы сүзләр сөйләүчеләр булды.

— Аларның да төрлесе бар, — диде артист, Гали абыйның сүзенә каршы төшеп. — Спектакль барганда сагыз чәйнәп утыручылар да була.

Артист хаклы иде. Казанны театрал шәһәр дип әйтсәләр дә, чын сәнгать белән хозурланудан бигрәк, урыс әйтмешли, "на людей посмотреть, себя показать", дип йөрүчеләр дә җитәрлек. Отеллоның газаплы монологында кычкырып көлгән кешеләрне дә күргәнем бар, антракт саен буфетка кереп өсти торгач, спектакль ахырына мәлҗерәп төшүчеләр дә була. Соңгы пәрдә ябылыр-ябылмас, дөбердәп, кием алырга йөгерүләре — анысы инде гадәти хәл. Шулай да... Шулай да тамашачының күбесе — сәхнәдәге хәлләрне күңеле аша үткәреп, кичереп, уйланып, гыйбрәт алып караучылар. Пәрдә ябылгач та аягүрә басып алкышлаган, артистларны сәхнәгә кат-кат чакырган тамашачы өчен иҗат газаплары кичерә ләбаса Хәким Сәлимҗановлар. Бүген соң... Бүген сәгатьләр буе тын да алмыйча аны тыңлаган кешеләргә ни әйтәсең. Күбесе эштән соң, өенә дә кайтып тормыйча, кереп утырган бит инде.

— Абыйлар, гафу итегез, сез язучылар бит, әйеме?

Кинәт бирелгән сорауга сискәнеп киткәндәй булдым. Өстәл янына килеп баскан кешегә игътибар итмәгәнмен икән. Чәчләре тузгып маңгаена төшкән, күзеннән нур качкан, ирен читенә кыяр орлыгымы, нәрсәдер ябышкан, яшел галстугы кыйшаеп, таушалган пинжәге эченә кереп беткән бер сәрхушнең ялагайланып, үз кешедәй әрсез елмаеп торуына сәерсенеп карадым. Менә ул имән бармагын Зәкигә төбәп:

— Мин сине беләм бит, син писа язасың. Минем дә бер дус писа яза, — диде.

— Йә, нинди писамны караганың бар инде, ягъни мәсәлән? —диде Зәки, бер генә минутка драматург роленә кереп.

Сәрхуш җавап бирергә ашыкмады, күрше өстәл читеннән урындык алып, яныбызга кысылып утырды. Шуннан соң гына йөзен чытып:

— Син миннән сорау алма инде. Сорау алырга мин үзем дә бик

оста, — диде һәм, кинәт айнып киткәндәй булып, урыныннан торды, гафу үтенеп, тәрәз каршындагы шау-шулы өстәлгә күчеп утырды.

Мәҗлесебезнең яме китә башлауга Шәрәфнең кәефе кырылуын күреп торам. Андый чакта аскы иренен чәйни башлый ул. Ярый әле бу бәндә вакытында китеп барды. Ярый әле Шәрәф дәшми калды. Шулай да шикләнеп:

— Әллә кайда күргәнем бар бу сволочьны, — дип куйды.

Шунда кылт итеп исемә төште: узган атнада Идият янына килгән иде бит ул.

## Көлсәң көл, еласаң ела

Казандагы берләнбер татар мәктәбендә язучылар, музыкантлар, сугыш ветераннары кебек күренекле кешеләр белән кызыклы очрашулар булгалап тора икән. Әле менә Габдрахман Әпсәләмовның чакырылуын белгәч, Урайский мине шунда җибәрде.

— Әйбәт кенә бер репортаж язып кайт әле, гонорар да булыр үзенә.

Читлектән чыккан кош кебек канатланып барсам да, укучы балалар кебек үк, дөньямны онытып тынласам да, репортаж язуның читенлеген кайтып өстәл янына утыргач белдем. Тәэсирләрем шул кадәр күп, кайсы башыннан тотып язарга белмим. Ә миңа 40-50 юллык урын бирелгән. Башлыйм да ташлыйм, сызам да бозам. Повесть язудан да читенрәк, билләһи! "Кыскалыкта — осталык" дип әйтәләр дә бит... Кыскалыгын булдырырсың да анысы, тик менә осталыгына ничек ирешергә? "Алдагы санга өлгертергә кирәк", — дип, шеф ашыктыра җитмәсә.

Кылны кырыкка ярырлык шундый вакытта, эч пошырып, Шәрәф килеп керде тагын.

— Менә бу кәгазьне Рәпкигә кертеп бир әле. Мин өйгә кайтам, — диде. Үзе нык дулкынланган дип әйтимме, берәрсе белән сүзгә килгәнлеге күренеп тора, аскы иренен чәйнәп алды. Күңелсез хәл булганны сизсәм дә, эшемнән аерылырга теләмичә:

— Нигә үзең кермисең? Күрәсең ич, эшем тыгыз, — дидем.

— Кайткач әйтермен. Хәзер үк кerткән бул, — дип, Сәхаб абыйга да бер авыз сүз катмыйча, җил-җил килеп чыгып та китте.

— Моңар нәрсә булган? — диде шеф, күңелемдә туган сорауны теле белән кабатлап.

— Приказ каты булды. Обсуждению не подлежит, — дип, Идият авыз ерып утыра тагын.

Шәрәф калдырган язуны ачып укымыйча түзә алмадым. "Моннан ары редакциядә кала алмавым сәбәпле, эштән азат итүегезне үтенәм", — дип, редакторга язган гариза иде ул. Укыгач аптырап калдым. Ни уйларга да белмәдем. Иртән эшкә бергә килдек. Китү турында сүз дә булмады. Командировкага җыенуын, авыл клублары турында проблемалы мәкалә язарга теләвен әле кичтән генә сөйләп утырган иде.

Уйладым-уйладым да, редакторга кермәскә булдым. Шәрәфнең холкын беләм, юк кына нәрсә өчен дары кебек кабынып китә дә соңыннан үкенә үзе. Ләкин кайтып төшәргә горурлыгымы, кирелегеме ирек бирми. Шуның аркасында күпме җәфа чикте инде ул. Бәлки бу юлы да алай ук зурдан кубарлык эш булмагандыр. Кайткач сөйләшербез, аңлашырбыз, үтәр әле.

Көнем борчулы үтсә дә, репортажны язып бетереп, машинкада да бастырып, Сәхаб абый алдына салгач, кайтырга рөхсәт сорадым. Хәлемне аңлый иде, каршы килмәде.

Трамвайдан төшеп бераз баргач, ике тау арасындагы кысан тыкрыкка керергә кирәк миңа. Тау астында да, тау битен кисеп ясаган бәләкәй мәйданчыкларда да уртасына пычкы чүбе салып, тактадан корылган өйләр

билдән карга батып утыралар. Олы урамдагы шау-шу килеп житми монда. Таулар каплап тора. Машиналар да әллә нигә бер, утын-мазар китерәсе булганда гына керәләр. Өйдән-өйгә сузылган сукмаклар булмаса, түбәләрдән төтен баганалары күренмәсә, иртәдән кичкә хәтле тынмаган бала-чага тавышлары ишетелмәсә, йокы патшалыгына килеп кергәндәй булыр иден. Ә биредә кешеләр яши, авыллардан паспортсыз килгәнгә күрә, хөкүмәт эшенә урнаша алмаган кәсепчеләр, базар сәүдәгәрләре, кесә караклары, яшәр урыны булмаган безнең ише интеллигент кисәкләре килеп сыенган бу эчпошыргыч тын, тыныч һәм тынчу чокырга. Балаларның шау килеп уйнап йөрүләре генә биредә дә гадәти тормыш барганын сөйли. Ә аларга чыннан да ирек. Тамакларын туйдырып чыгарсаң, артларыннан каравыллап йөрисе юк.

Тыкрыкка борылып керүгә, колагыма сабыйларымның тавышы ишетелде. Ишеттем дә шулар өчен кан калтырап торган йөрәгемә рәхәт булып китте, әйбәт музыка тыңлагандагы кебек, җанымны сөенеч биләде, көне буе тынычлык бирмәгән уйларым онытылды. Минем өчен бары тик алар гына, кадерлеләрем генә бар иде бу минутта. Бер көтү бала-чага чыр-чуы арасыннан да аерам бит мин аларның тавышларын, дөм-караңгыда булса да, тын алуларыннан да таныр идем үзләрен.

Шактый зур итеп салынган өебез утырган тау битендә чана шуалар. Аларга карап торуы үзе бер кызык икән. Берсе өстенә берсе өелгән балаларның яртысы таудан төшә-төшә үк чанадан коелып калды. Бүтәннәре, тау итәгенә төшеп җиттем дигәндә, чаналары салулап, җиргә чәчелделәр. Бер-берсенә торырга комачаулап кар өстендә әүмәкләшә башладылар, үзләре ачусыз гына әйткәләшәеп алдылар:

— Коз-зел!

— Ты сам козел!

Малайларны берәм-берәм кулларыннан тартып торгызырга туры килде. Улымның өстенә-башына карарлык түгел, пальто төймәләре чишелгән, шарфының бер очы җирдә сөйрәлә, күзенә төшкән бүреген күтәреп куйгач кына күрде ул мине.

— Әни-и...

Аның тавышында сагыну, ярату һәм шул ук вакытта минем тарафтан шелтә көтү дә сизелә иде. Ул арада тау башыннан кызым да йөгереп төшеп, миңа сарылды. Аның да чәчләре тузгып, шәл читеннән бүселеп чыккан. Икесенең дә өс-башларын тиз-тиз генә рәтләп алдым. Уеннан туймаганнар иде әле. Өйгә керәселәре килмәде.

— Уйнасагыз, тәртипле генә уйнагыз, — дигән сүземне әллә ишеттеләр, әллә юк, тыңлап та тормадылар, аяк эзләреннән шомарып беткән, пыяладай ялтырап торган сукмактан тау кәҗәләре кебек йөгереп менеп киттеләр. Мин дә кече улымны җитәкләп алдым. Бәләкәй булгач, аны уенга катнаштырмаганнар, тик торып туңып беткән бичарам. Берсүзсез кулыма ябышты. Йон бияләйдән булса да, боздай туңган бармакларын учым белән җылытырга теләдем. Шәрәфкә ачуым килде. Чыгып та карамаган шул балаларны. Аның ваемсызлыгын тою якты хисләремне сүндерде.

Без кергәндә Шәрәф язу машинкасында басып утыра иде, башын күтәреп карамады. Өйнең кече ягында улыма плитәдә сөт кайнатып эчердем, җылынып, бит алмалары алсуланып китте. Велосипедына атланып, бүлмә буйлап дөбер-шатыр йөри башлады. Мин дә “эш бүлмәсенең” ишегенә килеп сөялдем. Шунда гына Шәрәф эшеннән бүленеп:

— Рәпкигә кердеңме? — диде.

Сорыйсын беләм идем, җавабын әзерләп куймаганмын. Аптырап калдым. Сөйләшүне әрепләшүдән башлауның мәгънәсе юк. Шәрәфнең холкын беләм, тиргәшү аның җенен генә чыгара. Аннан соң күреп торам: бик бирелеп эшләп утыра. Андый чакта эшеннән бүлдерсәң кәефе кырыла, теше сызлаган кебек, көн буе чытылып йөри инде ул.

Иҗатына кагылышлы авыр сүз ишетсә, аеруча үҗәтләнеп, каләмгә тотына. Андый чакта әллә бар, әллә юк син аның өчен. Алдындагы ак

кәгазь генә тынычландыра аны. Эчендәге үртәлүләреннән шулай котыла. Аның уенча, тыныч көнелле кешеләр гомумән шагыйрь була алмый. Моның өчен йә шәхси фаҗига, йә дөнья, ил күләмендәге фаҗигаларны кичерергә кирәк. Тетрәндергеч вакыйгалар чорында иң башлап шагыйрьләр тавышы ишетелә. “Шундый хәтәр көннәрдә Шамун Фидаилар килә мәйданга, аларның тавышы набат булып яңгырый,” — ди Шәрәф. Фронтта һәлак булган сабакташ дуслары Әхмәт Әминов белән Габдулла Галиевне бик еш телгә ала.

Шәрәфнең соравына каршы:

— Кергән идем, Обкомга киткән, — дип алдашырга мәҗбүр булдым.

— Иртәгә эшкә баргач та кертеп бир.

— Син үзең бармыйсыңмыни?

— Юк.

— Ул гаризаңны язганда уйладыңмы соң бераз, ничек яшәрбез? Балалар бар бит.

— Гонорарга торырбыз.

— Гонорарга калган көн — таңы атмаган төн инде ул.

— Булмас! — диде Шәрәф тавышын күтәреп. Ачуы чыга башлаганын сизеп торам. Туктарга иде миңа, йә сүзне башкага борырга иде. Бер башлагач тыелып кала алмадым:

— Сиңа рәхәт. Теләсәң, эшкә барасың, теләмәсәң, ташлап кайтасың. Ә мин бурычка кирә-кирә туеп беттем инде.

— Акча гына булсын сиңа. Минем иҗат итәсем килә, аңлыйсыңмы шуны-юкмы? Шагыйрь бит мин. Дуңгыз караучы хатыннарны мактап плакат шигырьләре язучы түгел. Гарык мин андый эшләрдән.

— Әйбәт эшләгәч, нигә мактамаска, колбасаны барыбыз да яратабыз бит.

— Кызганырга кирәк аларны, мактарга түгел, резин итек белән тездән саз ерып йөриләр, өсләреннән пычрак кара халат төшми.

— Эшләре шул булгач...

— Немец фермерларын күрсәң икән бер.

— Күреп кайткансың бит, нигә шулар турында язмыйсың?

— Язып кара!

Кызып киткәннән генә әйтүем инде. Андый әйберләрнең басыла алмавын үзем дә беләм. Кешеләрне уңай мисал ярдәмендә тәрбияләү дигән фәлсәфә аркасында күз алдындагы кәекләрне дә күрмәмешкә салынабыз. Тәнкыйтьләп кара берәрсен, коллективка яла ягасың дип, авызыңны томаларлар.

— Кәкрене без генә төзәтә алмабыз инде. Бер-ике теше сынудан тәгәрмәч туктамый, әйләнә дә әйләнә. Без бит тәгәрмәч тешләре генә.

— Кирегә әйләнә түгелме соң ул?

Монысы бигрәк инде. Арттырып җибәрде Шәрәф. Әйтер сүз таба алмадым.

Без тормышка икебез ике төрле карыйбыз, ахры. Минем күп нәрсәне алсу төсләрдә күрүемне Шәрәф балалыктан чыгып бетмәвем дип уйлый. Ул үзе һәр нәрсәне төбенә-тамырына төшеп тикшерә дә күңелсез нәтиҗәләргә килә. “Сугышта кан ерып йөргәндә мин дә синең кебек оптимист идем. Фашистларны җиңгәч проблемалар үзеннән-үзе хәл кылыныр дип белә идем. Нәрсә күрдем соң мин илгә кайткач? Сугыш шартларында бер җан булып йөргән кешеләр икегә аерылды. Берәүләр түрә булды да Европаның пычрагын җыештырып йөргән безнең ише “дворниклар” белән рәтләп сөйләшмиләр дә”, — дип әйтергә ярата ул.

— Ә фронтовиклар күкрәк кагып, без кем дип йөрергә яратмыймы? — дип әйтәм мин аңа.

— Үзеңә булган мөнәсәбәткә каршы җавап кына ул. Энергия никадәр нык кысылса, шартлау көче шундый каты була.

Кайвакыт шулай тирәнгә кереп китәбез дә бер-беребезне аңламас хәлгә җитәбез. Кайчагында мин: “Туктагыз, тирәнгә кермәгез, ерып чыга

алмассыз", — дип, итәктән тартып торган гаире табигый көч бармы икән әллә бу дөньяда?" — дип уйлыйм. Бу юлы да әйткәләшә торгач, икебез дә туктап калдык. Шәрәф биргән гариза турында сөйләшүнең очы чуалганга көрсенеп куйдым. Шул вакыт шартлап ишек ачылды һәм балаларның үзләреннән алда тавышлары килеп керде:

— Гамир абый үлде!

— Ни сөйлисез, акыш-макышлар?! — дип, Шәрәф урыныннан сикереп үк торды.

— Үлде инде, үлде, — диде кызым.

— Күзен ачмый.

— Кайда соң ул? Кайда күрдегез?

— Тетя Полялар өе артында ята.

— Таудан егылып төште, үзебез күрдек.

"И Ходаем, өй стенасына бәрелдеме икәнни соң?" — дигән уй башымнан йөгереп үтте. Безнең өй утырган тау бите белән түбәндәге Полина түтәйнеке арасында ак кар өстендә җәелеп яткан Гамирны күргәч, очып төшкәндәй янына төштек. Кечке эңгер-меңгердә аның йөзе таш кебек каткан, зәңгәрләнеп киткәндәй күренде. Ник бер мускулы селкенсен дә, керфеген ник бер кагып карасын. Мәет тә мәет, ул да мәет. Шулай да күңел ышанмый, аңын гына җуйгандыр кебек.

— Кул тамырын тотып кара әле, тибәме икән?

— Ни булса да, өйгә алып керергә кирәк, әйдә, булыш әле, — диде Шәрәф, Гамирны кузгатырга азапланып. Кая ул! Үлгән кешене "авыр була" диләр иде. Дөрес икән. Икәү генә күтәрерлекме соң! Җитмәсә таулга каршы. Аптырагач:

— Миңлегали абый эштән кайткандыр, чакырып кил әле, — дип, аяк астында чуалган бер малайны күршегә кертеп җибәрдек.

— Кем үлгән? Кайда ул? И Ходаем, — дип такмаклый-такмаклый, ире артыннан Зәйнәп тә килеп җиткәч, дүртәүләп күтәреп алдык без аны.

— Авыр икән, кәҗә маен чыгарды, — диде Миңлегали абый, Гамирны диванга кертеп салгач.

— Авыр булмыйча, язучы кешенең эче тулы уй бит аның.

Зәйнәпнең әллә чынлап, әллә уйнап әйтүе булды, барыбызны да сискәндереп, әле генә тынсыз яткан кешенең, Шәрәф әйтмешли, "Гамирический" көлүе яңгырады. Бер мәлгә ни уйларга белмичә катып калдык, аңлап алгач, үзебез дә аңа ияреп көлә башладык. Тәрәзә пыялалары зыңгылдап куйды бугай.

— Куркыттың, сволочь! — диде Шәрәф, инде торып утырган дустын урынына төртеп аударды. Әллә бу Гамирның эчендә сәгать механизмы кебек берәр нәрсә бармы икән? Боруы беткәч, шып туктый торган. Без әле һаман тыела алмыйбыз, Миңлегали абый белән Зәйнәп тә күзләрен сөртә-сөртә чыгып киттеләр, ә Гамир бөтенләй икенче кешегә әйләнде дә куйды.

— Абыегызны кулда гына йөртерлек аны, — диде җитди төс белән.

— Ни өчен?

— Хәзер әйтәм, — диде ул, кабаланып кесәләрен капшый башлады. — Әллә төшеп калган инде?

Аның мастер кулы белән юынып ясалгандай шома, матур йөзе үзгәрде дип кенә әйтү аз, олы фаҗига кичергәндәй, агарынып киткәндәй күренде. Кызганып куйдым.

— Өстеңне салып эл башта, — дидем.

— Мужикмы син, юкмы! — дип, ачуын Шәрәфкә күчерде Гамир. — Өй салып керә алдың, шунар бер әйбәт баскыч ясап куя белмәдең. Берәрсенең егылып үләнен көтәсеңме?

— Сизиф хезмәте ул, — диде тегесе тыныч кына. — Син үлмәдең бит әле.

Шуннан соң ул эш бүлмәсеннән бер шешә коньяк алып чыкты да Гамирга биреп:

— Моны югалттыңмы әллә? — диде.

— Тупас кеше син, Шәрәф. Шаяра да белмисең. Инфаркт була язды бит.

— Берәр шатлыгың бармы әллә? Коньяк тотып килгәнсең.

— Син моның өчен беләсеңме кемгә рәхмәт әйтергә тиеш? Идият Абдулов галиҗанәпләренә. Матбугат йортыннан ияреп чыккан иде. Артымнан калмыйча килә дә килә. Кибеткә кереп тә котыла алмадым. Күзен шакмакландырып карап торганда үч итеп коньякның биш йолдызлысын алдым. "Затлы аракы эчәләр" дип сөйләп йөрсен әйдә.

— Абдулов исеме телгә кергәндә коньяк та эчмим мин.

Алар әйткәләшеп калды, ә мин кичке аш әзерләргә керештем. "Ашыйсы килә", — дип балалар кайтып керде. Аларның тамагын туйдырып урынга яткырганчы да бераз вакыт үтте. Олы якта өстәл әзерләп, Шәрәфләр янына кергәндә тезгә-тез куеп дип әйтерлек (бүлмәнең зурлыгы шулай гына) утырганнар да, Шәрәф Гамиргә нидер укый. Алларында ачып куелган коньяк шешәсе, ике рюмкада тулы эчемлек. Кәефем кырылып китте. Моны сизгән Шәрәф:

— Без әз генә... Европача тоткалап кына куябыз, — дип акланды.

— Кара әле, великолепно бит бу! — диде Гамир, әсәренеп. — Татар әдәбиятында беренче сонет. — Гамир Гамир буламы соң тәртгереп алмаса: — Тыңлап кал, Шәрәфтән мондый шедеврлар сирәк чыга, — дип чәнчеп куйды.

— Синең үзең кебек инде, — дидем төксе генә.

— Тыңлыйсызмы-юкмы, акыш-макышлар! — диде Шәрәф, чәкәләшүебезгә исе китмичә.

— Бетте, бетте, дустым!

Бер гаҗәп матур кыз гомер күгемдә,
Кояштай нур чәчеп, яктырып тора.
Көн димәс, төн димәс, һаман күнелдә
Мәхәббәт ялкынын яндырып тора.
Җемелдәп нур уйный сихри күзендә,
Әйтәчәк сүземнән яздырып тора.
Сизәдер, ут күп дип, йөрәк түрендә,
Сабырлык янгырын яудырып тора.
Бу кыз гел шул яктан аерылып тора:
Мин ярсып хисләргә артык бирелсәм,
Ул, охшап дулкынга, чигенеп китә, —
Беркадәр ял һәм тын алдырып тора.
Шул вакыт назланып мин дә чигенсәм,
Ул тагын артымнан йөгереп җитә.

Шәрәф тагын, тагын укыды. Онытылды, барысы да онытылды. Эреле-ваклы мәшәкатьләре, чүп-чар борчулары, дуслар һәм бик үк дус булмаган кешеләре белән тулы кырыс тормыш юкка чыкты. Әле бик үк еракта калмаган яшьлегем, дөньяны бары тик ал төсләр аша гына күргән вакытым әйләнеп кайтты. Мин үземне бөтенләй башка кеше итеп сиздем, яңадан чәчәк бакчасына кергәндәй булдым. Күңелемдә бәйрәм иде. Шушы сихри мизгелне Гамир бозды:

— Яңа жанрның тууын юмасаң, гөнаһ булыр, — диде ул, сонетлар укылып беткәч.

— Беләсең килсә, бу жанр моннан алты гасыр элек Италиядә туган.

— Булсын. Татар әдәбиятында яңалык әле ул.

— И дөнья, көләргә дә, еларга да белмәссең сезнең белән, — дидем, урынымнан торып. — Аш янына утырыгыз.

— Шуның өчен дөнья инде ул. Көлдерә дә, елата да. Оҗмах түгел, — диде Гамир, фәлсәфәгә бирелеп.

Бераздан мин урыныма кереп яттым, алар утырып калдылар. Ләкин

күземә йокы кермәде. Бер төн эчендә ике-өч шигырь язып газетларга илтә алган кешенең шул ук вакытта чын шигърият дөньясында да яши алуын аңламадым. Шигырь бит ул йөрәк каны белән языла. Кешедә йөрәк бер генә ләбаса. Салкын акыл белән дә язып буламы икәнни аны? "Кирәк тирәкне ега" диләр шул. Көндәлек тормыш өчен андый шигырьләр дә кирәктер. Коры сүзгә караганда шигырь юллары үтемлерәк була бит. Ләкин бер көнлек шигырьләр артык күбәеп китсә, шигъриятнең дә, шагыйрьнең үзенең дә дәрәҗәсе төшә. Шәрәфнең дулап кайтуын хәзер генә аңлый башладым кебек. Әлерәк кенә сөйләшкәндә: "Мин бит шагыйрь, әдәби батрак түгел", — дип өзелеп әйтте бит.

Соңгы айларда инглиз әдәбияты белән мавыгуын күреп йөри идем. Язу өстәлендә Шекспир әсәрләре, Байрон шигырьләре ята. Итальян сонетларының урысчага тәрҗемәләрен күргәч тә әллә ни исем китмәде. Югары дәрәҗәдәге шигърияткә сусавыннан, күңеленә ял алырга теләвеннән дип уйладым. Шул сусау аның йөрәк кылларында уйнап, шигъри дәртен уятып җибәргәнлеген генә аңламаганмын. Саф мәхәббәт, кешелек хисләре белән яшәгәндә, күңеле белән чын шигърият бакчасында йөргәндә, җанына ятмаган, йөрәгең кабул итмәгән нәрсәләр турында язу, "денем өчен түгел, көнем өчен" дип эшләү чын иҗат кешесенең көчен дә, дәртен дә, моңын да, фикри тирәнлеген дә йота барадыр, күрәсең. Шәрәф шуны белеп торган, шуңар баш күтәргән, шартлар дәрәҗәгә житеп үртәлгән. Ул аның редакция эшеннән туюы түгел, ярата ул газет эшен, фронт редакцияләрендә эшләгән чакларын әле дә сагынып сөйли. "Шул еллар мине шагыйрь итте", — ди. Әдипләр, нинди генә жанрда язсалар да, газет эшен белергә тиеш дип карый.

Ләкин тормыш дигән кырыс чынбарлык та бар бит әле. Үзең теләгәнчә генә язып, үзеңчә яшәү генә мөмкин түгел. Шәрәфнең дә иҗади мөмкинлекләренең коргаксый башлавына ризасызлык белдерүе икән ул.

Мондый халәттә ни эшли алам инде мин? Балалар дип, гаилә дип бәйләнү намуссызлык булыр иде. Кыен чакларда: "җан биргәнгә җүн бирер әле", — дип әйтә торган сүзе бар иде безнең әнинең. Чыннан да, бер җае табылып, тормыш үз эзенә төшә иде тагын. Миңа да шулай дип юанырга кала инде. Үзем эшләп торам. Шәрәфнең әйберләрен редакцияләрнең борып кайтарганнары юк әле. "Исән булсак, үлмәбез", — дип әйткән ди берәү.

## Сүнмәс утлар булмас әле

Татарстан язучыларының съездын бәйрәм көткән кебек көтеп алдык. Сугыштан соң икенче генә тапкыр җыелып сөйләшү бит әле бу. Күп җирләрдән кунаклар чакырылган. Мәскәү белән Уфаны әйтмим дә инде, Украинадан, Казакъстаннан, Урта Азия республикаларыннан исемнәре бик билгеле, танылган язучылар килгән. Әдәбият институтында бергә укыган сабакташы — кыргыз язучысы Камчы Юнысовны Шәрәф беренче көнне үк кочаклап алды.

Элек заманнарда колхозлар шулай уңыш бәйрәме үткәрәләр иде. Ул көннәрдә бөтен авыл гөрләп тора иде. Кунак-төшемнең чуты булмый торган иде. Бу съездны да мин бала чагымдагы шул уңыш бәйрәменә охшаттым. Язучы хезмәтенең уңыш бәйрәме иде ул.

Ленин бакчасына килеп кенә кергән идем, Хәким ага Сәлимҗанов белән йөзгә-йөз очраштык.

— Исәнмесез, Хәким ага?

Ул сәламемне алып тормады, көне буе бер бүлмәдә утырып эшләгән кеше кебек илтифатсыз гына:

— Менә машина оттым бит әле, шуны алырга язу килгән, —дип, кулыма бер кәгазь кисәге сузды.

Съезд утырышына ашыга идем, исәнләшеп кенә китәрмен дигән идем, туктап калырга мәҗбүр булдым.

— Кит әле! Менә шатлык! — дип, кабаланып кәгазьне алдым.

— Ядәч! — дип көлеп җибәрде Хәким абый.

Аптырап киттем. Шаяртамы соң ул? Минем аның белән ядәч аерганым юк лабаса.

— Ничек инде? — диде артист, чынлап торып гаҗәпләнде, кулыннан уенчыгын алган бала кебек, йөзендәге елмаюы югалды. — Оныттыңмыни, теге чакта ресторанда аерган идек бит.

— Шул вакыттан бирле исегездә тотасызмы?

— Ну, бу яшьләрнең хәтере! Ядәч сөяген башта Галиягә суздың, "мин хәзер үк отылам" дип, ул алмады. Шуннан соң икәү аердык.

— Ул кичне хәтерлим үзе. Онытылырлык булмады. Иртәгесен Шәрәфне идарәдә шелтәләделәр шуның өчен.

— Нинди унай белән утырганны әйтергә иде.

— Ул әйтми каламы соң? "Минем кайда кемнәр белән эчүемне тикшергәнче, поэма төгәлләвем белән котлар идегез, Хәким Сәлимҗанов ага тимерюлчыларга сәгатьләр буе укыды. Шуның өчен дә кунак итәргә хакым юкмыни", — дигән.

— Каян белгәннәр диген син аны?

— Хәтерлисезме, безнең янга бер сәрхуш килгән иде. "Мин сине беләм, син писа язасың" дип, Зәкигә бәйләнде.

— Шул булгандыр дисеңме?

— Үзе түгел, Союз тирәсендә чуалучы бер дусты бар аның.

— Кара син аны! — диде артист һәм күңелсез сүзне тәмамларга теләп: — Шәрәф хәзер нишли соң? — дип сорады.

— Башы-аягы белән инглиз әдәбиятына чумды. Шекспирның "Ричард-Арслан йөрәк"* дигән трагедиясен оригиналдан тәрҗемә итә.

Яраттылар. "Куябыз", — диделәр. Культура министрлыгында договор төзеп, ун мең сум гонорар да бирделәр. Ләкин әсәр театр репертуарына кертелмәде. Сәбәбен төрлечә аңлаттылар. Бу мажаралар башланганчы, Шәрәф Шекспир сонетларын да тәрҗемә итә башлаган иде. Шуның белән мавыгып, трагедиянең куелмавына артык пошынмады. Кульязманың бер нөсхәсе Хәким ага Сәлимҗановта калды. Аның архивында саклана булыр әле.

— Инглизчә беләмени?

— Телләргә хирыслыгы бар аның. Сөйләшә белмәсә дә, аңлап укый. Аңламаганын сүзлекләрдән карый. Әдәбият институтында укыганда хатларын инглизчә язып аптыратып бетерә иде. Ә мин төннәр буе сүзлек белән утырып, укып чыга идем аның хатларын.

Трагедия турында сүз чыккач, Хәким абый:

— Ничек бара соң эше? Бетерәме? — дип кызыксынды.

— Бетеп килә, ахры. Көне-төне утыра.

— Безгә килеп укысын. Театр кабул итсә, үзем куям.

Ул тагын да нәрсәдер әйтергә теләгән кебек иде:

— Хәким абый, гафу итегез, съездга ашыгам, — дидем.

Ул:

— Сәлам әйт үзенә, — дип китеп барды.

Халык урнашып беткән иде инде. Янына килеп утыргач Шәрәфкә: "Хәким абыйны очраттым. Сиңа сәлам әйтте", — дип пышылдарга гына өлгердем, сәхнәгә президиум әгъзалары һәм кунаклар чыга башлады.

Төп докладта Шәрәфнең исеме актив язучылар рәтендә телгә алынса, минем исем иҗат активлыгы җитәрлек булмаганнар белән бергә саналды. Докладчыга үпкәләрлегем юк иде, искә алынуына рәхмәт. Беренче китабымнан соң шактый вакыт үтсә дә, ике генә повесть язып бастырырга өлгердем. "Өй" диеп, "балалар" диеп, "редакция эше" диеп, язарга да

---

*Шәрәф бу трагедияне тәрҗемә итеп театрда укыды.

вакыт калмаган иде. Бервакыт Шәрәф "Ибиридән Исигә кадәр" дигән фантастик әсәр язарга тәкъдим итте. Хәтта планын да төзеп бирде. Галәм кинлегендә сәяхәт итәргә тиешле очкычның капитаны шагыйрь булырга тиеш иде. Аның өчен шигырь юлларын да язып куйган иде ул. Өйләнешкәнче үк әле: "Яртысын үзем язып булса да, исемеңне әдәбият дөньясына чыгарам", — дигән сүзе капыл искә төште дә киреләндем.

— Синең күңелеңдә туган бит. Эшләп бетергәнсең дип әйтерлек. Утыр да яз, — дидем.

— Миңа ышанмыйлар. "Җир астында җиде көн"не язып күрсәттең инде. Шулай булгач, монысын да яза аласың.

— Үзем уйлап тапкан тема булмагач, кереп китә алмыйм.

Шәрәфнең ачуы чыкты:

— Мин әйткәнгә язмыйсың инде, — диде.

Шуның аркасында берничә көн үпкәләшеп йөрдек. Иҗат эшеннән сүрелүемне теләми иде ул. Ә минем җегәрлегем җитмәде. Артык пошынмыйча, язасы килгәндә генә язып, үз җаема гына яшәүгә иләнеп килә идем бугай инде. Шәрәфнең, билгеле, моңа эче поша иде. Ә бүген бөтен халык алдында тәнкыйть сүзе ишетү минем дә йөрәк итемне чәнчеп куйды.

Ләкин әле бу баласы гына булган икән, алда икән әле аның анасы! Партия өлкә комитетының идеология секретаре Салих Батыев үзенең чыгышында күп язучыларның башына сугып үтте. Иң катысы Шәрәфкә эләкте бугай. Аның горурлыгы булган, каләмдәшләре яратып кабул иткән сонетларны тетеп салды. Чынбарлыгыбызның әһәмиятле мәсьәләләреннән аерылу, үзеңнең эчке хисләрең белән генә мавыгу поэзиябезнең күп кенә әсәрләрендә күренә, дигән фикере дөрес тә булсын, ди. Бу сүзләрне студент чагымнан ук ишетәм инде. Бәлки шулай кирәктер, дигән фикергә иләнеп беттем кебек. Ләкин бу очракта кабул итә алмадым. Нәкъ менә сонетларга карата әйтелгәнгә, күңелем карышты. "Мәсәлән, без моны Шәрәф Мөдәррис сонетларында, Нури Арслан шигырьләрендә күрәбез" — дип әйтүен ничек аңларга? Шул да чынбарлыктан аерылу булдымы инде? Яшь егет белән яшь кызның мәхәббәте, гаилә кору, балалар үстерүләре, тыныч, бәхетле яшәүләре турында бит ул шигырьләр. Шул ук совет гаиләсе турында. Янәсе, Шәрәф Мөдәррис үзенә утыз биш яшь тулуны хәсрәтләнеп искә ала. Тормышның гөрләп торган чагында үзенең югалткан балачагын, тормышының таңын сагына. Төшенкелеккә һәм эч пошуга бирелә. Шул фикерен раслау өчен Салих Батыев соңгы сонеттан өзек тә китерде:

Сукты чаң, яшемнең утыз биш чаңы,
Кайда син, балачак, гомерем таңы?
Күп микән мин күрер июньнәр саны? —
Уйласам шуларны, кинәт моңланам.

Укыдымы икән ул сонетларны Батыев, әллә кемдер әзерләп биргәннәргә генә таянып сөйләдеме икән? Аптырап залда утыручыларга карыйм, күпләрнең тыныч, ваемсыз, арый төшкән йөзләрен күрәм. Шәрәфкә карыйм, ул да исе китмәгән кебек утыра. Кыйнала-кыйнала авыртуны тою сәләтен югалтканмы икән әллә ул ? Әле иртәнге якта гына Гали Халит аның "Әбдүш Ялаяп" хикәясенә ябырылган иде. Имеш, Шәрәф Мөдәррисенең бу әсәрен сатирик хикәянең үрнәге дип атаучы иптәшләр белән килешми ул. Имеш, бу фельетон тискәре геройны — яла ягучы образын читлектән качкан һәм намуслы кешеләргә куркыныч булган ерткыч җанвар сурәтендә бирә. Имеш, безнең намуслы кешеләребезнең мондый мораль яктан гарип, әшәке бәндәләр белән реаль көрәшен сурәтләми.

Гали Халитнең шулай дип әйтүе гаҗәп түгел, ул, гомумән, Шәрәфне яратып бетерми кебек. Икесе дә каты әйтүчән, сүзгә килсәләр, чакма таш бәрелгән кебек очкыннар чыга. "Әбдүш Ялаяп" турындагы фикере дә безнең өчен яңалык түгел иде инде, "Чаян"да басылып чыккач ук ишеткән идек. Ә менә Батыевның сүзләре... Ул инде җитәкче органнар

фикере дип кабул ителә бит. Кешенең язмышы бәйләнгән анда. Ялгышырга тиеш түгел Батыев кебек кешеләр, бер сүз әйткәнче ун тапкыр уйлап карарга тиеш. Моннан соң нәшриятка якын да җибәрмәүләре мөмкин бит инде Шәрәфне.

Кичке утырыштан соң Шәрәфне көтеп тормадым, тиз генә кайтмаслыгы билгеле иде инде. Язучылар да таралышырга ашыкмый кебек. Төркем-төркем җыелып сөйләшкән, житди сүзләр уен-көлке белән аралашкан, чытык йөзләр, ерык авызлар күренеп киткән җирдән авыр тойгылар белән аерылып, редакция бүлмәсендә көндездән калган эшләремне эшләп утырдым. Үземнең дә өйгә аяк тартмады. Ялгыз өйгә кайтып керәсем килмәде. Җәй башыннан ук малайларны авылга җибәргән идек. Ел да шулай итәбез. Бер җәйне Шәрәфләр ягында булалар. Аннан нәкъ Каракитә* малайлары булып кайталар. Мишәрчә сузыбрак, мишәр сүзләре катыштырып сөйләшә башласалар, Шәрәфнең үзенә дә кызык булып китә.

— Сугын инде! — дип көлә ул, малайларының авылны белеп үсүләренә шатланып.

Редакция бүлмәсеннән караңгы төшеп, күз бәйләнгәч кенә чыгып киттем. Күнелем төшенке иде. Эш белән дә тынычлана алмаган идем. Өебезнең караңгы тәрәзәләрен дә күрәсем килмичә кайтып киләм. Йә Алла! Чатны борылгач та урамга караган өч тәрәзәнең өчесендә, ул гына җитмәгән, әле чоланда да, прожектор янып торамыни, ялт иткән утларны күргәч, аптырап киттем. Минем уемча, бу вакытта Шәрәф өйдә булмаска тиеш иде бит. Мөгаен, берәрсе белән кайткандыр. Шул гадәте бар аның. Әзрәк авызына керсә, кеше ияртеп кайта. Өйдә рәт бармы-юкмы — уйлап тормый. Ярый ла, Гамир кебек үз кеше булып беткән берәрсе килсә. Бөтенләй уйламаган, көтмәгән кешеләр белән кайтып кереп тә уңайсыз хәлгә калдырганы бар. Рәхмәт инде, шундый чакта күршем Зәйнәп коткара.

Бу юлы өй тулы кунаклар иде. Уфа язучылары. Аз гына вакытка каушап калдым. Ләкин үземне тиз генә кулга алып, түбәнә чаклы ачык торган ишектән эчкә атладым.

— Кунаклар бар икән, исәнмесез!

Табын янындагылар сикерешеп тордылар. Ир затлары өстәл артыннан чыгып, берәм-берәм каршыма килеп тез чүктеләр, кулымны үбеп күрештеләр. Бу көязлекнең бары уен гына, кунакларның шуклыгы, театраль трюк икәнлеген белсәм дә, уңайсыз булып китте.

— Ой, алай ук кирәкми инде, — дидем, кулларымны артыма яшерергә теләп.

— Ир-егетләр гомерләрендә ике генә очракта тез чүгәләр, — диде кунакларның таза гәүдәле, түгәрәк ак йөзлесе, Муса Гали дигән шагыйрь, җыр көйләгәндәй йомшак матур тавыш белән. — Полк байрагы алдында ант иткәндә һәм гүзәл ханымнар каршында.

— Әйтсә әйтә инде ул безнең Муса, — диделәр калганнары.

Шәрәфнең генә йөзе чытык калды.

— Кайда йөрдең? — диде ул төксе генә.

— Әллә көнләшәсең инде? — диде өстәл түрендә утырган ханымнарның берсе. Ә икенчесе:

— Хатынын яратмаган ир генә көнләшми ул, — дип, төзәтеп куйды.

Кунаклар миңа таныш иде инде. Съезд башланган көнне үк Шәрәф таныштырган иде. Өстәл түрендә утырган ике яшь, чибәр ханым белән дуслашып та өлгергән кебек булган идек. Хәер, аның берсен, зәңгәр күзлесен, Рәисә дигәнен электән дә белә идем. Гөлшат Зәйнашева белән радиода эшләгән вакытыбызда яныбызга килеп йөри иде. Педагогия институтында бергә укыган булганнар. Уйламаганда-көтмәгәндә Шәриф Биккол дигән шагыйрьгә кияүгә чыкты да Уфага китте дә барды. Ханымнарның икенчесе, кояштай якты елмаеп:

— Мин Фәния булам, — дип кулын бирде.

*Каракитә — Чүпрәле районындагы авыл.

Аңа каршы Рәисә:

— Гыйлемдар Рамазановның хәләл җефете, — дип өстәргә кирәк тапты.

Мин аларны, махсус әзерләнеп, кунак итеп чакырырга ниятләп куйган идем. Шәрәф кенә ашыгып ташлаган бит менә.

— Ләбибә кайткач, тәмләп индийский чәй эчәбез икән әле, — диде Нажар, башын чайкап, чал керә башлаган куе, калын чәчләрен артка ташлап куйды.

— Әле иртә, иртә! — диештеләр кунаклар, аның сүзен мәҗлесне төгәлләүгә ишарә дип уйлап.

Бу "чәй" дигәненең үзенә күрә матур бер истәлеге бар иде. Аны Шәрәф белән Нажар да, мин генә белә идек. Узган ел Нажар Казанны сагынып, Уфадан килеп төшкән иде. Радиокомитетта Шәрәф белән очрашканнар. Ике шагыйрь, ике фронтовикның сүзләре килешкән. Әдәби тапшырулар бүлмәсендә бик озак сөйләшеп утырганнар. Шуннан соң Тукай каберенә чәчәкләр куеп кайтканнар. Кичкә таба гына арып-талып, ләкин искиткеч матур истәлекләр белән килеп керделәр өйгә.

— Бик сусадык, Ләбибә, бер кайнар чәй эчик әле, — диде Нажар керә-керешкә.

Мин аларга виктория җиләге белән, куе итеп ясалган Һинд чәе эчерттем, Нажарның шуны искә төшерүе иде.

— Чәйгә өлгербез, — диде Шәрәф рюмкасын кулына алып. — Арслан тотарлык кына булса да менә бу "чәй"не күтәреп куйыйк.

Шәрәфнең сүзеннән көлешеп алдылар.

— Минем тәкъдимем бар, — диде Гыйлемдар, кулын мәктәп балалары кебек күтәреп. — Шушы табында утырган гүзәл ханымнар исәнлегенә булсын!

— Ә мин аларны җыр белән тәбрик итәм, — диде Нажар, хуплаганны да көтмичә җыр башлады:

Ирәндеккәй тавы бигрәк биек,
Тора-тора мендем башына,
Кемнәр генә гашыйк, әй, булмады,
Сәлимәкәй, кара кашына...

Нажарның ягымлы баритон тавышы, киң күкрәктән чыккан иркен сулышы, сагышлы моңы әсир итеп, студент чакларымда йөргән Урал тауларына алып менеп китте дә, яңадан гөнаһлы җиребезгә кайтарып куйды. Дөньясын онытып җыр тыңлаган бер мин генә түгел икән әле. Карасам, Шәриф тә күзен сөртеп утыра.

— Безнең Шәрифулла җыр тыңлый алмый ул, күзләре яшьләнергә генә тора, — дип, Рәисә иренең чәченнән сыйпап куйды.

— Бу кадәр моң каян килә сиңа, Нажар? Әтиең бүләгеме, әниеннекеме? — дип сорамый түзә алмадым, әле булса моң дингезендә тирбәлгән көе.

— "Атаңа җиткерә алмыйсың, балам, атаңның күкрәге киңрәк иде", дип әнкәйнең әйткәне исемдә калган, — диде Нажар.

Җәйге төн болай да кыска була, утыра торгач, яктырып беткәнен сизми дә калганбыз.

— Казан урамнарын яңгыратып бер җырлап кайтыйк әле, яшь чаклар искә төшсен, — дип, Нажар урыныннан кузгалды.

— Беркая кайту юк, шушында ятып йоклыйбыз да, чәй эчкәч, бергә чыгып китәбез, — дип, Шәрәф аңа каршы төшкәч, берсе дә икеләнеп тормады.

Эш кенә түгел, кунак булып утыру да алҗыта икән ул. Ир-атлар өстәлне бер читкә алып куйдылар, Рәисә белән Фәния билләренә алъяпкыч бәйләп, савыт-саба юа калдылар. Ә мин, мич башыдай җылы, гәрәбәдәй сары идәнне тагын бер кат тиз генә юып алдым да ирләр өчен урын салдым. Фәния белән Рәисәгә үзебезнең ятакны бирдем.

— Авылдагы кебек тәгәрәшеп йоклыйк әле бер, — диде Гыйлемдар, йомшак мендәргә башын салгач.

Шәрәф бүлмәсендәге кушеткада ирләрнең ярым пышылдап сөйләшүләренә колак салып озак яттым. Сүзләре Померанцев дигән кешенең "Новый мир" журналында чыккан мәкаләсе турында иде. "Әдәбиятта эчкерсезлек турында" дигән мәкалә тирәсендә шау-шу съездга кадәр дә күп булды. Университет студентлары хәтта шул турыда диспут та оештырып маташканнар. Партия Үзәк комитеты бу мәкаләне тәнкыйтьләп чыккач, бөтен ил буйлап сәер бер дулкын йөгереп үтте. Моңа кадәр язган әсәрләрне яңабаштан карап, яңача бәя бирү шаукымы безнең съездда да нык сизелә иде. Хәтта Мирсәй абый да "Ялантау кешеләре" дигән романы турындагы тәнкыйтьне кабул итү генә түгел, әйтелмәгән җитешсезлекләрне үзе дә өстәп чыгыш ясады. (Гаебеңне тану судта да җиңеллек китерә бит). Тик шунысы кызык, мин дип түгел, автор дип тәнкыйтьләде ул үзен. Автор шулай дип әйткән... автор шуны биреп җиткермәгән...

Шундый чакта да шәхси хисләреңне белдерү языкмы иканни?

## Әкренләп тәэсир иткән агу

Сөенечләре, көенечләре белән, ниһаять, съезд да узып китте. Язучылар сугылган көлтә кебек бушап калгандай булдылар. Җәй аен сылтау итеп, кайсы кая — иҗат йортларына, шәһәр янындагы дачаларына китеп бардылар.

Ләкин бу вакытлы гына тынычлану иде. Алга таба да сүзләр булыр әле. Белгәне дә, белмәгәне дә үзен күрсәтергә теләп нәрсәдер әйтергә тырышыр. Шәрәф тә шиңгән гөл кебек сулып калды. Съезд барган көннәрдә сынатмаган иде югыйсә. Әкренләп тәэсир итә торган агу шикелле, тәнкыйтьнең нәтиҗәсе соңыннан беленә башлады. Ике съезд арасында күпме әйбер язып, бер җылы сүз ишетмәү авыр иде аңа. Иҗатында кимчелекләр дә булсын, ди. Эшләмәгән, язмаган кешедә генә булмый ул. Ләкин Шәрәф чүп-чар яза торган графоман түгел, аның үзенә өйрәнергә килүчеләр бар. Яшьләр газеты каршындагы әдәбият түгәрәгенә җитәкчелек итүен дә хуплыйлар. Шулай булгач, иҗатында уңай күренешләр дә бардыр бит инде? Нигә шуларны да телгә алмаска? Аның газапларын күреп тору миңа да авыр. Борчуларын үзем күтәрердәй булып сүз башласам, иркә баладай тагын да киреләнә, көйсезләнә башлый. Дәшми утырсаң да ярамый. Всеволод Кочетов дигән урыс язучысының матбугатта шаулаган "Журбины" романын укый башлаган идем. Көндезләрен вакыт булмагач, кичләрен озак утырам. Шәрәфнең шуңа эче поша икән. Бер кичне, бала-чагага әйткән кебек, дорфа гына:

— Ташла әле шул халтураны, утны сүндер! — диде.

— Нигә халтура дисең, менә дигән әсәр.

— Барысы да ялган бит алар.

— Булсын, ямьсез чынбарлыкны күргәнче, матур ялганны белү рәхәтрәк, — дидем, киреләнеп.

— Менә шулай алдыйбыз инде без үзебезне.

Соңгы көннәрдә холкы бозылып бетте Шәрәфнең, вакчылланды, кулыннан эш төште, юктан-бардан шикләнә башлады. Җитмәсә, йокысызлык чире белән интегә. Төннәр буе керфек какмый ятканда нинди уйлар килмәс кеше башына? Аңар карап торуы миңа да җиңел түгел. Әмма түзүнең дә бер чиге була бит.

Бер көнне:

— Уфа кунаклары килгәндә кайда йөрдең син? — дип сорап куймасмы бу.

— Һи, тик торганнан торжагын! Тагын шуны казып чыгардыңмы? Бер әйттем бит инде, — дидем ачуым чыгып.

— Юк, әйт әле! Кешедән ишеткәнче, үзеңнән белим, — дип бәйләнә калды.

— Син соңга калып кайтканда сүз әйтмим бит. Миңа да бераз тын алырга ярыйдыр, — дидем, акланырга да, кабат анлатырга да теләмичә.

— Мин ир кеше!

— Ә мин хатын кеше. Бохара әмирлегендә яшәмибез, хокуклар бертигез.

— Кайда яшәсә дә, ире кайтканда хатыны өйдә булырга тиеш.

Кемнәндер көнләшә бит бу җүләр. Әллә болай гына, ачудан гына бәйләнүеме? Күңеленә шундый әшәке уй керсә өзми дә, куймый да инде ул. Тама-тама тамчы да ташны тишә. Бу юлы мин нык рәнҗедем. Ярый, күңелендәге ризасызлык, чарасызлык, гаҗизлек газапларыннан бушанырга да кирәктер аңа. Якын кешеңнең башына сугу мәҗбүриме икәнни моның өчен? Мин дә бит һаман-һаман яшен кайтаргыч була алмыйм, минем да җаным, горурлыгым бар.

Без тагын үпкәләштек. Ничә көн инде рәтләп сөйләшмибез. Ул да, мин дә килешүгә беренче адымны атларга теләмибез. Шәрәф үзенең бүлмәсендә кәгазьләренә капланып утырып кала, мин эшкә чыгып китәм. Ул инде минем эшкә йөрүемнән дә көнләшә башлады бугай. Артымнан:

— Ул редакциягә нигә дип шулкадәр ашкынып барасындыр, —дип калды бер көнне.

— Йдият Абдулов янына ашыгам, — дип әйтергә теләгән идем дә, артыкка китәр дип, телемне тешләп калдым, сүзсез генә чыгып киттем.

Яшәп булмый иде болай. Шундый чакта балалар да яныбызда түгел ичмасам. Алар барында кара көеп йөреп булмый, бала күңеле артык сизгер. Аларга белдермәс өчен генә дә мин-минлегеңне онытып, тигезлек сакларга тырышасың. Сабыйлар ир белән хатын арасындагы буфер кебек бит алар, каты бәрелешүдән саклап торалар.

Кәефем юклыгы йөземә чыккан булгандыр шул, Матбугат йортына кереп барганда Атилла абый Расих очрап:

— Берәр хәл булдымы әллә? Бик күңелсез күренәсең, — дип хәвефләнеп сорады.

Шул минутта барысын да сөйләп бирәсем, эчемне бушатасым килеп китте. Әмма болай аяк өстеннән, узып барышлый гына ачылып китәргә дә мөмкин түгел иде. Күңел шул хәтле тулган, саксыз кагылдыңмы, чайпалып китәргә генә тора. Көне буе эшлисем бар бит әле минем, кешеләр арасында буласым бар.

— Юк, Атилла абый, берни дә булганы юк, — дидем, елмайган булып.

Ләкин аның күңеле нәрсәдер сизенә иде:

— Әйт син аңа, артык борчылмасын. Язучыга кайчан җиңел булганы бар? — диде, Шәрәф башына яуган бозлы яңгырга ишарәләп.

Соңыннан, эшкә кереп утыргач, өйдәге салкынлыкның чын сәбәбен әйтмәвенә сөенеп утырдым. Атилла абыйлар үзләре бик тату яшиләр. Зәкия апа "Әтилләм" дип кенә эндәшә иренә. Тәртипле, тәрбияле бу гаилә күп яктан безгә үрнәк булып, үзебез дә сизмичә, күңелебез белән аларга тартыла идек без. Алар белән сөйләшеп утыру рәхәт, тормыш ыгы-зыгыларыннан



*Атилла Расих, Ләбибә Ихсанова һәм Шәрәф Мөдәррис. 1955 ел.*

арынып, чистарынып, тынычланып калгандай буласың. Без үзара бик еш очрашабыз. Алар элек Чехов базары янындагы өйнең чарлагында яшиләр иде. Күптән түгел генә Дербышкидан — Дәрвишләр бистәсеннән фатир бирделәр үзләренә. Тәрәзәләре нарат урманына караган, бөтен уңайлыклары булган (андыйны күргәнмени без?) бу фатирда үзеңне гел икенче кеше итеп сизәсең. Балалар фильмоскоптан әкият карый, без жай гына сөйләшеп утырабыз. Бераздан, жыйнаулап, урманның сагыз исе катыш иркен һавасын сулап керәбез, табигать хозурлыгыннан күңеле кузгалган Атилла абый скрипкәсен кулына ала.

Атилла Расих белән очрашудан туган уйларымнан арына алмыйча утырганда, Урайский эш кушты:

— "Спартак" клубында хор түгәрәге әйбәт эшли, диләр. Барып кайт әле шунда. Якындагы санга репортаж бирербез.

Яшьлегендә опера жырчысы булган, ә хәзер берсеннән-берсе матур көйләр язган Сара Садыйкова хорын яратып тыңлый идем. Элегрәк концертларга йөри идек без. Әллә инде дөнья мәшәкате басты — айга бер театрга барсак, атнасына бер кино карасак, шуңар да канәгать булабыз.

Телефоннан шалтыратып белештем. Хорга йөрүчеләр эштән соң сәгать бишләргә, алтыларга гына жыелалар икән. Болай булгач, бүген дә өйгә вакытында кайтып булмый бит. Шәрәфнең тагын кашы жимерелер инде. Әллә үзен кисәтеп килимме соң?

Төшке аш вакытында шул ният белән урамга чыккач, икеләнә калдым. Гаепле кеше кебек нигә акланам соң әле мин? Башына шундый әшәке уй кереп утырган икән, ышаныр дип беләсеңме син аны? Күңелем тулы болганчык уйлар, язгы ташу вакытында елга тутырып аккан чүп-чар кебек, берсе өстенә берсе өелә. Өйгә кайтыргамы, әллә кире керергәме, дип атлый торгач, Лобачевский урамына борылуымны, тауны менеп, Ленин урамына чыгуымны сизми дә калганмын. Һавада озаграк булу өчен шулай урау юл сайладым дип уйлаган идем. Хатип абыйлар өе янына килеп житкәч кенә нинди максат үземне әйдәп китергәнен аңладым. Редакциядә югалтсалар югалтырлар, керим әле, сөйләп бирим әле борчуларымны. Алар безнең тормышны беләләр, хәлне аңлыйлар. Алардан яшереп торуның хажәте юк, якын туганың белән сөйләшкән кебек ачылып китәргә була анда.

— Шәрәфнең бер дулап ала торган гадәте бар инде. Үзең дә беләсең, ачу сакламый бит ул, — дип юатты Хатип абый Госман. — Сиңа бәйләнүе дә пар чыгару өчен генә булыр. Кызулык белән әйтеп ташлаган да хәзер ничек чигенергә белми. Мишәр бит. Ләкин аны да аңларга кирәк, — диде ул, һөжүмне миңа күчереп. — Син язучы кеше, аны син аңламасаң, кем аңлар? Ижат газабы кичерә ул. Съездагы тәнкыйтьтән айный алмый.

— Бигрәк озакка китте шул.

— Тәнкыйть майлы ботка түгел, күпкә китсә, ботка да туйдыра. Тәнкыйть ул әкренләп тәэсир итә торган агу кебек, үтереп тә бетерми, терелтеп тә жибәрми. Савыгыр әле. Көчле егет, андый гына хәлләрне башыннан кичергән кеше.

— Үзе белән сөйләшер идегез, Хатип абый. Бер-беребезне аңларлык дәрәжәдә түгел әле без.

— Бүген барып чыксам, өйдә булырмы соң?

— Өйдә, өненнән чыкмаган аю кебек, тәмәке суырып ята. Минем үземнең генә редакция йомышы белән барасы жирем бар.

— Хатыннар булмаганда ике ир сөйләшү жиңелрәк. Булдыра алсаң, озаграк тор. Йә кинога кереп чык шунда, — дип, шаярып бетерде сүзен Хатип абый.

"Спартак" аяк киемнәре комбинатының Бауман урамындагы клубыннан сәгать сигезләрдә генә чыгып китә алдым. Кич буе жыр тыңлап күңелем нечкәргән иде, көндез эштә, кич клубта дигәндәй, яшьләрнең дәртләнеп йөрүләренә кызыгып утырган идем. Сара ханым Садыйкова белән танышу минем өчен үзе бер вакыйга иде. Урамга чыгуга йөземә салкын жил бәрелгәндәй булды: өйгә кайтып керәсе бар бит әле.

Хатип абый кинәшен тотып, берни булмагандай, авыз-борын салындырмыйча кердем мин өйгә. Җыелмаган өстәл өстен күреп, Хатип абыйның килеп киткәнен аңладым.

— Кунак бар идеме әллә? — дип сораган булдым, Шәрәф янына кереп утыргач.

— Хатип килеп китте.

— Ни эшләп йөри соң?

— Болай гына. Хәл белергә дип килгән. — Ул, ниһаять, алдындагы кәгазеннән башын күтәрде. — Якшәмбедә Аккош күленә баралар икән. Пионер лагерендагы малайларының хәлен белергә. Безне дә чакырды.

— Ни эшләрбез икән соң?

— Барырбыз дип әйттем. Бу ел җәйне күргән юк бит әле.

Якшәмбе иртәсендә Кольцодагы балык кибете янында очраштык. Уртак дусларыбыз Ләйсән белән Баян Гыйззәт тә килгән. Ирләр кибеткә кереп чыктылар. Юл өстендәге базарга төшеп, балыкчы кәрзиненнән тупырдап торган эре балыклар сайлап алдык. Җәй көне шәһәрдә бездән башка кеше калмагандыр, дисәм, автобус тукталышында кара яу кебек халык төркемен күрдем. Машина килеп туктауга, этешә-төртешә, кычкыратиргәшә, штурм белән яулап кереп утыралар. Шушы тамашаны читтән карый торгач, рәттән өч автобусны үткәреп җибәрдек.

— Болай булмый, егетләр, — диде тәвәккәл Баян, кулындагы сумкасын Шәрәфкә биреп, юл уртасына чыгып басты. Каршына бер иске "Запорожец" килеп туктагач, шофер белән сөйләшеп алды да безгә кул изәде. Машинага кереп утырыштык. Шәрәф белән Баян автобуска калдылар.

Иртә уңмаган кич уңмас, дигәндәй, юлда озак маташа торгач, Хатип абыйлар малайлары белән очраша алмадылар. Отрядлары белән урманга киткәннәр, төшке ашка гына кайтачаклар икән. Ярый әле, Шәрәфләр озак көттермәде, аларга ияреп Шәйхи Маннур да килгән булып чыкты. Маннурлар язучыларның Аккош күле буендагы дачаларында яшиләр икән. Шәһәргә кайтып килүе булган да юлда безнекеләр белән очрашкан.

— Тирән күлнең аргы башына барыгыз, анда матур урыннар бар, — дип киңәш итте ул, аерылып китешли.

— Шәйхи абый, Тәгъзимә апа белән икегезне ухага көтәбез инде, — дип калдык без аны озатканда.

— Маннур да картая, җилкәләре салынган, — диде Баян, салмак кына атлап киткән шагыйрь артыннан карап калды.

— Еллар түгел, дөнья баса ир асылларының җилкәсен, —диде Шәрәф аңа каршы.

Теге елны Кремльдә узган зур җыелыштан соң да Шәйхи абыйга тәнкыйть кусәгеннән шактый татырга туры килде әле. "Тартай арбасы"ның җиле тиз генә басылмады. "Озын яза, юл артыннан куа", дип бәйләнүчеләр дә булды. Ләкин аның талантлы, олы шагыйрь булуын танымый хәлләре юк иде. Әнә, СССР язучыларының икенче съездына делегат итеп сайладылар үзен.

Артык ерак та китмәдек, җайлы урынга очрап, шунда туктарга булдык. Кояш дисәң, кояшы житәрлек, күләгә яраткан кешегә күләгәсе бар, иң әйбәте шул — кеше аяк асты түгел, ял итәргә килүчеләр күлнең бу ягына чыкмыйлар икән, дөнья безгә генә калгандай иркен, тын, тыныч.

Ухага дип су буеннан бәрәңге әрчеп менешемә култыгына шахматын кыстырган Шәйхи абый да килеп житте. Язучылар арасында аннан да оста уйнаучы юк. Шахмат клубының иң актив әгъзасы ул. Нәҗметдиновның үзе белән көч сынашкан кеше. Шуны белә торып Шәрәфнең уйнарга утыруына аптырадым. Мин бу ярышның ахырын күз алдына китерәм инде. Шәйхи абый аны ике йөрештә тар-мар итәчәк. Ярый ла, акылы булып, Шәрәф гарьлеген тыеп кала алса, берәр күнелсезлек китереп чыгармаса. Алар каен күләгәсенә кырын ятып, шахмат тактасына фигуралар

тезә калдылар, Хатип абый белән Баян да, кызыксынып, яннарына килеп утырдылар, уенның барышын күрәсем килмичә, мин су буена төшеп киттем.

Су өстенә карап утырырга яратам мин. Аның да бит кеше җаны кебек төрле вакыты була. Кояш баеган чакларда, алтынсу нурлар чагылышында ул бик ямансу, сагышлы, яшьлеген уйлап офтанган карт кебек моңлы тоела. Иркә дулкыннарның, пышылдап, яр буе комнарына сер сөйләгәнен, мәхәббәт җыры көйләгәнен дә тыңлаганым бар. Бик усал вакытын да беләм мин суның. Җилле бер көнне, яр буенда көймә көтеп утырганда шомлы музыка тыңлагандай әсәрләнүемне хәтерлим. Елга өсте кап-кара иде. Кургашындай кара дулкыннар ишелеп-ишелеп киләләр, ярсып чапкан атлар кебек ак күбекләр чәчәләр, умырып-умырып яр буе балчыгын ашыйлар иде. Ләкин бүген минем арыган, алҗыган йөрәгемә мәхәббәт җылысы да, үткәннәргә алып киткән сагыш та, ашкындыра, шаштыра торган ярсу көч тә кирәкми. Бушап калган җаныма күл өстенең тыныч, ваемсыз йөзенә карап утыру, озын аяклы энә каракларының тәкәббер генә атлап йөрүләрен күзәтү генә дәва була алыр кебек.

— Ләбибә! Тиз генә менмәсәң, ухадан коры каласың! — дигән авазга сискәнеп киттем, теләр-теләмәс кенә урынымнан тордым.

Ирләрнең сүзләре әле һаман шахмат тирәсендә бара икән.

Шәйхи абыйның:

— Шигърияттә көч сынаша алсак та, шахматта буының сыек икән, — дигән сүзеннән уенның ничек тәмамлануын аңларга була иде.

— Бәхәсләшмим. Мин бит сиңа пар кирәккә генә утырдым. Болардан алай да булмый ул, — дип, Шәрәф Баяннарга карап куйды.

— Сүзегез бетәме, юкмы? Ризыкның тәмен җибәрәсез, — диде хуҗабикә роленә кереп алган Марфа.

— Икегезгә бер савытка салам, серләрегез берексен, — диде ул, хуш исле балык шулпасын алдыбызга куеп.

— Аларның сере болай да бер инде. Син аны Ләйсән белән миңа телә, — дип, Баян хатынына карап елмайды.

— Безгә нәрсә булган! — диде Ләйсән, үпкәләмичә.

— Минем хатын матур киенергә ярата, ә миңа китаплар кирәк. Кулга акча кергән саен тарткалашабыз.

— Нинди бәхетле сез, егетләр! Кадерен генә белмисез, —диде Шәйхи абый. Аның тавышында һәм күзләрендә бик тирәнгә яшеренгән сагышмы, борчумы, әрнү дип әйтимме, газаплы бер кичереш сизелә иде.

## Иң мөкаддәс нәрсә — эш

"Ике хатын бергә килсә — базар, өчәү булса — ярминкәгә әйләнә" дип юкка әйтмиләр. Нәшрият буфетында, төшке аш вакыты житсә, нәкъ шулай була. Ирләр дә хатын-кызлардан калышмый монда. Кара-каршы бүлмәләрдә утырып эшләгән, әле машбюрода, әле китапханәдә, әле тагын кайда көненә әллә ничә тапкыр очрашкан кешеләр, гомер күрешмәгәндәй, туктаусыз сөйләшәләр, кычкырып көләләр, телләрендә җор сүз, кызык анекдотлар.

Буфетчы хатынның:

— Бака туе ясамагыз! — дип шелтәләве дә файдасыз. Кешеләрнең көне буе басылып эшләп утырганнан соң сулышлары кинәеп, таралып алган мәлләре.

Эшемне бетереп төшкәндә чират буфет ишек төбеннән үк иде. Борылып китәргә ниятләп торганда Суфия апа күреп алды һәм мәгънәле итеп күз кысты. Янына барып басуыма арттан берәү:

— Чиратсыз кертмәгез, — дип ризасызлык белдерде.

— Чираты бар аның, бар, миңа алырга кушкан иде, — диде Суфия апа, күз дә йоммыйча.

Әйбер урлап тотылган кешедәй читенсенеп торуыма җиңемнән тартып алдына бастырды.

Салкын котлет белән винегрет һәм бер стакан томат согы алып, ишек янындагы өстәл артына кереп кысылдык.

Бераздан яныбызга Зәки килеп утырды.

— Ни хәл, кызлар! Бот кашып утырасызмы? Ха-ха-ха!

— Тәрбиясез. Янында ханымнар утыра, — диде Суфия апа, үпкәләп.

— Нәрсә әйттем әле? — диде Зәки, гөнаһсыз кешедәй. —Ботка ашап утырасызмы, дидем. Аның ни гаебе бар?

— Нәрсә ашаганны күрмисеңмени?

— Күрәм, винегрет — кәҗә боткасы инде ул.

Ишектә Бибарсова күренде. Нәрсә беләндер тулган зур сумка күтәргән. Икенче кулында уты сүнгән тәмәке.

— Кеше күп икән. Ашарга өлгереп булмас, ахры, — диде ул, бусагадан узмыйча.

— Иртәрәк киләләр аны.

— Нәфесемә булышып, карлыганга чират тордым шул.

— Мәгъмурә апа! Кайда саталар аны? Кеше күпме?

— Яшелчә кибетендә. Өч җирдә үлчиләр. Чираты тиз уза.

— Киттем, Суфия апа. Редакциягә менсәм, вакыт әрәм, янында булса, акча биреп тор, кайткач та кертермен.

Кагыйдә дигән нәрсәнең "К" хәрефен дә бозарга яратмаган Бибарсова сумкасын көчкә күтәреп баскычтан менеп китте, мин үз юлыма йөгердем.

Кичен, эштән кайткач, карлыганны чүпләреннән араларга утырдым. Җәй үтеп бара, ә минем кышлык өчен берни дә әзерләгәнем юк әле. Варенье гына булса да кайнатып куйыйм, ичмасам.

Чүпләнеп утырганда, ни өчен икәнен үзем дә белмим, кылт итеп Абдулов искә төште. Секретарь кульязмасын кабул итмәгән иде, кызарынып-бүртенеп керде дә кәгазьләрен өстәлгә ташлап, телефонга ябышты. Кемнендер номерын кат-кат җыйды, ләкин җавап бирүче булмады. Кәефе тагын да ныграк кырылып, бүлмәдән үк чыгып китте.

— Пешергәннәр, ахры, моны, — дип калды Сәхаб абый аның артыннан.

— Пешерерсең аны!

"Шул кеше дә газетта эшли бит әле", — дигән уй килде башыма. Җитмәсә яшьләр газетында, җитмәсә сәясәт бүлегендә. Летучкаларда исеме телдән төшми. Язганнарын төзәтә-төзәтә Зәкинең җаны чыга. Кулына тоттырып кына җибәрер иде, коеп куйган демагог икәнен белә. Бәйләнеп кара син аңа! "Орденлы фронтовикка көн күрсәтмиләр", — дип, дөньяны сасытыр. Кеше фәрештә түгел, тырнак астыннан кер эзләсәң, табыла. Идият кебекләр оста андыйга. Гайбәтчеләр теленә кереп, берәүнең дә исемен пычратасы килми. Ә бүген Зәки түзмәгән, язган хәбәрен сызгалап бетереп, кире биреп чыгарган.

Шуларны уйлап, яныма Шәрәфнең килеп утыруын сизми калганмын, сискәнеп киттем.

— Куркыттың бит!

— Бераз булышыйм үзеңә, — диде ул, уч тутырып кара карлыган алды. — Бигрәк эре, чия хәтлеләре бар.

— Бәясе дә эре шул аның.

— Хәерченең акчасын арзан товар бетерә, алсаң шундыйны ал инде ул.

Беравык дәшми генә эшләп утырганнан соң Шәрәф:

— Бик каты уйга калдың, берәр хәл булдымы әллә? — диде, кызыксынып.

— Абдуловны әйтәм әле. Чиле-пешле әйберләр белән секретариатны туйдырып бетергән иде, Зәки кызык итте үзен. Материалын кире борып чыгарды.

— Шушы карлыган чүбе кебек итеп кенә алып ташлап булмый бит шуларны, — диде Шәрәф, йөзе каралып китте.

— Андыйларга тиеп кара син!

— Тигән идем дә, таякның юан башы үземә төште. Халитның чыгышын ишеттең бит. Безнең системада андыйлар була алмый, имеш. Редакциягә килгән аноним әләкләрне беләме икән ул? Ертып ташланган хатлар белән кайсы көннәрне чүп кәрзине тула.

— Андый хатларда да дөреслек бар дип әйтәләр бит. Игътибар итәргә кушалар.

— Шулай итеп үрчетәбез инде Ялаяповларны.

— Йә, тагын кыздың инде. Кем нәрсә әйтмәс. Хикәяңне укучылар яратты бит, никадәр хат алдык. Матбугатта уңай рецензия булды, җыентыгыңа керде, — дип, юатырга тырыштым.

Шулай да тиз генә тынычланып китә алмады Шәрәф. Абдулов турында юкка сүз кузгаттым, дип үкенеп куйдым.

Аккош күлендә ял итеп кайтканнан соң Шәрәфнең йөзе бераз ачылып киткәндәй булса да, сизеп торам, әле дә җанына тынычлык таба алмый, газаплы уйлар һаман да бәгырен кимерә, кан саудыра. Ә үзе шуны миңа сиздермәскә тырыша, эчтән кичеренә. Иртән өстәлен тәртипкә китергәндә аркылы-торкылы сызылган шигырь юлларына ясалган тырпайган колаклы кеше башларын, ереле-ваклы шүрәле сурәтләрен күрәм. Аяк астында йомарлап ташлаган кәгазь битләре ята. Эшли алмый интегеп утыруның галәмәте бит инде бу. Тән газабы гына түгел икән ул җан газабы. Тән газабына мең төрле дәва бар, ә җан газабына кайдан алырга?

Шәрәф кулындагы карлыганны савытка кире салды, бүлмәсенә кереп тәмәке алды да тышка чыгып шактый торып керде.

— Берәр җиргә барып кайтырга кирәк, — диде ул тагын яныма килеп утыргач. — Дөнья күреп, жилләнеп кайтсаң, әйбәт булыр иде. Өй белән редакцияләр арасында йөреп сөрсеп барам бугай инде. Башка бер рәтле уй килми, эшләп булмый.

Аның сүзен бик тиз күтәреп алдым:

— Авылга барып кил. Балаларны да алып кайтырсың. Алар булмагач күңелсез.

— Балаларны Сания китерер. Хат язармын. Авылга кайтуның әлегә кызыгы юк. Ел да булам мин анда. Бу юлы ераккарак китәсем килә.

— Сугышта йөргән юлларыңны сагынмыйсыңдыр бит?

— Ул да авыр истәлекләр генә уятыр.

— Белмим шул, котыпка барсаң гына инде, — дип шаярттым. Шәрәф тә елмаеп куйды.

— Ак аюлар янынамы? Расих Уральскига барырга киңәш итә.

Шәрәфнең элек тә бу турында сүз башлаганы бар иде, ныклап торып уйлану гына җитмәде. Әйтелде дә онытылды. Бу юлы ниятенең катгый икәнен тиз аңладым. Юк, дустының киңәшен тоту гына түгел иде бу. Күрәсең, күптән хыялланып йөргәндер дә, хыялындагын дөрләтеп җибәрүче генә булгандыр Расих. Шәрәфнең Тукай шигъриятенә мөкиббән икәнен беләм мин. Еш кына Кырлайга барып кайтуы да шуннан. Дөрес, анда безнең дусларыбыз Әнәс белән Рәшидә Кариевлар яши. Әнәс тә шигырьләр яза, Рәшидә урта мәктәптә ана теле һәм әдәбияты укыта. Очрашсалар сөйләшеп сүзләре бетми. Ләкин анда Сәгъди абзыйның ятим Апушны сыендырган җылы өе бар бит әле, шүрәле урманнары бар, Тукай бәләкәй чакта утыртылган каеннар гөрләп үсә. Аларны ничек барып күрмисең дә, шулар турында ничек илһамланып сөйләшмисең. Безнең китап киштәсендә, кул сузымында гына, Тукайның сугышка хәтле басылган кара тышлы калын китабы тора. Истәлекле китап ул.

— Хатип мине алгы сызыктан, окоптан килеп тапты. "Фронт хакыйкате" дигән газетка эшкә чакырып: "Сине эзләп озак йөрдем", — ди. Өс-башы керләнгән, үзе ач. Биштәрендә Такташ белән Тукай томнарыннан башка ипи валчыгы да юк", — дип сөйләгән иде Шәрәф бервакыт. —

Немецлар төнлә куркалар, бертуктаусыз яктырткыч ракеталар җибәреп торалар. Шуның яктысында таң атканчы Тукай шигырьләрен укып утырдык. Взводта бер-ике татар солдаты да бар иде, алар да килде. Шул китапны Хатиптан ялына-ялына сорап алдым. Вакытлы гына дип биргән иде, соңыннан әллә онытты, әллә менә яхшылык эшлисе килде, кабат исенә төшермәде.

Бу көннәрдә мин ул китапны Шәрәф кулында бик еш күрә идем. Элегрәк тә эче пошкан вакытта саф энҗеләр тезелгән битләрне актаргалап утыра иде. Юкка булмаган икән. "Татарның бөек гражданины" дип әйтә ул Тукайны.

Шигъриятең турылардан
турырак бер юл табып,
Караңгы төн караңгысын
яшендәй ярган, Тукай! —

дип язды ул аның турында. Атаклы "Кисекбаш" үрнәгендә "Янки базары яхут яңадан яңа Кисекбаш" памфлетын иҗат итте. Аеруча яраткан авторлары бар аның. Байрон шигырендәге ярсу дәртне, Гашекның мөлаем, йомшак юморын, Ильф белән Петровның әче сатирасын ярата. Ләкин табыну дәрәҗәсенә җитеп олылаганы бердер, икедер. Шуларның да беренчесе, әлбәттә, Тукай.

Шәрәфнең үзеннән дә бигрәк тырышып, аны юлга әзерли башладым. Бер көнне кибетләрне йөреп чыктык. Шәһәр мәктәпләренең китапханәләренә дип бик күп китаплар җыйдык. Бүләккә кара бәрхет түбәтәйләр алдык. Заманында аны Тукай да кигән. Безнең язучылардан да бер ишесе шундый түбәтәйдән йөри. Килешә үзләренә. Төшкән җирендә чәй эчәрләр дип, чәк-чәк катырырга уйлаган идем. Төшке ял вакытында, бал алырга колхоз базарына йөгердем. Хөкүмәт эшендәге хатын-кызның хәле билгеле инде. Тын алырга да вакыты юк. Төшке ял җиткәнен көтеп кенә тора. Кемгә ял, ә аңа икенче смена эше башлана. Ике кулына ике сумка тотып тегендә чаба, монда йөгерә, "Фигаро там, Фигаро тут" дигәндәй, әле базарда, әле кибеттә күрәсең аларны. Парикмахерына кереп чыгарга да өлгерә, ательеда күлмәк тә кистереп кайта, аяк өсте генә капкалап ала да төп эшенә утыра. Минем дә хәлем шундый. Сөйләп торасы юк.

Азык-төлек базарына кереп җитәрәк вак сәүдәгәрләр утыра. Алларына капчыкмы, брезент ише әйберме җәеп салганнар да шунда вак-төяк тимер-томыр тезеп куйганнар. Алар анда төпләнгән кебек, көннең кай вакытына килсәң дә очратып була. Урыннары да билгеле, берсенекен икенчесе алмый, исемнәрен дә беләләр. Берәр кешегә шөрепме, гайкамы, су краны кебек әйберме кирәк булса, сукыр Садыйктан, йә аксак Шакирдан барып таба. Биредә авыр эшләргә ярамаган сугыш гарипләре утыра. Өйдә күз көеге булып ятасылары килми, акмаса да тама дип, әз-мәз акчага да риза булып йөриләр. Узганда-барганда мин дә алар байлыгына күз төшереп киткәлим. Кирәк әйбер чыгып куя. Бүген менә башка әйбер түгел, ярты кило бал гына кирәк юкса, әмма "чир китсә дә, гадәт китми" диләр бит, ни ашыксам да аягым шул абзыйлар ягына тартты. Тәбәнәк урындыкка җәелеп утырган сыңар куллы таза гына абзый алдында яткан өч-дүрт китапны тартыбрак китерде. Китап дигәндә тыныч кала алмыйм. Кулыма тотып, битләрен актаргалап карасам да күңелем була. Кайчагында бер тиенгә тормаган макулатура арасында көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмаслык кыйммәтле басмалар да очрап куя. Күңелем сизгән икән, килеп туктауга ук "Уральск шәһәренең юлкүрсәткеч белешмәсе" китабына күзем төште. Шатлыктан йөрәгем еш-еш тибә башлады. Кабаланып китапка үрелдем. Әйтерсең лә, артымда шул китап өчен унлап кеше чиратка баскан.

— Күпме сорыйсың?
— Күпме бирәсең соң?
— Өч сум җитәме?

— Сез нәрсә, ханым? Шундый китапны өч сумга бирергә... Сораган кешем бар. Хәзер килеп җитә ул, алсаң алып каласың...
— Биш сум.
— Ярар, миннән булсын яхшылык, — диде агай, зур казага калгандай йөзен чытып. — Игелеген күр.
Бал алырга акчам җитмәвен белгәч, китап сатучы агай белән озаграк сатулашмавым өчен үкенеп куйдым, бик сорасам, өч сумга да биргән булыр иде әле. Шулай да өйгә кош тоткан кебек кайтып кердем мин.
— Күзенне йом, — дидем Шәрәфкә, китапны сумкадан чыгарырга ашыкмыйча.
— Ни булды тагын?
— Йом инде, йом!
— Йә, йомдым, ди.
Китапны алып, борын төбенә үк китереп куйдым.
— Инде ач, кара, менә нәрсә алып кайттым мин сиңа.
Шәрәф аны әйләндереп карады да исе китмичә генә:
— Монда язганнарны әдәбияттан укып беләм инде, — дип куйды. — Кырык алтынчы елда чыккан җыентык бу. Искергән дә.
Аның битарафлыгы хәтеремне калдырды калдыруын, шулай да бирешергә исәбем юк әлегә.
— Иске булса ни. Безнең географлар сәяхәткә чыгар алдыннан иске китапларны өйрәнәләр. Яңасын алар үзләре барып та күрә алалар.
— География җене китмәгән икән әле синнән.
— Географиянең "Г" хәрефе дә калмады инде. Эшләмәгәч, онытыла икән ул.
— Син әдәбиятның "Ә" хәрефенә ныклапябыш.
— Бернәрсәгә дә ярамыймы инде бу китап? — дип куйдым, биш сум акчаны җәлләп.
— Алай димим. Кайбер белешмәләрне алырга була.
— Рәхмәт әйт, ичмаса.
— Рәхмәт ярым рәхмәт, — диде Шәрәф, эре тешләрен күрсәтеп көлеп куйды. Әз генә җинел булып китте.

## Сәхнәдә уйналмаган комедия

Ашыгуыбызга карап кына Шәрәф юлга чыгып китә алмады. "Бәндә юрый, Ходай юллый", диләр. Инде көнен билгеләп, билет алырга җыенып йөргәндә судка чакырып язу килде. "Чаян" журналында "Әбдүш Ялаяп" басылып чыккач Абдуловның исе китмәгән иде. Укымаган булгандыр, ахры. Кулында яшьләр газетыннан башканы күрмәссең, аның да үз әйбере басылган саннарын гына җыеп бара. Күп нәрсәне күрмәгәнгә, белмәгәнгә салынып уздырып җибәрә торган гадәте бар аның. Шәрәфнең "Көлке түгел" китабына бу хикәянең дә кергәнен белгәч, съездагы тәнкыйтьне исенә төшерде.
— Аның белән башка җирдә сөйләшерләр, — дип йөри иде, судка бирүен әйтүе булган икән.
Кызык бер эш булды ул. Эш түгел, менә дигән кәмит. Андыйны театр сәхнәсендә күрмәссең. Акча түләп керсәң дә...
Ул көнне эштән сорап киттем. Вакытым иркен иде, юл уңаеннан базарга кереп чыктым. Мин килеп җиткәндә Курчак театрына каршы йорттагы Молотов районы халык суды ишегә төбенә шактый кеше җыелып өлгергән иде. Кулымдагы каклаган казны күргәч, Фатих Хөсни:
— Әллә Шәрәфкә передача алып килдеңме? — дип кеткелдәп куйды.
Аның шаяруын Нәкый Исәнбәт элеп алды:
— Балалары күп инде, судья шуны искә алса, ярар иде, — дигән булды.

Абдулов үзе дә шунда икән.

— Тиешле җәзасын бирмәсәләр, ни эшләргә белермен! —диде, әдипләрнең шаяруын чынга алып.

Шулай көлешә-көлешә сөйләшеп торган арада безне хөкем залына чакырып алдылар. Зал дигәннәре җыйнак кына бер бүлмә. Әлегә хәтле мин "суд" дигән җирнең ишек төбеннән генә үтеп йөри идем. Инде менә эченә кереп утырырга да язган икән. Борынгы йортның берәр метрлы калын стеналары тыштагы эссе һаваны үткәрми, тәрәзәләренә дә кояш төшми, күрәсең. Гомумән, бүлмә шактый шыксыз, ялангач стеналарга хәтле салкын кырыслык биреп тора. Ни хәл итәсең, тантаналы кичәләр уза торган җир түгел шул инде бу. Хак белән хаксызлык тартышкан урын. Әллә шул тәэсир итте, әллә кыска җиңле юка күлмәктән булгангамы, чыерап киттем. Тәнем буйлап салкын дулкын йөгереп үтте.

Бер-берсенә беркетеп куелган каты утыргычларга урнашып та өлгермәдек, тәрәзә кырыендагы өстәл артыннан секретарь кыз торып:

— Басыгыз, суд килә! — дип боерды.

Яңадан кузгалып, судья белән халык утырышчыларын каршыладык. Судья урындыгына кереп утырган утызлар тирәсендәге кешене күргәнем бар минем. Язучыларның гомуми җыелышларында булгалый, консультация бүлмәсе тирәсендә очраштыргалый. Шигырьләр яза бугай. Бәлки әле, атаклы Кони кебек, үз һөнәреннән мавыктыргыч берәр әсәр язарга да хыяллана торгандыр. Әдәбиятка якын кеше булуы әйбәт, билгеле. Ләкин судны ничек алып барыр бит әле.

Дөресен, бары тик дөресен генә сөйләргә дип, гаепләнүче белән хаклык эзләүчене ант иттергәч, судья Шәрәфкә мөрәҗәгать итте. Башта рәсми-формаль сорауларга җавап алды. Аннан соң каралачак эшнең нидән гыйбарәт икәнен белдерде һәм Шәрәфтән:

— Үзегезне гаепле саныйсызмы? — дип сорады.

— Юк, санамыйм. Мин әдәби әсәр яздым. Героем тормыштан алынган, гомумиләштерелгән образ. Аерым шәхес турында белешмә түгел, — дип, сүзен башлады Шәрәф, бу әсәрне язу уе кайчан, ничек тууы турында кыскача гына сөйләп бирде. Шаһитлардан сорау алу да әллә ни кызык булмады. Иҗат кешеләренең бетмәс-төкәнмәс җыелышларында сөйләнә торган сүзләр иде алар.

Ниһаять, Абдуловка чират җитте.

— Шәрәф Мөдәррикнең пешмәгән бу әсәре миңа пычрак атудан тора. Бу пасквильне язучылар съездында да бик каты тәнкыйтьләделәр.

Абдулов кесәсеннән блокнот алып, калтырана-калтырана, битләрен актарып азапланды. "Әһә, менә ул!" — дип үз алдына мыгырданды һәм Гали Халитның җыелышта сөйләгән чыгышыннан өзек укый башлады.

— Мәсьәләгә якынрак килегез, без биредә съезд карарын тикшермибез, — дип, судья аны бүлдерергә мәҗбүр булды.

— Гафу итегез, — диде Абдулов, һәм, нәкъ хикәядә тасвирланганча, төче елмаюын йөзенә җәйде. — Минем турыда язылганын раслый торган документларым бар. Менә алар.

Гаепләүче кулындагы бер көлтә кәгазьне селкеп күрсәткәндә, бүлмәдәгеләр җитдилекләрен югалтып, кычкырып көлеп җибәрделәр.

— Тыныч кына утыруыгызны үтенәм, — диде судья, алдындагы кечкенә кыңгырауга кагылып куйды. — Ә сез, иптәш Абдулов, дәвам итегез.

— Рәхмәт. Мөдәррисов үзенең героен, ягъни мине, исемсез хатлар — анонимкалар язуда гаепли. Бер дә исемсез анонимка түгел, моны җавап хатлары алуым белән дәлиллим.

Дүрт-биш кәгазьне, карта уйнагандагы кебек итеп, өстәл өстенә берәм-берәм китереп салды Абдулов. Судья аларны укып чыккач, халык утырышчыларына да күрсәтте, үзара сөйләшеп алдылар, шуннан соң гына ул:

— Язганнарыгыз расланмады дип җавап алгансыз, — дип куйды.

— Анысы икенче мәсьәлә.

— Дәвам итегез.

— "Үз-үзен начар тотышы турында Ялаяповны эшләгән жирендә тикшергәннәр", дип тә язган. Бу да минем турыда. Менә ул жыелышның беркетмәсе.

Залдагылар ни тырышсалар да түзә алмадылар, дәррәү көлеп жибәрделәр. Суд кешеләре үзләре дә чак тыелып утыралар иде. Ләкин судья — закон кешесе. Дилбегәне кулдан ычкындырырга ярамый аңа. Ә залда бик хөрмәтле кешеләр утыруын белә, аларга да тупас кагыла алмый. Әмма закон закон инде ул. Закон сагында торган кешеләр һәрчак житди, гадел булу өстенә, кирәк чакта кырыслык та күрсәтә белергә мәжбүрләр.

— Иптәшләр, хөкем залында утыруыгызны онытасыз. Мин сезне чыгарып жибәрергә мәжбүр булырмын, — диде ул, тагын бер кисәтеп.

Шуннан соң да әле бүлмә һавасы көлүләрдән бер-ике тапкыр шартлап алды.

Хөкем карарын озак көтәргә туры килмәде. Мәсьәлә бәхәсле түгел иде. Ничек итеп уйласаң да, бер карарга килерлек һәм шулай булды да:

— Жинаять составы расланмау сәбәпле, эшне туктатырга!

Суд карары укылганда Абдуловка күзем төште. Ул кечерәеп, бөрешеп калгандай күренде. Болай да карсак кеше яман эш белән тотылган малай кыяфәтенә керде дә калды. Йөзе, хикәядә сурәтләнгәнчә итеп әйтсәк, "турнепс кебек агарган" иде. Зәңгәрләнеп торган юка иреннәре арасыннан:

— Мин сезнең белән икенче жирдә сөйләшермен, — дигән сүзләрне кысып чыгарды да каты-каты басып китеп барды. Без аны күз карашыбыз белән дәшмичә генә озатып калдык. Бу мизгелдә язучыларның йөзләрендәге һәм күзләрендәге шаян очкыннарны тирән уй, хафалану алыштырган иде.

Урамга чыккач Нәкый ага:

— Судьяның теңкәсенә тия әле бу бәндә, — дип куйды.

— Теге елларда шундыйлар житте инде бер гаепсез кешеләрнең башына.

— Бүген үк судьяның нәсел-нәсебен тикшерә башлый ул.

— Пычагым да кыра алмый. Ул заманнар үтте инде.

— Белмәссең...

Шәхес культы фаш ителгән вакытлар гына иде әле. Кешеләрнең күңел богауларыннан арынып яши башлаган мәлләре. Ижат кешеләре өчен бигрәк тә күк капусы ачылгандай булды. Жаның теләгәнне яз, күңелең уйлаганны әйт. Тик аңа карап, язучылар бик ашыкмадылар. Нәрсәдер тота иде кулны. Канга сеңгән куркудан тиз генә арынып булмый иде. Дус дигән кешең белән очрашканда да тәмам ачылып китеп сөйләшә алмыйсың. Шулай да жылы жилләрнең тәэсирен сизми тору да мөмкин түгел, судтан соң аерылып китәргә ашыкмаган әдипләрнең сүзендә дә шул нәрсә сизелә иде.

Мин яңадан эшкә барып тормадым. Шәрәф белән өйгә кайтып киттем. Бераз жир үткәч, артыбыздан Атилла абый куып житте.

— Институтка барасым бар. Моннан юл кыскарак, — дип, безнең урам аша китәргә булган.

Без аны чәйгә чакырдык. Ул сәгатенә карап алды, вакыт барлыгын белгәч, керергә булды.

— Ләбибә чәй кайнаткан арада юынып алыйк, — дип Шәрәф аны үзе ясаган душ бүлмәсенә алып керде.

Бүлмә дигәч тә, чоланның бер башын бүлеп алган кечкенә генә аралык инде ул. Түбәдәге бакны кояш жылыта. Теләгән вакытта жылы су белән коенып чыгу үтә рәхәт.

Озакламый самоварым гөжләп кайнап чыкты. Каклаган казны телемләп кисеп куйдым, яшел кыяр турадым. Ирләр дә килеп керде. Тазарынып, битләре алсуланып, чибәрләнеп киткәннәр.

— Закускаң әйбәт икән, тегесе бармы соң? — диде Шәрәф, өстәл өстенә карагач.

— Кирәкмәс, дустым, сәгать дүрттә гыйльми советка керәсем бар, — диде, көзге каршында юеш чәчен тарап торган Расих.

— Ярый инде, менә Уральскидан йөреп кайтыйм әле, бер әйбәтләп утырырбыз, сөйләшеп.

— Кайчан барырга җыенасың инде?

— Билет алырга йөргәндә бу мәшәкать килеп чыкты бит.

— Әйе, кызык кына булды ул суд дигәннәре.

— Абдулов кебекләр белән судлашып йөрү дәрәҗә түгел инде ул.

— Ни эшлисең, дөнья бит.

Расих белән Шәрәф күптәнге дуслар, мәсләктәшләр. Атилла абыйның да язганнары авырлык белән бара. Ләкин аңа тормыш итүе җиңелрәк. Ул фән кешесе дә, ветеринария институтында укыта, ай саен хезмәт хакы килеп тора. Ләкин аңа карап чын иҗат кешесенең җаны тыныч каламыни? Әдәби хезмәт аның сөекле баласы кебек. Бала язмышы ата-ананы борчыган кебек, иҗади эш тә язучының күңеленә шырпы булып кадалган, йөрәкне чәнчеп, авырттырып тора. Әдәби язмышларының тигез юлдан тәгәрәп бармауларын Атилла Расих, Әмирхан Еники кебекләр партиядә тормаудан күрәләр, Шәрәф тә партиясез. Әле хәзер дә юлда башланган сүз өстәл янында тагын дәвам итте:

— Партиягә керергә кирәк сиңа, Шәрәф, — диде Атилла абый, дустының зарын тыңлап утыргач.

— Син дә кермисең бит.

— Мине алмыйлар. Ишан оныгы бит мин. Әтием мулла булган. Беләсең бит.

— Минем дә артым чиста түгел шул. Галим Мөхәммәтҗановның туганы дип, кырыгынчы елны институттан кудылар.

— Аның каравы, әтиең чын большевик. Маргелан партия активында доклад сөйләгән вакытында инфарктан үлгән дип сөйләгәнеңне хәтерлим әле.

— Әтием әйбәт кеше иде, шуның өчен мине дә партиягә алыгыз дип булмый бит. Партияле булудамыни хикмәт! Намусың чиста булсын.

— Шулай анысы. Кызыл билет йөртүчеләрнең дә төрлесе бар, — дип килеште Расих.

— Фронт газетында эшләгәндә омтылып караган идем мин. Редактор йөземә суккандай итте. Каршында бер маңка малай басып торамыни! — дип сүзен дәвам итте Шәрәф, — "Мин сиңа рекомендация бирә алмыйм, баш редактор алдында оятка калдырдың. Хәрби уставны да санга сукмыйсың. Тәртипсез кешеләргә урын юк коммунистлар партиясендә", — дип акыл өйрәтә башлады. Күз алдында ук гаризамны ертып ташладым, бүтән беркайчан да бу турыда сүз кузгатмаска ант иттем.

Расихның стаканында чәй бөртеге йөзеп йөри, күзен алмыйча ул шуңа карап утыра, Шәрәфнең сөйләгәннәрен тыңламый да кебек. Ишеткән икән, сәерсенеп сорап куйды:

— Хәрби уставка буйсынмаган кешене трибуналга бирәләр. Синең белән андый хәл булмады кебек.

— Трибуналга барып җитмәдем анысы.

— Ни булган иде соң?

— Вак мәсьәлә. Сөйләп торырлык та түгел. Безнең редакция хезмәткәрләре барысы да офицерлар иде. Хәрби корреспондентлардан бер мин солдат булып калганмын. Шуны уйлапмы, миңа да ефрейтор званиесе бирмәкче булдылар. "Гитлер белән бер дәрәҗә йөрергә теләмим" дип, баш тарттым.

— Гитлер да ефрейтор булган шул.

— Сугышка солдат булып кердем, солдат булып тәмамларга язсын, мин әйтәм.

— Дошман пулясы өчен алгы сызыкта солдаты да, офицеры да бер иде. Теге дөньядагы кебек, барыбыз да бер тигез булдык анда, — дип куйды Расих.

Атилла абый китеп барганнан соң, дөнья хәлен белеп булмый, тагын берәр мәшәкать чыгып куюы бар дип, кинәштек тә Шәрәфне билет алырга жибәрдем.

Өч көннән мин аны Казан аэропортында озатып калдым.

— Самолет өч сәгать очачак, — диде Шәрәф. — Димәк, йөз сиксән минут. Ә Тукай бу араны унсигез көн барган.

Кызык чагыштыру иде бу.

## Безнең урамда бәйрәм

Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы була дигән хәбәр күптән йөри иде. Чынга аша бугай инде. Язучылар союзы идарәсендә бик бәхәсле жыелыш булган. Әзерлек мәсьәләләрен караганнар. Кемнәрнеңдер китапларын ашыгыч рәвештә бастырып чыгарырга , ниндидер әсәрләрне урысчага тәржемә итәргә булганнар. Декада вакытында тикшереләчәкләрен сайлап алганнар, докладчылар билгеләгәннәр. Бу көннәрдә нәшрият йорты гөжләп тора. Кемне очратма, шунын авызында бер сүз: декада. Берәүләр үз язмышын кайгырта. Анын да китабын чыгарырлармы? Ни өчен тәржемәгә бирмиләр? Докладларда исеме телгә алынырмы? Икенчеләре булачак бәйрәмне туй көткәндәй ашкынып көтә. Туйга әзерләнгәндә генә дә өйдә ыгы-зыгы куба. "Кунак килсә, таптыра, ат урынына чаптыра", диләр бит. Ә монда республика хәтле республика Мәскәү алдында хисап тотачак. Күңелгә төрле уйлар килә. "Татар барда хәтәр бар, тагын берәр хәл килеп чыгар әле", дип сөйләнеп йөрүчеләр дә күренә. Андый юраулар да нигезсез түгел. Татарстан декадага, шау-гөр килеп, бер тапкыр әзерләнде бит инде. Барабыз дип йөргәндә генә сугыш башланды да барысы да челпәрәмә килде.

Онытылырлык кына булмаган иде ул яз. Унынчыны тәмамлап чыгасы елыбыз иде. Әй, ул чактагы хыяллар! Кызларның күбесе врач булам, ди. Егетләр очучы һөнәренә кызыга. Тәлгать дигән классташыбыз филармониягә китәм дип йөри. Тавышы матур анын, чын артист кебек жырлый. Март башларында, декадага әзерләнүче үзешчәннәр белән бергә, аны да Казанга чакырып алдылар. Сөенечле хәбәр безгә Тәлгатьнең үзеннән алда килеп житте. "Кызыл Татарстан" газетында зур мәкалә басылган, үзешчәннәр смотрынын йомгакларын язганнар. Кукмарадан Тәлгать Бәширов дигән егетнең аеруча уңыш казануын әйткәннәр. И сөендек шуны укыгач, и куандык, кызлар, бер-беребезне кочаклап, бии-бии шатландык. Әйтерсең лә, үзебез турында шулай мактап язганнар. Соңыннан, Казаннан кайткач, Тәлгать барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде. Ул жырлагач, жюри әгъзасы Фәхри Насретдинов хәтта кул чабып куйган. Озакламый Тәлгать Казаннан хат алды. Ул хатны без кулдан-кулга йөртеп тә, бергәләп тә укыдык. Көн саен дип әйтерлек радиодан тавышы ишетелеп торган атаклы жырчы Фәхри Насретдинов Тәлгатьнең декадага барачагын әйткән, киләчәктә нинди юллар белән булса да музыкаль белем алырга киңәш иткән. Бу сөенечле көннәрдә тиздән сугыш башланасын да, егетләребезнең фронтка китеп барасын да белми идек әле без.

Шуннан бирле унбиш елдан артык вакыт үткән. Ниләр генә күрмәгән дә, ниләр генә кичермәгән адәм башы. Барыбер зурдан кубып бәйрәм итәргә әзерләнәбез. Тфү, тфү! Ул-бу чыгып кына куймасын инде.

Газетлар карыйм дип, китапханәгә кергән идем, Мөслихә белән "суган сатып" утырабыз. Язучылар союзы секретаре Хөршидә ишектән башын тыгып:

— Ләбибә, сине Гомәр абый чакыра, — диде дә шул минутта ук күздән югалды.

— Нәрсәгә кирәк булдым икән? — дип, сәерсенеп кенә бардым.

— Кер, Ләбибә, уз, — диде Гомәр Бәширов ишектә күренүемә, каршына килеп утырганчы миннән күзен алмады. Кеше төбәп караса,

уңайсызлана торган гадәтем бар. Ишек белән өстәл арасын сират күперен үткәндәй үттем. Гомәр абый йомышын тиз генә әйтергә ашыкмады. Сүзен хәлемне сорашудан башлады. Минем ничек яшәвем нигә кирәк булды икән әле Язучылар союзы председателенә? Мин бит союз әгъзасы түгел, бары тик яшь язучылар рәтендә йөрүчеләрнең берсе. Ә ул әкрен генә сораша да сораша: балаларымның яшьләрен белү дә кирәк аңа, гаилә мәшәкатьләренең редакция эшенә, язуыма комачау итү-итмәве белән дә кызыксына, сүз арасында "Шәрәф булышамы соң?" дип тә сорап куйды. Аның исеме чыккач, йөрәгем кысылгандай булды, чигә тамырым сугып куйды. Берәр хәл булмагандыр бит аңа? Союзга яман хәбәр килгәндер дә, Гомәр абый әйтергә кыенсынып утыра кебек тоелды. Уральскига киткәненә айга якын вакыт үтте. "Бу якларга бер килгәч, йөрим әле, Магнитогорски татарларын да күреп кайтасым килә, юл уңаеннан Алма-Атага төшеп, Жубан дус белән күрешергә дә исәп бар, бераз акча сал" дип язган хатыннан башка хәбәре юк. Болай да борчыла башлаган идем инде, Гомәр абый каршында утыру шигемне көчәйтте генә.

Соңгы вакытта үземдә сәер бер тойгы уяна башлавын сизәм мин. Таяныр талым, терәгем булырга тиешле кешемә балаларыма караган кебек карыйм түгелме соң? Озаграк кайтмый торса, "кайда йөри икән, бәла-казага юлыкмаганмы?" дип пошына башлыйм, үзем эш белән тоткарлансам, "суык өйдә туңып утыралардыр, карыннары ачтыр" дип кайгырам. Гомер иткән ирең шулай балаң кебек газиз була икән дип уйламый идем. Иренә булган мәхәббәт тә еллар үтүгә икенчегә әйләнә икән ул. Әйткән, ди, бит шулай бер хатын: "Биш балам артыннан җыештырып бетереп булмый, булышырга кызым да юк ичмасам", — дип. Аңа икенче берсе: "Ахирәт, синең балаларың дүртәү генә түгелме соң?" — ди икән. "И җанашым, бишенчесе ирем ул. Бер үзе дүрт балага тора", — дип җавап биргән, ди, тегесе. Шуның кебек, мин дә бөтен мәшәкатьне үз өстемә алып барам бугай инде.

Гомәр абыйның тагын нәрсәдер сорашырга иде исәбе, мин түзмәдем:

— Берәр эш бар идеме әллә? — дип сорарга мәҗбүр булдым.

— Без сине бик җаваплы эшкә кодаларга торабыз, үзең ни әйтерсең тагын, — диде ул, янадан бер сынап карап алгач.

— Нинди эш соң ул?

— "Пионер" журналына редактор итеп билгеләсәк, эшли алырсыңмы?

— Аның редакторы Абдулла Әхмәт бит.

— Абдулла абыең пьеса яза. Олы кешегә ике эшне алып баруы кыен. Балалар журналына яшьрәк кеше кирәк. Уйладык-уйладык та сиңа тукталдык.

— Бигрәк көтелмәгән эш бит әле бу, Гомәр абый. Киңәшергә Шәрәф тә өйдә юк.

— Ул кайчан кайта соң?

— Кайтырга тиеш иде инде.

— Аңа кадәр бер карарга килеп куй инде син. Без дә тагын бер кат уйлашырбыз.

Председатель яныннан чыгуга беренче эшем итеп редактор бүлмәсенә кагылдым. Редакция эшчесе бит әле мин. Алай-болай китәргә туры килсә, иң элек редакторга әйтергә тиешмен. Аннан соң Гали абый, Шәрәф кебек үк, акыллы киңәш бирерлек тә кеше. Тәҗрибәле журналист, эшнең рәтен белә. Мине дә сынап өлгергәндер инде. Мөмкинлекләремне чамалый алыр кебек.

Шундый өмет белән килсәм, редактор ишеге бикле булып чыкты.

— Мәгъфрүз, Гали абый кайда ул? — дип, янәшә бүлмәдә утырган машинисткадан сорадым.

— Командировкага китте бит ул.

— Кайчан кайта соң?

— Бер атнага диме...

— Шулаймыни-и?

— Зәкигә кер, аның урынына Зәки калды.

— Алай икән.

— Алай икән, өй түбәгез калай икән, — дип калды Мәгъфрүз артымнан. Беләмени ул минем хафаны, кара күзле шаян кыз.

Ул төнне мин рәтләп йоклый алмадым. Әллә ниләр уйлап, хыялланып беттем. Бераз шикләнсәм дә редактор булу кызыктыра иде мине. Йомышчы бала кебек, кеше кушканны эшләп йөрү түгел инде бу. Үз башың, үз фикерең, максатың булу мәҗбүри.

Мин ул редакциягә кергәләп йөрим, анда эшләүчеләрне беләм кебек. Килешербез төсле. Уйларның икенче төрлесе дә килә башка. Эшли алмасам? Журналның дәрәҗәсен төшерсәм? Гомәр абый да ышанып бетми кебек, тагын бер кат уйлашырбыз дип калды бит. Гали абыйның очрамавы хәерлегәдер әле. Булмаган эш турында сөйләп көлкегә калуым бар иде, алдан кычкырган күкенең башы ярылган кебек.

Вакыйгалар мин көткәннән тизрәк әйләнә башлады. Бер көнне партия өлкә комитетының культура бүлегенә чакырып алдылар. Ишек төбендә милиционер утыра иде. Бик озаклап, җентекләп партия билетымны карады. Битләрен ачып, взнос түләгәнме, юкмы икәнлеген тикшерде. Билетны кулыма кире тоттыргач, ничәнче катта, ничәнче бүлмәгә керергә кирәклеген әйтеп, честь биреп озатты.

Культура бүлегенең мөдире Шәмси Хамматов дигән кеше иде. Шәрәф яшьләрендә булыр. Шулай бервакыт сүз арасында Шәрәф аның шигырь белән мавыгуы турында әйткән иде. Дулкын кара чәчле, калын кысалы күзлек кигән, чандыр гәүдәле, шактый сөйкемле кеше иде ул. Ишеккә килеп каршы алды, кул биреп күреште, урын тәкъдим итте. Шундый мөгамәләдән бер баш үсеп киткәндәй булдым. Үз-үземә соклану дип әйтимме, горурлану шикеллерәк бер тойгы уянуын сиздем. Бу мина кыюлык бирде. Гомәр абый алдында утырган вакыттагы кебек икеле-микеле уйлар юк иде инде. Ни өчен чакыртканнарын беләм. Йокысыз төннең дә файдасы булгандыр. Мин инде ныклы бер карарга килгән идем. Эшли алмам дип тә артык борчылмыйм хәзер. Редакция эшен биш бармагы кебек яхшы белгән Шәрәф янымда бит. Үзем дә бер кадәр тәҗрибә тупладым кебек.

Хамматов белән сөйләшүе җиңел булды. Яшьләр газетыннан башланып киткән сүз әдәбиятка килеп ялганды. Мин аның әдәби процессны бик әйбәт белүен төшендем. Ахырдан сүз төп мәсьәләгә күчте.

— Мәскәүгә барып, комсомол үзәк комитетында расланып кайткач та эшкә тотынырсың. Иртәгә өлкә комитеты бюросында комсомоллар раслар, — диде ул, мәсьәлә хәл кылынып беткәндәй булгач.

Ә минем күңелдә байтактан бирле бер сорау кымырҗап тора иде. Шуны әйтергә дә кыюлыгым җитми, әле эшли башламаган, теләнергә тотынды дип уйлавы бар, әйтмичә дә мөмкин түгел. Редактор булып эшли башласам, өстәл артында гына утырып тора алмыйм бит инде. Командировкаларга йөрисе булыр, җыелышларның чуты-чиге юк. Аяккулым бәйле көе эшләп булырмы соң? Әле хәзер дә "Мәскәүгә барырга кирәк" дип утыра бит Хамматов.

— Шәмси Хәбибуллович, минем бер үтенечем бар иде, — дидем, ниһаять, батырчылык итеп.

— Фатир гына сорама, калганын үтәргә тырышырбыз, — диде ул, уены-чынын бер итеп.

— Әлегә фатир кирәкми. Салып кергән өебез бар.

— Ул яктан молодец Мөдәррис, ялынып йөрмәде. Йә, нинди үтенеч, тыңлап карыйк.

— Улларымны балалар бакчасына урнаштыра алмыйбыз. Якын-тирәдә урын юк.

Мөдирнең йөзе җитдиләнде. Бераз уйланып торганнан соң телефон трубкасын алды.

— Әминә Вәлиулловна, исәнмесез! "Пионер" журналының яңа редакторына ярдәм итәсе иде бит. Беләм, Мәгариф министрлыгының да органы икәнен белгәнгә сезгә шалтыратам да инде. Нинди үтенечме? Балаларын детсадка урнаштырасы иде. Рәхмәт. Юк, шикләнмәгән идем.

— Безнең өчен бик зур проблема иде ул. Ярдәм итүегез өчен рәхмәт!

— Уңышлар телим!

— Хушыгыз!

"Нинди әйбәт кешеләр бар дөньяда!" дип, күңелем булып чыктым мин аның яныннан. Югыйсә гел баштан гына сыйпап тормыйлардыр мондый җирдә. "Обкомга чакыралар" дигән сүздән пошаманга төшкән кешеләрне дә күргәләгәнем бар. Андый чакта беркатлылыгым белән, әйбәт эшләсәң, сиңа кем сүз әйтсен дип уйлый идем. Биш-алты ел да үтәр-үтмәстән, бөтенләй икенче шартларда аңлатма биреп утырасымны башыма да китерә алмый идем.

Өлкә комитетында туган тәэсирләремне кем белән дә булса уртаклашасым килә иде. Шунысы кызганыч, ни Шәрәф өйдә юк, ни Гали абый авылларда йөри. Бер-ике тапкыр Гомәр абый бүлмәсенә кагылып карадым.

— Килмәде әле ул, — диде Хөршидә.

Ә минем эчем тулы бимаза, хәзер кемгәдер сөйләмәсәм, әйтмәсәм, шартлармын төсле. Аптырагач Зәки янына кердем. Көтелмәгән хәбәр әйтеп шаккатырыйм әле, янәсе.

Озын аякларын өстәл астына сузып җибәргән дә ул көлә-көлә нәрсәдер укый. Керүемне сизмәде, ахры. Каршына килеп утырдым да уйнап-көлеп әйткәндәй генә:

— Озакламый сездән китәм инде, иптәш секретарь, — дидем.

— Хәерле юл, — диде теленә шайтан төкергән Зәки, башын күтәрмичә генә.

— Чынлап әйтәм мин.

— Башта менә моны укы, аннары китәрсең, — дип, "Комсомольская правда"ның "Клеветник узнает себя" дигән мәкаләсенә бармагы белән төртеп күрсәтте.

— Берәр указ бармы әллә?

— Хуже.

Стена буена тезелгән урындыкларның берсенә күчеп утырдым. Иркенләп укы, дигәндәй, Зәки бүлмәдән чыгып китте. "Комсомольская правда"ның корреспонденты булып эшләүче Казан язучысы Геннадий Паушкин Шәрәф өстеннән булган әлеге дә баягы суд турында язган икән. Укып чыккач эчемнән: "Дөньяга фаш иткән икән", — дип куйдым. Газетны калдырып чыгыйм дип торганда Зәки үзе килеп керде.

— Гена анда булмады бит, каян белгән? — дип сорадым аннан.

— Суд беркетмәсе нәрсәгә? Русча языла бит ул.

— Бу газетны миңа бир инде, Шәрәфкә күрсәтермен.

— Укыгандыр инде ул аны. Ал, әйдә, киргә чыгар. Кая китәм дип куркыттың әле син?

Башта әйткән сүз колагына кереп калган икән. Тыңламаган да кебек иде.

— "Пионер" журналына кодалыйлар.

— Беләм мин ул турыда.

— Гали абый да беләме?

— Ул да белә. Абзаннардан сорамыйча гына эшләнми андый эшләр.

— Хуплыйсыз болай булгач?

— Җигел, әйдә, сиңа да җитди эшкә тотынырга вакыт.

Өйгә кайтуыма почта ящигында Шәрәфнең "Каршы ал" дигән телеграммасы ята иде.

## Еллар һәм юллар

Уфада яңгыр булу сәбәпле,... номерлы рейс бер сәгатькә тоткарлана! Бу белдерүне баштарак күңел белән тыңламаган идем, кат-кат ишетә торгач, рейс санына игътибар иттем. Шәрәф кайтасы самолет турында белдерәләр түгелме соң? Ә нигә Уфадан килә ул? Нигә Магнитогорскидан йә Алма-Атадан түгел? Хатында: "Җубан Молдагалиев янына кереп чыгам", дип язган иде бит. Җубан белән бер үк фронт газетында эшләгәннәр алар, еллар буе бер купеда яшәгәннәр, ут астында алгы сызыкка барып йөргәннәр. Шул якларда булсын да, фронтташ дустының хәлен белеп кайтмасынмы инде? Бу бер сәгать миңа бер тәүлектәй озын булып тоелды. Ай буе сабыр гына көтеп тә соңгы сәгатьләрен үткәрүе кыен икән аның.

Күз күргән кешеләр очрамасмы дип, бар тирәдән әйләнеп килдем дә, очу кырын киртәләп алган рәшәткә буенда туктап калдым.



*Сулдан уңга: Шәрәф Мөдәррис, Габдрахман Әпсәләмов, Яков Ухсай, Әхмәт Исхак һәм Әхмәт Ерикәй.*

Яшел үлән каплаган искитмәле зур, тигез ялан өстендә, кара тасма булып, самолетлар очып китә торган юллар сузылып ята. Очкычларның бер ишләре гөрелдәп килеп төшәләр, берәүләре авыр гына кузгалып китәләр. Бик еракта кара үрмәкүчләр кебек, ике канатлы "У-2"ләр утыра. "Кукурузник" дип йөртелгән бу бәләкәй самолетлар бик таныш миңа. Үзем утырып йөргәннән түгел, канатларыннан этеп, фронтка очырып җибәргәннән беләм мин аларны. Ун еллап вакыт үткән, югыйсә, бүгенгедәй күз алдында үзе.

Төне буе бурап-бурап кар яуган иде ул чагында. Иртән торуга шәһәр урамнарын, күзне чагылдырып, ак кар көрте басканын күрдек. Трамвайлар йөрми, җәяү баруы да авыр, атлаган саен аяк яшь кар өстеннән артка шуа. Көч-хәл белән университетка барып җиттек, геодезиядән лекциягә чак-чак кына өлгердек. Ләкин профессор Дубягоның лекциясен тыңларга туры килмәде, аркадагы тир дә суынып өлгермәгән иде әле, безне машиналарга төяп, аэродромга алып киттеләр. Аэродромны кар баскан, самолетлар оча алмый, диделәр. Шулайдыр шул, монда машинабыз да чак кына бара. Буксовать итә башласа, сикереп төшәбез дә тәгәрмәч астыннан кар көрибез, артыннан этеп кузгатып җибәрәбез.

— Барып житкәнче арып бетәбез, көрәк тотарлык та хәл калмас, — дип сукрана кызларның кайберләре.

— Очучы егетләр белән кар атышып уйнарлык кына хәл калыр әле, — дип көлешә икенчеләре.

Барып житсәк, исләр китте. Бер без генә түгел икән монда. Әллә бөтен шәһәрне куып китергәннәр инде. Ак кар өстен, кара чебен кебек, халык сарган. Леля белән икебезгә бер көрәк биреп, безне дә корсагына хәтле карга чумган ике канатлы бәләкәй самолет янына бастырдылар. Алмаш-тилмәш кар көрибез. Киевтан эвакуацияләнеп килгән Леляның көче юк, кечкенә гәүдәле, ябык кыз ул. Карап торганы — стипендия дә, биш йөз грамм ипи. Шуңа күрә тиз арый. Көрәк күбрәк минем кулда. Миңа да жиңел түгел, эшебез әкрен бара. Житмәсә, салкынча саф һава үтереп ашыйсын китерә башлады. Ашказанының сулкылдавын басар өчен учлап кар кабабыз. Шундый бер мәлне, бот төбеннән озын унта кигән, очучылар киемендәге берәү яныбызда туктады да:

— Ашамагыз, салкын тигерерсез, — дип, кулымдагы карны кагып төшерде. Куенына тыгылып, бер плитка шоколад алды, аны икегә бүлеп, берсен Леляга, берсен миңа сузды. Кыстатып тору кая, рәхмәт әйтергә онытмадык микән әле. Аннан соң ул безне, кечкенә балаларны күтәргәндәй, жиңел генә күтәреп, самолет канатына утыртып куйды.

— Әзрәк ял итегез, — диде, ә үзе карга кадап куйган көрәкне алып, кызу-кызу эшли башлады.

И ул биргән шоколадның тәмлелеге! Мин аның исемен дә белми идем әле. Тәмле конфет дип әйтүемә Леля:

— Шоколад ашаганың юкмыни? — дип сорады.

— Юк шул. Авыл кызы бит мин. Ипи белән бәрәңге инде анда.

— Әйтмә, әйтмә, авыздан сулар китерәсең, — диде Леля, шоколад маена буялган бармакларын ялый-ялый.

Шул исемә төшкәч, "У-2" ләргә тагын бер кабат карап куйдым. Гомеремдә беренче тапкыр шоколад ашаткан бу очучы сугыштан исән-имин кайта алды микән? Кайткан булса, хәзер кайда яши икән? Әле һаман шул эшендәме икән?

Ниһаять, көтеп алынган рейсның очу полосасына кабул ителүен белдерделәр. Күз ачып йомганчы кырга чыга торган ишек төбенә халык жыелды. Һәркемнең, алданрак житешеп, көткән кешесен тизрәк күрәсе килә иде. Мин дә шунда барып кысылдым.

Самолеттан кешеләр төшеп бетә иде бугай инде, берән-сәрән генә чыга башладылар. "Утырырга өлгермәгәнме әллә?" — дип уйлавым булды, ике кулына шактый зур ике сумка тотып чыккан Шәрәфне күреп алдым. Менә ул траптан төште, бер сумкасын жиргә куеп, артыннан килгән ханымга кулын сузды, жайлап кына жиргә төшәргә булышты. Менә алар, көлешә-көлешә сөйләшеп, ашыкмый гына, чыгу юлына борылдылар. Секундның ничәнчедер бер өлешендә йөрәгемне көнләшү кебегрәк нәрсә чәнчеп алды. Шунда ук аны: "Кем булыр бу?" — дигән кызыксыну алыштырды. Ара якынайган саен ул миңа кемнедер хәтерләтә кебек булды. Жәмилә түгелме соң бу? Юктыр ла, каян килеп ул булсын. Күзләремә ышанмыйм, Жәмилә шул! Билләһи, Жәмилә! Яныма килеп туктауга Жәмиләнең:

— Башкорт жирендә адашып йөргән картынны кайтара килдем. Кабул итеп ал, — дип әйтүе дә элеккечә, киналәле, уены-чыны бер булып ишетелде.

Ул Шәрәфнең аркасыннан жиңел генә этеп жибәрде дә тегесе, сумкалары-ниләре белән, кочагыма кереп сыенды. Мин аларның кайсысына карарга, кемгә башлап сүз әйтергә белми торганда:

— Жә, минем белән дә күреш инде, — диде Жәмилә.

— Исәнме, дускаем. Мин бит сине башта танымадым.

— Ун ел үтте бит. Картайганмындыр.

— Картаю кая. Шул ук Жәмилә әле син.

Еллар аны чыннан да үзгәртмәгән. Хәйләкәр елмаеп караган шул

ук яшел күзләр, ерылырга гына торган зур авыз. Минем кебек тазарып та китмәгән. Нечкә билле кызның тулай торактан чыгып, университетка ашыккан чагы кебек.

Шәрәф такси артыннан йөргән арада чемоданнарны китерделәр.

— Минем әйберләремне калдыр инде, Рәмзиягә китәрмен, —диде Җәмилә, багажникка куярга җыенган Шәрәф кулындагы сумкасын алып.

— Рәмзияне бездән якынрак күрәсең икән, — дидем, бераз хәтерем калды.

— "Казанга килсәң үземә төш", — дип, бик каты чакырып китте. Бармасам, үпкәләр.

— Үпкәләмәс. Рәмзиягә дә житешерсең. Хәзер безгә кайтабыз, — диде Шәрәф, бу мәсьәләгә нокта куйгандай итеп.

Бераз җир киткәч, шофер белән янәшә утырган Шәрәфнең җилкәсенә кулым куеп, борылып карарга мәжбүр иттем.

— Шулай да әйт әле, нишләп Башкортстанга барып чыктың әле син? Жубан янына керәм дип язган идең бит. Алма-Атадан кайтасың дип уйладым мин сине.

— Сөйләрмен әле. Үзе бер хикәя ул, — диде Шәрәф, җәелеп китмичә генә.

— Башкорт шагыйре Гыйлемдар Рамазанов белән килеп чыктылар. Безнең як шагыйре ул. Туган ягын күрсәтәсе килгәндер, — диде Җәмилә.

— Магнитогорскиның "Урал" кунакханәсендә Фәрит Камалов дигән башкорт егете белән бер бүлмәдә тордык. Дөресен генә әйткәндә: "Салават батыр йөргән юлларны да күреп кайт", —дип ул котыртты. Тукайны хәтерләткән урыннар Уфада да күп бит. Шул да тартып китергәндер инде, — дип Шәрәф сүзгә кушылып китте.

Ерак барасы түгел иде, такси безне, җилтерәтеп, Нестеров чокырына китереп куйды.

Юлчылар "душтагы" җылы су белән юынып, өс-башларын алыштырып өлгергәнче самаварым өстәл башында гөжләп утыра иде инде.

— Шәһәр уртасында торсагыз да авылдагыча яшисез икән, —дип куйды Җәмилә, чәйле чынаякка үрелгәндә. Аныкын тиз генә аңламасссың, әллә хупный, әллә өнәп бетерми иде ул безнең тормышны.

— Ир кеше өстенә төшкән өч бурычның икесен үтәдем, — дип мактанып алды Шәрәф. — Өй салып кердем, ике улым үсеп килә. Агач утыртасы гына калды.

— Язган шигырьләрең агач урынына булыр инде, — дип, салпы якка салам кыстырып куярга ашыктым, ничек тә аның күнелен күрергә тырышып.

Өйгә кайту шатлыгыннан күңеле күтәренке булса да, арыганлыгы бөтен кыяфәтеннән күренеп тора иде. Күз алмалары кызарган, аның кан басымы күтәрелсә, шулай була. Йөзе суырылып, агарып киткәндәй күренде. Алдына дару китереп куйгач, елмаеп җибәрде, әмма эчәргә ашыкмады. Бик илһамланып, Уральски шәһәрендә күргәннәрен сөйли башлаган иде.

— Син биреп җибәргән белешмә-китап ярап куйды бит, —диде ул. — Күпме эзләсәм дә янасын очратмадым. Тукай яшәгән, укыган, эшләгән урыннарны шул китаптан карап таптым.

— Менә шулай, олылар сүзен тыңлыйлар аны.

— Тукайны белгән кешеләр юктыр инде анда?

— Бар әле. Гариф Төхвәтуллин белән Галимҗан Нугаев дигән кешеләрне эзләп таптым. Картайганнар инде. Хәтерләре яхшы үзе. Гариф абзый белән Чаган буена төшеп утырдык. Мотыйгыйлар өеннән ерак түгел икән. "Тукай монда су коенырга килә иде, балык тотарга йөри идек, күбрәк ә-әнә теге борылышта утырырга ярата иде", — дип сөйләде. Ул күрсәткән якка әйләнеп карасам, су өстенә иелеп үскән карт өянке төбендә ике малай кармак салып утыра иде. Шуларның берсе бәләкәй Апуш кебек күренде.

— Хәзерге заман малайлары Апушка охшый димени? Галлюцинация булган сиңа.

— Булуы да ихтимал. Бөтен җанымны, күңелемне, уемны Тукай билән алган иде бит. Гариф абзый белән көне буе аның турында сөйләшеп йөрдек, — диде Шәрәф. Чәе суынган стаканны кулына алды.

— Галимҗан абыйларда бер кич куныш кайттым. Син җибәргән чәк-чәк белән чәй эчтек. Төне буе сөйләшеп утырдык, Тукай белән бер мәдрәсәдә укыганнар икән. Җәй айларында, хәлфәләре өенә кайтып киткәч, аның урынына Габдулла дәрес биргән. "Сабагын белмәгән малайларны шигырь әйтеп оялта иде", — ди. Үзе Тукайның шигырьләрен яттан белә. Аның алдында миңа әзрәк уңайсыз да булды. Аның хәтле үк белмим икән. Гөл бакчасы кебек бүлмәдә шигырь сөйләп таң атканын да сизмәдек. Гөлләр үстерергә ярата ул, сиңа да гөл орлыклары биреп җибәрде, — дип, Шәрәф урындык аркасына элгән костюм кесәләрен актара башлады.

— Соңыннан да өлгерерсең. Хәзергә калдырып тор, — дип тынычландырдым аны.

Азактан без Җәмилә белән икәү генә калдык. "Балаларны карап килим әле", — дип өстәл янынннан киткән Шәрәф әйләнеп килмәде. Рәхәтләндек сөйләшеп, искә алмаган кеше калмады. Кайдадыр әтәч кычкырып, төннең узып барганын искә төшерде. Тәрәзә яктысына очып килгән зур чуар күбәләкнең шапылдап пыялага бәрелүе сикәндереп җибәрде. Авызын учы белән каплап, Җәмилә озак итеп иснәп алды.

— Арыгансындыр, юлдан кайткан кеше бит син, — дип, аның хәленә кердем.

— Сездән ике сәгать алда йөрибез бит. Йокыдан торыр чагыбыз җитә инде.

Урын-җир алырга дип кергәч, ике улын ике яктан кочаклап, караватта җәйрәп яткан Шәрәфне күрдем. Балалар әтиләренең куенына кереп беткәннәр, өчесе дә тәмле итеп, әкрен генә тын алалар.

— Җәмилә, кил әле, кара әле боларга гына, — дип, әкрен генә кунагымны чакырып алдым.

— Кешенең иң бәхетле сәгатьләре шушы буладыр инде, —диде Җәмилә дә озак карап торгач, пышылдап.

Без йокыдан уянып, иртәнге эшләрне караштыргалаганчы, Җәмилә университетның тулай торагы тирәләреннән әйләнеп кайтырга да өлгергән иде инде.

— Үзебез яшәгән бүлмәнең тәрәзәләренә бик озак карап тордым, — диде ул моңсу бер тавыш белән.

— Кара пәриең күренмәдеме соң? — дидем сүзне уенга борып.

Яшерен мәхәббәтен исенә төшергәч, Җәмиләнең йөзе яктырып китте.

— Төштә күрсәң генә инде ул чакларны, — диде. — Хәзер кайда икән ул, белмисеңме?

— Утыз меңчеләр хисабыннан бер колхозга председатель булып китте, дип ишеткән идем. Шуннан бирле хәбәрем юк.

— Булдырыр ул. Укыганда ук бик актив егет иде бит.

Чәйдән соң Шәрәф аны Рәмзияләргә озата китте, мин редакциягә йөгердем.

— Шәрәф әйбәт кенә йөреп кайткanmы? Нәрсәләр сөйли? —дип каршылады мине Сәхаб абый.

— Сөйләп сүз бетәрлек түгел әле. Кайтышлый Уфага да кагылган бит.

— Берәр нәрсә язса, безгә китерсен.

— Язар әле, бераз ял итсен.

Эшем эш булмады бүген. Барысын да калдырып тизрәк өйгә кайтасы килеп үткәрдем вакытны.

— Сәхаб абый, китим әле булмаса, Зәки сораса, эш белән җибәрдем дип әйтерсең. — Бүген килмәсәң дә сүз әйтмәс иде.

Күңел сизә дигән булалар. Әгәр шулай булса, әллә нинди сөенечләрем бар кебек, очып кайтып килмәс идем мин. Тау астында торган "Ашыгыч ярдәм" машинасына да исем китмәде. Күрше карчык еш авырый,

шуңардыр, дип уйладым. Өй эчендә ак халатлы кешеләрне күргәч кенә коелып төштем.

— Нәрсә булды? Ни эшләгән ул? — дип, диванда чалкан яткан Шәрәф янына атылып барып җиттем.

— Куркыр урын юк. Кан басымы күтәрелгән. Магнезий уколы ясадык, — диде врач, Шәрәфнең кул тамыры тибүен санап туктагач. — Ял кирәк хәзер аңа.

Шәрәфнең гипертония кризислары элек тә булгалый иде. Әллә яшьлек белән беленмәгән, врачларга мөрәҗәгать итеп, "Ашыгыч ярдәм" машиналары чакыртып мәшәкатьләнгәне юк иде. Үзенең мондый хәлдә калуын ул контузия шаукымы дип карый. Немецлар Сарны шәһәрен бомбага тотканда авыр контузия алган булган.

Төн уртасы җитеп килә, ахры. Күземә йокы төшкәне юк әле. Күңелем тыныч түгел, котылып булмастай зур бәла көткәндәгедәй эч поша. Вакыт-вакыт Шәрәф яткан диван янына киләм. Уколлардан соң тыныч кына йоклап китте. Миңа ул кергәненнән артык тыныч булып күренә. Шикләнеп, иренәнә кулымны куеп торам, җылы сулышын тойгач кына бераз җиңел булып китә, алай да муенына, күкрәгенә тибеп чыккан кызыл таплар бөтенләй үк тынычланырга ирек бирми.

Мин тагын "эш бүлмәсе"нә кереп утырам. Шәрәфнең таралып яткан кәгазьләрен кулыма алам. Юлда алган тәэсирләрен тәртипкә китереп утырган булса кирәк. Блокнот битләренә ашык-пошык язган юлларны укыйм.

"... Төхвәтуллиннар йортыннан ерак түгел ике катлы, соры таш бина. Анда элек "Мотыйгия" мәдрәсәсенең рус классы урнашкан булган. Тукай монда Әхмәдиша учительдән рус дәресләре алган, беренче мәртәбә шунда рус һәм көнбатыш әдәбиятының гүзәл үрнәкләре белән танышкан".

Бирелеп китеп, блокнот битләрен тагын, тагын ачам. "... Шәһәр гостиницасы, "Казахстан". Монда рус, татар, башкорт, казакъ мосафирларын очратырга була. Гали Абдрахманов дигән кеше белән бер бүлмәдә кундык. Чаңгыртау районыннан килгән бу егетнең биредә эше күп икән. иртүк китә, кич кайта. Ләкин Тукай исемен ишетүгә үк "үлән әйтеп" җибәрә:

Валлаһи и, валлаһи и, валлаһи,
Бәхете барлар кырда җәйли, валлаһи!

Бүлмәдәге өченче иптәшебез Каратүбә кешесе Мирхәйдәр Абдрахимов шигырьне казакъча дәвам итә:

Ак нан кусып асаптындай таза һава,
Җер җап-җасыл, кос та сайрар, уаллаһи!
Һәм бераздан татарча күчеп китә:
Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунарлык җирне сайлый, валлаһи,
Аз гына бер җил исү белән үлән
Җирдәй уйный, кайный-кайный, валлаһи!

— Татарчаны әйбәт беләсең, татарлар арасында үстеңме әллә? — дим.

— Әнием татар минем. Тукай шигырьләрен яттан белә, шуннан өйрәндем, — ди Мирхәйдәр..."

Сәяхәтче шагыйрьнең тар гына вакыт арасында кәгазьгә төшереп калдырыйм дип, ашыга-ашыга язган юллары... Җөмләләр төгәлләнмәгән, сүзләре ярты-йорты калган битләр бар. Чит кеше кулына төшсә, морзе әлифбасына караган кебек карар иде, ә мин буш җирләрен күңелемнән тутырып, камил әсәр укыгандай укыйм. Бу егетләрнең үзләрен күргәндәй булам. Шәрәф белән янәшә утырып, Тукай шигырьләрен үз телләрендә укыганын тыңлаган кебек тойгы кичерәм. Ә вакыт дигәнең үтә тора, инде тәрәзәгә таң яктысы төште. Балаларның кайсыдыр берсе йокы

аралаш “әни” дип куйды. Мин бит инде икенче таңымны шулай йокысыз үткәрәм. Иртән эшкә барасы бар. Урынга ятардан элек тагын Шәрәф янына киләм. Уң ягына әйләнеп яткан, куш учын яңак астына куеп, тыныч кына йоклый. Нәкъ сабый бала кебек. Йөзендәге, муенындагы кызыл тимгелләр дә беткән. Мин дә шөкер итеп, инде кирәге калмаган утны сүндерәм. Нинди генә катлаулы, мәшәкатьле булса да, якты дөньяда яшәвең бер бәхет дигән уй белән күземне йомам.

## И гомер агышлары

Әле генә журналның төсле рәсемнәр белән басылган контроль нөсхәсен китерделәр. Хәзер ул “Ялкын” булып чыга, “Пионер” түгел. Яшьлек ялкыны, костер ялкыны дигән мәгънәләр салып, шундый исем куштык без аңа.

Художникның журналны өстәлгә китереп куюы булды, типография буявының исеннән сизгәннәр дип әйтерсең, артыннан ук бүлмәгә хезмәткәрләр килеп керде. Машинистка белән курьер да калмаган хәтта. Сөенечләре йөзләренә чыккан. Шулай булмый ни, төрле оешмаларга күпме үтенечләр, аңлатмалар, тагын шундый мең төрле кәгазьләр басарга туры килде бу тыйнак, аз сүзле, күп эшләүчән машинистка кызга. Курьер да әле анда, әле монда йөгереп кенә йөрде. Нинди мәшәкать чиккәнне алар да белә. Бу көнне күрер өчен күпме тырыштык, артыннан күпме йөрдек бит. Башта: “Акча юк, машиналар иске, мастерлар житми”, — дип, ниятебезне хупламадылар. Чигенмәслегебезне белгәч: “Көтегез, киләсе елның сметасына кертербез”, —диделәр. Яңа ел килеп житкәч тә бик ашыгып тормадылар, ләкин “сабыр төбе сары алтын” булды. Сабыр итә торгач, менә без дә шушы көнгә килеп життек. Дүрт төрле төс белән басылган журнал, әлбәттә, күзне чагылдырырлык матур иде, килмәгән бер генә жире дә юк кебек күренде. Бераздан йөрәк тибеше тынычланып, шатлыгыбыз басыла төшкәч, жентекләбрәк карый башладык. Әниләр сабыйларын беренче кат кулга алгач, күкрәк сөтен биргәнче үк, унике әгъзасы да исән-саумы, тәнендә-йөзендә ят таплар юкмы дип, аяк-кул бармакларына хәтле берәм-берәм саный-саный, сөенеч катыш хәвеф белән карый торган булалар. Журналның битен-биткә бөртекләп тикшерә торгач, иң элек жаваплы секретарь Илдар Юзеев телгә килде:

— Мансур абый, тышлыктагы рәсемнәр карангырак күренә. Тиражда тагын да авыраймасмы?

— Мин әйттем аны, — диде художник. — Зәңгәр төсне киметергә булдылар.

— Менә бу каен чугы өстенә басылган текстны укуы авыр, —диде Галимжан Латыйп та үз бүлегеннән киткән шигырьне кайгыртып.

— Карагыз, игътибар белән карагыз. Төзәтергә соң түгел әле, басарга биргәч кире алып булмас, — дип, тәнкыйтьне кыздырып торам.

— Моның бар жире дә килгән, төзәтәсе дә юк.

— Күргәч, укучылар аптырап калыр әле.

— Мәскәү журналы килгән дип уйларлар.

— Тиражыбыз да артыр инде.

— Эчендә укырлык әйбер булмаса, төсләр белән генә алдый алмассың.

— Нишләп булмасын, сан саен яңа әйбер биреп барабыз.

— Яңалыктамыни хикмәт! Яратып укырлык әйбер кирәк.

— Анысы язучылардан тора инде. Алар язмагач, каян аласың? Декада вакытында да балалар әдәбияты аксый дип әйттеләр түгелме соң?

— Бу нинди шау-шу? Мин генә житмим икән монда, — дигән тавыш кабынып китәргә торган бәхәсне бүлде.

Ишек төбендә култыгына нindидер төргәк кыстырган Шәрәф елмаеп тора иде.

— Әйдә, Шәрәф, әйдә, — дип, аны бүлмәгә чакырдылар.

— Менә журнал чыгарабыз, — диде Мансур, ни өчендер аклангандай итеп.

— Матур булган бит бу! Ну, молодец, егетләр. Балалар журналының безнең тарихта беренче тапкыр төсләр белән басылуы бит бу, — диде Шәрәф, битләрен актарып карагач, шаярып өстәде. — Юарга кирәк моны.

— Юасы әйберләр болай да бар әле. Шекспир сонетларының татарча тәрҗемәсе чыккан, дип әйтәләр, — диде Илдар, хәйләкәр елмаеп.

— Каян белдең?

— Үзем күрдем. Нәшрият витринасында яңа китаплар янында тора.

— Витринада гына күреп йөрмә, мә алай булгач, тотып та кара, — дип, Шәрәф култыгындагы төргәктән бер китап алып бирде.

— Ә автографы?

— Анысы соңыннан. Болары өйгә кайтасылары.

Журнал онытылды, барысының да игътибары дәфтәр битенең яртысы хәтле зурлыктагы кызгылт тышлы китапка юнәлде.

— Әй, әй, читкә киттегез. Журналның эшен бетерик башта. Әйтер сүзләрегез юкмы? — дидем.

— Әйдә, кул куй да төшереп җибәрик инде, — диештеләр барысы да.

— Миннән рөхсәт, — дип Шәрәф тә күндереп алды.

"Төзәткәннән соң басарга ярый" дип, сырлап-сырлап имза салуымны дәшми генә карап тордылар.

— Кулың җинел булсын, — дип куйды машинистка.

— Үзең кайтканда алып кайтырсың, бүген безнең түгәрәк утырышы, соңгарак калырмын, — дип, китапларын калдырып киткән иде Шәрәф. Союзда берәр җыелыш булса, аны тиз генә көтмә инде. Төн уртасында кайтып житсә, рәхмәт әйтерсең. Менә мин кичке эшләрне бетереп, җылы өемдә, йомшак диванда аяк бөкләп утырам. Кулымда Шекспир сонетлары. Кызым әтисенең эш өстәлендә дәрес әзерли. Улларым дөньяларын онытып кинескоптан әкият карыйлар. Өйдә сирәк була торган тынлык, җанымда да илаһи тынычлык. Ник бер кылы шөбһә белән типсен. Йотылып сонетлар укыйм. Менә кайда ул тормыш фәлсәфәсе, яшәү мәгънәсе, хыянәт ачысы, мәхәббәтнең сихри биеклеге. Барысы да шушы кечкенә китапка сыеп беткән. Һәр юлы, һәр сүзе таныш дисәм дә артык булмас, машинкада ничә кат бастым бит мин аларны. Өр-яңадан кичереп, хисләнеп, тетрәнеп укып утырам.

Миндә уй күп, ничек шуны әйтми калыйм,
Каләм алгач җырым сиңа баглар өчен?
Тик яңа сүз, яңа зур хис каян табыйм
Сыйфатларың бүтәнчәрәк мактар өчен?
Һич каян да! Бер Ходайга кылган догам
Булган төсле көн дә бер үк, көн дә иске —
"Син — минеке, мин — синеке"! дим дә торам,
Күптәнге сүз, гел яңа, һаман изге.
Гел иске дә, гел яңа ул, үлмәс гыйшык,
Һич вакытта ятмый аңа тузан кунып.
Җыерчыклар китә алмый ямен кыйлып,
Картлык исә калган анын колы булып.
Вакыт жирдән мәхәббәтне куып тора,
Тик мәхәббәт өр-яңадан туып тора.

Йә Хода! Без бит бу. Безнең тормыш, безнең язмыш. Шәрәфнең сүзсез, кырыс мәхәббәте. Минем, яктыга үрелгән гөл кебек, җылы караш, назлы сүз көтеп яшәвем. Шушы көтүләр, зарыгу, сагынулар кадерле иткәндер дә әле ул мизгелләрне. Болыт арасыннан чыккан кояш та бит көн дә нур сибеп торганыннан тансыграк була.

Шәрәфнең сөюе телендә түгел, йөрәгендә икәнен күңелем сизә. Чәчәкләр бүләк итми ул миңа. Үпкәләмим. Чәчәкләрне мин үсеп утырган

жирләрендә яратам, аның риясыз, якты карашы чәчәктән дә кыйммәт. Төрле мәшәкатьләр арасында күмелеп калган игътибарны да күнел күзем белән күреп торам. Тирги-тирги язарга өндәве дә җанга рәхәт. Мәхәббәтнең үзе түгелмени болар барысы да?

И гомер агышлары... Тиз йөрешле поезд икән ул. Тукталыштан тукталышка чаба да чаба. Берсе кирә пассажирларнын, берсе төшеп кала. Кергәннәре урын көйләп ыгы-зыгы килә. Озак та барасы түгел, югыйсә. Шулай да үзе теләгәнчә урнашып калырга ашыга.

Сонетларны тәрҗемә итүгә ике ел гомер сарыф итте Шәрәф. Максат куеп, ныклап утырудан башлаган эш булмады ул. Урал якларыннан йөреп кайткач, эшкә тотына алмыйча шактый изаланды.

"Хисләр шундый күп, чуалчык, язгы ташкын кебек дулый, кайный, акыл киртәләрен пыран-заран китереп ташлады. Әзрәк суынырга кирәк мина, аек акыл кирәк", — дип язып куйган иде алдындагы кәгазь битенә. Өстәл янына утыра алмыйча газапланып йөргән көннәрендә Шекспир сонетларын укып ята торган булды. Бер көнне карыйм, тәрҗемә итеп утыра бу.

— Укып кара әле, барып чыкканмы? — дип янына чакырып алды.

— Матур булган. Эчтәлеген дөрес бирә алдыңмы соң? Син бит аны оригиналдан эшлисең.

Шулай башланган эш булды бу. Мавыгып китеп утыра торгач, декадага өлгертәм дигән максат та куйды. Ләкин җиңел эш булмады. Кайбер сонетлар "Совет әдәбияты" журналында гына чыгып калды.

Бөтен Мәскәүне аякка бастырган татар әдәбияты һәм сәнгате бәйрәме шаулап-гөрләп узып та китте. Башкаланың урамнары, мәйданнары, концерт заллары, театрлары татарча сөйләшүләрдән, татар моңнарыннан яңгырап торды. Шаян телләр сөйләп йөргәннәр ди анда:

"Батый* җитәкчелегендәге татарлар Мәскәүне яулап алды", — дип.

Декада ахырында Татарстанның ундүрт язучысы орденнар-медальләр белән бүләкләнде. Шәрәфкә дә "За доблестный труд" медале бирделәр. Без аны сугышта алган "Кызыл йолдыз" ордены һәм "За отвагу", "За боевые заслуги" медальләре янына салып куйдык. — Сонетлар өчен аванс бу, — диде Шәрәф.

## Яшибез икән әле

Партиянең егерменче съездыннан соң исеме телдән, рәсеме газет битләреннән төшми башлаган Никита Сергеевич Хрущев Мәскәү язучылары, сәнгать кешеләре белән очрашулар үткәрә икән. Аларның кайберләрендә безнең Гомәр абыйга да катнашырга туры килгәли икән. РСФСР язучыларының беренче оештыру съездында мин дә күрдем Хрущевны. Бөтен эш бетеп, съезд тәмамланган көнне делегатларны Зур Кремль сараеның Георгиевский залына фуршетка чакырдылар. Монысы аяк өсте генә үтә торган мәҗлес кебек нәрсә инде. Съезд барган чакта да татар-башкорт язучылары бергә булдык. Хәзер дә "П" хәрефенә охшатып тезелгән өстәлләрнең уң канатына барып бастык. Минем өчен бөтен нәрсә яңа, бар да кызык. Патша хәзрәтләренең баллар үткәргән җиренә кунак булып килдек бит. Кара фраклы официант егетләр күкәй кабыгы хәтле генә көмеш савытларда ак соуста пешкән гөмбә куеп киттеләр. Ир-егетләр ут күк уйнаклап торган шәраб бокалларын кулларына алдылар. Антресольдән серле моң агыла башлады, мәрмәр паркетта парлап әйләнгән затлы кавалерларның, назлы дамаларның мамыктай җиңел аяк тавышлары ишетелгәндәй булды. Әмма хисләргә озак бирелеп тору мөмкин түгел иде монда. Шунын өстенә кемдер берәү: "Алгарак узыгыз, хәзер Никита Сергеевич чыга", — дип пышылдап китте. Бәллүр бокалларны кулга

*Партия өлкә комитетының икенче секретаре Салих Батыевка ишарә.

тоткан көе, ашыга-ашыга, аркылы өстәл кырына килеп кысылдык.

Озак та үтмәде, түрдәге ян ишектән Хрущев, аның артыннан Ворошилов, Микоян, тагын кемнәрдер килеп чыкты. Хрущев нәкъ рәсемдәгечә тәбәнәк буйлы, шактый калын гәүдәле, безнең Гариф абый Гобәйнеке кебек ялтыравык башлы кеше икән. Ул безне съездның уңышлы тәмамлануы белән котлады, шампан шәрабе салынган бокалын язучылар белән чәкештереп чыкты. Дамаларга вазадан алып, хризантемалар бүләк итте. Озак сөйләде ул. Сөйләргә ярата икән. Ярты сәгатькә сузылган нотыгыннан бер җөмләсе бик истә калды. "Безнең төрмәләрдә хәзер сәяси тоткыннар юк", — диде. Моңар ышанырга була иде. Төрмә газапларыннан котылып кайткан Хәсән ага Туфан белән Мин Шабай үзебезнең арада бит. Бер вакыт Гомәр Гали күзгә күренеп китте. Ибраһим Сәләховны Казакъстанга барып урнашкан дип ишеттек. Зәй якларыннан Сөббух Рафиков Казанга килеп киткәли. Гарәфи Хәсәновның хикәяләре басылып тора.

Өстән күрсәтмә булганмы, мондый очрашулар өлкәләрдә дә үткәрелә башлады. Инде менә Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Семен Денисович Игнатьев та язучыларны очрашуга чакырды. Бездә яңа кеше әле ул. Элекке Беренчене үзәккә эшкә алгач, җибәрделәр. Кайсыдыр республикада эшләгәндә ниндидер хатасы булган да, имеш, безгә сөргәннәр. Татарстан үзе сөрген урыны дип әйтерлек хәтәр җир түгел дә түгелен, союз республикасы дәрәҗәсеннән автономиягә төшерелүе юкка булмагандыр. Язучылар җитәкчелеккә урыс кешесе килүенә риза иделәр, милләтчелектә гаепләмәсләр, диделәр.

Безнең өйдә телефон юк. Шәрәф чыгып йөрмәгән көннәрдә кирәк хәбәрне мин кайтып әйтәм. Игнатьев янына барасын белгәч, ул чыгыш ясарга әзерләнә башлады. Дипломатия саклый торган кеше түгел, әйтсә, егылып китәрлек итеп әйтә. Шуңа күрә бу ниятен хупламыйча:

— Сөйләгәнең көмеш булса, тик торганың мең алтын. Сиңа гына димәгән. Башкалар сөйләсен әнә, — дидем.

— Син дә мулла, мин дә мулла булгач, атка печән кем сала соң?

— Муллалар синнән башка да күп. Нәшрият коридорында бик батыр сөйләшәләр.

Кая ул! Башына бер уй килсә, кеше сүзе колагына керәмени? Болай да өлкә комитетына хат язарга йөри иде, форсат чыкты үзенә. Күптән түгел Апас якларыннан йөреп кайтты ул. Күргәннәре турында бик ачынып сөйләп утырды:

— Борын төбендәге чеп-чи татар авылы югыйсә, бөтен эше урысча бара. Бер җирдә бер татар язуы күрмәссең. Райкомда тетмәләрен тетеп кайттым үзләренең.

— Артыңнан язып җибәрерләр әле менә. Чакырып алып үзеңнең тетмәңне тетәрләр.

— Чакырсыннар. Чакырсалар, тагын да катырак әйтермен.

Йокым йокы булмады бу төндә. Ике-өч тапкыр уянып Шәрәф янына чыгып кердем. Ул һаман кәгазенә капланып утыруында. Бүлмәдә тын алырлык түгел, борынны ярып тәмәке исе керә, көл савыты сигарет төпчеге белән тулган.

— Шушы тотеңдә ничек башың авыртмый, — дип, бер килүемдә форточканы ачып куйдым. Ыргылып, төнге салкын һава керде.

— Баш авырттырырлык хәлләр булганга утырам да инде.

— Ят, әйдә, ял ит.

— Ятарга кирәк шул, — диде ул да, яза торган кәгазен йомарлап өстәлгә ташлады.

Язучыларның үз җыелышларына да бу хәтле кеше килми иде. Аякка баса алганнарның барысы да монда бүген. Театрга йә кунакка килгән кебек ыспай киенгәннәр. Кеше кубәйгән саен бүлмәдә тәмәке һәм арзанлы одеколон исе куерып, төчкерәсең китерә башлады. Язучыларның кергән берсе шыпырт кына килеп утыра, якын тирәдәгеләр белән сүзсез генә кул биреп исәнләшә. Изге храмга йә музейга килгәннәрмени? Мин

Шәрәфне көтәм. Миннән өйдә калган иде. Сонладымы икәнни? Әллә бөтенләй килмәскә уйлаганмы? Шулай гына булса ярар иде, дип уйлап бетермәдем, ишектә ул күренде. Кул изәп чакыруымны күргәч, яныма килеп утырды.

Нәкъ ун тулуга түрдәге ишектән Игнатьев белән Батыев килеп чыкты. Болай да тын бүлмә кешеләрнең сулыш алуларына хәтле ишетелерлек булып калды.

Яңа секретарь олы яшьтәге кеше икән. Авыл агайлары кебек тулы түгәрәк йөзле, маңгаендагы җыерчыклар аны җитди, хәтта кырыс итеп күрсәтә. Киң җилкәле, нык бәдәнле, ышанычлы кеше тәэсирен калдыра. Тавышы калын, карлыгыбрак чыга. Киноларда күреп өйрәнгән егермебишменчеләрне хәтерләтте ул миңа, утызынчы елларда колхозларга ярдәмгә җибәрелгән Питер эшчеләренең берсен.

Семен Денисовичның чыгышында яңалык булмаса да, Беренченең үз авызыннан чыккан сүзләр булганга бирелеп тыңладык.

— Сораулар бармы? — диделәр.

Сорау бирергә атлыгып торучы күренмәде.

— Сөйләргә теләүчеләр?

Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Гази Кашшаф бу очрашуның бик файдалы булуын, киләчәктә дә шундый дәрәҗәле зур сөйләшүләр кирәклеген әйтеп кыска гына чыгыш ясады. Инде сөйләшү ахырына җитте, түгәрәкләргә вакыттыр дип торганда, Шәрәф урыныннан кузгалып:

— Иптәш Батыев, сүз бирегез әле, — диде.

Батыев Беренчегә нәрсәдер әйтеп алды, ә тегесе Шәрәфкә сынаулы авыр караш ташлады.

— Сөйлә, Шәрәф, — диде Батыев, тыңларга әзерләнеп терсәге белән өстәлгә таянды, каты кара чәченә симез бармакларын батырды.

Шәрәф үгезне мөгезеннән тотып алды. Тыныч күл өстенә төшкән таш кебек авыр-авыр сүзләр яргыта башлады. Батыев өстәлгә ярым яткан җиреннән тураеп утырды. Игнатьевның кашлары җыерылды. Кайбер язучыларның күзләрендә борчу, кайсыларында хуплау иде.

— ... педагогия институты кадрларны җитәрлек әзерли, имеш. Университетның татар бүлеген ябу өчен сылтау булды ул. Сугыш вакытында ачылган бүлекне.

— Бүлек ябылмады. Эшли, — диде Батыев.

— Беләм, ябылмады. Шул бүлекне тәмамлаган утызлап язучы, галим, укытучылар кул куеп хат язгач. Таякны катырак бөктек дип уйладыгызмы? Өлкә газетларының дубляжга әйләнүенә, чуашлар өчен чыга торган "Херле ялав"ның ябылуына ни әйтерсез? Инглиз колонизаторлары да эшләмәгән әшәкелекне эшләдегез!

Бүлмәдә бомба ярылдымыни? Исен җуйган халык аңына килгәнче Игнатьев авыр гына урыннан кузгалды да:

— Унбиш минутка тәнәфес! — диде.

Бер утка кердем, бер суга төштем мин шушы минутларда. Күтәрелеп карасам, залда берүзем утырам икән. Урынымнан кузгалып, коридорда шаулашкан кешеләр янына чыгарга хәлем дә, теләгем дә юк. Кинәт аркама кемнендер җылы кулы кагылуга сискәнеп киттем. Гали Хуҗи икән. Сүзсез генә янымa килеп утырды.

— Нәрсә булыр инде хәзер, Гали абый? — дидем, еларга җитешеп.

— Бер нәрсә дә булмас, кайгырма, — диде ул, юатып. —Андый гына хәлләрдән чыкканы бар аның.

Эшкә аягым тартмыйча гына килдем. Нәшрият йортындагы бар кеше кичәге хәлләр турында гына сөйлидер кебек. Ярый әле, иртәнге сәгатьләрдә коридорлар буш була. Редакция бүлмәсенә килеп кергәнче берәү дә очрамады. Эш күплеге дә хәлемне җиңеләйтте. Яңа ел санын әзерлибез. Тышлыкның икенче битенә бәскә уралган каен рәсемен китерделәр. Рәсем асты кирәк.

— Илдар, дүрт кенә юл шигырь сорала, — дим.

— Шәүкәткә әйтим әле, тиз генә язып бирер, — дип, ул Шәүкәт Галиев эшләгән “Чаян” редакциясенә кереп китә.

Шактый озак торгач, икәүләп әйләнеп керәләр.

— Күндереп булмый әле, үзен сөйләш, — ди Илдар.

— Болай булмый инде ул, җәмәгать, — ди Шәүкәт, акланудан бигрәк һөҗүмгә күчеп. — Аяк өстеннән шигырь язып буламыни? Аннары, мин балалар шагыйре дә түгел.

— Вакыт бар әле, Шәүкәт. Иртәгә китерсәң, без риза. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр бит.

— Бу бит үзе шигырь, — ди Илдар, рәсемгә күрсәтеп.

— Ник үзең язмыйсың соң?

— Редакция кешеләрен күп басалар дип бәйләнәләр.

— Бер куплет өчен инде...

— Шушы матурлыкны мактап шигырь яз. Куплет кына булуы мәҗбүри түгел, — дип, шагыйрьне икәүләп үгетлибез.

Кыстый торгач, Шәүкәт ризалашкандай була. Шулай да:

— Бик ышанып көтмәгез, — дип кисәтеп куя.

Телефон челтерәвенә сүзебез бүленә. Трубканы алам.

— Миңа Ихсанова кирәк.

— Ихсанова тыңлый.

— Мин Семен Денисовичның референты булам. Хәзер сезнең белән ул үзе сөйләшә.

Онытылып торган борчуым янарды. Йә Хода! Нинди сүзләр ишетермен икән? Йөрәгем кагуы секретарь булмәсенә дә ишетелеп торадыр кебек.

— Вы супруга Мударрисова? — дип сорады карлыккан таныш тавыш.

— Әйе, Семен Денисович.

— Скажите ему — хороший он мужик. Пусть приходит ко мне завтра к двум часам.

Шулай диде дә, җавабымны да көтмичә, трубканы куйды. Ике учым белән йөземне каплап күзләремне йомдым. Кичә тәнәфестән соң пыр туздырып тиргәгән кешедән нәрсә ишетәм? “Хороший мужик...” Ышаныргамы моңа? Алдан куркып тормасын дип кенә әйтүеме? Дөрес, кичә Шәрәфкә генә эләкмәде. Барысына да кагылды аның җиле. Язучылар союзы җитәкчеләренә дә, партия оешмасына да. Ләкин таякның юан башы Шәрәф җилкәсенә төште. Җәнҗалның сәбәпчесе ул иде бит. Тизрәк кайтып әйтергә кирәк үзенә. Әйбәтләп әзерләнсен. Әйтәсе сүзен уйлап барсын.

— Берәр күнелсез хәбәрме әллә? — диде Илдар, әле булса дәшми утыруыма гаҗәпләнеп.

— Шәрәфне Игнатьев чакыра.

Шәрәф гомерендә галстук бәйли белмәде, ә үзе арттан каптырмалыларын яратмый. Өйдә булмасам, муенга киярлек итеп кенә бәйләп калдырам. Бүген мин аны үз кулларым белән киендергәндәй, очрашуга әзерлим. Каршымда кичәге ярсулы, гайрәтле шагыйрь түгел, бәләкәй малайлар кебек муенын сузып галстук бәйләтеп торучы, аптырап калган, юаш, борчулы кеше басып тора. Миңа ул бик кызганыч булып китте, күземнән тәгәрәп яшь чыкты. Муеныннан кочып алдым да күкрәгенә башым куеп сулкылдап җибәрдем.

— Йә, акыш-макыш, елама, сугышка озатмыйсың бит, — диде ул.

— Көтеп торам, туры өйгә кайт, — дип калган идем, ике сәгатьтән әйләнеп тә кайтты. Авыз ерылган, күзе көлә, бүрек баш артына киткән.

— Нәрсәгә шул хәтле сөендең? Орден бирәбез, диделәрме әллә? — дип каршыладым.

— Орден гынамы соң!

— Йә рәтләп сөйлә, нәрсә диделәр?

— Килеп керүемә Игнатьев өстәл сугып, бик яман сүгенеп җибәрде.

— Шуңа сөендеңме?

— Тыңлап тор. Беләсеңме, нәрсә диде: "Син әйтмәсәң, без белмибезмени бу хәлләрне?" — дип тирги башлады. — Газетлар ябылганда нәрсә карап тордыгыз? Сугыш беткәч батырлар табыла. Башкортлар әнә "Кызыл таң"ны саклап калдылар. Сезгә дә тавыш кубарырга иде, безгә таяныч ноктасы булыр иде ул", — дип тезеп китте. Аннары: "Утыр, — диде, шуннан соң тавышы йомшарды. — Салих Гыйлемханович синең турыда сөйләде миңа. "Талантлы егет" диде. Талантларның кадерен белергә кирәк. Кичәге эшең өчен курыкма, тынычлап эшлә. Язучылар оешмасына Маяковский урамында төзелеп килгән йорттан өлеш чыгарабыз. Шамовка әйтермен, синең дә фатир хәлеңне яхшыртырлар. Ике язучы икән бит сез..." Аннары хәлемне сорашты. "Нәрсәләр язасың?" — диде. Сонетларны алып бармавыма үкендем. Син дә әйтмәдең. Биреп калдырган булыр идем. Шундый җитәкчеләр булганда яшисе килә башлады әле. Иртәгә үк "Полк намусы"на утырам.

## Соңгы сүз

Берәр елдан Игнатьев әйткән йортны өлгерттеләр. Фатир бүлгәндә безгә дә тәрәзәләре Эрмитаж бакчасына карап торган йорттан өч бүлмәле фатир бирделәр. Монда Гомәр Бәширов яшәгән икән. Яңа йортка күчкәндә әйтте:

— Шәрәф, мин монда күп яза алмадым, инде сиңа эшләргә язсын, — диде.

Теләге кабул булмады Гомәр абыйның. Шәрәф "Полк намусы"н да тәмамлый алмады. Яңа җиргә күчеп, кешечә яши башлагач кына, сәламәтлеге кинәт начарланып китте. Беренче Май бәйрәмен каршы алырга йөргәндә, язгы матур таңда, башына кан савып, дөньядан да китеп барды.

Җеназасына халык күп килгән иде. Кабер өстендә Хәсән Туфан абый шигырь укыды. Хәсрәтле башыма аның бер генә юлы кереп калды:

Без зинданда булганда,
Сез җиһанда йөргәндә...

Бераздан чәчәкләргә күмелгән кабер янында Хатип абый белән икәү басып калдык.

— Сугыштан исән кайткан кеше бит, иллесе дә тулмаган көе китеп барыр дип кем уйлаган? Әйдә, кайтыйк инде, — диде ул бераздан, сүзсез генә озак басып торгач. — Син монда күп тапкырлар килерсең әле.

Әрвахларның тын һәм тыныч патшалыгыннан әкрен генә атлап чыгып барабыз. Зират капкасына җитәрәк йөгерә-атлый килгән Шәйхи Маннурны очраттык.

— Соңга калдыммыни? — диде ул, безне күргәч, әрнү катыш үкенү белән. — Васильевода ишеттем. Поезд бит...

Без аны Шәрәф каберенә озатып куярга теләгән идек, баш тартты:

— Үзем генә барыйм әле. Урынын гына әйтегез.

Авыр атлап китеп барган шагыйрь артыннан, ул борылышка җиткәнче, карап калдык.

**Редакциядән:** *Безнең коллективта озак еллар эшләгән, журналыбыз елъязмасында якты эз калдырган күренекле әдибә Ләбибә Ихсанованың август аенда туган көне. Аны ихлас күңелдән тәбрик итәбез, сәламәтлек, озын гомер телибез. Ул әле яңа әсәрләре белән укучыларыбызны киләчәктә дә сөендерер дигән өметтә калабыз.*

# ШИГЪРИЯТ



## Гәрәй Рәхим

### АУЛАК БУ ҖИҺАНДА

#### Аулак

**Ни өчендер мин гомерем буе**
**Аулак почмакларны яраттым.**
**Аулак урамнарда,**
**Урманнарда**
**Аулак хисләремә җан аттым.**

**Аулак өйләр,**
**Аулак тугайларда**
**Аулаклыкка тәмам өйрәндем.**
**Мин шигырьдә яклыйм**
**Аулак фикер,**
**Аулак сурәт,**
**Аулак ямь тәмен.**

**Иксез-чиксез дәртле мәхәббәттәй**
**Мин омтылам һаман аулакка.**
**Шул аулакта бөтен теләгемне,**
**Дәртләремне үтәп калмакка.**

**Аулак өнәр кызыктыра мине,**
**Күңелләрнең аулак почмагы.**
**Аулак кыйтга,**
**Аулак материклар,**
**Галәмдәге аулак Җир шары.**

**Аулак Кояш,**
**Аулак Ай,**
**Йолдызлар,**
**Аулак Марс,**
**Аулак Венера...**
**... Мин алардан аулаграк бугай —**
**Фикри япа-ялгыз мин торам.**

Аулаклыкның бөеклеген тоеп,
Аулак татар өчен көрәшәм.
Гәрчә аулак кына бу җиһанда
Мин нибары аулак керәшен...

...Гомеркәем, мине ташлама син —
(Бу минем бер аулак табыну...)
Озын гомер — сирәк бәхет бит ул,
Ул — аулакта йолдыз кабыну!

## Аксубай

*Танылган татар галиме Әнвәр Хәйри туган ягы Аксубай төбәгендә борынгы болгар халкының бишеге булырдай урыннарны ачыклады.*

Аксубайда булганым юк иде —
Онытылган ерак бер төбәк.
Мондый ерак, аулак төбәкләрдә
Серләр булмый калмый ул, димәк.

Әй, Аксубай!
Ап-ак суларга бай,
Тарихымның йөзек кашы син.
Шәҗәрәләремне белү өчен
Ачыккан җанымның ашы син.

Син бит бөек болгар бабаларның
Могъҗизалы, серле бишеге.
Бүген әле безгә ачылмаган,
Әмма ачылачак ишеге.

Шул ишекне атлап кердем бүген:
Син — халкымның ерак ярасы.
Ап-ак сулар гына түгел, синдә
Суларның бар икән Карасы *.

Бөеклектән алып — җимерелү,
Бетү, сүнү, онытылулар...
Кальгаларың җиргә тигезләнгән,
Калаларың инде буш кырлар...

Карасуда, шул ук Аксубайда
Бүгенгечә туып торалар
Сары чәчле, сылу, ап-ак йөзле
Тупырдашып торган болгарлар.

Оныкларның оныклары үсә,
Болгар оныклары бу якта!
Ник килмәдем икән моңа кадәр?!

---

* Аксубай районында Карасу авылы бар.

Миңа рәхәт...
Миңа оят та...

Аксубайда булганым юк иде —
Онытылган аулак бер төбәк.
Тамырларын эзләп йөргәннәрне
Чакырачак әле,
Үзен таптырачак,
Яраттырачак әле ул, димәк!

## Чишмә

*Иҗади остазым, якташым, танылган*
*татар язучысы Шамил Бикчурин истәлегенә*

Күңелемдә дистә еллар буе
Яшеренеп йөри бер җырым.
Ул сулкылдап шакый күңелемне...
Бу җыр синме, Шамил Бикчурин?!

Син җыр кебек олы моңлы идең,
Син җыр кебек ачык, җилбәгәй...
Синдәйләрне чорлар алып китми,
Синдәйләргә салкын җил бәрмәй.

Җиз чәчеңне җилгә җилфердәтеп
Йөрисеңдер әле урамда.
Озын кулларыңны бутый-бутый
Йөзәсеңдер тормыш-буранда.

Мәҗлесләрдә бас тавышың белән
Тетәсеңдер таныш ария.
Тыңлыйлардыр сине бердәй тынып
Татар Мәрьям, урыс Мария.

Бүген сине җыр итәргә телим.
Син сулкылдап җанга дәшәсең.
Әй, яшәсен икән бу дөньяда,
Синдәй фида җаннар яшәсен.

Синдәйләр аз, синдәй киң күңелле
Адәмнәргә кытлык, йә Ходам!..
Кече күңеллелек өлкәсендә
Син бит безнең соңгы могикан.

Ташны бәреп чыккан чишмә кебек
Күкрәгемне бәреп чык, җырым!
Безне тартты җырга, шигърияткә
Шигъри җанлы Шамил Бикчурин.

## Азнакай каены

*Азнакайда мин яшәгән кунакханәнең тәрәзә каршында ап-ак гәүдәле каен кызлары йөгерешә иде*

**Тәрәзәмне ачсам
Күзләрем камаша.
Бу нинди аклык соң,
Бу нинди тамаша?!**

**Тәрәзәм төбендә
Каен кызы тора.
Гүзәллеген күреп
Хет көл син, хет ела.**

**Азнакай каены
Тәрәзәмә килеп,
Алгысыта мине,
Карап тора көлеп.**

**Азнакай каены,
Карамачы миңа.
Ничек түзәрмен соң
Гашыйк булсам сиңа?!**

**Азнакай чибәре
Үз хәйләсен иткән —
Каен сурәтенә
Әверелгән икән!**

**Каян белгән минем
Йомшак булганымны,
Тик мәхәббәт өчен
Җиргә туганымны?!**

**Инде бетте, тәмам!
Янам, дөрләп янам,
Каен кузы сыман,
Каен тузы сыман!**

**Үземә кычкырам:
— Сөярсең син мәңге
Азнакай каенын,
Әй, Шөгер имәне!**



# Халисә Мөдәррисова

## ГОРУР ЯЛГЫЗЛЫК

### Ялгыз кабер

Зират урыны... Асфальт юл үтә:
(Ялгыз кабер Сырыш-елгада...)
Агыла кеше, агыла машина, —
Ашыга гавам фани дөньяда.

"Нәрсә өчен килдең, кем идең,
Кая киттең?" — Юкка җан кыйнау.
Ялгыз кабер — өнсез мәңгелек,
Җаваплары булмас бер сорау...

Үтәрмен бит мин дә дөньядан,
Яңгыр юар кабер ташымны,
Их, шул чакта җавап бирәлсәм,
Ташларыма куйгач башыңны...

Ялгыз кабер ташын җил кайрый,
Вакыт тора комнан, күмердән, —
Бу дөньяның барлык соравы,
Бар җавабы шунда күмелгән.

### Җәяүле буран

*Каенатаем Х. Янгиров истәлегенә*

Басу аръягында атлы —
Җәяүле буран яра,
Толып якасын күтәреп
Офыкка кереп бара.

Яшьлекнең алсу еллары
Окопта янган чакта,
Дошман — алдан, безнекеләр —
Аркага аткан чакта.

Шушындый җәяүле буран
Булды өй дә, җаный да.
Хәзер менә йөзне капшый,
Танымый да, таный да.

Чор үзгәрде, гавам — шул ук,
Бары башкарак тамга.
Алга да, артка да түгел,
Тәрәп аталар җанга.

Яшәү — мизгел, дөнья — фани,
Җилгә туза табышлар,
Буранда адашып кала
Ваклыклар, ышанычлар.

Гомер буе шушы буран
Озатты, тотам калмый,
Бер — дус булып, берчә — дошман,
Бер — юата, бер — алдый,
Тик барыбер ул — хәрәкәт,
Ул — омтылыш, ул — армый!

Бер — җыр җырлап, бер — шом салып,
Бер — көч бирә, бер — тыя,
Шуңа микән — бу дөньяда
Яшәүләрдән кем туя?!

... Юл башында җайдак-оньык
Җилләргә йөзен куя.

* * *

Аерылуның ачы җиле
Аралардан узды инде,
Күңелләрдә — көзге салкын —
Читләшүнең бозы инде.

Ялкын гына җылытала,
Җылытучы төтен булмас,
Бер киселгән икмәк кире
Бөтен булмас, бөтен булмас.

Йокыларың кисеп таңда,
Тәрәздән болыт агылса,
Йәки ятим көчек кебек
Тезеңә җилләр кагылса,

Юатучың, юк, мин булмам,
Күздән киткән — җаннан купкан,
Кемгә — хәсрәт, кемгә — шатлык,
Уртак хисне упкын упкан.

Урамда — май, дөнья гөрли,
Офыкларда — яшел ялкын,
Араларда — ачы җилләр,
Күңелләрдә — көзге салкын.

Үз-үземә урын тапмыйм.

## Зәңгәр күзле ак эт

Без яшь әле, сөю — бар дөнья...
Зәңгәр күзле көчек болдырда

Буталмыйча, бахыр, кемгә дә
Сырпаланды килеп эргәгә.

Терәп тезгә тугры башкаен,
Зәңгәр күзле ап-ак маңгаен,

Ул илгәзәк без дип җан атты,
Икебезне бер тиң яратты.

Кайнар төннәр, дымлы иреннәр,
Су коену төнге Иделдә...

Уртак еллар, дуслар, табыннар,
Анда-санда чит-ят чалымнар.

... Гомер үтә, йөздә — җыерчык,
Көзгедәге чырай — кыерчык,

Шиңгән гөлләр кебек бакчада —
Сатып алып булмый акчага.

Җиталмадык бергә "кичүгә"
Бер сөюне бүлеп икегә.

Сөю үткәч, нәрсә бүлешик?
Миңа — уңга, сиңа — сул ишек.

Тик бер әйбер икән уртак бар:
Зәңгәр күзле ак эт — уртак мал.

Кайда итик аны, ни эшлик,
Уртагамы аны бүлешик?

Койрык болгый тугры, ни чара?
Зәңгәр күзле ак эт-бичара.

• • •

Югалту артыннан, югалту...
Ә ялгыз минутлар ачылар.
Сиреньнәр куагы өстенә
Тама да, тәгәри тамчылар.

Тама да тәгәри... Ничә яз,
Ничә көз тәрәзәм артында.
Шыбырдый шул сирень куагы
Һәр төндә ялгызлык хакында.

Ул мине юатып сүз әйтми,
Ул әрни мин һаман көткәнгә,
Көннәрең артыннан елларың,
Гомерең заяга үткәнгә.

Ах, сирень, син дә бит ялгызсың,
Шыбырда, юат бер тагын да.
Битараф ят белән бер мендәр бүлгәнче,
Шул горур ялгызлык хакында.

# Чәчмә әсәрләр



## Ркаил Зәйдулла

# КЕЧКЕНӘ КЕШЕЛӘР

хикәяләр

### Мылтык

Чолан эче ярым караңгы иде. Муртайган такта ярыкларыннан саркып кергән чапраш кояш нурлары гына тыгыз караңгылыкны телеп алып, яктылык тамчыларын чәчрәтә. Түшәмгә эленгән мәтрүшкәләр, дүркәләр, төрле дару үләннәренең исе аның чыраен сыйпады, борын канатларын кытыклады. Ул, былтыргы миннекләрне аралап, почмак якны капшады, анда аның ике көпшәле мылтыгы эленеп торырга тиеш иде. Учы шуның салкынча шома түтәсенә килеп орынгач, ниндидер алжыткыч рәхәтлек бөтен тәненә таралды. Аның инде күптән кулына мылтык алганы юк иде. Ул инде аның барлыгын да онытткан иде.

Гаҗәп, заманында ул шәп аучы санала иде бит.

Ниһаять, пәрәвезләргә чорналып, каен яфракларына тиенеп кояш күзенә чыкты, ишегалдына түшәлгән сары-кызгылт яфракларны ерып, җилкапка кырындагы эскәмиягә таба атлады. Көз җитте, дип уйлады ул иренеп, аны раслагандай, иске эскәмия шыгырдап-ыңгырашып алды. Өстенә аварга торган сап-сары урманда ымсындыргыч тынлык хөкем сөрә иде.

Шул чакта урман үз эченнән иңенә көянтә аскан яшь хатынны этеп чыгарды. Ул балдызын танып, елмаеп куйды. Кер чайкап кайта. Инде өченче катлый. Күп җыелган кер... Хатын җизнәсен күреп, балкып елмайды.

— Ауга чыгарга җыендың мәллә, җизни?

“Әйе шул, берәр асылкош эләкмәсме миңа да...”

Ул үзенең шаяртуыннан кыенсынып, кинәт тынып калды, куе кашлары җыерылып килде, саңгырау тавыш белән:

— Күптән инде кулга мылтык алган юк иде, — дип мыгырданды.

Хатын исә, үзе кер чайкаган урман чишмәсе тавышын чыгарып, челтерәп көлде:

— Сиңа да асылкош эләкмәгәч инде, җизни...

Ишегалды буйлап сузылган баугa кер элеп йөрүче балдызына аратирә күз ташлап, ул мылтык көпшәсен чистартып утырды. Хатынның чыланган күлмәген төртеп торучы күкрәкләре, ачык таза беләкләре, җыерылган итәге астыннан ялтырап күренгән шома ботлары күз карашын өстери дә китерә, өстери дә китерә иде.

Балдызы монарчы шәһәрдә торды. Анда кияүгә дә чыккан иде. Туйга аларны чакырдылар бугай, әмма барып булмады. Ул хатынының туганнары белән аралашмый иде. Дөресрәге, алар үзләре аны тиң күрмәде. Хатынын да аңа кияүгә чыккан өчен гафу итмәделәр. Кызының гади урман каравылчысын, кешеләр белән аралашмый торган, үз эченә бикләнгән сәер адәмне сайлавын кичермәде атасы. Киявенә дә кул бирмәде, сыңар сүз катмады, өенә алдырмады. Картайгач йомшарыр әле ,дип, баштарак хатыны өметләнгән иде, әмма, юк, боз эремәде. Карт бик киребеткән булып чыкты.

Ләкин кияүнең дә моңа бик исе китмәде. Урманда хатыны белән акрын гына гомер кичерделәр. Бәхетлеләр дә иде тесле... Тик балалар сөенечен генә татый алмадылар...

Әйе, балдыз аерылып кайткан. "Урыстан да битәр эчә", —дип, ире турында апасына сөйләп торганын колак очы белән генә ишетеп калган иде ул.

Ачык чырайлы, көр күңелле хатын... Менә аларга да кер уарга, өй җыештырырга, булышырга килгән. Әтисе ничек җибәрде икән? Әллә аңа сиздермичә генә чыгып киткәнме?

Ул мылтыкны коймага терәде дә, үзе өйгә таба атлады. Аяк астына сары-кызгылт юрган булып түшәлгән яфраклар үзара серләшүдән туктап, аяк табанына сырпаландылар.

Идәнне шыгырдатмаска тырышып, ул түрдәге чаршауланган ятакка якынлашты. Кыргычлап юып чыгарылган сайгаклар үзләренең табигый саргылт төсен кайтарырга азапланып яталар иде.

Ул, чаршауны аралап, ятак кырындагы тәңгәлгә килеп утырды. Юрган астындагы ябык гәүдә аны күрүгә кымшанып куйды, пәрәвезләр сарган сары йөзендә елмаю чалымы сизелде.

— Хәлең ничек? — дип сорады ир. Җавап таләп итми торган гадиз сорау иде бу. Мең тапкыр кабатлаудан мәгънәсен югалткан әлеге ике сүзнең иреннәре арасыннан ычкылып чыгуына аның инде ничәнче кат ачуы килеп куйды. — Бүген көн чалт аяз тора... — диде ул бераздан. Аннары нигәдер өстәде: —Яфраклар коела...

— Туңып торам әле, — диде хатыны. — Җеп өзәр дәрманым юк. Авызым кипте.

Ир янәшәдәге урындыктан чынаякны алып, хатынына суынган чәй йоттырды. Чабуы тиеп киттеме, андагы бер дару шешәсе идәнгә төшеп, ишеккә таба тәгәрәде.

— И-и, бигрәк жайсыз инде син... — дип, хатыны зарланган сыман сөйләнеп алды.

— Шушы көннәрдә сары бия колынларга тиеш, — диде ир, гаепле тавыш белән.

— Эчемдә нидер өзелгән... Казанда Минкәев дигән бер табиб бар икән, Кукмарадан торып Кара диңгез астындагы җир тетрәвен туктата, ди. Шуңа күренәсе иде. — Хатын кипшенгән иреннәренә юеш кульяулыгын тидереп алды. — Күктәге болытларны ары-бире куып йөртә, имеш. Мине генә терелтә инде ул...

Хатынының йөзенә кызыл таплар йөгерүен күзәтеп утырган ир кузгалып куйды.

— Бүген ауга чыкмакчы булам әле. Берәр киек эләксә...

— Кем алып барсын соң мине ул табиб янына, — дип еламсырады хатын.

— Бераз рәтлән, барырбыз. Ә бәлки аның үзен алып килермен әле...

— Алмакай кайда? — Хатыны сенелесенә нигәдер шулай эндәшә иде.

— Керләр элеп йөри...

— Шәһәрдә нинди чибәрләнгән... Умырып эшли. Әле тагын өч-дүрт көн торам дигәние дә, бездә эш бетмәс, тоткарланма, мәйтәм... Әти белсә...

Ир чистарып, яктырып киткән өй эчен карашы белән айкап алды. Һава да үзгәргән, дару исе алай ук борынны ярып керми иде. Анысы тиз генә бетмәс инде, ун ел буе стеналарга сеңгән ис ич.

— Торасы килгәч, торсын... Нигә куарга?

— Иреннән уңмаган, мескен... — диде хатыны өзек-өзек. — Әтидән сорамыйча гына килгән ул.

— Алайса кайтсын...

— Миннән туйгансыңдыр инде... Сөйләшүеннең дә рәте-чираты юк. — Хатыны тагын еламсырап алды.

— Мылтыкны күптән тоткан юк иде, — диде ир. — Барлыгын да онытканмын. Менә бүген чоланнан алып чыктым әле.

— Шул табибның сурәтен эчкә куеп торсаң да, чирне ялап ала икән. Алмакай сөйләп торды әнә, шул фотоны куеп йоклагач, Аю Шәвәли хатынының чәче яңадан карала башлаган, ди. Авылга төшеп, шул фотоны апкайтыр идең.

Ул иелеп караватт астын карады.

— Мәшәкатьләнмә, Алмакай түкте инде, — диде хатын.

— Иртәгә барырмын. Бүген урманга чыгам. Киек шулпасының сихәте тимәсме...

— Юк инде, үләрмен, ахрысы... Котылырсың инде... Кырыгымны уздырмас борын өйләнәсе булма түлке...

— Тузга язмаганны сөйләмә! — Ир авыр гына урыныннан кузгалды. — Тиздән йөгереп йөрерсең әле.

— Алмакайга рәхмәт, күпме дару гына алып килгән...

— Сыерга печән төшерергә кирәк. Бераздан сөтен калдырыр инде, бозауларга ике ай гына калып бара, — диде ир, үзалдына сөйләнгәндәй.

Көз дә житте, дип уйлады ул янә кояш күзенә чыккач. Тик нигәдер жанда моңсулык юк, йөрәк тә үз урынында сыман түгел. Ауга чыгасы булганга шулайдыр.

Балдызы ишегалдында күренми иде. Ул мылтыгын жилкәсенә асып, урманга таба атлады. Шул чагында артта көләч тавыш ишетелде: "Асылкошсыз кайта күрмә, жизни!" Ир борылып елмайды, аннары шул елмаюыннан уңайсызлангандай, тәвәккәл адымнар белән юлын дәвам итте.

Урманга керер алдыннан, ниндидер тонык авазлардан әсәренеп, ул күккә карады. Анда, биектә, киек кошлар төркеме чылбыр булып тезелеп каядыр еракка, ул белмәгән якларга очып бара иде.

## Сөембикә

Тәрәзәдә хатынның чалыш чырае күренде. Мөгаен, ашың өстәлгә куйгандыр да суына дип борчыладыр. Мин ишегалдындагы "КамАЗ"ымны янә әйләнеп чыктым, көпчәкләргә типкәләдем. Барысы да әйбәт кебек төсле. Иренеп кенә өскә күз салдым —ашлык белән шыплап тулган кузов брезент белән нык капланган, яңгыр-фәлән яуса, тамчысы да үтәрлек түгел. Юл ерак — Каф тавы артына, шуңа машина жырлап торырга тиеш.

Көзнең шушындый чалт аяз көннәрен яратам мин. Һавада йөзгән тоҗымнар адашып йөзгә орынып үтсә, әллә нишләп китәм. Ындыр ягыннан саркылган төтен исе борыннарны кытыклый. Бәрәңге сабагы яндырганда чыккан төтен бөтенләй үзгә ул!

Тамак ачыккан булса да, өйгә керәсе килми иде.

Шул чагында капка шыгырдаганы ишетелде. Анда көтүче Йосыфның бөрешкән гәүдәсе күренде. Ул бер ара капка төбендә таптанып торды да гаепле кыяфәт белән миңа якынлашты.

— Нихәл, олан...

Мин сүзсез генә башны селкеп куйдым.

— Ерак юлга чыгарга җыенгансыз икән, хе-хе... Әрмән иләнә диген, ә... — Йосыфның эренле күзләре кызгылт җыерчыклар эченә чумып, югалып торды.

— Ни йомыш? — дидем мин тупас кына.

— Йомыш әллә ни юк, хе-хе... Син инде анда Сөембикәне күрерсең, карчык белән мәктүп сырлаган идек, тапшыра алмассыңмы?

— Нигә тапшырмаска... Хатның авырлыгы юк, барып житүгә үк үз кулына бирермен... — Йосыфның үзен өнәмәсәм дә, Сөембикә исемен ишеткәч, мин бераз йомшадым.

Ул тагы ни әйтергәдер теләп, таптанып алды.

— Бер-ике тапкыр хат язып, илләренә киткән әрмәннәргә биреп җибәргән идек, әллә тапшырмаганнар, әллә... Җавап-фәлән килмәде.

— Тапшырырмын дидем ич инде. Җавабын да алып кайтырмын.

— Менә рәхмәт, менә рәхмәт, — дип, бер сәбәпсезгә кеткелдәде көтүче. — Әрмәннәр бик бай яши, диләр, күреп кайтырсың инде. Кияүдән дә хәбәр юк. Көннәр чалт аяз тора, йортны күтәрергә иде бит. Син телдән шуларны да аңлатырсың инде, урысчаң яхшы...

Мин чыраемны сытып куйдым:

— Бай кешеләр, Йосыф абзый, ничәмә мең чакрымнан илләренә икмәк ташымый.

— Алай димә, алай димә, — диде көтүче. — Калхуз исәбеннән булгач, нигә алып кайтмаска? Юлы да безнең мажик өстеннән ич аның, әрмән корсагын киереп утырып кына кайта.

"Кара әле, дип уйладым мин, эчә-эчә мие кибеп бетмәгән икән, дөрес чамалый бит абзый..."

Менә ун еллап инде безнең авылда әрмәннәр шабашкала эшли. Аларның кайсысы килә, кайсысы китә, ә бригадирлары — Рафик дигәннәре — тәмам безнең авыл кешесе булып беткән иде. Әрмәннәр үзләре салган таш йортта торалар, ә бу Рафик исә Гәүһәр дигән тол хатынга йортка кереп, шунда яши иде. Ул теттереп татарча сөйләшә, безнең авыл кешесеннән аерып та алып булмый, дияр идең, үзен бик кибарь тота, хәтта түрәләр кебек муенына галстук асып йөри иде. Башта алар әйбәт кенә эшләделәр, хәзер әллә колхозның акчасы бетте, әллә төзисе әйбер калмады, әрмәннәр инде вак-төяк эшләрдә генә йөриләр, яртысы район үзәгендә персидәтелгә катижмы, матижмы, диләр, өч катлы йорт салып ята иде. Шулай да илләренә кайтырга ашыкмыйлар. Нигә ашыксыннар, безнекеләр айлар буе акча алмаганда, болар Ходай бирмеш һәр ай азагында бухгалтер бүлмәсе тирәсендә чуала, елтыраган күзләренә караганда юкка гына чуалмыйлар да иде төсле. Телевизор да, радио да алар иленде сугыш бара дип лаф ора, ә монда кая башны тыкма — әрмән дә әзери, белмим, үзләрендә кемнәр генә сугыша торгандыр, әллә картлар белән бала-чага буза куптарып ята инде?

Рафик исә тир түгеп маташмый, кайчан карама, ул персидәтел эргәсендә, анда чаба, монда йөгерә, Казаннанмы, районнанмы зур кунаклар килсә, ул инде Аулак болында: табын әзерли, шашлык кыздыра. Татар сарыгыннан әрмән кыздырган шашлык хәйран тәмле була, имеш. Кешеләр сөйли, минем үземнең авыз иткәнем юк югын. Янәсе, ул Рафикны район башлыгы безнең персидәтелдән үзенә дә алмакчы булган, тик безнеке кул-аягы белән каршы килгән: "Җанымны ал, иптәш район башлыгы, тик Рафик җанымнан гына аерма", — диеп ялынган, имеш. Булса да булыр, сезнең шашлык бигрәк тәмле, дип, әллә кайлардан, хәтта хатын-кызлары белән машиналарга төялеп киләләр бит.

Әрмәннәр клубта да күз өстендәге кашка әйләнделәр. Сиздек инде, кызларның йөрәгенә ут капты. Болар бит без Шалпы малайлары кебек колак шалпайтып башны җилкәгә качырып йөрми, гәүдә купырайган, ияк һаваны ертып бара, борын җилле... Менә шунысы бигрәк безнең кызларның һушын алды инде. Хатын-кыз бит чагыштыру юлы белән ялгыш нәтиҗәләр ясарга чос кавем.

Безнең мона ачу килә инде — минем ул чакта егет чак — куллар кесәдә, тик кесә эчендәге йодрык белән кемне куркытасың? Йөрибез шулай теш кайрап, бер-беребезгә зарланышып. Шулай да әрмәннәр алай ук начар малайлар түгел икән, ара-тирә безнекеләрне җыеп, бер-ике ярты куялар, эчеп алгач инде җегетләрнең авызы җәелә, хет бөтен авыл кызын шыплап төяп машинага салып китсеннәр.

Әрмәннәр мал аера белә икән. Күзләре шунда ук көтүче Йосыфның кызы Сөембикәгә төште. Арсен дигәннәре бигрәкләр дә тирәсендә бөтерелә инде. Шоколадтыр, чикләвектер белән сыйламакчы була, артыннан күләгә кебек ияреп кайта. Сөембикә безнең авыл җегетләреннән дә озаттырмый иде, ут кыз икән, әрмәнне дә якын китерми. Минем үземнең дә аңа күңел яткан иде, тик юаш шул мин, бер сүз кушарга кыймыйча тик исәнгерәп йөрим.

Инде бөтен авыл әрмән белән Сөембикәне сөйли, әрмән, имеш, бөтенләй ашау-эчүдән калган, янәсе, кайберәүләр кызны мактый, бигрәк тә җегетләр: "Маладис, җүнле кыз теләсә нинди кара күт белән тел пычратамы", — диләр, ә ахирәт кызлары үз артында көнләшүдән буылып гайбәт сата: "Үзен әллә кемгә куйган була бит әле, адәм срамы, көтүче кызы гына түгел, хан кызы, диярсең..."

Арсен ым гына каксын, аларның һәрберсе аңа ияреп китәргә әзер иде төсле. Безнең кызлар бит ул җунглидан орангутанг килеп чыкса, аңа да ябышырга әзер, тик маймыл татарга гына охшаган булмасын.

Ләкин әрмән дигәнең тоткан җирдән сындыра торган халык икән. Беркөнне Йосыф абзыйны персидәтел кантурга чакырып алган. Шунда ук Рафик белән Арсен да утыралар, ди.

— Нихәлләрдә ятасың, Йосыф абзый? — дип персидәтел гомер булмаганны елмаеп, көтүчене ишек төбенә үк килеп каршы алган, җилкәсеннән кочкан. — Бер дә күзгә-башка күренгәнең юк, авырып китмәгәнсендер ич?

Аптырап-каушап калган Йосыф абзый:

— Юк, болай, карчык кына ютәлләп тора, — дип мыгырданган.

Өстәлгә ярты менеп утырган, тәлинкәләргә затлы кунаклардан калган шашлык калдыкларын куйганнар. Ул шашлыкның тәмлелеген көтүче Йосыф ярты ел сөйләп авыз суын корытты.

— Синең йортың бик тузган икән, беркөнне карап үттем, —дип, бераз салып алгач, персидәтел сүз башлаган. — Колхозга биш фин йорты кайтты. Берсен сиңа бирим мәллә? Яшә карчыгың, бала-чагаларың белән рәхәтләнеп яңа өйдә.

Иренен җыеп алырга азапланган Йосыфның "ә" дип тә, "җә" дип тә әйтерлек рәте калмаган, тик башын чайкап утыра икән, бичара.

— Тик шунысы бар, Йосыф абзый, — дигән персидәтел, —менә Арсен синең кызга үлеп гашыйк булган икән ич. Перәме Мәҗнүн инде, ашаганы — аш, йокысы йокы түгел, тире дә сөяккә калган. Ә безнең колхозга андый кешедән ни файда? — Ул горылдап көлеп җибәргән. — Син аңа кызыңны бир, ә без сиңа туй бүләге итеп йорт бирербез.

Тагын берне салып куйгач, Йосыфның бөршәйгән кулы персидәтелнең дәү учына кереп югалган.

— Егет син! — дип мактаган аны персидәтел, — текущий моментны аңлыйсың.

Вәгъдә билгесе итеп әрмәннәр Йосыф абзыйга нигәдер "аэродром" кепка, карчыгына күлмәклек ситса сонганнар. Әмма көтүче ул кепканы киеп йөрмәде, күрәсең, зуррак булгандыр, әрмән башы татарныкы ише генә түгел бит.

Безнең персидәтел шундый — әйтте икән бетте, икенче көнне Йосыф абзыйның турына фин йортын китереп тә бушаттылар. Җый да куй. Ул әле дә шунда ята. Тик такталары гына шактый кимегән, чөнки көтүче бик юмарт кеше безнең, сорап килгән кешене, бер ярты да куйса, буш кул белән җибәрә алмый. Ә авылда тактаның һәрвакыт кирәге

чыгып тора. Аннары төннәрен бердер, икедер тактаны болай гына, кулга сыланып торганга гына да алып китәләр иде булса кирәк.

Арсен Сөембикәне иленә алып китте. Алар кузгалганда мин нигәдер кантур каршында утыра идем. Анын яшьле карашы минем йөзне кисеп үтте, күпергән иреннәре нидер әйтергә теләп, кыймылдап алды. Мин бу чарасызлыкны күрмәскә теләп, башны түбән идем. Соңыннан Сөембикәне тәкәбберлектә гаепләгән кыз-хатыннар аны шулай чит илгә алып китүләре турында бәет тә чыгардылар. Безнең халык нигәдер бәхетсезләрне, кимсетелгәннәрне ярата, әзелеп, чын күңелдән шуларны кызгана.

— Шулай да йорт торгызырга жыенуым турында әйт син, —диде көтүче мина якын ук килеп. Йөземә төнә эчелгән аракының сасысы килеп бәрелде.

— Ул калдык-постыклардан нинди йорт торгызмакчы буласың?

— Анысы такталар бераз кимеде инде кимүен, житмәгәнен персидәтелдән сорармын...

— Тоттырыр, — дидем мин, ачы көлемсерәп. — Кыз бит инде түгү!

Бу турыда исенә төшерүем ошамады булса кирәк, картның йөзендә пәрәвез селкенеп куйды. Хәзер аты-юлы белән сүгенә дисәм, эчтән тынды тагын, йомыш белән килгән бит. Ә ул сүгенә башласа, туктатам димә инде, эшереп чыгарсаң да югары очтан түбән очка кадәр ярты сәгать әче тавышы ишетелеп торачак.

— Бирмәсә инде, — диде ул янә юашланып, — моңарчы яшәдем ич әле, алга таба да шул иске йортымда көн итәрмен. Миңа инде озак калмаган. Ә фин йортын мәчет салырга бирәм. Тирә-юньдә барысы да мәчет өлгертә, ә бездә исе дә юк. Шул турыда кичә Шәриф мулла белән дә сөйләшеп тордык әле. Халык та бераз булышса, ерып чыгабыз аны, пускай Шәриф мәчетле булсын.

Тәрәзәгә тагын хатынның чырае сытылып алды.

— Сау бул, Йосыф абзый, — дидем мин, саруым кайный башлавын тоеп. — Әманәтеңне үтәрмен.

— Тукта әле... — Көтүче янә миңа таба елыша төште. — Бирәр нәрсәң юкмы, юл аягы дию ем... — Ул кызганыч елмаеп куйды. — Кичә ныграк киткән.

Мин эндәшмичә генә болдырга таба атладым. Ул бераз таптанып торды да ыңгырашкан адымнар белән капкага юнәлде.

Без авылдан өч КамАЗ чыгып киттек. Мин алдан барам, ни әйтсәң дә армияләрдә булып, бераз дөнья күргән кеше. Рафик, әлбәттә, минем машинага утырды. Ул бик сөйләмчәк кеше булып чыкмады, әйбәт. Күп шоферлар руль артында йокымсырап китмәс өчен күршеләренең тел тегермәне тартып баруын яратсалар да, мин үзем лыгырдыкларны җенем сөйми.

Үзалдыңа уйланып баруга ни житә. Уйларың ялыктырса, музыка жибәрәсең, кәеф!

Күпмедер юл киткәч, кабина идәнендә нидер кыштырдаган төсле булды. Карасам, утыргыч астына таба уч төбе кадәр генә соры күләгә шуып үтте. Тычкан! Күрәсең, иген төягәндә кереп калгандыр. Рафик та игътибар иткән, “хәзер тотып сытабыз”, — ди. “Тимә, — дим, — ул бит безнең авылныкы.”

Рафик ирен чите белән генә елмаеп куйды: “Ну син даешь, авылдаш тапкан...”

Юлда бу тычканга мин тәмам ияләштем, утыргыч астына бодай сибәм, ул да үзенә хәерхаһ булуны аңлады, ахрысы, рәхәтләнеп кыштырдавын белә. Чит жирләр аша үткәндә янәшәдә генә синең белән туган илеңнең бер жан иясе баруын тою күңелгә ниндидер тынычлык өсти икән. Хәтта ул жан иясе гади генә бер тычкан булса да...

Ул да бит синең белән бер жирдә ялгаган, бер икмәкне ашаган.

Менә без таулардан түбәнгә таба төшә башладык. Аста — тау итәгендә зур гына авыл жәелеп ята иде. Рафикның йөзе үзгәрде, күзләрен яшь элпәсе каплады.

— Безнең авыл, — дип пышылдады ул. Мин аның дерелдәгән мыегына гаҗәпләнеп күз төшердем. Һәркемгә үз җире кадерле шул. Шушындый оҗмахтай җирләрне ташлап, болар нигә читкә чыгып китәләр икән? Яшәсен иде туган йортында җиләк-җимеш ашап, шәраб чөмереп. Нигә һәркем үз илендә яшәми, нигә һәр халыкның үз ватаны юк?

Ашлыкны бушатып, тыйнак кына тамак ялгап алгач, мин Рафиктан Сөембикә турында сорадым. Аның елмаюы сүнеп, кашлары җыерылып килде, шикле карашы, ниятемне белергә теләгәндәй, баштан-аяк гәүдәмне капшап чыкты.

— Нигә ул сиңа? — диде ул, чатнаган тавыш белән.

Мин ваемсыз күренергә тырышып, авызны җәеп елмайдым.

— Атасы хат җибәргән иде.

— Бир, үзем тапшырырмын.

— Юк инде, Рафик, — дидем мин кискен генә. — Шул кадәр юл килеп, Сөембикәне күрмичә китсәм, атасына ни әйтермен?

Ул миңа беравык кызыксынып карап торды. Артына салам бөртеге тыгылган “фатыйманы” малайлар шулай дикъкать белән күзәтәләр. Шалпы малае да тешен күрсәтә ала икән, дип уйлагандыр, мөгаен.

— Ярый, кичкә барырбыз. Ял итегез әле башта...

— Юк, йортын күрсәт тә, хәзер барып кайтам. — Аның аптырап калуы миңа тагын да кыюлык өстәде. Пычагымны эшли аламы ул миңа, аның да бит Татарстанга кире китәсе бар...

Бәхәсләшеп тормады, җилкәсен сикертеп куйды да урамга таба атлады егет.

Коры көньяк һавасы борын тишекләреннән үтеп, сулыш юлларын кытыклый иде. Рәхәт бөркүлек. Йөзем бакчалары куенына кереп поскан җилнең койрыгыннан тартып чыгарасы килә.

Менә Рафик таш койма белән әйләндереп алынган бер йорт янына килеп туктады. Ишектәге бауны тартты, эчтә нәни генә кыңгырауның әрсез челтерәгәне ишетелде. Бераздан ишек чинап кына ачылды, бусагада мыеклы бер әрмән карты басып тора иде. Алар үзара тиз-тиз нидер сөйләшә башладылар. Ара-тирә кычкырышып алалар, кулларын бутыйлар. Талашалармы, ярашалармы, Алла белсен. Күпмедер шулай ыгы-зыгы килгәннән соң, карт өенә юыртты.

— Кер, — диде Рафик, — хәзер Сөембикә чыга. Сүзне бик озакка сузма, мин монда көтеп торырмын.

Мин аякларны буташтырмаска тырышып, ишегалдына үттем.

Кара күлмәктән, башына да кара яулык бөркәнгән хатынны башта танымыйчарак тордым.

— Сөембикә!

Аның йөзе дә кучкылланып киткән, борыны да озынаеп калган шикелле. Әйе, әйе, Шалпы авылының Сөембикәсе әрмән хатыннарына охшый башлаган иде...

Ул миңа бер метрлар якын килмичә туктап калды. Мин кулны сузып үзем аңа омтылдым, яргаланып беткән кытыршы бармакларын учыма алдым. Бармаклар бераз дерелдәп алдылар да җайсыз гына учтан шуып чыктылар.

— Исәнме...

Нинди дә булса шаян сүз әйтеп, бу киеренкелекне таратып җибәрәсем килде.

— Авылда сөйләгән булалар тагын, имеш, синең колак-борыннарны кисеп, ябып асрыйлар, дип... Ә менә син! Дүрт ягың төгәл, килмәгән төшең юк... — Мин гаҗәеп үткен сүз әйтүемә шикләнмичә көлеп җибәргән булдым.

Сөембикә тавышсыз гына сулкылдап куйды. Мәнсез дә инде мин — шундый шаярту буламыни...

— Әти-әниеңнән хат алып килгән идем... — Ул бөрешеп, таушалып беткән конвертны куенына яшерде.

— Исән-сау яшәп яталармы?

— Аллага шөкер. Йосыф абзый йорт торгызмакчы була. Такталары гына житеп бетми бугай. Тик колхозда биш ай инде акча биргәннәре юк.

"Нигә боларны сөйлим әле", — дип уйладым мин. Мәңге салынмаячак йортта аның нинди гаме булсын?

— Киткәненә өч ел инде, кайтып та күрмисен...

Ул кызганыч кына елмаеп куйды.

— Итәктә ике балам бар, андый озын юлга ничек кузгалыйм...

— Малайлармы, кызлармы? Исемнәре ничек? — дидем мин, сүз юктан сүз булсын өчен генә.

— Тигран белән Вазген, малайлар. — Сөембикәнең күз төпләренә сөенеч нурлары сызылды. — Әле йоклыйлар, күрсәткән булыр идем.

— Арсен да күренми...

— Карабахта ул. Бер ел инде хәбәре-хәтере юк. — Хатынның борыны мышкылдап алды.

"Кайчан өйгә чакыра соң бу?", — дип уйладым мин. Безнең илдә бит капкадан кергән кешене чәйләмичә чыгармыйлар. Ләкин Сөембикәнең андый теләге сизелми иде. Ул гасабиланып кулларын угалый, күзләре ишегалды буйлап йөгерешә иде.

Китәргә кирәк... Башка сөйләр сүз дә юк бугай инде. Әти-әнисенә кучтәнәч биреп жибәрми микәнни?

— Хуш, алайса... Ә-ә... кибетегез кай төштәрәк? Юлга азык-төлек, өйгә кучтәнәч алырга иде.

Ул билгесез тарафка кулын селтәде: "Шунда..."

Минем эчтә ниндидер бер тиле ният уянды:

— Әйдә, жыен, алып кайтам.

Ул жавап бирергә өлгермәде, ишектә теге әрмән карты күренде, Сөембикәгә кулларын болгап нидер әйтте. Караңгы ишеккә суырылып кергән хатынның соңгы сүзләре бусагага коелып калды:

— Сәлам әйт...

Икенче көнне без илгә кузгалдык. Муфтадан аякны алганда нидер чи-ик итеп куйды. Инде минем тәмам өйдәшкә әйләнеп беткән теге тычкан ялгыш табаным астына килеп кергән икән. Менә бит ул — меңнәрчә чакрымны исән-сау үт тә, аз гына саксызлык аркасында дустыңның табаны астында сытылып үл. Мин машинаны туктаттым да терсәгем белән рульгә таянып, йодрыкларымны күземә батырдым. Тик озак утырырга туры килмәде, арттагылар зәһәр итеп кычкырта башладылар. Мин ишекне ачып, канлы тычкан гәүдәсен тузанлы әрмән туфрагына этеп төшердем.

КамАЗ уһылдап алга кузгалды. Берәм-берәм тау тезмәләре артта калды, алда мине үксез илем көтә иде.

## Бала

Тулай торакның ишегеннән килеп керүгә үк борынга мәче сидеге катыш әллә нинди әчкелтем-төчкелтем авыр ис килеп бәрелде. Стеналардагы штукатур кубып төшкән, күптән юылмаган идәндә чүп-чар өемнәре. Тәрәзәсе ватык кечкенә бүлемтәдә вахтер әби сохари җебетеп чәй эчеп утыра, ул керүчегә төксе күз карашын ташлады да янә кара кучкыл стаканын авызына китерде. Икенче катка күтәрелгән төштә зур итеп урысларның яраткан өч хәрефле сүзе язылган иде.

Бүлмәсенә килеп җиткәч, ул кечкенә сумкасыннан ачкычын эзли башлады. Гаҗәп хәл, ир-атлар үз ишекләренә җитәргә байтак ара калгач ук ачкычларын барлап учларына алалар, ә хатын-кыз кайтып җиткәч кенә, букчасында яисә кесәсендә актарына башлый.

Коридор очында, бәдрәфкә каршы, аның күршесе тәмәке тартып тора иде. Кинчә йөзенә гадәттәгечә кызыл төс йөгергән, андый чакта ул үткән-сүткән хатын-кызга сүз кушарга ярата, хәтта кайчакта, җае туры

килсә, кулы белән йомшак жиренә орынып алырга күп сорап тормый. Ләкин бу юлы эндәшмәде, тәмәке көлен идәнгә чиртеп төшерде дә, тәрәзәгә борылды.

Хатын болай күз төшмәслек түгел түгелен. Арча ягындагы чирмеш кушылган авылларда туучыларга хас булганча жирән чәчле, яшькелт күзле, почык борыны тирәсендә сирәк-мирәк сипкелләр сибелгән. Бераз кәкрерәк булса да, аяклары да матур, гәүдәсе дә төз.

Әмма күрше егет тәрәзәдән башын алмады.

Ниһаять, кыйшайган ишек ыңгырашып кына ачылды. Бүлмә пөхтә итеп жыештырылган, ишек төбендәге ике шкаф арасына бау сузып чаршау эленгән. Түрдә — тәрәзә буенда — читәнле бала караваты тора. Аның баш очында Филипп Киркоровның зур сурәте эленгән.

Үз тизәгенә буялган бала торырга азапланып ята, быдыр-быдыр килә, бияләй кебек асылынып төшкән аскы иреннәннән селәгәй ага иде, ул әнисе кайтканны төшенә иде, ахрысы.

Хатын имәнеп китте. Һәрвакыт шулай, инде биш ел узуга карамастан, ул үз баласының кыяфәтенә күнегә алмый, кайтып керүгә аны күргәч имәнеп китә.

Өстен дә салып тормыйча коридорга чыгып китте, табак белән жылы су алып керде, баласын чишендереп шунда утыртты, үзе плитәгә манный боткасы пешерергә куйды.

Баласын юындырган вакытта күз чокырына жыелган яше пылт-пылт итеп табактагы суга тамды. Көн саен күз яше катыш суда юынган гарип баласы савыгырга, аякланырга, күзе, теле ачылырга тиеш, югыйсә... Юк шул, юк шул... Баланың аңы үзе генә белгән караңгылыкта адашып йөри, бу дөньяда алыш-биреше юк иде.

Тапкач та табиблар аны күпме үгетләделәр, туган-тумачасы да сүзгә килеп бетте: "Калдырып чык, бу беркайчан да кеше булмаячак, гомерлек бәла, мәшәкать белән тормышыңны әрәм итәчәксең" — диделәр. Тыңламады. Ничек инде үз баланны, бәгырь жимешеңне, үз кулың белән чит-ят кулларга биреп калдырасың? Алып кайткач та, авылдан килгән әнисе — үзе дә яшьтән тол калган хатын — караватына капланып елады. "Ирең дә юк, бу гарибеңне ничек кенә карап тәрбияли алырсың, и бәхетсе-ез..." — дип такмаклады. Кыя кебек торды ул вакытта яшь ана, илдә чыпчык үлми, янәсе.

"Бәлки чыпчык үлмидер дә, — дип уйлана ул хәзер, — ә кеше үлә, үлә, жанкисәгем. Әнә теге атнада гына өченче катта яшәүче ялгыз карт, түзәрлеге калмагач, тәрәзәдән ташланып үлде". Соңгы вакытта аны гел чүп савытлары тирәсендә күрәләр иде, ул шуннан калдык икмәк кисәкләре, бәрәңге кабыклары жыеп алып кергән икән. И юләр баш, дөнья күрмәгән бәндә, шул чакта табибларның, әнисенең сүзен тыңлаган булса соң... Соңрак аңлады ул аларның хаклыгын, берәр балалар йортына-фәләненә тапшырырга дип йөреп тә карады. Аны ишектән үк кире бордылар. Андый урыннар гарип балалар белән шыплап тулган иде. "Алай гына булмый, — баланны алып калсын дисәң, детдом нәчәлнигенә төртергә кирәк, жаным". Ә кайдан алып төртәсең? Ул үзе дә шул баласына дип бирелгән пенсиягә жан асрап ята. Инде менә ярты ел эш эзли, кайда гына житмәде, яшь баласы барын белүгә үк ишектән кире боралар.

Ул баласын итәгенә алып, манный боткасы ашата башлады, кашыктагы ботканың яртысы гына авызга керә, яртысы ирен читләреннән аска агып бара иде.

Баланы ул инде утызга килеп житкәндә, ялгызы калудан куркып, картлыгында бер тэрәк булыр ичмасам, дип тапкан иде. Төс-кыяфәте мөлаем генә булса да, егетләр аңа ябышмыйлар, күзендәге салкынлык, йөзендәге житдилекме аларны якын жибәрми иде. Егетләр бит чыркылдык, жиңел холыклы кыз-кыркынны ярата, өйләнгәнче алар белән шаярып алгаларга жайлы сыман тоела. Ә өйләнгәндә, әлбәттә, житди, якын жибәрми торган кызларны карарга кирәк. Әмма, ни хикмәт, алар төннәрен

кунгалап-китеп йөри торгач, шул уйнак кызларга күнегеп китәләр, үзләре дә сизмәстән шуларга өйләнеп тә куялар иде.

Ул кичне ахирәт кызының туган көне гадәттәгечә башланды. Табын мул иде — көне буе алар кышкы салат, винегрет ише тәм-томнар әзерләделәр, токмачлы-итле аш пешерделәр. Өстәл уртасында аракы, шәраб шешәләре тырпаеп утыра. Кара озын чәчле, йөзен куе сакал баскан егет касәләргә шампан койды, ниндидер тост әйтте. Ул кайдадыр Казан читендәге бер хастаханәдә баш табиб булып эшли икән.

— Как в лучших домах Лондона и Парижа, — диде ул винегретны сакалы арасына батырыр алдыннан.

Бераз кыза төшкәч, бу сакаллы тагын сикереп торды: "Милләт өчен! — дип кычкырды. — Торып басып эчик".

Ахирәт кыз янына килеп йөри торган аксыл чырайлы, сары чәчле егет хатын-кызларны мактап ниндидер тост әйтеп маташты. "Дөньяда ямьсез хатын-кыз булмый, исергәнче эчәргә кирәк", — дип, янә сүзгә кушылды сакаллы табиб. Кызлар, аның ни әйтергә теләгәнен аңлап бетермәсәләр дә, хихылдап көлеп куйгандай иттеләр.

— Син нишләп күңелсез, — дип, ахирәтенә ябырылды туган көнен үткәрүче кыз. — Йәле, күтәреп куй берне.

— Әйе, нигә алай аерымланып утырасың, — дип, сакаллы табиб та аның янына елыша төште. Кыстый-кыстый бер чәркә аракы эчерделәр.

Дөнья үзгәреп китте! Кыз юк сәбәптән дә көлә башлады. Табында яңгыраган һәр исерек сүз үткен, зирәк булып тоела иде.

Мәҗлес таралгач, кара сакал аны бүлмәсенә кадәр озата барды. Чайкалып киткәндә ул кызның иңенә таянгалап ала, үзе: "Менә бу кулларны күрәсеңме? Алтын куллар... Миндәй врач табып карагыз Татарстанда", — дип сөйләнә иде. Бүлмәгә кергәч тә йодрыгын төйнәп, нигәдер "Азатлык!" дип кычкырып маташты.

Кыз аны кумады. Кая куу — төннәр буе ялгызлыктан интеккән тәне белән куе тир исе килеп торган иргә сыланып ятты. Иртән торып киткәндә:

— Татарны арттырырга кирәк. Ату урыс басты дөньяны, —дип мыгырдады ир.

Шуннан соң хатын аны күрмәде. Бала тудыру йортына да аны ахирәт кызы гына озатып куйды.

Караңгы төшеп килә иде инде. Тәрәзә каршында үскән кырыкмыш өянке канатсыз кош кебек күккә тотына, чарасызлыктан ыңгыраша сыман иде. Хатын тумбочка өстендә яткан кәгазь тартманы кулына алды. Бүген иртән аны ахирәте кертеп чыккан иде. Ул инде кияүдә, өч бүлмәле фатирда рәхәтләнеп тормыш итә, ике бала үстерә. Затлы тунын җилбәгәй җибәреп, бик тиз генә әйләнде ул. "Вакытым юк, кунакка ашыгам, — диде. — Менә сиңа ампула. — Бик зур блат белән генә таптым. Бер укол җитә. Ул бит барыбер кеше түгел. Нигә үз-үзеңне җәфалап яшисең? Син аңа бит яхшылык кына кыласың — туп-туры оҗмахка керә инде ул, гөнаһсыз җан... Ул да бу тәмуггтан котыла, син дә... Тик теләңне генә тик тот, юкса бу гарипнең нидән үлгәнен кем тикшереп торсын. Сиңа яхшы булсын дип тырышам ич, юләр..." — Һәм ул бүлмәдә затлы хушбуй исләре калдырып чыгып та китте.

Алар бу хакта ничәмә-ничә тапкыр сөйләшкәннәр иде инде. Хатын хәтта төш тә күрде: баласы канат җилпеп фәрештәләр белән очып йөри, имеш. Тирә-юньдә кошлар сайрый, чишмәләр челтери, җимешләр пешеп утыра. Оҗмах инде, оҗмах... Анда аңа әйбәт булачак, анда Аллаһы тәгалә аның дүрт ягын төгәл итәчәк...

Укол кадаганда бала еламады. Ул, мөгаен, авыртуны да сизми иде. Бармакларсыз кулын гына кайдадыр сузгандай итте...

Хатын утны кабызмады. Караңгы сарган тәрәзәгә карап кымшанмый утыра бирде.

Өченче көн аңа училищеда бергә укыган егет очраган иде. Якында

гына яшәгәнен белгәч, бүлмәсенә кереп чыгарга рөхсәт сорады. Тиз генә кибеткә кереп шәраб, шоколад ише әйберләр алды. Егет кызмача, хатын ягыннан зуррак нәрсәгә өмет иткәне дә күренеп тора иде. Кибетләргә кереп шулай өтәләнеп йөрүе кайчандыр бергә укыган кызны сагынудан түгел ич инде. Ул чакта егет аңа игътибар да итми иде.

Хатын ачкычны бик озак тишегенә туры китерә алмыйча азапланды. Балам бар дигәч, аеруча сөенеп киткән егет түземсезләнеп янәшәдә таптанып торды. Ләкин кереп баланы күрүгә аның йөзе агарынып китте. Өстәл тирәсендә бераз урынлы-урынсыз сөйләшеп утыргач, шәрабне дә эчеп бетермичә чыгып китте. "Киләм әле, киләм", — диде ул киткәндә. Аның бүтән монда килмәячәге икесенә дә ачык иде, югыйсә.

Инде ир заты күрмичә картаячагына ул үзе дә ризалашкан иде. Дөрес, аңа әрмәннәр белән сугыштан качкан бер малайсымак әзәрбәйҗан килгәләп йөрде. Аның шәһәрдә ике ларегы бар, анда ялланган кызлар утыра, үзе исә базардан шуларга һәр иртән җиләк-җимеш китерә иде. Әзәри саран түгел, бозыла башлаган җимешләрне аңа шактый мул ташыды. Баланы күрүгә дә чирканмый иде. Тик соңгы вакытта ул да килүдән туктады.

Бала сәер авазлар чыгарып караватында ята, ә болай бүлмәдә тынлык, шомлы тынлык. Хатынның бугазына төер тыгылды да ул акылдан шашынган төсле ишеккә ташланды.

Урамда яз сулышы, корымлы пычрак карлар йортлар күләгәсендә генә калган — эреп бетә алмыйча интегәләр.

Ул үзенең кая барасын белмичә атлады да атлады, караңгы урамнардан узды, шыксыз ишегаллары аша үтте, — анда җыелып торган үсмерләр аның артыннан ямьсез сүзләр әйтеп, көлешеп калдылар.

Кире кайтканда тулай торак ишеге эчтән бикләнгән иде инде. Бик озак шакып торгач кына, теге якта гадәти мыштырдау ишетелде. Вахтер карчык сукрана-сукрана ишекне ачты, хатынга иксез-чиксез нәфрәт белән карап, читкә борылды: "Йөриләр төне буе өстерәлеп..."

Хатын аңа каршы сүз әйтеп маташмады, бусаганы үтүгә икенче катка йөгерде. Бүлмәгә кергәч утны кабызды, кинәт күзенә ыргылган яктылыктан башта берни дә күрми торды. Күргәч ахылдап куйды: "Балам...". Ә баласы караватның читенә тотынып баскан, елмая, иреннәрен бөрештереп "Әни!" — ди иде.

Хатын, газиз баласына, бәгырь җимешенә таба ике кулын сузып, язгы тәрәзәгә таба атлады. Анда — тәрәзәнең теге ягында — дөнья матур, дөнья киң иде.

## Итек

— Әй, булмый болай, — диде хатын, — үзем өскә меним.

— Җайдак... — ир ятакка чалкан килеп төште. Урамдагы утлардан төшкән яктылыкта аның вак йөз сызыклары аермачык булып күренә, уч төбедәй ак чырай кечкенә башка ябыштырып куелган кебек тоела иде. Күзлеген салгач ул шулкадәр чарасыз, баласымак кыяфәткә кергән иде ки, хатынның аңа карата жәлләүле мәхәббәте тагын да тулышып, мөлдерәгән имиләреннән ирнең тар, йонсыз күкрәгенә тамчылап тамар төсле иде.

Карават бөтен тутыклары белән көчәнеп ыңгыраша башлады.

Юка стенаның теге ягында кемнендер шаркылдап көлгәне ишетелде.

Бүлмә давылда калган иске көймә кебек шыгырдап чайкала иде.

Тәрәзәләр капшанып пәрдә эзләделәр.

Тулай торак, ерак галәмнәргә омтылган кораб сыман, космик тизлек белән күккә ыргылды.

Шул вакыт каты итеп ишек шакыдылар. Хатын сулышын тигезләргә тырышып: "Ач-ма", — дип пышылдады. Ир аңа сыенып бетте, бу дөньялыктан качып аның тәненә сеңәсе, бөтенләй моннан югаласы килә иде.

Ишекне йодрык белән төйделәр.

— Ач, сез өйдә бит, беләбез, — дип кычкырды кемдер.

Тормыйча булмый иде. Ир ыштанын киде дә өметсез адымнар белән ишеккә таба китте. Коридорга чыкты, күзенә сикергән әрсез яктылыктан беравык сукыраеп торды.

— Нигә ачмыйсың, авызыңны фәлән...

Ул тавыштан таныды: бу — күрше бүлмәдә торучы богыл гәүдәле егет иде.

— Йокларга яткан идек, — дип гаепле төстә мыгырданды ир.

— Мишәтләдек мәллә, кандала? — дип авызын җәеп көлде күршесе, калын иреннәре табак биткә генә сыешмыйча, янгырдан соң шыткан суалчаннар сыман колагына таба шуышты. — Төн озын әле... Безнең җитмәде, синең алып куйган "Чистай малаең" юкмы? Акча бар...

Бу егет автобус йөртә — чып-чын гегемон. Шулай да күршесенең институтта Кандалый иҗатына карата фәнни хезмәт язуын кайдандыр ишетеп калган, хәзер очрашкан чакта аны "Кандала" дип кенә атый иде.

— Кайдан килеп...

— Бәлки хатынында бардыр?

— Юк инде, булса кызганыч түгел...

Хезмәт хакы очын-очка ялгарга җитмәгәч, ул өенә аракы алып кайтып куя, аны төнлә тугарылып киткән егетләргә кыйбатрак бәягә сата иде. Нишлисең, чәй-шикәргә булса да ярап тора. Ләкин соңгы арада ул тәмам корыды, мондый "бизнес" белән шөгыльләнерлек тә рәте калмады.

Күршесе, хәлнең өметсез икәненә ышанып, кулын селтәде дә, шаулап торган бүлмәсенә таба китте, авыз эченнән: "Интеллигент сраный", — дип сүгенгәне ишетелеп калды.

Хатыны янына кире килеп ятканда аның дәрте дә беткән, йокысы да качкан иде.

— Бер сүз әйтсәм, ачуланмыйсыңмы? — диде хатыны, шактый гына яткач.

— Нигә ачуланыйм, әйт...

— Итегем бик тузган бит, яңасын алырга иде...

— Күптән алырга кирәк иде дә... — Ир авыр сулады. — Тик на какие шиши?

— Мин бергә эшли торган хатыннан биш йөз мең тәңкә алып тордым. Ачуланмыйсыңмы?

— Юк, нигә ачуланыйм... Тик... кайчан түли алырбыз икән соң ул әҗәтне...

Хатын иренең битеннән үбеп алды.

— И-и, әйбәт тә кеше инде син.

Ир читкәрәк авышкан булды, үзенең йөз мускуллары язылып китте. Ниндидер яхшы гамәл эшләгәненне аңлаганнан соң шулай була.

— Итек сиңа да кирәк инде ул... — Хатыны тагын аңа елыша төште. Алар селкенгән саен пружиналы карават эчне пошырып шыгырдап куя иде.

— Бу кышны бәлки чыгып булыр...

— Бүрек тә кирәк, — диде хатыны, аны тыңламыйча.

Ир студент вакытта алган арзанлы бүрек киеп йөри иде.

Башта алар кооператив фатир алырга дип, тамакны кысып, акча җыйдылар. Ләкин җитәрлек акча тупланып бетте дигәндә, инфляция аркасында, ул бернигә ярамаслык булып калды. Аннан соң инде аларга җыярлык та, рәтле бүрек алырлык та акча кермәде.

— Алайса иртәгә мин базарга чыгам...

Ире аркасы белән борылып ятты.

— Йоклыйк, вакыт соң инде... Сиңа бит анда таң тишегеннән торып барырга кирәк.

Хатын нәкъ иртәнге биштә урыныннан сикереп торды. Чәй кайнатып

маташмады, кичәгесен генә берничә мәртәбә уртлап куйды, салкын тары боткасы капкалады.

Ишек төбендәге шкаф артына куелган аш өстәле кечкенә генә, җыйнак кына иде. Түшәмдәге зәгыйфь утның яктылыгы "зал ягына" да төшә, анда караватта җәйрәп яткан ирнең чырае аксылланып күренә иде. Хатын килеп аңа берара карап торды. Ирнең авызы ярымачык, шул төштә мендәре бераз юешләнгән. Авыз сулары бүленерлек нинди төшләр күреп ята икән ул?

... Әле яктырмаса да базар тулы кеше иде. Моңарчы андый урыннарда йөргәне булмаганга, хатын аптырап, миңгерәеп калды, кая барып бәрелергә белмичә, бер читтәрәк таптанды. Ләкин озак торырга туры килмәде аңа, кинәт алдында, җир астыннан чыккандай, кечкенә буйлы, каратут йөзле бер егет кисәге пәйдә булды.

— Нәрсә кирәк чибәр ханымга? — диде ул чателдәп, утлы күмердәй күзе белән хатынның өстен- башын капшап чыгарга да өлгерде. — Күгәрчен сөте дә табып бирә алам!

Хатын каушады, тавышы әллә чыкты, әллә эчкә йотылды:

— Кышкы сапошки...

— Сапошки? Ничәнче размер? Утыз сигезме?

Хатын "әйе" дигәндәй башын селкеп куйды. "Хәзер, җан кисәге", — дип, егет каядыр китеп тә барды. Аның соңгы сүзләре хатынга нигәдер "җан көеге" булып ишетелде. Менә нинди икән ул кала базары! Аның үз авылларындагы базардан башканы күргәне юк иде. Анда һәр чәршәмбе көнне мәйданга халык җыела, күрше-тирә яктан чуашлар сыердыр, бозаудыр, сарыктыр алып килә, иң шаулап торганда да йөздән артык кеше булмый иде.

Бер-ике минуттан егет, эттән туган нәмәстә икән, кәгазь тартма күтәреп килеп тә җитте.

— Мәгез, карагыз. Чын күннән, итальянский!

Итек чыннан да әйбәт, күне шыгырдап тора, эчендәге куе мехы кулны иркәләп рәхәтләндерә иде. Хатын аны киеп тә карады, үлчәп теккәндәй тап-таман!

— Алам, — диде ул. — Күпме тора?

— Дүрт йөз.

— Ярар, — дип, иңенә аскан ридикюлен кулына алды. Ридикюль затлы, әллә ничә кесәле, күп акча сыйдырышлы иде. Егетнең йөзенә "моңардан күбрәк сорыйсы калган икән" — дигәндәй үкенү галәмәте чыкты. Шунда аның башына тәвәккәл уй килде бугай, ул хатын кулыннан ридикюльне тартып алды да йөгерә-атлый гөҗләп торган халык арасына кереп югалды. Хатын башына суккандай аңгыраеп калды, кычкыра да, селкенә дә алмады. Култык астына кыстырылган тартма җиргә төшкәч кенә, аңына килде. Ярдәм сорап кычкырыргамы, милициягә йөгерергәме? Бу тикле кеше дингезе эчендә ул каһәр сукканны ничек тапмак кирәк?

Хатын авыр гына атлап, автобус тукталышына китте. Гарьлектән, чарасызлыктан йөзе буйлап аккан күз яшьләрен дә сөртмичә атлады да атлады. Йөз мең тәңкә акчасын күз алдында суга салды бит... Нигә шулкадәр пешмәгән бәрәңге кәлҗемәсе икән ул? Кемгә генә охшап шулай җебегән булды икән... Бүтән туганнары бит баскан җирдә ут чыгаралар. Йөз мең тәңкә... Аны аңа ярты ай эшләргә кирәк. Ридикюль дә җәл. Әллә ничә кесәле, эченә бәләкәй генә көзге дә беркетелгән. Өченче ел аны туган көненә абыйсы бүләк итеп биргән иде. Абыйсының төсе... Былтыр ул юл фаҗигасенә эләгеп һәлак булды.

Иремә ни әйтермен, дип уйлады ул. Аңа әйтмәсәң дә була инде, югыйсә. Төпченеп, һәр әйбереңне, гамәлеңне тикшерә торган кеше түгел. Шул ук вакытта ул аңардан бу талауны яшереп калдырмаячагын да белә иде. Иреннән ул бернәрсәне дә яшерми...

Автобустан төшеп, Иптәшләр урамына борылгач, хатын туктап күзен сөртте, тынычланырга тырышты. Ярар инде, дип үз-үзен юатты, баш

бәласе түгел әле. Йөз мең тәңкә кем өчендер вак-төяк кенә дә инде ул. Безнең өчен зур шул.

Ул, ике тулай торакны үтеп, үзе торганына житте. Бу урамда тулай тораклар күп, шуңа исеме жисеменә туры килеп тора.

Ире инде уянган, юынып йөри иде.

— Әһә, кайтып та життеңме? — дип кычкырды ул хатынын күргә. — И башсыз, башсыз.

Хатын аптырап аңа карады. Кайдан белгән бу? Аның ридикюлен угры тартып алганны кем житкергән?

— Соң син бит акчаңны тәрәз төбендә онытып калдыргансың, — дип көлде ире. — Менә бит... — Ул тәрәз төбеннән резинкага кыстырылган кәгазь акчаларны үрелеп алды.

Хатынның култык астындагы бәлале тартма шапылдап идәнгә төште дә ачылып китте, эченнән чүпрәк-чапрак, төрле чүп-чар коелды.

Ире гажәпләнеп аягы белән тартмага төртте.

— Нәрсә бу? Нинди чүп-чар күтәреп йөрисең?

— Карак... Угры талады мине, ридикюлемне тартып алып халык арасына качты. Ә мин анда акча бар дип торам. — Хатын урындыкка утырып чатнаган тавыш белән көлеп жибәрде. — Ну көлкегә калды инде үзе дә... Ачып жибәрә, ә анда берни юк, хи-хи-хи... — Ул тагын чүп-чар тулы тартмага карады. — Ә мин тагын итек үземдә дип сөенеп кайтам... Итальянский итек дигәне күз буу гына булды микәнчи?

— Һе, бирерләр сиңа итек... Акчаны онытып калдыруыңа шөкер ит.

— Ридикюль кызганыч инде барыбер. Абый төсе иде, — дип уфтанды хатын.

Ире, арттан килеп, ике аксыл кулын аның жилкәләренә салды.

— Кайгырма, иртәгә базарга бергә барырбыз. Итекнең дә сиңа ин кәттәсе булыр! — диде ул.

Үзенең куллары жеп-жиңел һәм алар жиңелчә дереллиләр иде.

## Алла

Лапаста яңа чапкан печән исе, ат тизәге исе аңкый иде. Ахияр тирән итеп сулыш алды, күкрәгенә шушы жанга тансык исләр белән кинәнү, рәхәтлек, канәгатьлек, тел белән әйтеп булмый торган әллә нинди хисләр кереп тулды. Хужасын танып, аранда ат пошкырды. Ахияр, арба аша үрелеп, атның муенын сыйпады, бөрчәйгән бармакларын аның калын ялына батырды. Ниндидер рәхәт дулкыннар бербереен куыша-куыша гәүдәсе буйлап таралдылар, Ахияр сөенеченнән көлеп жибәрде. Алла да (байталының исеме шулай сәер иде) аның бу сөенечен аңлый иде, ахрысы, үзенең дә мәхәббәтен, тугрылыгын белгертергә теләп, йомшак жылы иреннәрен хужасының кырынмаган йөзенә тидерде.

Ахияр Алланың акыллы күзләренә карады, ир белән атның күзләре очрашты. Ирнең күкрәге жылынып китте, ул уңайсызланып, йөзен читкә борды. Бөтен дөньяда хәзер аңа иң якын, иң газиз, аны иң аңлаган зат шушы ат иде, ахрысы...

Ахияр яшәгән Тиресле авылында гына түгел (Тиресле исеме, кайбер туган якны өйрәнүче акыллы башлар фикеренчә, жир ашлый торган тирес сүзеннән түгел, ә бу төбәктә кире, үжәт мәгънәсендә кулланыла торган тирес сүзеннән килеп чыккан. Биредәге халык тирә-юньдәгеләрдән гадәттән тыш кирелек белән аерылып тора иде. Шуңа күрә аларны еш кына яратмыйча Тиресле чуашлары дип тә мыскыл итәләр иде), гомумән, мишәрләр яшәгән бөтен жирләрдә элек-электән атны бүтән хайваннардан аерып карыйлар. Утызынчы елларда кочләп колхозлар оештырганда, Тиреслеңең чуаш кебек кире, мукшы кебек төмсә ирләре башка малны түгел, ә жаннарыннан да артыграк күреп атларын, затлы дирбия-збруйларын кызганып еладылар. Атсыз ир — канатсыз кош! Күпләре авылга кулларын

селтәп, төрле якка таралды. Аларның байтагы Мәскәүгә юл алды шикелле, анда алар дворник булып, вокзалда йөк ташучы булып урнашты. Колхоздан качып килгән бу авыл агайлары кара эштән курыкмыйлар, хәер, курыксаң да кая барасың? — Рәсәйдә кара эш махсус татарлар өчен кебек бит ул...

Тиреследә дә, чын мишәр авылындагы кебек, борын-борыннан сугымга ат чалганнар. Ләкин Совет влачы көчәйгән саен, бакчасында алмагачы булган өчен дә салым түли башлагач, авыл халкы кышкылыкка ат түгел, сарык та суя алмый башлады. Сугыш вакытында инде ит дигән сүзне дә оныттылар диярлек, алабута, үлән-чүлән белән юандылар. Ат итеннән казылыктыр-фәләндер кебек төрле нигмәтләр әзерләү дә онытылды. Нииндидер мәгънәсезе "торгынлык" дип атаган елларда авыл кешесенең бераз хәле рәтләнгәч, Тиресленең ир-атлары, балта-пычкыларын тотып, урыс якларына шабашкага таралдылар. Анда йортлар салып, абзарлар корып (урыс үзе йорт салмый, салганны көтеп ята, һәм дөрес эшли, татар Рәсәйгә ни өчен кирәк?), акча эшләделәр. Көз көне аларга атлар ияреп кайта. Эш шартларын сөйләшкәндә сүз үзәгендә ат булмый калмый. Ат алырлык түгел икән, чын мишәр эшкә тотынып та тормый иде.

Дөнья — куласа шул, бер көе генә тормый, әйләнә дә бер баса, диләрме әле, менә хәзер ат асрарга да рөхсәт иттеләр. Тиреследә хәзер һәр аранда ат пошкыра, малайлар аларны төнлеккә урманга алып китәләр, юлда тояк тавышлары ишетелә, капка төбенә чыккан агайлар җитди чырай белән, эндәшми генә тәмәке пыскыталар, шатлыкның эчтә тыптын тантана итүе үзе бер өстәмә сөенеч бит ул!

Ахияр да Пермьнең Урда авылыннан, үзе эшләгән җирдән ат алып кайтты. Атны бик озак сайлаган иде, ялгышмаган икән, акыллы, җайлы булып чыкты Алла. Ахияр ел буе шул ат белән мәш килде. Арба ясады (үзе җинел, үзе нык), тугым бөкте, ияр, камыт эзләп Казанга чапты.

Аның үзен авылда өнәп бетермиләр иде. Үз эченә бикләнеп яши, тел күтәреп беркемгә бер сүз эндәшкәне юк, исәнләшкәндә дә башын селкеп кенә үтә. Байталының нинди исемдә икәнен белгәч тә, әбиләр як-якка төкеренеп куйдылар, хатыннар бот чабып көлде. Ирләр дә күпмедер вакыт теш агартып алгалады. Бу исемне, билгеле, Пермь өлкәсендә үк кушканнар, елкычы, мөгаен, Алла Пугачевага мөкиббән берәр кеше булгандыр. Исемдә басым да беренче иҗеккә төшә, тик татар урыс теле законнарын санга сугамыни ул? Ахияр әбиләр теленә керүдән курыкмый иде куркуын, "кяфер" димәгәйләре, чурт дисеннәр, тәһарәтсез кәмперләр ни сөйләмәс? Тик авыл тилесе Дерминең кибет каршында "Ахияр Алласын айгырдан каплатып кайтты", — дип сөйләнүен ишеткәч кенә, әллә нишләп китте ул. Шуннан соң байталның исемен дә үзгәртеп карады, "Милка, Милка", — дип, көнгә йөз мәртәбә генә кабатламагандыр, әмма мал иясенә охшый, дип дөрес әйтәләр икән, ат, Алла дип эндәшмәсәң, борылып та карамый иде.

Аяк белән этүгә, ярым караңгы лапасның ишеге салмак кына мөгрәп ачылып китте дә Ахияр, кояшны аралап, көн күзенә чыкты.

Ишегалдындагы йомшак бәбкә үләннәренә басып ул өйгә керде. Ачыккан иде, өстәл янына утырды, ипи валчыкларын терсәк белән читкәрәк сыпырып куйды, зур баш суганны кабыгыннан арындырып, эре тозга манып, калын икмәк телеме белән умырып чәйнәргә кереште.

Күзе түр почмактагы пәрәвезгә төште, анда, кара ноктала арасында, бер чебен эленеп калган, ул җан-фәрманга аякларына сарылган җепселләрдән котылырга маташа, бәргәләнә, бәргәләнгән саен тагын да ныграк чәбәләнә иде. Үлем белән яшәү арасындагы әлеге көрәшне битараф кына карап торды Ахияр.

Өстәл яныннан торганда аягы буш шешәләргә тиеп китте, алар, бер-берсенә бәрелеп, мескен генә тавыш биреп куйдылар.

Ул мич янындагы җыештырылмаган ятагына килеп ауды, керләнеп каешлана башлаган мендәрен калкытыбрак куйды.

Марҗасы киткәннән бирле кулыннан эш төште аның. Тиресле

ирләре елның күп өлешен читтә, урыс арасында уздыралар. Шуна күрә күбесе анда ялгыз маржаларга йортка кереп, семья корып диярлек яши, кайсысының инде иләндә тәгәрәшеп балалары да йөгереп йөри. Алай да ирләр авылдагы төп гаиләләрен онытмыйлар, ай саен акча җибәрәләр, бәрәңге утыртканда, бәрәңге алганда ялт итеп кайтып төшәләр, кышын да газиз хатыннары янында уздыралар. Ягадагы маржалар аларга исәпкә бар, санга юк сыманрак төсле иде. Ләкин яшь, өйләнмәгән егетләрнең байтагы шунда ябышып та кала, һәм нигәдер калучылар авылның ин чибәр, эре гәүдәле, озын буйлы оланнары була иде. Ахияр да Урда авылының Валя исемле бер кызына ияләште. Маржаның куены нигә шундый да тирән, шундый да кайнар икән ул? Ахияр да баш-аягы белән йотылды, сеңеп бетте анда. Иртәнге биштә торып эшкә барганда ул уянып житми иде әле, шулай аягөсте йоклап атлаганда юлдан тайпылып, койма-капкаларга килеп бәрелгән чаклары да булды.

— Өйләнешик, — диде беркөнне Валя. — Иптәшләреңнән аерылырсың, Петр Степанович сине иртәгә үк машинага утыртырга вәгъдә бирде. Югыйсә, тире дә сөяккә калдың ич инде. Коллар бит сез! Кеше шулкадәр ватылып эшли димени... Өйләнешик. Безнең кебек яшәрсең.

Ахиярның әти-әнисе инде вафат, маржага өйләнмә, дип мыгырдаучы юк, үз авылында күзе төшкән кызы да күренми, жаны бик үк тартмаса да, ул Валяга өйләнергә ризалык бирде.

— Тик безгә кайтабыз, — диде ул. — Мин нигезне ташламыйм, анда дум совет кебек йортым бар.

— Кайтырбыз, кайтырбыз, — дип елмайды Валя. —Бер-беребезне яраткач, кайда да яхшы булыр. Анда да бит шул ук Россия...

Сүзенә каршы килмәгәнгә и сөенде шул чак Ахияр, маржасының мул гәүдәсен кочагына кысты, эчке күлмәк авызыннан бүселеп чыккан имиләренә изрәп киткән йөзен яшереп, хатынының әчкелтем исен озак иснәп ятты.

Туйны гөрләтеп үткәрделәр. "Эчләре янсын, — диде Валя, — кияве татар гына дип пышылдамасыннар әле, от души гуляйт итәбез". Туйга Петр Степанович та килде. Аны кадерләп түргә утырттылар. Беренче тостны да ул әйтте, Валяны мактады, Ахиярны да онытмады: "Саша кебек егетләр безгә бик кирәк, — диде ул. — Ызба тутырып бала үстерсеннәр, калхузда эшче көчләр күп булсын". Сөйләп кенә калмады, калхуз исеменнән ике чучка баласы да бүләк итте.

Ахияр авылына кайтырга вәгъдәләшсәләр дә, тиз генә кузгала алмадылар. Анда кайтып та нишлисең? Эш юк, калхузда селкенеп йөргән өчен тиеннәр түлиләр. "Бераз түл жыйгач кайтырбыз, — дип уйлады Ахияр. — Акча кайда да юл ача".

Туй иткәч ул бригадага кайтмады, калхузда машина йөртә башлады. Эш хакын әйбәт түлиләр, кузовта да анысы-монысы ияреп кайта. Бераздан тупылдап малайлары да туды. Ахияр аны Тимур дип атарга ясканып караса да, Валя якын да килмәде. "Петр дип кушабыз! — диде ул. — Петр Степанович хөрмәтенә... Күңеле булыр персидәтелнең... Крестный булырга да риза булыр. Яши белергә кирәк, Саша..." Ахияр Валяның барыбер үз сүзен сүз итәчәгенә күнегеп килә иде инде, эндәшмәде. Юкса бит Тимурны урысы да, татары да куша, икесенең дә күңеле почмакланырга тиеш иде дә кана... "Үзебезгә кайткач, шулай үзгәртермен дә әле, — дип үз-үзен юатты ул. — Валя да анда артык чыгымчылый алмас".

Петя инде йөгереп йөри, ә Валяның Ахияр авылына кайту турында авыз да ачканы юк. Ул гына да түгел, Ахиярның авылдашлары яңа гына салган йортны алырга йөри башлады, көн дә Петр Степанович янына чаба... Петяның крестные белән бигрәк тә дуслашып киттеләр соңгы вакытта, авызны авызга куеп серләшәләр, ара-тирә персидәтел өйгә дә сугыла, кечкенә Петяга йә күлмәк, йә ыштан кыстырып килә. Шундый ярдәмчел булгач, малаеңны чукындырганга да сүз әйтеп булмый инде. Ахиярның андый вактәяккә исе китми иде. Кайткач аш пешкән, ыштан төшкән булса, дөньясы нигә чукынып китми шунда!

Шулай сыман иде... Ләкин тора-бара Валяның һаман үз ягына каеруына, аның сүзенә колак салмавына ачуы да килә башлады. Ул ачу акрын-акрын эчкә җыела килде. Мәрхүмә әнисенең "йортка кергәнче, утка кер", — дигән сүзе дә ешрак искә төшә иде.

Авылдашлары белән ул хәзер сирәк очраша. Шуңа да эче пошып тора иде, тегеләрнең ял көнен чамалап, беркөнне алар янына китте. Чүпрәк букчасында ике "урыс малае" да бар иде. Рәхәтләнеп утырдылар үзләренчә цөкердәшеп. Али карт — ул бригадада аксөяк, ишек ясый, тәрәзә куя, бүтән эшләргә катнашмый, — бераз исереп киткән иде, калтыравык тавыш белән җырлады:

Ат җибәрдем үзәнгә,
Үлән тамырын өзәргә...
Үзем үлсәм, сүзем калсын
Үзәгенне өзәргә...

Ахиярның күзе дымланды, бугазыннан ниндидер аваз тырналып чыкты. Ул бит үлеп китсә, сүзе дә калмаячак... Исеме дә... Саша бит ул монда, Саша...

— Петр Степанович сезгә бик ешлады, — диде бригадир Рафаким. — Валя белән серләре килешә, ахрысы...

Ахияр, бригадирның мыскыллы елмаю кунган йөзенә текәлеп, сүзнең дәвамын көтте. Тик тегесе тел чарларга җыенмый иде, сәгатенә карап алды:

— Ятарга вакыт, иртәгә урыс праздниги төгел...

Рафакимның бу сүзе дә Ахиярга мыскыл итү булып тоелды, кара янып, китәргә кузгалды.

— Кайда йөрисең син?! — дип кычкырды аңа хатыны, тик иренең акайган күзләрен күргәч, телен тешләде. Акыллы хатын иде Валя, кайчан уларга, кайчан юлларга икәнен яхшы белә иде. Сыер дуласа аттан яман, диләр, сөяленә бассаң, әллә нәрсә майтарып ташлар бу үшән татар...

— Минем авылга яшәргә кайтабыз! — диде Ахияр.

— Ярар, ярар, — дип, килешергә ашыкты хатын.

Иртән ул аны гадәтенчә мыштым гына эшкә китәр, бу турыда бүтән авыз ачмас, дип уйлаган иде дә, иртән Ахияр бер тустаган салкын су эчеп караватына кире барып яткач, мөлдерәп торган зәһәреннән бер мәлгә хәтта катып калды...

— Баста. — диде ир. — Бүтән эшкә чыкмыйм. Җыена башларга кирәк, минем авылга кайтабыз.

Хатын елап та карады, ялварды да, тузынды да, тик Ахиярны сүзеннән кире кайтара алмады, киребеткән мишәр акрын гына җыенырга булды. Кичкә таба аны идарәгә — Петр Степанович хозурына чакырдылар.

— Ташлап китмәкче буласың икән безне, кум, — диде персидәтел. — Тагын бер кат уйла әле. Анда бит сезнең эшсезлек. Мужикларыгыз бит безгә килеп бил бөгә. Сиңа ни житми? Живешь как у бога за пазухой. Ну что тебе надо? Хочешь, я тебя снабженцем назначу? По всяким командировкам будешь ездить, мир повидать...

Тик Ахияр да Тиресле мужигы иде шул. Тоткан җирдән өзә торган җыктан. Ниһаять, кум да моны аңлады, йөзен чытып, кулын селтәде: "Дурак!" — диде. Бүрене бүреккә салсаң да, урманга карый, янәсе.

Нишләсен, иренә ияреpгә мәҗбүр булды Валя. Персидәтел машинасына төялеп, Верещагин шәһәренә — тимер юл стансасына чыктылар. Соликамски поездының калтырча вагоннары ыңгыраша-ыңгыраша туган илгә тәгәрәде.

Валя авылга ияләшә алмады, башта марҗа белән аралашырга атлыгып торган күрше-тирә хатыннарның да Ахияр өенә эзе суынды. Валя алардан үзен ничектер өстен куя, тегеләр дә аның белән уртак сүз таба алмыйлар, мәктәптә өйрәтеп тә инде онытыла башлаган урыс сүзләре җәелеп китеп сөйләшерлек түгел иде. Марҗаны чөгендер китмәнләргә, бәрәңге чүбен утарга чакырып карадылар. Ә ул кибарәнә елмаеп: "Мин бит колхозница

түгел. Мин — медсестра!" — диде. Ахияр аптырап, кулын гына җәйде, авыл медпунктында ул урын буш түгел иде шул.

Беркөнне, Ахияр кайдандыр кайтып кергәндә, хатын кечкенә малайны киендергән, чумаданга кирәк нәрсәләрен тутырып, ишек төбендә ирен көтеп утыра иде.

— Син теләсәң нишлә, без монда кала алмыйбыз, — диде ул елый-елый. — Мин инде сине күпме кыстадым китик дип...

Чыннан да төн буе сүз шул турыда гына була иде, или, или иде Валя ирен, мыш-мыш сулап бер сүз эндәшмичә ята иде Ахияр! Юкса бит төнлә ирләрнең колагы бөтенләй ачылып бетә...

Ахияр аларны Канашка кадәр озатып куйды. Иске автобус пошкыра-пошкыра алга юырта. Валя инде үгетләп арган, бер сүз дә чыгармыйча тәрәзәгә капланган. Күпереп утырган урманнар ямьсез, офыкка тоташкан кырлар шыксыз булып күренә аңа. Алай да поездга утырганда: "Әйдә безнең белән", — дип әйтеп карады. Ахияр йөзен читкә борды.

— Ну и живи среди своих вонючих татар, — дип ачыргаланып кычкырды хатын. — Неблагодарный чучмяк!

Моны ук көтмәгән иде Ахияр, җаны өшеп, вокзалга таба китте. Тик борылып карамыйча булдыра алмады: вагон тәрәзеннән нәзек кулларын сузып малае Петя сыек тавышы белән: "Папа!" — дип кычкыра иде.

Менә хәзер шул күренеш аның төшенә кереп йөдәтә. Валя да бик еш искә төшә. Ямьсез сүзләрне бик ачуы килгәнгә генә кычкырды бит ул. Яратмаса, аңа ияреп кайтыр идемени?.. Чыннан да, өстерәлеп нигә монда кайттылар алар? Туган ил, имеш. Кемгә кирәк ул биредә?

Ахияр ятагыннан торып, түр тәрәзәгә килде, кесәсеннән бөгәрләнеп беткән тәмәке кабы чыгарды. Тик анда тәмәке беткән иде.

Акча да юк.

Кире китәргә булды Ахияр. Тик китәр өчен дә акча кирәк. Эчтән сыктаса да, үзен-үзе җиңде — байталын сатарга уйлады. Әмма авылда беркем дә атны алырга теләми иде. Хәтта ата карак, исерек Атай да кулын гына селтәде, андый кушаматлы ат алып, языклы булыр хәлем юк әле, янәсе.

Атны суярга да кулы күтәрелмәде аның. Суйсаң да итен авылда алмаячаклар иде.

Күрше авыллардагы чуашларга сатар иде, чуашның атка исе китәмени аның?

Атын ышанычлы кулларга тапшырасы иде дә бит... Бәлки ул бөтенләйгә китмидер? Әйләнеп кайтса, байталны кире үзенә сатып алыр иде.

Капкага таба кемдер якынлаша иде. Таныш түгел кеше —авылда мондый адәмне Ахиярның күргәне юк. Теге дә тәрзә янында торган хуҗаны шәйләп алды, ахрысы, тук йөзенә елмаю җәелде, нидер кычкырып, кул изәп куйды.

— Ахиярмы буласың? — диде ул, кул биреп күрешкәч. — Синме ат сатасың?

— Ә син кем?

— Шыгырданнан мин. Сатсаң, атыңны хәзер үк алып китәм. — Шыгырданнар күрше-тирә яктан мал җыялар, аларны суеп, итен Казан базарына ташыйлар иде.

— Аның исеме бит Алла, — диде Ахияр, нәрсәдер өметләнгәндәй. Хәлиткеч минутны һаман сузасы килә иде.

— Һи, безгә Алла ни, мулла ни, — диде Шыгырдан кешесе көлеп, — Бисмилла әйтеп суйгач, мөселман ризыгы була инде ул. Йә, әт сүзеңне. Без живой весын алты тәңкәдән алабыз. Акчасын хәзер үк түлим. — Адәм кабарып торган кесәсенә сугып алды.

Ахияр аңа керфеген дә селкетмичә карап торуын белде.

— Әбзәй, нәстә, телеңне йоттың мәллә?

— Ат аранда, — дип пышылдады ул.

Алладан аерылгач, Ахияр үз-үзенә урын таба алмый йөрде. Тик мал абзарына — паетка кирәргә җөрьәт итмәде. Анда сугылды, монда сугылды да, кибеттән аракы алып кайтты. Ярым караңгы өйдә ул берүзе эчеп утырды. Хәер, берүзе генә түгел, күз алдына нәзек кулларын сузып әле Петя килә, әле Валя тыела алмыйча көлә, әле Алла башын чайкый, пошкыра, үзенең эренле күзләреннән бертуктаусыз яшь ага иде.

Икенче көнне ул таң тишегеннән үк юлга чыкты. Автобус Шыгырданнан китә иде, анда исә өч чакрымнан артык түгел, шуңа машинамазар көтеп тормыйча, җәяү генә атлады. Автобус тукталышында берничә кеше басып тора, шулар арасында Ахияр төнлә аның Алласын алып киткән шома чырайлы бәндәне танып алды. Күкрәгендә нindидер кайнарлык пәйда булды, шул акрын гына бугазына таба шуыша иде. Ахиярның бәндә белән исәнләшәсе дә, хәл-әхвәл сорашасы да килми иде... Тик тегесе үзе үк аны искәрде, иске танышын очратуына сөенгәндәй, елмаеп янына килде.

— Атыңны насиля алып каттык, — дип сүз башлады ул. — Каерыла да артка карый, каерыла да артка карый. Үзе җылый, күзләреннән мөлдерәп яше ага мескеннең. Сиңа нык ияләшкән икән.

Ахиярның Аллага тагын бер күз ташлыйсы, соңгы мәртәбә хушлашасы килде.

— Әле суеп өлгермәгәнсездер, — диде ул, шома бәндәнең җиңеннән эләктереп.

— Суймыйца... — диде тегесе, черт итеп җиргә төкерде. — Ите инде Казанга барып җиткәндер.

Ахиярның кулы, бушаган дилбегә сыман, салынып төште.

— Колыны цыкты бит аның. — Бәндә ничектер уңайсызланыбрак киткәндәй булды. — Буаз икәнен ник әтмәдең? Бәлки колынлаганцы үземдә асраган булыр идем...

Ләкин Ахияр инде аны тыңлап торырлык хәлдә түгел иде, койма артына кереп сулыга-сулыга укшый башлады. Авызыннан асылынып төшкән селәгәй тасмасы белән бергә аның күңеле дә җиргә тама иде төсле.

## Шүрәле

Урман безнең авылга кыйшаеп тора. Шуңа күрәме, кышлык утын әзерләп бик мәшәкатьләнмиләр. Әзерләнгән утын кайчакта ярты кышка да җитми. Урман якын булгач кайгырасы юк — ягарга бетсә, тагын бер олау шыгырдап торган каен кайтарып аударасың. Кар ерып урманда йөрергә иренсәң инде, бакча коймасы ни өчен? Җәен өрлнадан тотып куясың ич аны...

Ә хәзер нәкъ менә җәй уртасы. Бүген күрше Минзук белән урманга барырга сөйләшкән идек. Аның ишегалдында иске "Беларусь" гөрләп утыра. Иртән күзне тырнап ачтым да, хатынның мыдыр-мыдыр сөйләнүен ишетмәс өчен, тиз генә тышка чыгып киттем. Коедан су сосып алырга дип чиләкне төшергән идем, кире тартканда бавы өзелде... Менә бит көн ничек башланды, каһәр... Табак төбендәге җылымса суда күзне, иренне чылатып алдым да, Минзук янына ашыктым.

Хатыны абзарда тавыкларга җим сибә иде, ахрысы, мине күргәч, аркасын борды. Кичә Минзук белән урманга барасыны шактый гына юган идек, шуңа турсая булыр, хәерсез.

Минзук үзе чоландагы чаршау белән уратып алынган караватында ыңгырашып ята иде. Мине күргәч, торып утырды. Андый чакта дус-ишнең килеп керүе сөендерә бит. Бәлки аның берәр фикере бардыр? Минзук быдыр-быдыр нидер әйтте. Колакны тырпайткач, аңлашылды тагын: "Авызда чүчкалар куныш чыккан төсле", — диюе икән. Быдырдарсың да шул, нибуч, урманга барасы дигән шатлыктан икебезгә бер чирекне түнтәргәнбез ич. Соңыннан Шәвәли дә килеп кушылды бугай әле.

Кыяфәте куркыныч иде күршенең — шешенке күз кырыйларына эрен укмашкан, иреннәре бер-берсенә ябышып каткан. Һи-и, нәрсә сөйләп торам, һәркемнең башыннан үткән хәл инде. “Әйдә, мәйтәм, тизрәк чыгыйк моннан, ату синең сулышыннан чебеннәр дә ангыраеп, идәндә мүкәләп йөри...”

Урманга бару исендә дә юк монын! “Андый зур эшкә киткәндә җингән бер ярты кыстырып җибәрә инде”, — дигәч, Минзукка бераз җан керде, ахылдап-ухылдап урыныннан кузгалды.

Ярый әле, тракторга кичә ягулык тутырып куйганбыз, утыруга кузгалып та китте, малкай... Мин тиз генә балта-пычкы, хатын әзерләп куйган букчаны апчыктым. Анда салынган шешә ботка тиеп күңелне кинәндерде инде, валла!

Урманга кул сузымы калган булса да, түзеп торып буламыни, авылны чыккач ук туктаттык тракторны, теге яртыны букчадан алып койдык Минзукның бардачукта йөри торган ыстаканына. Хәер, аның ыстакан икәнен бик кыенлык белән аерып була, беркайчан да юмаганга күрәме, ул калынаеп, әкәмәт бер кыяфәт алган иде.

Кәефләр күтәрелеп китте, җаный! Трактор тигез генә келтерәп урманга таба йөгерә. Минзукның да башы чатнамый хәзер, эре сары тешләрен күрсәтеп ыржайган була әле, адәм тәганәсе.

Үзебезнең диләнкегә барып җитеп, шешә төбендә калганны җиффәргәч, үлән өстенә тәртәләрне суздык та тәмәке кабызып җибәрдек. Рәхәт! Күк йөзе чалт аяз, кояш нәкъ түбәдә кыздыра. “Кояш басылгач кисә башларбыз, эш бүре түгел, урманга качмый”, — ди Минзук. Рас шул. Минзук тәре, андый акыллы сүзләрне кайдан белә дер, кичләрен телевизорга капланып утыра, нәгаләт, шуннан отып ала булса кирәк...

Мин күзне ачканда, урманга караңгы төшә башлаган иде инде. Йокым сак минем — янәшәдә генә нидер кыштырдаган төсле тоелды, бак... Борылып карасам, чак телдән язмадым, бездән ике-өч метр гына читтә йонлач бер нәстә — адәм дисәң адәм түгел, шайтан дисәң, шайтанны кем күргән... Күзе ут яна, маңгай турысында кечкенә генә мөгезе дә бар сыман, куллары озын... Иң шаккатмалысы — әптермәне тезенә җитә!

Минзук та уянган икән, чәрелдәп кычкырып та җибәрде: “Шүрәле!”. Минем дә мәптектә үк ишеткән әкият искә төште: тучны Шүрәле! Тик әкият әкият бит инде ул, ә монда без, субственны персун, дигәндәй... Тик алдында шундый әптермәнле йонлач нәстә басып торса, әкияткә түгел, Аллага да ышанырсың, әкәмәй.

Минзук та төшеп калган җегет түгел икән, тәре, сикереп тә басты, балтасына да ябышты. Мин дә тиз генә Шүрәленең артына төштем. Кулга ничек күсәк килеп эләккәндер, ыстинага терәсеннәр хәзер, һич әйтә алмыйм, тик шунысы ачык хәтердә: куаклар арасына шыларга маташкан Шүрәленең башына чык! берне шуның белән... Кәтәләп тә китте Шүрәлең...

Утын кайгысы калмады инде бездә. Шул урман сарыгын көч-хәл белән әрҗәгә салдык та элдерттек авылга. Без кайтып җиткәндә ул һушсыз иде әле.

Минзуклар ындырында әллә кайчаннан инде зур гына читлек аунап ята. Кайдан алып кайткандыр ул аны, кирәксә-кирәкмәсә дә, аяк астында нәрсә ята — өенә ташый торган гадәте бар... Дөрес тә шул. Йортта һәр нәрсәнең кирәге чыга. Читлекне абзарга көч-хәл белән кертеп, ишеген рәтләгәч, Шүрәлене шунда яптык. Йозагын шартлатып бикләп тә куйды Минзук.

Ята җәелеп Шүрәле читлек эчендә. Безнең утынсыз кайтканны күргәч, хатын нидер чырылдамакчы булып авызын ачкан иде дә, йонлач җан иясен күргәч тынды тагы...

Нишләргә? Читлектәге нәмәстәкәйнең Шүрәлеме, чуртмы икәнен ничек ачыкларга? Минзукның андый чакта баш эшли аның: “Раунл Галыч янына барыйк, аның белмәгәне юк”, — ди. Чыны шул, безнең

авылда бердәнбер әфтәрит ул Рауил Галыч. Авылны учында биетеп тора. Шуның өчен Чүпрәледән махсус китергәннәр аны. Бүтән вакытта безнең эше вак маймычларны чутка да кертмәгән кеше, Шүрәле турында әйткәч, хәтта көлеп җибәрде. Без дә кушылып көлгән булдык. Шундый кеше көлгәч, күңелгә рәхәт булып китте. "Эчә-эчә сезнең күзгә Шүрәле күренә башлаган инде, — ди бу. — Ылтыпыга җибәрми булмас сезне". Ә без бу арада эчү турында бөтенләй онытканбыз! Нахак сүзгә үпкәләп тә уйдык бераз. "Рауил Галыч, — дидем, — валла! Ышанмасаң, Минзуклар абзарына барып кара, шунда читлектә утыра ул".

Без килгәндә читлек тирәсенә күрше-тирәдән әллә күпме кыз-хатын җыелган иде. Минеке дә шунда болгана. Безне күргәч, учларына көлешеп, читкәрәк киттеләр. Шүрәле инде аңга килгән, күзләре йалт-йолт, ярсып читлеккә ябышкан. Ябышып нишлисең, бер-берсенә береккән арматур селкенми дә ул. Минзук, лыкы булганда да, ыбыр-чыбыр нәрсәне өенә апкайтырга юләр мәллә...

"Да-а", — дип кенә куйды Рауил Галыч. Шундый адәмне дә шаккатыргач, без тагын да кукрәкне киердек инде. Минзук барып, хатынының кабыргасына төртте, тырпаеп торма, янәсе, апчык бер "чистай малаен"...

"Кар кешесе"дер бу, — диде Рауил Галыч. — Ну, җегетләр, чабыгыз Чабаксарга җитә инде хәзер".

Ә теге, Шүрәлеме, "Кар кешесе"ме шунда, йонлач нәмәстәкәй гыгы-гыгы килә, озын куллары белән әптерманен капламакчы була, интегә, мескен, тик кая ул, каплап кына бетерерлекмени... Безнең хатыннар шуңа күрә, моннан, магнитка тартылгандай, китә алмый торалар икән!

"Казанның үзенә хәбәр итәргә кирәк, килсеннәр, күрсеннәр", — дип, Рауил Галыч идарәгә таба китте.

Минзукның хатыны алай да бер яртыны алып чыкты. Берәрне җиффәргәч, Минзук әйтә куйды: "Әйдә, малай, — ди, — Шүрәлегә дә бераз тамызабыз". Сусаган булгандыр, бахыр, каплады ыстаканны авызына. Ы-ыйк дип кикереп тә куйды хәтта.

"Бу да безнең эше икән"...- Минзук, канәгать кенә тамак кырып, җилкә чокырын кашыды.

Көне буе урманда йөреп арылган, ашыйсы да килгән икән, без бер яртыны сытканнан соң, өйләргә таралдык.

Шуннан шул, әлеге Шүрәле безнең авылда яши башлады. Әллә Рауил Галычның хәбәр итүе шуның кадәр генә булды, әллә анда үз мәшәкатьләре баштан ашкан, Казаннан беркем күренмәде. Һи, Шүрәле — мөрәлегә исләре китәме соң Казан кадәр Казанда, алар аның кем икәнен дә белмидер әле.

Хәер, бәлки килгәннәрдер дә, без белми калганбыздыр, Шүрәлене апкайтканның өченчеме, дүртенчеме көнендә Рауил Галыч безне — мине, Минзукны, Шәвәлине — калхуз диләнкәсенә урман кисәргә җибәрде. Нигә һаман без дә без, дип, тавыш чыгарып та булмый, нәгаләт, бөтен авылына өч-дүрт бөртек ир-ат инде без. Калганнар югары очта, тупыл агачлары артында...

Ике атналап яттык без урманда. Кайтып төшсәк, малай, авыл ничектер үзгә. Юк, йортлар да шул ук, тупыллар да шулай ук шаулап утыра, әмма нидер, нәрсәдер үзгә. Бераз башны кашып торгач, төшендек тагын: хатыннар үзгәргән безнең! Затлы күлмәкләрен киеп, урамнан кәс-кәс атлап үтәләр, минсиңайтим! Авылның һавасы ук бөтенләй бүтән, кукрәккә тулып, йөрәкне кытыклый.

Үземнең хатын да, гомердә булмаганны, капка төбенә үк чыгып каршы алды, адәм тәганәсе, "Ничекләр йөреп кайттың, атасы, бик авыр булмадымы, фәләнме-төгәнме?" — дип сораштыра әле үзе. Өстәл мул итеп әзерләнгән, уртада бер ярты да кукраеп утыра! Аны бил каешына кыстырдым да, шаккатудан әвеш-тәвеш килеп, Минзукларга йөгердем. Керсәм, анда да шул ук хәл. Түрдә авызын җәеп Минзук утыра, инде яртының төбенә үк төшеп җиткән. Тирәсендә хатыны йөзеп кенә йөри,

аккош диярсең. Бераз пирәшләп алгач, тәмәке тартырга дип, ишегалдына чыктык. "Безнең Шүрәле нишләп ята икән?" — дип, Минзук абзарга ымлый. Бәтәч, без аны бөтенләй онытып җибәргәнбез ич. Ә абзарга керсәк, анда читлекнең ишеге шар ачык, Шүрәледән җилләр искән!

Безнең арттан Минзукның хатыны да кереп җиткән икән, аптыравыбызны күргәч, учына гына көлештереп, гәүдәсен-сынын уйнаткалап, әйтеп куйды: "Аны, — ди, — Сапый Җәмиләсе чәйгә алдырган иде". Беләбез ул теленә тилчә чыккан Җәмиләне, сүгенә башласа, фермадагы сыерлар да йөзләрен печәнгә яшерәләр. Мәрхүм ире Сапый белән шактый шешәнең башына җиткән кеше без. Былтыр исерек килеш ишегалдында адашып, туңып үлгән иде, мескен. Минзук акыра: "Нәрсә, мулла мәллә ул чәйгә алдырырга", — ди. "Ул да бит кеше кебек, бер килмәгән җире юк, — ди аңа каршы хатыны. — Мәхлук ич, ялгыз... Аны инде ярты авыл чәйгә алдырды. Бүген Җәмиләнең чираты..."

Бераздан үзләре дә күренде. Алдан кин-киң алдырып, Шүрәлебез атлый, артыннан теркел-теркел Җәмилә йөгерә. Җен алмаштырган, юк ла, Шүрәле алмаштырган, диярсең үзен, йөзенә алсулык йөгергән, балкый, "саумысыз, абзыйлар", — дип, безнең белән исәнләшә! "Әминә апакаем, менә сиңа нәни генә бүләк", — дип, Минзукның хатынына күлмәклек төртеп маташа.

Минзукның йодрыклары йомарланган иде, Шүрәлегә карап алгач, язылды тагын... Хатынын каш астыннан сөзеп: "Хәллә-әр", дип кенә сузды.

Җыйнаулашып өйгә кердек. Мин алып кергән ярты әле башланган гына иде, Минзук аны гөрләтеп өч чокырга бүлде. "Әйдә, Шүрәле дус, иптәш, ахир, бажай, — диде. — Доңкик берне".

"Ул бит кеше түгел, аңа ярамый, харап итәсез, фәлән", —дигәләп арага хатыны кереп маташты маташуын. Минзук бер генә ырлады, ирләр арасына кысылма, янәсе. Шүрәле башта йөзен чытып маташкан иде дә, өченче чәркәдән соң гыгы-гыгы килеп,баш бармагын күтәреп маташа, сасык.

Алардан ничек аерылганны хәтерләмим. Шүрәле җилкәсенә салып апчыгып куйган дисәң инде...

Шул көннән соң үзгәрде ул Шүрәле, адәм кыяфәтенә керә башлады, кая барсаң да арттан калмый, ә безнең кая бару билгеле инде, ничек тә өч борынга әтмәлләп булмасмы, дип йөрү.

Авыл тагын үз төсенә кайтты. Хатыннарның сөмсере коелды, теге Җәмиләгә хәзер очрый күрмә... Минзукның хатыны Шүрәлене өйдән куып чыгарды, тагын читлектә яши башлады, бахыр. Хәер, анда да озак тормады, "Абзарны сасытып ята", — дип, идарәгә барып чәрелдәгәч, Рауил Галыч безнең дусны яшелчә бакчасына каравылчы итеп куйды. Анда алачык бар, яшелчә муре, яшә рәхәтләнеп. Баш та бар икән Рауил Галычта, нәгаләт, төрле кош-корт яшелчә бакчасын бер чакрымнан әйләнеп уза хәзер. Йоны коелса да, Шүрәле Шүрәле шул! Без килгәнне көтеп, көне буе калтыранып утыра ул шунда. Кулда ярты күрсә, чүт кенә дурт аякланмый инде, мескен, хәтта кызганыч булып китә. Безгә иярмәсә, балда-майда гына йөзеп яшисе җегет иде бит, югыйсә...

Көз көне, яшелчәләр бик уңгач, күнеле булган Рауил Галыч Шүрәлегә районнан пачпорт апкайтып бирде, киң төпле ыштан бүләк итте. Шуннан соң нәкъ безнең сыман гап-гади кешегә әйләнде дә калды Шүрәлебез. Аңа инде җүнләп игътибар итүче дә юк, тик кайбер кыз-хатыннар гына, аны күргәч, ниндидер кадерле нәрсәләрен искә төшергәндәй, ирен читләре белән сизелер-сизелмәс кенә сагышлы елмаеп куялар.

## ШИГЪРИЯТ

# КАЙТУ

*Хәзер күпләр китаптан бизде дибез. Бу сүзләрдә хаклык бар. Аның каравы, — піародокс, — китаплар да бик күп чыга бит. Элегрәк, ягъни 15-20 еллар элек, мәгънәгә ия һәм дә кирәк китапны кулга төшергән кеше, төлке тоткан кебек, бәхетле, бүтәннәр алдында абруйлы, хәтта бай кеше исәпләнә иде. Ә хәзер? Урамчатлар, киоск-киштәләр китаплар белән тулы. Дөресрәге, төрле төстәге, төрле форматтагы, төрле бизәктәге полиграфик товар белән тулы. Ә асылда чын китаплар, классик мәгънәдә без анлаган яхшы китаплар сирәк, һәм бик сирәк.*

*Әле күптән түгел — быелгы җәйнен эссе июнь көннәрендә кулыма бер яна китап керде. Карап торырга матур, затлы китап. Күзне дә, кулны да иркәләрлек. Тышында авторның исеме — Мөдәррис Вәлиев, титул битендә китапның исеме — "Яшьлектән хат". Үтә бер кызыксыну белән, үзгә бер халәттә, бер тында укып чыктым мин бу китапны. Кичерешләр дә үзгә иде: яшьлегем искә төште, монланылды да, эссе чүлдән талгын җилле яшел оазиска кергәндәй дә хис иттем, нечкә тоемга көйләнгән аерым строфалар сокландырды да, сискәндерде дә... Нәрсәдер янага сусау булган ахры (гәрчә мина эшем буенча көнгә ким дигәндә 150-200 бит язма укырга туры килә). Чын мәгънәсендәге профессиональ осталыкка, тәгәллеккә сусау. Сүздә чама хисен белгәннәргә сусау. Туган җир, Туган як турында Ана һәм Яр турында төчеләнмичә, тыйнак итеп, серле дә, шул ук вакытта әдәпле итеп әйтә белгәннәргә сусау, һәм дә, ахыр чиктә, (без һәрберебез күпмедер дәрәҗәдә сабый да бит әле!) эчтәлегенә ярашлы матур бизәкле "тәти" китапларга сусау... Шулай тәэсирләнеп укуның тагын бер сәбәбе бар. Мин бу егеткә (хәзер инде дөньялыкта ат уйнаткан ир-егет) заманында беренче шигырьләренә, үземчә фатиха биреп, республика газетасында чыгарышкан идем. Бу утыз еллап элек булган хәл. Ул вакытта аның исем-фамилиясе Салих Маннапов иде, уналтысы яна тулган иде. Менә хәзер ул — 45 яшьлек Мөдәррис Вәлиев булып беренче шигырь китабын чыгарган. "Татарстан яшьләре"ндә (30 октябрь, 1969) басылып чыккан әлеге фатыйха-кереш сүздән берничә абзац китереп узасым килә. "Таныш булыгыз: Салих Маннапов" дип атала ул бәләкәй мәкалә.*

> *"Әдәбиятны бик яратып, аның сер-тылсымнарына төшенергә тырышып, үзләре дә каләмнәрен сынап караган укучылар арасында ин активлардан берсе — Салих Маннапов. Ул — Әлки районы Татар Мулласы авылында яши. Алпар урта мәктәбенен 9 классында укый. "Коммунизм юлы" газетасы каршындагы әдәбият-иҗат түгәрәгенә йөри. Инде менә өч-дүрт ел буе аның матур гына шигырьләре район һәм республика балалар газетасы битләрендә басылып килә. Шигырьләрен игътибар белән күзәтеп, җентекләп укып барам. Мина калса, яшьли ятим калып та, мәрхәмәтле, игелекле кешеләр куенында үксезлек күрмичә, тулы хокуклы гражданин булып чыныгып үсеп килүче, тырыш укучы, җәмәгать эшләрендә актив катнашучы Салихның күнел түрендә шигъри талант чаткылары, кешеләргә әйтер сүзе, табигать күренешләренә, кешеләрнен яшәешләренә, гомумән, дөнья хәлләренә карата үзгә бер поэтик карашы бар.*
>
> *Әлбәттә, Салихның шигырьләрендә әле тәгәлсезлекләр, инде күпләр тарафыннан әйтелгән, кабатланган образлар, тиешле поэтик югарылыкка күтәрелә алмаган юллар, тәгъбирләр дә бар. Кайчак шигъри бизәкләр, образлар стихиясе аны төп фикер агышы магистраленнән читкә алып-алып китәли: тәҗрибәсе житенкерәмәгән яшь автор, атын тыя алмаган, тарантас башындагы малайны хәтерләтеп куя... Сүзнен бөтен мәгънәви төсмерләрен, нечкәлекләрен*

*сизеп, тоеп, анлап, анын калерен белергә өйрәнү, әйтеренне төгәл, кыска, шигъри итеп сөйли белү, ахыр чиктә, чын мәгънәсендәге осталык — вакыт, тәҗрибә һәм тырышлык белән килә торган сыйфатлар. Әгәр Салих, әдәбият эшенә ихлас күңел куеп, алга табан шуна бар сәләтен һәм тырышлыгын салырга теләсә, ана шатлык һәм газаплар белән тулы Өйрәнү мәктәбен узарга туры киләчәк. Тагын шуны әйтәсе килә: заманыбыз — акыл, гыйлем заманы, укымышлылар заманы. Үз эшләренен бүгенге осталары, заманга иш һөнәр ияләре, белгечләр, нинди генә өлкәдә эшләмәсеннәр, аларнын һәркайсы әдәбият-сәнгать турында шактый бай мәгълүматка ия. Димәк, алар яратып кабул итәрлек, уйландырырлык, күңелләренә хуш килеп, эстетик ләззәт китерерлек әсәрләр, бу очракта, шигырьләр язу уен эш түгел. Димәк, бүгенге көн кешеләрен, үз замандашларынны дулкынландырырлык итеп язу өчен, безгә тикле яшәгән бабаларыбыз калдырган хәзинә мирасны да, бүтән халыклар әдәбиятлары казанышларын да тирәнтен үзләштерергә, бүгенге талант ияләренен иҗатларын да яхшы белергә тиеш булабыз. Кыскасы, армый-талмый өйрәнергә, җанын-тәнен белән тырышырга, бар күңел байлыгын салып иҗат итәргә! Яшен уналтыла чакта, күңелен тулы дәрт-ашкыну булганда һәммә авырлык чигенә әле! Яшьлек җинеп чыкмаслык нәрсә бармыни ул дөньяда!"*

*Ярый, заманына хас (яшь чакта безне дә тәүфикълы булырга бик шәп өйрәтәләр иде!) дидактик оетка күбрәк булса да, яшь шагыйрьгә бу үгет-нәсихәтле язма беркадәр тәэсир иткәндер, бәлки. Ә хәзер Шагыйрьнен үз китабына кереш сүз итеп язганнарын укып карыйк.*

*"Исәнмесез, хөрмәтле Укучы! Бу "хат"ны (ягъни китапны) язучы кем икән дип аптырап калмагыз. Мөдәррис Вәлиев — бик күпләр шикелле, гап-гади сүзләрнен шигъри юлларга әйләнеп китү хикмәтен бала чагында ук кичергән затлардан. Бер каләмдәшебез әйтмешли, әллә инде "Игезәкләр" йолдызлыгы астында туды аркасындамы, бишектә чакта ук "чып-чын" тәхәллүсе (псевдонимы), ягъни икенче исеме булган анын. Чынында, һич тә уйлап чыгарылмаган, кырыс дөнья бабай кушкан яна исем-фамилия, тора-бара, үзеннән-үзе "Салих Маннапов" дигән әдәби кушамат булып китә. Ихтимал, ике исем кушып, бу малайга язмыш ике мәйданда берьюлы иҗтиһад итү мөмкинлеге биргән, бер ук вакытта, ким дигәндә, икеләтә көч-хезмәт түгеп кенә ике исеменне дә аклый алу шартын куйгандыр... Шигырьләре белән "күзгә чалына" башлаган Салихны төрле хәл-әхвәлләр әдәби тәнкыйть дигән өлкәгә алып кереп китә. Китаплары чыга, җәмәгатьчелектә таныла. Аннары инде гомумән дә ана, Мөдәррис Вәлиев дигән рәсми исеме белән, нәшрият хезмәтен җигелеп тартыр чак килә. Мөгаен, нәширлек — шулай ук иҗат эшедер, һәм аны һәркем табигать биргән сәләтенә карап башкарадыр. "Күкрәгендә шигырь уты сау" булса да, беренче мәхәббәт шикелле, ул инде эчкәрәк йомыла, читят, салкын-саксыз кулга кагылдырасы да килми башлый икән. Нигездә моннан күптәнмедер вакыт элек язылган "парчалар"нын бер өлешен болай туплап чыгару — "яшьлектән килгән хатлар"га кеше гомереннен калерле һәм мәгънәле бер сәхифәсе итеп карау белән бәйле. Шуна күрә әлеге китапнын авторы, бәлки, инде "җитмешенче-сиксәненче елларда ук калган" Салих Маннапов түгел, ә анын бүгенге "варисы" — Мөдәррис Вәлиев булырга тиештер, дип уйланылды. Сез күрерсез: кош теләдәй генә бу китапта "шагыйрьлек"кә дәгъва да һәм, ин мөһиме, андый ихтыяҗ да юк (дөресен әйтим, бу җөмлә мине сискәндереп һәм сагайтып та куйды — Р.Ф.). Бар-булганы — бар тик күңел халәте, җан хәрәкәте генә".*

*Документ рәвешендә китерелгән бу ике сөземтә-цитата (ретростатик язма булып чыкты бугай бу) күп нәрсәгә ачыклык кертә, байтак кирәк мәгълүмат бирә шикелле. Аларда — үсеш кардиограммасы, нәтиҗәсе матур булган метаморфоза. Шигырьләренә сүз бирер алдыннан Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе турында биобиблиографик белешмә биреп узсак, алар, һичшиксез әдип иҗатын ныграк анларга ярдәм итәр.*

*Мөдәррис Харис улы Вәлиев 1953 елнын 30 маенда Татарстанның Әлки районы Яңа Камка (Мәүләшә) авылында туган. Балалык һәм үсмер еллары шул ук районның Татар Мулла авылында үткән. Алпар авылында урта мәктәп тәмамлаган. Казан дәүләт университетында белем алганнан соң, хезмәт юлын "Татарстан яшьләре" газетасы редакциясендә башлый. 1979 елдан ул — "Казан утлары" журналы редакциясендә: өлкән редактор, җаваплы секретарь, баш редактор урынбасары булып эшли. 1989 елдан 1992 елга кадәр — Татарстан китап нәшриятының баш редакторы хезмәтендә. Бүгенге көндә — "Мәгариф" китап нәшрияты директоры.*

*Аның шигырьләре 60 нчы еллардан башлап республика матбугатында даими басыла, күмәк җыентыкларга керә, радио-телевидениедән яңгырый. 80 нче елларда ул әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив иҗат итә. "Сезгә ышанам" (1984), "Тамыр тирәнлеген яфрак тоя" (1988), рус телендә "Возвращение Звезды" (1992) дип исемләнгән китаплары басылып чыга.*

*Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов) — Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм "Казан утлары" журналының редколлегия әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

*Кыскасы, инангансыздыр, булдыклы, шәп егет икән бит бу Мөдәррис Вәлиев дигәннәре! Һәрхәлдә "Казан утлары" күзлегеннән караганда тәгаен шулай. Ун ел редакциядә эшләп, журналыбызның иҗтимагый абруе өчен көчен кызганмаган зат. Аның бүген дә журналдан аерылганы юк. Инде унбиш еллап редколлегия әгъзасы, даими авторыбыз. Дөрес, күбрәк ул әдәби тәнкыйтьче һәм җитәкче нашир булып катнаша. Ә шагыйрь буларак иҗатын башлаган әдип "Казан утлары"нда нибары бер тапкыр — моннан 16 ел элек басылган икән. Журналыбызда шигырьләренең икенче тапкыр басылуы. Моны кайту димичә нәрсә дисең инде.*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**
*Июнь, 1998.*



# Мөдәррис Вәлиев

## Нигез

***Ил күзәнәге — өй.***
**(Әйтем)**

**1 И туган җир!**
**Иң элек син фатиха бир,**
**кыл игелек:**
**тирәнрәк ит син безнең тамырларны,**
**тармакланып күтәрелсен эшләр-җырлар;**
**Яктыга үрләгән чакта**
**шул тамырлар өзелә калса,**

тартып ал да тының белән, —
без сиңа кайтыйк яңадан
кояш нуры буйлап,
яңгыр дымы белән...

2 Башладык, егетләр,
учларга төкердек!
(Эшнең "бисмилласы"...)
Бу өй нигезенә,
көмеш тәңкә булып,
хәләл тиребез тамсын!

Очкындай сибелсен йомычка.
Җырласын пычкылар.
Ул шундый җыр булсын, —
коелсын кайнар тир
корганда эшләрнең, уйларның зурысын,
шик-шөбһә иләнсен,
ваклыклар җиләнсен!

Ниргәгә куйган күк ниргәне,
бер төпкә куйыйк без
иңнәрне.
Өй үссен нык һәм төз нигездә,
хуҗалар атласын бер эздән.

Күтәрдек, егетләр,
иң белән, ил белән!
(Чутлыйсы — мүклисе...)
Ниргәләр йөзенә
кояштай җаннардан
алтынсу нур иңсен!

3 Гадилек, гаделлек,
өй-тәхеткә түрдән үт!
Бусагасын келәм белән төргәннән дә,
масаюлы текә түбәдән дә
килмәстер ул бәхет.
Бусагадан ачы күз-яшь үтми калсын.
Түбәләрдән
күкләр аязлыгы яусын.
Учагының ярсу ялкынында
буш хыяллар, авыр уйлар янсын!
Кайгы-хәсрәт,
мич авызыннан кайтарылып,
күңелләргә ягылмасын,
корым-сөрем булып җанга сарылмасын,
сыек зәңгәр моңга әверелеп,
җил иркенә калсын.

Башладык, егетләр!
Мич чыгарыйк хутлап.
Кешеләр табынсын
яктыга, җылыга,
күңелдәге утка!

4 Мичтәге таба көенә
җырла, бишек силәсе!
Самавыр, табынбаш булып,
матур җырлар көйләсен...

Түшәмнәрне биегрәк итсен
тәрәз төбендәге яран гөлләр.
Хәтта яңа идән сайгаклары:
"Бию көен уйна, әйдә!" — диләр

Мич башыннан
сикереп төшсен дә, куштан песи
өстәл аягына сырпалансын.
Оялып кына торган урындыклар
табын тирәсендә урын алсын.

Күтәрик, егетләр,
хуҗаның кәефен!
(Өй туена килдек.)
Бәхетләргә — киңлек,
Өйләргә — иминлек,
Илләргә — иминлек!..

## Ут

Мин төш күрдем...
Имеш, өебез яна, —
Кызыл айгыр өзгән тышавын.
Әни калган, өй эчендә — Әни
тотып калган
янган түшәмне.
Бер чиләк су сипми... тора халык,
тора, дәшми, китми исе дә.
Әни генә калган ут эчендә, —
кулын алса — түшәм ишелә!

... Авылыма кайткач,
искә төште
шул төш, —
мин үземчә юрадым:
бу матчаны, кайнар яшьләреннән
пешә-пешә,
Әнкәй куллары
тотып торган бөтен гомер буе.
Дөнья баскан, сагыш, әрнүләр.
Безнең бишекләрне таза тоткан,
таза тора матча әле дә.

Әллә инде безнең язмышларга
чәчрәп калган утлы күмерләр.
Бу утлардан чыгу әмәле юк,
экрен-экрен көйри гомерләр...

Әниләр дә сула... экрен-экрен,
көннәр-айлар-еллар аркылы, —
көйдерде шул инде аларны да
авыр заманнарның ялкыны.

Ул ялкында без өстәгән
күпме
рәнҗүләр бар, бардыр үпкәләр...
Әгәр шул ут көйдермәсә,
бәгырь
телгәләнмәс иде бу кадәр...

## Пәри туе

Бала чакта
Шундый кисәтүләр
Шом салмады кебек уема:
“Суырып алып китәр —
Кала күрмә
Өермәдә — пәри туенда!”

Без шук идек, күз — ут, курку-ни юк,
Әбиләрнең сүзе кермәде —
Пәри туен күргән саен, күңел
Уртасына шуның өндәде.

Уй-гамь белән үтмәсә бу гомер,
Шомлы уен булып үтәдер.
Безне нинди “пәри туе” суырып,
Нинди җилләр алып киткәндер?!

Тормыш — шундый экият микәнни ул? —
Их, шул әбиләрдән сорарга.
Адашып ла йөргән бу җаннарны
Кем чыгарсын туры юлларга?

Иген шавы хәтта ят шикелле,
Кем җыры ул бездә, кем моңы?
Ятлар иккән басу уртасында
Тою кыен икән җир дымын...

Тын кысыла: пәри туе уйный,
Туктат идең үзен, иярлә!
Ә ул күккә аша... Итәгенә
Безнең энекәшләр ияргән...

## Җил юк

*— Әйләнәсең дә шул тарафка карыйсың, канатым. Көтәр кешең бармы әллә?*
*— Яңгыр шул яктан килер төсле...*

Пәрәвезләр зеңли көз күзендә,
Җил юк, Әнкәй, синең керләргә.
Яран гөлле тәрәзәңә төшкән
Тупыллардан сары күләгә.

Иртән яңгыр иде.
Керләр юдың, идән...
Песи битен юа —
кунак килер микән?

Идәнең юылган — сап-сары.
Күзләрең күзәтә капканы:
“Ахрысы, кайтмавы...
Кайтмавы...”

Самавырың сүндер инде, Әнкәй,
кайталмадым
көткән көнеңдә.
Ак керләрдән
сөенеп тамар иде
вак тамчылар!—

Җитми җил генә...

## Айсылу

*Бала йоклаганда гына үсә...*
**(Әниләр сүзе)**

Йокла, кызым,
Ай нурына манган
татлы төшләр йомгагың сүт әле.
Ай күк сылу сының күрер көнне
Кояш белән бергә мин көтәмен.

Йокла, кызым,
Күкләр зәңгәрлеген
бәллүр бөркәнчегең итеп ябыйм...
Аяз көн күк көләч йөзләреңне
Килер язлар яктысыннан таныйм.

Әлли-бәллү...
......................
Ә син йокламыйсың!
Үсми калам дип тә шүрләмисең.

Кил, әнисе!
Яшь белән уңа күрмәсен
Күзләренең шомырт кара төсе:

Бу дөньяны җете күрү кирәк,
Көннең мең төсмерен,
Төннең җитмеш серен белү кирәк, —

Йоклап кына булмыйдыр шул үсеп!
Кызыбызның
күзләреннән
Кояш үпсен...

## Сулыштан — сулышка

Хыяллар рәшәсе
Тирбәлә дөньяда.
Офыктан-офыкка —
Ир бала,
Ир бала...

Үләннәр таҗыннан
Кайтанур югала.
Чәчәктән-чәчәккә —
Кыз бала,
Кыз бала...

Җир-әнкәй... Нур белән
Керфеге чылана.
Сулыштан-сулышка —
"И бала..."
И бала!

## Сабырлык

Изгелекне күбрәк күктән көтә, —
Олыгайган шул Әнкәй, олыгайган.
Бәла-каза килсә — "күрәчәк", — ди,
Сабырлыклар иңсә — "Ходайдан".

— Ничек түздең, Әнкәй, иңгә баскач
Кара төндәй кайгы-авырлык?
— Үткәнемнән якты саркып килде,
Саклап калды хәтер-сабырлык.

— Түккән яшең — ачы дәрья булган,
Дәрья булган — батып калырлык...
— Якты ярны күздән югалтмадым,
Алып чыкты өмет-сабырлык.

Түзем безнең татар хатыннары!
Аерылмый Әнкәй күпләрдән.
Ходайны ул куша болай гына, —
Үз кайгысын үзе күтәргән.

Сезгә дә мин якты көннәр телим!
Тик шулай да, килсә авырлык,
Әнкәй кебек, әй Ходаем, димен,
Бирә күрче безгә сабырлык!

## Син генә!..

*Сөюеңне*
*бозлы тәрәзәмә*
*төшкән*
*ромашкалар белән юрадым.*
*Кар-чәчәкләр — салкын күбәләкләр:*
*"Соң түгелме соң?!" — дип сорады.*

Әйттеләр: "Син юкка ашкынма,
Насыйпсың бары үз тиеңә".
Әйттеләр: "Канатың көйдермә!
Сибелмә! Сибелмә! Сибелмә..."

Еракта иде ул...
Шулай да
Барлыгын тоям да сөенәм:
Бер чугым булса да ирешер, —
Сибеләм...
сибеләм...
сибеләм...

Сагыштай сап-сары кар яугач,
Сабакка уралыр җил генә, —
Шул чакта җилфердәр соңгы чук:
"Син генә...
син генә...
син генә!"

## Саубуллашу

Ераклаша, тоныклана бара
Киек Каз юлыдай якты сүзләр...
Салкын мендәр төсле ак болытлар!
Мин күлдәвек булып карыйм сезгә.

Гүя кемдер, изге тәсбих итеп,
Сиңа язган хатларымны тезгән... —
Тезелешеп очкан кыр казлары!
Мин буш оя булып карыйм сезгә.

Сулган яфрак ява күзләремә.
Эзләреңне җуяр көндер, ахры.
Кичер мине, —
Күзләр килмәс, диеп
Ышандырган идем, — гөнаһлымын...

## Камышлар сере

Аумакай димә син безне,
Үзсүзле камышлар без!
Җил уңаена аумыйбыз, —
Җилләргә дөрес юнәлеш
Күрсәтеп авышабыз.

Сертотмаслар димә! Бездән
башта сер алып кара! —
Җиде җил чатында калып,
Гомер буе шыбырдашып,
Гел серле булып кара!

Безнең "халык" усал, имеш, —
Кисәргә генә тора...
Алайса, үзең җавап бир,
Юк, безнең сорауга түгел, —
Үзеңнән үзең сора:

Кышын җаныңны боз булып
кыскан, суырган суны
Җәен
кибүдән сакларлык
Камыш булаласыңмы?..

## Ачыну

Күз алдымнан китми яман төш күк —
Төш кебек тә, нәфрәт-хис кебек тә:
Уттай урак өсте. Көн уртасы.
Авыл урамында — исерекләр.

Кыргыйрак бөтен вәхшиләрдән
һәм искерәк һәммә искелектән,

Бар чүплекләр җирәнерлек төсле,
Ава калса шушы исерекләр.

Төшеп калган алар кешелектән,
Бу дөньяда гаме-хисе беткән...
Икмәк рухыннан да ары юл юк!
Кая бармакчы бу исерекләр?!

Күз алдымнан китми яман төш күк,
Онытып та булмый, кичереп тә.
Безнең җанны шешә бөкеседәй
Каерырга тора исерекләр.

Уян, авыл! Юлдан язган затлар
Куркытмасын сине өрәк төсле.
Ачынуның бүген бер сурәте:
Исерекләр... Уттай урак өсте...

## Талпыну

Талпынган чак. Болытларга
Табынасы килә.
...Бала-чага кулындагы
Шар буласы килә.

Беркатлы сөенеч белән
Очырсыннар күккә,
Күңелнең шундый саф чагын
Көтә идем күптән!

Беләм, бу — хәтәр талпыну,
Җитмәс, бәлки, көчем...

Ә бит тормыш — бер булса да
Күккә ашу өчен!..



*Халкыбыз тарихына*



**Мөсәгыйт Хәбибуллин**

# ҺУННАР–БОЛГАРЛАР, КЫПЧАКЛАР ҺӘМ БҮГЕНГЕ ТАТАР ХАЛКЫ

Мәгълүм ки, тарихчыларны һәм бер тарихчыларны гына түгел, бәлки күп санлы укытучыларны һәм укучыларны да Һәмишә татар халкының килеп чыгышы кызыксындыра. Кызыксыну —эзләнүгә юнәлеш, йә булмаса бер чара, диләр. Эзләнә торгач, замана-чор фаҗигаларын кичереп тә исән калган һәм китап кадерен белгән кешеләр ярдәмендә китапханә киштәләрендә урын алган, ә кайберләре янадан басылган борынгы "хәзинәләрне" актара-актара мин дә үземә бер хакыйкать ачтым: бүгенге көндә бер генә халыкны да диярлек моннан мең еллар элек булган исеме белән атамыйлар. Халыклар яшәеш вә тереклек итү чорында йә әүвәлге исемен бөтенләй җуйган, йә теге йә бу халыкның исемен алырга мәҗбүр булган, йә булмаса аңа — ошбу халыкка — бөтенләй ят булган исем тагылган. Аннары янә бер нәрсәгә төшендем: халыкларга теге йә бу исемне йә илдән-илгә йөрүче мосафирлар, йә сәүдәгәрләр, йә сәяхәтчеләр биргән. Иң сәере шунда: алар бу исемне йә шул ук халыктан, йә булмаса, күрше халыклардан ничек ишетсәләр, шулай язып алганнар. Ул гынамы, үз телләре алфавитына җайлап язып алганнар һәм шул рәвешле тарихи әйләнешкә дә кертеп җибәргәннәр. Бер генә мисал: скифлар, хуннар, гуннар, болгарлар, кыпчаклар, татарлар...Кыскасы, чорлар үтә торган, халыкларга кушылган исемнәр үзгәрә барган — ә бактың исә, халык бер үк, бер телдә сөйләшкән. Һәм бүген дә шул телдә сөйләшә, бер үк гореф-гадәт белән көн күрә, тереклек итә. Дөрес, яшәеш чорында ниндидер күләмдә теге йә бу телгә үзгәрешләр дә кергән, гореф-гадәтләр дә аз-маз янарыш кичергән. Әмма һәр халыкта да бабаларының гореф-гадәтләрендәге төп кануннары барыбер сакланып калган.

XI гасыр төрки халыкларның бөек галиме "Төрки телләр сүзлеге" хезмәтен язучы Мәхмүд Кашгари китабына материал җыю нияте белән төрки илләр буенча сәяхәткә чыгып китә. Китабының кереш сүзендә Кашгари болай дип яза: "Мин төркиләр, төрекмәннәр, угызлар, чигилләр, ягмалар, кыргызларның шәһәрләрен, кышлау һәм җәйләүләрен күп еллар дәвамында гизеп чыктым, сүзлекләрен тупладым, төрле төркем сүз хосусиятләрен өйрәнеп, аныклап чыктым. Минем бу эшкә керешүем төрки телен белмәгәнлектән түгел, бәлки бу телләр арасындагы һәрбер кечкенә генә аермаларны да аныклар өчен иде. Югыйсә, мин телдә аларның иң зур осталарыннан, иң зур белгечләреннән, хуш фикерләреннән, нәселе борынгыларыннан, сугыш кырларында оста сөңгечеләреннән идем. Аларның телләре минем күңелемә бөтенләй үк тирән кереп урнашкан иде. Мин төркиләрнең телендә кулланылып килгән шигырьләрдән, шатлык һәм хәсрәт көннәрендә кулланыла торган хикмәтле сүзләреннән, мәкальләреннән үрнәкләр китердем. Әйдә, алардан файдаланучылар укысыннар, тыңлаганнар тыңласыннар, тыңлаганнар исә үз нәүбәтләрендә, шул телдә сөйләүчеләргә җиткерсеннәр."

Бу бөек хезмәтне Мәхмүд Кашгари 1074 елда тәмамлаган һәм шул сүзлеккә

Идел буенда көн күргән төркиләрнең дә, ягъни болгарларның да мәкаль, җыр һәм шигырьләрен керткән. Кашгари сүзлеге зур күләмле "хәзинә" — ул 600 биттән артып китә. Сүзлек мәкаль-әйтемнәргә гаять бай — анда 9 мең тирәсе сүзгә аңлатма бирелгән, 300 дән артык мәкаль һәм әйтем теркәлгән һ. б. Мәхмүд Кашгариның бу хезмәте безнең заманда 1915 —1917 елларда 3 томда Истанбулда, ә 1960 — 1963 елларда Ташкентта басылып чыкты. Гәрчә Мәхмүд Кашгариnең хезмәтен мәктәп дәреслекләренә кертсәләр дә, татар укытучысының һәм укучысының алтын хәзинәсенә тиң ошбу китапны кулына тотып караганы юк. Кызганыч, бик кызганыч! Кашгаридан бер мисал:

Алп Әр Тоңа өлдимү?
Исиз ажун калдыму?
Өзләк өчин алдыму?
Әмди йүрәк йыртылур!

Бүгенге татар теленә күчергәндә, болайрак тәрҗемә ителә:

Алып ир Туңа батыр да үлдемени инде?
Ул да бу явыз дөньядан киттемени инде?
Язмыш аңардан да үч алдымыни?
Инде хәзер безнең йөрәкләр өзгәләнә!

Бу юлларны борынгы төрки бабаларыбыз язганнар. Скиф —сөнхун — һуннар кем булган соң? Алар нинди телдә сөйләшкән? Көч вә куәтләре ни чамада булган?

Моңа да җавап табарга була икән: безнең борынгы бабаларыбыз турында ташларга уеп калдырганнар икән ич!

Ассириянең бөек патшасы Асархаддон (б.э.к. 681 — 668) үз иленә скиф-һуннар басып кергәч: "Бу хәл Хода тарафыннан безнең башка төшкән бәла", — дип ташка уйдыртып калдыра.

Галимнәр арасында тарих атасы исемен алган грек Геродот (б.э.к. 484 — 425): "Безгә билгеле булган халыклардан бары тик скифлар генә орышларда зур осталыкка ияләрдер. Аларның көче шуннан гыйбарәттер: скифлар дошманнарына качарга ирек бирмиләр, ә менә үзләре шул хәлдә калганда җинел генә качып котылалар", — дип яза.

Геродот фарсылар шаһиншаһы Дарийның (б.э.к. 514) 70 мең сугышчы һәм 600 кораб белән скифләрне буйсындырырга килүе хакында язып калдыра. Әмма Дарий шул кадәр көч белән килсә дә скифләрне җинә дә, буйсындыра да алмый, скифләрне далаларында куа-йөри торгач, бик күп гаскәрен югалта һәм, ахыр чиктә, чарасыз калып, иленә кайтып китәргә мәҗбүр була.

Скиф-һуннар хакында тарихчылар күп язалар. Греклар аларны скифләр, кытайлар хуннар-һуннар, фарсылар тураннар, кушаннар, дип атыйлар. Мәгәр иң сәере шулдыр — кайда ул халык бүген? Шулай ук эзсез юкка чыктымы?!

Тарихта шактый тирән эз калдырган скифләр патшасы Атей (Әти) бар. Геродот бу сүзне борынгы греклар алфавиты белән "ә" дип яза, ләкин рус телендә ул "а" белән язылган. Шулай ук грек телендә "ей" түгел, ә "и" белән язылган. Ә бит бу язманы Геродот б.э.к. IV гасырда язган. Тарих атасы заманында Кавказ таулары аша үтеп, скиф-һуннар иленә килә. Ә скифләр бу вакытта Ассириягә яу йөриләр, хәтта борынгы Мисыр дәүләте чикләренә кадәр барып җитәләр. Хак, болай еракларга яу йөрү скифләргә әйбәт бетми. Лидия патшасы Киаксар (кардәш халык булулары ихтимал) скиф-һуннарның яубашларын мәҗлескә дәшә, бик каты сыйлый һәм тегеләр исерешкәч, барысын да үтертә. Юлбашчыларсыз калган скифләр илләренә — Кавказга, Алгы Азиягә кайтып китәргә мәҗбүр булалар.

Шушы хәлдән соң заман тарихчылары ике йөз елга якын скифләр турында бик аз телгә алалар. Ә менә б.э.к. 339 елда Александр Македонскийның әтисе Филипп II скифләр белән сугышырга ниятли. Ләкин скифләрнең тактикасын яхшы белгәнгә, ул башта скифләрнең үзләреннән 30 мең ат сатып ала һәм башта гаскәриләрен атта сугышырга өйрәтә. Шуннан соң гына яу чыга. Скифләр гаскәре башында югарыда телгә алынган Әти тора. Аңа туксан яшь була инде.

Әнә шул туксан яшьлек Әти гаскәриләре белән бер сафта орыша һәм дошман тарафыннан үтерелә. Әмма теге якка да, бу якка да җиңү килми, һәрьяк җиңүне үзенә язып, тыныч кына аерылышалар. Геродот шулайрак язып калдыра. Әмма тарихка соңгарыбрак килгән авторлар ошбу җиңүне Филиппка бирәләр. Монда инде тарихка идеология керә башлый.

Б.э.к. III гасырда көнбатыш скифларгә көнчыгыштан килгән кардәш сарматлар (тарихчылар һәм археологлар раславынча, шул ук бер төрки телдә сөйләшүче һәм бераз иранлашкан халык) килеп кушылалар. Аларның телләре генә түгел, гореф-гадәтләре дә бер була, дигән фаразлау бар. Нәкъ менә шул чорда көнбатыш скифләр борынгы исемнәрен югалталар һәм "сарматлар" дип атала башлыйлар. безгә мәгълүм булганы шул; б.э. I — II гасырларда бүгенге Альп тауларын Аурупа халыклары һәм тарихчылар Сармат таулары дип атаганнар.

Скифләр мәсьәләсендә бер нәрсә бәхәс уята: тарихчыларның барысы да, бер сүздән диярлек, скифләрне күчмә халык дип расларга тырышалар. Ә менә шул чорларда яшәгән грек тарихчысы Диодор скифләрнең грекларга мал-туар, коллар белән бергә ашлык сатулары хакында да язып калдыра. Янә шул чордан кайта-киләрәк яшәгән тарихчы префект Ритор Фемистий (317 —388): "Константинополь сәүдәгәрләре кала халкын бодай ашлыгы белән Мисыр, Боспор, Херсонестан китереп тәэмин итеп торалар," — дип яза.

Көнчыгышта исә бөтенләй башка хәлләр бара. Тарихчы Л. М. Гумилев көнчыгыш скиф-һуннары хакында болай ди: "Һуннар кытайлыларга каршы сугышалар. Сан ягыннан чагыштырып карасаң, 1:20 сугышчы туры килә, ягъни бер һун сугышчысына 20 кытайлы каршы чыккан була. Шуңа карамастан, кытайлылар һуннардан куркып яшиләр, үзләренең иманнарына тугры калырга тырышып, әсир ителгән һун илтабарларын бабалары кабере өстендә корбан итәләр. "Әнә шундый хәтәр үлемгә 660 елда император полководецы Су Динфан Ташкентта әсир иткән көнбатыш төркиләре илбашы каһан Тумын дучар ителә. Әмма соңгы чиктә каһанны әсир иткән полководец император алдында үзе үк Тумын илбашының гомерен саклап калырга кирәк, дип чыга, — дип яза кытайлыларның Тан династиясе чорын тикшерүче галим Эдвард Шефер үзенең "Золотые персики Самарканда" дигән китабында.

Безнең эраның 155 — 158 елларында кытайлылар һуннарны янә бер җиңүгә ирешәләр. "Һуннар олауларын, хатын-кызларын югалта-югалта, Идел-Урал елга буйларына таба күчеп китәргә мәҗбүр булалар." (Л. М. Гумилев. Хунны в Китае. — М., 1974.)

Икенче бер мәшһүр тарихчы скифләр хакында болай ди: "Скифләр дәүләте җимерелгәч, җиңелүчеләр көнбатышка таба чигенеп, Идел-Урал араларына килеп урнашалар. Күп тә үтми, алар биредәге җирле халыкларны — угыр-финнарне, иран телле алан-сармат кабиләләрен буйсындыра-буйсындыра, һун-скифләрнең бер өлеше Төньяк Кавказга килеп чыга, аннан Көнчыгыш Ауропага һөҗүм итә. Нәкъ менә шул яулап алучыларны көнбатыш авторлары "гуннар" — һуннар дип атаганнар. (Артамонов М. И. История хазар. — Л., 1962.)

Безгә билгеле булган төркиләрдә бер сүз бар — илтабар. Бик борынгы заманнардан ук төрки хәрби-демократик союз башында илтабар торган. Бу адәм үз халкына җир-су һәм ил табучы булган. М. И. Артомонов "иран телле алан-сарматларны буйсындырып" була дип яза, ягъни ошбу халыкларның тел һәм гореф-гадәтләрен юк итеп була. Ләкин бу мөмкин хәлме? Юк, әлбәттә. Менә ничек тиз икән чит халыкларны буйсындыру һәм икенче телгә күчерү! Мәгәр бер хакыйкать бар, теге йә бу халыкны буйсындырган хәлдә дә аның телен, динен, гореф-гадәтен тиз генә әсир итеп булмый. Тел вә дин һәм гореф-гадәт һәр халыкта да бик акрын үзгәрә, ахыр килеп, тел сугыш кырында үзгәрми, ә халыкларның үзара аралашу нәтиҗәсендә, анда да ниндидер күләмдә генә үзгәрергә мөмкин. Димәк, көнчыгыш скиф-һуннары бер дә чит-ят җиргә күчеп китмәгәннәр, алар үзләренең кардәш хәрби-демократик берлекләренә (союздашларына) гына килеп кушылганнар. Ә теге йә бу кардәш хәрби союзга килеп кушылу төрки берлекләрнең көч-куәтенә карап хәл ителгән.

Скиф-һуннар хакында Кытай тарихчысы Сыма Цяня (б.э.к. 221): "Илтабар Мәҗүн б.э.к. 201 елларда Себер төбәкләрен яуларга керешә. Ил белән идарә итә

башлауга "Акыллы" кушаматы алган илтабар Мәҗүнгә рудниклар кирәк була. Мәҗүн рудникларны яулый һәм корыч коюны җайга сала. Шул хәлләрдән соң һуннар II гасырда ук инде җир сукалау өчен чуен калаклы сабан кулланганнар," — дип яза. (Материалы по истории древних кочевых народов группы дунху. — М., 1984.)

Бире табарак килеп карасак, Византия тарихчысы Зимарх 568 елда Өйтау — Алтау төрекләре иленә килә. Аларда ул эрүташ (руда сүзе дә шуннан) чыгара торган шахталар күрә, ташларны кайнату мичләре белән таныша, чүкелгән ярымкорыч мәгъдәннәрне кулына тотып карый, хәтта илдәшләренә күрсәтү өчен бер кисәген сатып та ала.

Тарихчы Л. Р. Кызласов үзенең "Урта гасырда көньяк Себер тарихы" китабында (М., Высшая школа, 1984.): "Яна материалларга таянып әйтергә була, мона кадәр һуннарның социаль төзелешен "күчмә" халык итеп күрсәтү фәндә инде күптән искерде. Шулай ук һуннар дәүләте ыру кабилә берләшмәсеннән генә торган, дигән теория белән килешеп булмый. Бездән соң да һуннарны тикшерүчеләр онытмасыннар иде: борынгы һуннарда күчмә халыклар берләшмәсе түгел, ә хәрби-демократик союз хөкем иткән. Бу союз үз халкын территориаль һәм вассал бәйләнешләрга бәйләп, ун данәгә, йөз данәгә, мең данәгә һәм түмәнгә бүлгән. Иң мөһиме, бу бүлекләрдәге 15 яшьтән алып 50 яшькә кадәр ир-ат хәрби яуларда катнашырга мәҗбүр ителгән," — дип яза. Искәртеп үтим, Чыңгыз хан үз чирүенә 15 яшьтән алып, 70 яшькә кадәр ир-атны яу йөрергә карар кылган.

"Һуннар Идел-Урал араларына килеп урнашкач, биредә биш гасырга кадәр хөкем иткәннәр. Шул вакыт эчендә алар кул астындагы күп кенә угыр-фин кавемнәрениндидер күләмдә төркиләшеп китә," — дип яза тарихчы галим Г. Таһирҗанов. (Тарихтан — әдәбиятка. — К., 1979). Олуг тарихыбыз бераз ялгыша. "Һуннар Идел-Урал араларына күчеп урнашмыйлар" — алар бик борын заманнардан ук шул төбәктә көн күрәләр.

VI гасыр тарихчысы Прокопий Кессарийскийның үзенең "Готлар белән сугыш" китабында төрки болгарлары хакында мондый юллар бар: "Илтабар һунның ике кулы була — Утригур һәм Көтригур. Бу ике илхан, әтиләре дөнья куйгач, икегә аерылып яши башлыйлар. Алар еш кына берләшәләр һәм Византиягә яу йөриләр. Хәрби-демократик берлеккә нигезләнеп төзелгән бу ике дәүләт империянең куркыныч дошманына әверелә. Алар Византиядән бүләк (дань) таләп итәләр, еш кына империяне кыен хәлгә калдыралар."

Прокопий төрки болгарлары турында исә: "Аерым яшәсәләр дә, бу ике халык бер телдә сөйләшә, гореф-гадәтләре дә бер. Илтабар Көтригур кавеме Истр (Дунай) белән Һун (Дон) араларын били, ә илтабар Утригур Һун (Дон) елгасының сул як җәйләүләрен һәм Азов диңгезе буйларын, Таман ярымутравын били," — дип хәбәр итә.

354 елда Әрмән тарихчысы Моисей Хоренский беренче тапкыр болгарларны телгә ала һәм: "Болгарлар Азов диңгезе буенда Атилла хан килгәнче үк тереклек иткәннәр, " — дигән фикер әйтә. Димәк, болгарлар янә бер төрки союзы булып торган. Атилла исә үз гаскәрләре белән аларга килеп кушылган гына.

Икенче бер тарихчы: "448 елда болгарлар Византия ягында һәм Италиядә сугышып йөриләр, шул яуда болгар ханы (илтабары) Бүҗән үлеп калды," — дип яза. 502 елда готларга каршы яу йөриләр һәм Балкан ярымутравы төбәкләрен яулыйлар. Бу юллар да тарихтан. Күренә ки, һуннар инде Балкан төбәкләренә ия булырга җыеналар, әлбәттә, VII гасырда Кубрат ханның өченче улы Аспарухның шул төбәкләргә күчеп китүе табигый хәл булгандыр.

530 елда Атилла хан кул астындагы ике болгар ханы Дунай елгасын кичеп, империягә һөҗүм итәләр. Бер ханның гаскәрен франклар илтотары тар-мар итә, ә менә икенчесе Византия легионерларын җиңүгә ирешә.

Ниһаять, "537 елда Рим императоры Велизарий үзенең федератлары — болгар һәм антлар ярдәме белән готларны Римнән куа. 539 — 540 елларда Греция аша үтеп, Кече Азиягә чыгалар, андагы ныклы кирмәннәрне җимереп, халыкны талап, үзләре белән 120 мең кешене әсир итеп, илләренә алып кайталар", — дип яза шул ук Прокопий.

Сирия тарихчысы Захарий Ритор (VI): Тимер капка (Дербент каласы)

артында болгарлар яши, диннәре мәҗүси, әмма зур-зур калалары бар", — дип язып калдыра.

Тарихчысы Иордан исә (VI): "Кара диңгезне үтүгә болгарлар иле башлана", — дип искәртә.

Тарихчы Агафий (VI): "Болгарлар иле Кара диңгез һәм Азов диңгезе һәм Һун (Дон) елгасы буйлары белән төгәлләнә", — дип яза.

571 — 632 елларда Көнбатыш һуннарның хәрби-демократик союзы үзләре белән кардәш булган төрки каһанлыгы белән берләшә. Бу хәл Атилла хан үлгәч була, белгәнебезчә, Атилла хан 56 яшендә авызыннан кан китеп үлә. Димәк, Атилла хан канаты астындагы төрки болгарлар илләренә юнәлергә мәҗбүр булалар һәм Ашин ыруына кергән төркиләр белән берләшергә дучар ителәләр булса кирәк. Чөнки күп тә үтми Дулу ыруына кергән болгарлар 582 — 584 — 594 елларда үзләренә мөстәкыйль хәрби-демократик союз төзү максаты белән баш күтәрәләр. Әнә шулай итеп Төрки каһанлыгында тәхет өчен ызгыш башлана. Бу ызгышны бастыру нияте белән Кубрат ханның агасы Ураган каһан көнчыгышка юнәлә һәм шул ызгышта үтерелә. 630 елда Көтригурлар ханы Буҗән аварлар союзыннан аерылып чыга һәм туганые Кубрат ханга килеп кушыла. Кубрат хан энесен яклау нияте белән аварларга каршы яу кузгала һәм авар каһаны Баянны үтереп, аның гаскәрен үзенә кушып, үз иленә, ягъни Таман ярымутравына кайта. Хак булса, бу хәл хак булса кирәк, — аварларга каршы Кубрат ханны Византия императоры котырта һәм шул хәлдән соң Кубрат ханга патрикий титулы бирә. Аннары Византия тарихы аша үсмер Кубрат ханның император сараенда тәрбия алуы да билгеле. Бу хакта VII гасырда яшәп, әрмәннәр географиясен төзегән Я. М. Манандян хезмәтләрендә дә мәгълүматлар бар. Нәкъ шул чорларда Кубрат хан көнчыгыш Ауропада беренче булып дәүләт төзи.

Әүвәл — скиф-һун, ары килеп — сармат, бире килеп — болгар, хазар, кыпчак, татар исемнәрен йөрткән халык нинди телдә сөйләшкән соң?

Бәхәссез — төрки телдә. Моны раслау өчен, иң әүвәл, б.э.к. 500 ел элек яшәгән тарих атасы Геродотка мөрәҗәгать итик. Дөрес, бу хакта Геродот бик үк тулы мәгълүматлар бирми, әмма тел белгечләре өчен аңарда гаять кызыклы, хикмәтле мисаллар табып була. Хикмәт шунда, тарих атасы амазонкалар турында, ягъни ир-атлар белән сугышып яткан легендар хатын-кызлар турында яза. Геродот әйтә: "Скифләр амазонкаларны үзләре "эрпата" дип атыйлар, ягъни ир-атны үтерүчеләр дип. Эор — ир, пата — атучы, ди. Мин бу сүзләрне грек хәрефләренә салып карадым. Рус телендә "эорпата" булса да, грек телендә "ир-ата" икән, ягъни ир-атны атучы хатын-кызлар. Аннары Геродот әйтә, скифләр үзләре ул хатын-кызларны — ирдәүкә дип атыйлар, ди. Бу соң безнең бүгенге "ирдәүкә" сүзе түгелмени!? Ирдәүкә, ягъни артыгы белән ирләрчә кыланып йөргән хатын-кыз. Миңа калса, безнең бабаларыбызның — скиф-һуннарның, ары килеп — болгар-татарның нинди телдә сөйләшүләренә ныклы һәм ышанычлы күпер бу. Әйтсәм әйтим инде, шуңа охшаш берәр сүз русларга тарган булса, алар бөтен скифләрне урыс итәчәкләр иде. Ә бит бу күпергә бүген 2500 еллар инде.

Ахыр килеп: "Остеологик, археологик, мифологик һәм лингвистик материалларга нигезләнеп әйтергә була: атларны әүвәл Урал-Идел араларында яшәгән кешеләр кулга өйрәткәннәр", — дигән нәтиҗәгә килә шушы өлкәне озак еллар буена өйрәнгән олуг белгечләрнең берсе Е. Е. Кузьмина (Борынгы заманда һәм Урта гасырда Урта Азия. — М., 1977.)

Бәхәссез, скиф-һуннарның олуг ханнарының берсе нәкъ менә Урал-Идел даласыннан чыга һәм бары тик атлы гаскәр белән генә сугышкангамы, аңа исемне дә Атилла дип, "ат иле" атын кушалар.

М.З.Зәкиев үзенең "Татар халкы теленең барлыкка килүе" хезмәтендә һуннар ханы Атилла исемен атлылар иле, аты бар, иле бар, дип аңлата, Атилланың беренче улы — Иллак, икенче улы — Диңгизил, өченче улы — Ирнак. Бүгенге транскрипция белән язганда Ат иле, Диңгез иле түгелмени?..

Чынында исә Атилла хан үлгәннән соң Һунстан илендә зур ызгышлар башлана. Атилла ханның баш улы Иллак үтерелә. Ә Диңгизил белән Ирнак туган якларына — Кара диңгез буйларына кайтып китәләр. Атилла ханның хатыны Күркәм исемле була. Бу хакта тарихчы Иордан да яза. Бу исем дә безгә бик якын — Күркәм, матур, чибәр, гүзәл, димәк.

Яшәеш гомерендә безнең татарларга нинди генә исемнәр такмыйлар: кимрәй, скиф, һун, туран, кушан, түргәш, түке, хакас, уйгур, болгар, хәзәр, кыргыз, угыз, төрекмән, үзбәк, казакъ, әзәрбәйҗан, башкорт, чуваш, якут, каракалпак һ. б. — кыскасы, исемнәргә шул хәтле бай ки төрки халкы, шаклар катмалы. Бактын исә, тел һәм гореф-гадәтләрендә аерма бик аз. Һәммәсе дә гомум төрки телдә сөйләшәләр, аралашалар. Ә телләрдәге зур булмаган аерманы төрки хәрби-демократик союзларның бер-берсеннән ерак яшәүләре белән генә аңлатырга кирәктер. Мине әле дә булса бер хәл гаҗәпләндерә, урысларның XIX гасыр иң белемле язучылары Лев Толстой да хәтта көнчыгышта яшәгән барлык халыкларны татарлар дип атый. Искитмәле хәл! Ә инде исемнәргә килгәндә, урыслар кыпчакларны — половецлар дип атаганнар. Гарәпчә кыпчак — кыр кешесе, русча да шулайрак килеп чыга. Шул ук вакытта халыкларга "теш үтмәслек" исемнәрне дә биргәннәр. Әйтик, франки сүзе — иреклеләр сүзен аңлата, свевы — бродяги, маркоманнар — чит саклаучылар (пограничники), алеманнар — сброд, жыелма халык. Һәр этнос ул — төрле яклап сөттән каймак булган исемне йөртә. Татар исеме исә безгә кушамат рәвешендә ябыша. Хәер, урысларга да урыс исеме шулай ябышкан. Борын заманда да, әле дә финнәр һәм эстоннар русларны — венедлар, дип йөриләр һәм хәтта карталарына да Россия дип түгел, Венедия дип язалар. Чөнки руслар ул —борынгы варяг-норманнарга греклар биргән исем. Кытайча — да-да — кыр агай, та-та — кыр кешесе. Н. А. Баскаков татар атамасын — атлы хәбәрче, илче-чапкын, сөенче китерүче, гонец, посланец, дип аңлата. Кытайлыларның һөнәрче — тимер коючы төркиләргә татар дип әйтүләренә дә бер дә шаккатасы түгел, чөнки алар тимер чынын "таатар" дип ишеткәннәр, чөнки татар төркиләре кытайлыларга төрле тимер җиһазлары, кораллар, сука-сабаннар ясап бирүче булганнар. Һөнәрчеләрне бер генә яулаучы да рәнҗетмәгән, киресенчә, аларга бөтен шартларны да тудырган. Татар сукасы, татар кылычы, татар сөңгесе, татар хәнҗәре, татар чукмары һ. б. шуннан килгән. Әнә шул исем тора-бара мангул баскынчыларына да ябышкан. Әйе, әле хәзер дә әйтәләр бит урыс мунчасы, урыс каены, урыс аракысы, урыс чабатасы дип, нәкъ менә шул халәттә "татар" сүзе дә бериш төркиләргә ябышкан, шул исәптән болгарларга һәм кыпчакларга да — төрки халыкларының иң куәтлеләренә һәм мәгърифәтлеләренә. Гәрчә урыслар XVI гасырга кадәр мунча дигән юыну һәм чабынып коену урынын күрми-белми яшәгәннәр, патшаларына кадәр тәпәндә һәм мичтә юынганнар. Моны дәлилләү өчен бер кинофильмда (исемен хәтерләмим) Иван Грозныйның тәпәндә юынып утыруын искә төшерү дә җитәр кебек.

Урысларның борынгы тәгаен исемнәрен VI гасырда яшәгән Иордан язып калдыра — антлар, венедлар, склавеннар. Соңрак бу халыкларны дулебларга, волыннарга, древляннарга, поляннарга, дреговичларга, северяннарга, уличларга, вятичларга, радимичларга һ. б. исемнәргә бүләләр. Тарихчы галим Мурад Аджи үзенең "Полынь половецкого поля" хезмәтендә урыслар турында тагын да тәфсилләбрәк яза. Ул бу исемне болайрак раслый: "Русский кем ул?" — дигән сорауны куя да, ана үзе үк җавап та бирә. Аның җавабы без — татарлар өчен үтә кызыклы һәм гаять җитди булу сәбәпле, мин аның тексттан тулысы белән китерергә булдым.

**"Борынгы урыс халкы, көнчыгыш славяннар үзаңы белән, беренче Киев Русе феодаль дәүләтендә (Киев Русе — IX — XII гасырлар) барлыкка килә — Рәсәйдә рәсми рәвештә расланган караш шулдыр. Бары тик. Ә соң Киев кадәр Киевтә кем булган? Буш җирдә хасил булмагандыр бит инде бу халык? Кемнәр алар Днепр елгасына күчеп утырган халыклар? Һәм каян күчеп утырганнар? Нигә алар нәкъ менә IX гасырда гына бу төбәккә күчкәннәр?.. Ахыр килеп, Киев дәүләте өч гасыр тулар-тулмас шул чиккә җитеп, бердәм һәм куәтле оеша ки — шаклар катмалы.**

**Аннары шунысы аңлашылмый: алай булгач, нигә соң Киев дәүләтенең төп халкы украиннар, нигә урыслар түгел? Киев —Рәсәй ич! Ул гынамы, нигә урысларның мәдәнияте бу халыкларныкыннан күзгә бәрелеп аерылып тора? Русия булгач, мәдәнияте дә бердәй булырга тиештер бит инде? Тамырлары бер ич диярсез. Әйе, тик тарихка тирәнгәрәк кергән саен бу ике халык арасында җир белән күк арасыдай аерма күрерсез.**

**Безгә мәгълүм булганы шул: Киев Русе туганга кадәр борынгы Мисыр цивилизациясе чәчәк атып үлә. Борынгы Греция Борынгы Көнчыгыш дәүләтләре вә**

**империяләре турында әйтеп тә торасы юк. Нәрсә булды икән шул чакларда Киев Русе җирләрендә? Буш булмаган да булмаган инде ул җирләр?! Кызганычка каршы, Рәсәй тарихында моңа тәгаенләп җавап бирүче юк. Киресенчә, җавап урынына бихисап сораулар туа. Сакланмаган бу чордагы документлар. Ә бәлкем аларны юк итә барганнардыр?.. Иллә мәгәр бу хакта дөнья халкы күптән белгән икән инде. Бу хәл бераүгә дә сер булмый, бу бары тик Русиядә яшәгән халыклар өчен генә сер итеп саклана килә, әлегә кадәр бу чорның барлык мәгълүматларын кеше күзеннән яшерәләр, ул гынамы, бу мифик халык турында яңадан-яңа уйдырмалар туып тора. Ә бит борынгы чорда "русь" сүзе белән греклар гына түгел, римләннәр дә, гарәпләр дә, кыпчак һәм фарсылар да — бөтен дөнья халкы — бер халыкны гына беләләр —варягларны, ягъни скандинавия халыкларын. "Русь" борынгы исланд диалектында "ишүчеләр" дигәнне аңлата. Бу халык — Швециядән чыккан борынгы кавем, бер сүз белән атаганда — "диңгез халыклары". Хакыйкатьне юк-бар шикләрдән арындыру өчен шул да җитә, шведларга күрше халыклар эстоннар, финнар, борынгы гадәтләре буенча, Швецияне бүген дә "Руссия" дип атыйлар һәм карталарына да шулай дип язалар. Ә СССР картасын төшергәндә Россия дип түгел, "Вения" дип язалар".**

Боларның барысын да укыйсың да: "руслар" сүзе белән "славяннар" арасында һичнинди уртаклык булмаган икән ич!" дигән нәтиҗәгә киләсең. Бит Өлкән Плини (24 — 79 еллар) буенча да бүгенге славяннар үзләрен "венедлар" дип атаган. Шул чорларда яшәгән Рим тарихчысы Рацит та (58 — 117) венедлар исемен раслау белән бергә аларның кай төбәктә тереклек итүләрен дә күрсәтеп үтә — Ауропаның Висла һәм Одер елгасы арасында, ди.

Көнчыгыш тарихчылары да бу халык турында яхшы белгәннәр. Әйтик, Ибн-Рустә: "Русларның сөрү җирләре юк, алар бары тик славян халыкларыннан җыйган ризык белән тукланалар", — дип яза. Аның сүзләрен куәтләп, икенче бер көнчыгыш тарихчысы Гардизи: "Аларда (ягъни, урыслардан. — М. Х.) һәрдаим 100 — 200 кеше (урыслар) славяннарга яу йөреп торалар һәм көчләп-талап бар булган әйберләрен алып китәләр", — дип без шикләнгән тарихны ачыклый.

Рәсәй тарихының тоташ мифлардан торуын һәммә Ауропа һәм көнчыгыш тарихчылары да белә. Һәм бу дөнья тарихчылары өчен күптән сер түгел. Бу мәсьәләне ачыклау өчен шушы өлкәдә шактый эшләгән янә Мурад Аджи хезмәтенә мөрәҗәгать итәм: "Тарихка мифләр кертүне иң элек кенәз Владимир Мономах башлап җибәрә. 1116 елда ул Нестор елъязмасын Печер монастыреннән алдыртып, үз сараендагы Выдубицкий монастырена китертә. Анда күчерелгәч, елъязма игумен Сильвестр кулына эләгә. Һәм менә шул кеше Русь тарихын "күчереп" яза. Әмма славян рухында тәрбияләнгән кенәз Владимир аның бу эшеннән канәгать булмый: ул ошбу елъязмада, ягъни тарихта, русьның славянлыгын танымый. Ике елдан соң Нестор елъязмасының яңа тексты барлыкка килә. Аны Владимир Мономахның олы улы кенәз Мстислав — иң тәвәккәл рус редакторы яза. Англия короленың оныгы, Швед короленың кияве була ул, һәм нәкъ менә аның белән берлектә варяг традицияләре көчле булган Новгород боярларында тәрбия алган кенәз Мстислав Русия тарихын үзе кирәк дип тапканча редакцияләп чыга. Язучы кенәзнең тырышлыгы белән Новгород Киевне "каплап китә". Шул рәвешле тарихтагы Киевнең урыслар тарафыннан яулап алыну хакындагы юллары сызып ташлана. Һәм бу вакыйга өч йөз ел дәвамында укучылардан яшерелә. Аның каравы, тарихта варягларның роле беренче урынга чыга. Янәсе, киевләннәр үзләре варягларны ил белән идарә итәргә чакырганнар. "Безгә кенәзлек итәргә килегез һәм хуҗа булыгыз", дигәннәре мәңгеләштерелә. Яңа тарихта норман Хельгның Киевне басып алуы да төшереп калдырыла. Киев каһаны Әскәрнең (урыслар аны Аскольд дип язалар) үтерелүе дә юкка чыгарыла. "Славян-норман" редакторы кенәз Мстислав Россия тарихына шул хәтле буталчык кертеп калдыра ки, аларны укыганда тәннәр чымырдый. Әмма Мстислав калдырган "яңалык" заман үтү белән чынлап та Русия тарихының нигезенә әверелә. Әнә шулай Мәскәү кенәз-варяглары хакимлегенә дучар ителгән халыклар — руслар дип аталалар. Хәер, Русия тарихын аннан соң да әнә шулай туктаусыз редакцияләп торганнар, моңа Иван Грозный патша да кул тыккан. Моны алар ихласи урыслар үз тарихларын белмәсеннәр, бабаларын онытсыннар өчен эшләгәннәр", — ди Мурад Аджи.

Борынгылар ялган тарихны ялган галимнәр тудырыр, дигәннәр. Шуның кебек безнең бериш татарларыбыз: "Без болгарлар!" дип лаф орып, паспортларына кадәр "болгар" дип яздырып йөриләр. Искитмәле хәл. Наданлыкмы бу, әллә соң ялган тарих белән гасырлар буенча яшәгән баскынчы урыслардан куркумы?! Тегесе дә, монысы да бар бугай, юкса, алар ата-бабаларының исемнәреннән баш тартмаслар иде — бүгенге исемнәреннән. Бит урыслар бер дә үзләрен: "Без венедлар, баскынчы "руслар" түгел, лаф орып, паспортларын алыштырып йөрмиләр һәм йөрмәячәкләр дә. Чөнки алар әнә шул ялган тарихларыннан үтә канәгатьләр.

1919 елда В. И. Ленин тарихчы белгечләрдән Идел-Кама буйларында көн күргән халыклар турында мәгълүматлар соратып ала. Ана татарлар турында болай дип аңлатма бирәләр: "Татарлар үзләрен бу исем белән атамыйлар. Татар сүзе кытайлылардан килә. Кайчандыр IX гасырда Алтайда яшәгән төрки кавемнәрне кытайлылар — дада, тата, тадзе, таатар дип атаганнар", — дип язып бирәләр. Ни өчен сорый соң моны ил башына килгән олуг большевик? Хакыйкатьне табу өчен. Чөнки ул әлеге татарлар арасында яшәгән кеше һәм аларның белемгә, мәдәнияткә омтылышы, белемнәре һәм укымышлыклары белән урыслардан да өстен булуларын күреп белгәнгә сорый. Русия тарихчылары расларга тырышкан кебек, бу халыкның кайдандыр Идел-Кама буйларына күчеп килгән халык түгеллеген аңлый ул, аңлап кына калмый, моңа бу халыкның көнкүреш хәлләре аша да инана. Шуңа шиккә кала — күчмә дә, кыргый да түгел бу, ә мәгърифәтле, мәдәниятле, һөнәр-хезмәткә һәвәс халык. Шуна күрә булса кирәк, Ленин нәкъ менә татар зыялыларына мөрәҗәгать итә: "Сез кемнәр?" Ягъни татарлармы, болгарлармы? Мангулармы?

"Без татарлар!" — дип җавап бирәләр шул чор зыялылары. Һәм бик дөрес эшлиләр. Без чынлап та татарлар, ә борынгы бабаларыбызның исемнәре болгарлар һәм кыпчаклар. "Болгар" тарафдарлары! — телисез икән, бу хакыйкатьне кабул итәсез, теләмисез икән, кесәгездә "болгар" дигән паспорт йөртәсез. Һәммә кеше өчен дә ирекле эш бу. Тик менә Татарстан илендә җир-табын бүлешкәндә бу исемне йөртүчеләргә җир бирелерме икән — мин белмим, бирелмәскә тиеш, чөнки бу милләтне йөрткән халык бары тик Дунай тарафларында гына яши. Хәер, бу хәл дә мәшәкать тудырмас, юристлар мона да җаен табарлар, сез тик барыбер үги анадан туган халыктай хис итәрсез үзегезне.

Әйе, әйткәнемчә, кытайлылар тимерче төркиләрне "таатар" дип атаганнар. Бу хакта Кытай тарихында (Бичурин буенча) мондый юллар бар. Төрек тимерчеләре кытайлыларга сабан, сука, кылыч, сөнге, ук очлары, китмән, хәнҗәр, пычак кебек кораллар сатканнар, кытайлылар исә Алтау төрекләренә ефәк тукымалар, янмый торган күлмәкләр китергәннәр. Тагы да сәере шулдыр, кытайлылар тимерне тимергә суккач чыккан тавышны "таатар" дип ишетәләр икән, ә без исә аны дан-дон, чан-чон дип. Мин моны тикшерү өчен кытайлы язучылар Казанга килгәч тимерне тимергә сугып карадым һәм нинди тавыш ишетәсез? дип сорадым. Һәм алар Бичурин әйткәнне расладылар — таатар, диделәр. Мин авызымны ачтым да калдым, чөнки мин чан-чон тавышын ишеттем.

Борынгы Болгарда илче йөзендә килгән Ибн Фадлан Болгар ханы Алмас җибәргән кешене "тимерче булган" дип әйтә. Ә бит бу кешенең исеме бар — Тикин-төрек. Димәк, Болгарда тимерче гаять дәрәҗәле кеше булган икән. Һәм XIII гасыр башында ук болгарларның чуен коя башлауларына да бер дә шаккатасы юк. Бу хәл аларга борынгы төрки халыкларыннан ук килгән.

Мәгәр, укучым, син хикмәт исемдә түгел, җисемдә, диярсең. Һәм бик хаклы буларсың. Тик бит, туганкайлар, һәр халык үз исеме белән горурлана, ә безнең кайберләребез генә түгел, хәтта бабаларыбыз да (болгар) татар исеме белән бер дә горурланмаганнар, хәтта гарьләнгәннәр, шуннан: "Татар барда — хәтәр бар", дигән мәкаль дә туган булса кирәк. Казанлыларның: "Без татарлар түгел, без мөселманнар", — дип йөрүләре дә бары тик татар атамасының асылына төшенмәүдән генә булгандыр. Чөнки теге йә бу дингә инану һич кенә дә милләт атамасына кагылмый — бөтенләй башка мәгънәне аңлата. Ахыр килеп, ни өчен бабаларыбыз "татар" исемен йөртүдән хурланганнар соң?

Шуның өчен: кем инде үз илен басып алган халык исеме белән горурлансын ди. Тик бит урыслар да славяннарны басып алганнар һәм аларга үз исемнәрен

такканнар. Нигә соң алар бер дә үз кушаматларыннан зарланмыйлар, киресенчә, горурланалар. Шуның өчен, чөнки бу исем белән алар үзләре дә баскынчыларга әверелгәләр, бик күп халыкларны басып алып, үз канатлары астына җыялар. Ә хак сүз хаким кулында, дигәннәр борынгылар.

Ауропалылар һәм урыслар өчен татар баскычны, күчеп йөрүче, ярымкыргый халык. Кайбер галимнәр татарларның хәтта язмалары да булмаган, дип расларга маташалар. Тик бит бу ялган, безнең борынгы бабаларыбыз бик борынгы заманнардан ук рунида язганнар, әнә шул руни язманы Атилла Ауропага алып килә. Һәм шунда бу язу тугандаш этрусклар язмасы белән кушылып, бүгенге латин алфавитын китереп чыгара. Борынгы һун бабаларыбызның үз язмалары булуны археологик казылмалар да раслый, әдәби мирас исә моны янә бер ныгыта, әйтик, Култәгин баһадир язмалары. Дөрес, Култәгин баһадирның ташка язылган юлларын ул бары тик иске таштан яңарттырган һәм үзе кичергән вакыйгаларны өстәгән, дигән фаразлау да бар. Иншалла, бу да үз вакыты белән расланыр.

Борынгы бабаларыбыз — болгар төркиләре яшәгән төбәкләрдә: "Төньяк Кавказ, Дунай һәм Идел-Кама, Урал-Агыйдел буйларында — рун язулы текстлар табылды", — дип яза үз хезмәтендә бер археолог (Шербак А. М., 1954.).

Кайбер галимнәр бу язуларны иске сармат язуы, дип гоман итәләр. Ләкин бит сарматлар төрки болгарларының канкардәшләре генә түгел, туганнары да булалар, шул ук вакытта һуннарның да, ягъни борынгы скифләрнең дә туганнары.

"Борынгы төркиләр арасында балаларны уку-язуга, исәп-хисапка өйрәтү II-III гасырларда ук башлана", — дип әйтелә Урта Азия тарихында (Тураев Б. А. — "История древнего Востока., Ташкент). X гасыр башында Болгарга сәяхәт кылган Ибне Рустә: "... аларның шәһәрләрендә генә түгел, хәтта авылларында да мәдрәсәләр бар", — дип яза. Шулай ук Идел буе болгарларының Бохара, Сәмәрканд, Балх, Бәйхак, Сәбзәбер, Әмәл, Багдад, Киев, Новгород, Торжок, Владимир һ. б. шәһәрләрдә махсус товар иншләре (товарищество) булуы мәгълүм. Моның өстенә болгар бабаларыбызның Кытай, Иран, Көнчыгыш Ауропа, Рим, Византия, Мисыр илләре белән сәяси-сәүдә мөнәсәбәттә булуларын да читләтеп узу тарихыбызга карата гадел караш булмас иде. Ә сәяси-сәүдә мөнәсәбәтләр, бәхәссез, язма-килешүләрсез булмаган да булмаган.

Ә менә Русия тарихын тирәнгәрәк төшеп танышкач, аның нигезе хак булуына шундук шик туа. Русия тарихын миңа балачактан ук өйрәттеләр. Ә мин тарих фәнен бик яраттым, яраткач торган саен тирәнгәрәк төшәргә тырыштым, тирәнгә төшкән саен ялган өстенә ялганга тап була башладым. Шуннан Русиянең хакыйки тарихын эзләүчеләр рәтенә бастым. Ә Рәсәйнең хакыйки тарихын эзләүчеләр бер мин генә түгел икән. Әйтик, шул ук Мурад Анджи үзенең "Полынь половецкого поля" хезмәтендә русь графикасы турында менә ни ди: "...славян укытучылары — агалы-энеле изге Кирилл һәм Мефодий тарихы аеруча гыйбрәтле: аларга Русиядә һәйкәлләр куелган, алар хөрмәтенә бәйрәмнәр уздырыла. Ләкин аларның славян булуларын кем һәм кайда дәлилләп күрсәткән соң? Чынында алар славян җирләреннән еракта, борынгы төрки болгарлары башкаласы Фанагориядә — Бөек Болгар каһанлыгында туганнар. Төрки телдә, дөресрәге борынгы болгар телендә сөйләшкәннәр һәм язганнар. Нинди славянлык булсын монда, яңа язуны бу ике туган үзләренең төрки халкы — болгарлар өчен иске рун язмасы нигезендә алмашка уйлап тапканнар. Бу ике туганның урыс телен белүләре кытай яки зулус телен белүләреннән бер дә артык булмаган. Изге Кирилл славян алфавитын — кириллицаны уйлап чыгармаган, ул глаголицаны уйлап тапкан. Ә болар икесе ике нәрсә. Төрки болгарлар һәм кыпчаклар борын заманнардан ук ул чорларда Ауропада гамәлдә булган грек һәм латин хәрефләреннән аермалы булган рун язуыннан (алфавитыннан) файдаланганнар. Үз язмаларына Ауропа кыяфәте бирергә теләп, әлеге ике туган рун язуын литерга (глаголицага) үзгәртеп куйганнар. Бары тик!

Глаголицага юнәлеш алганда грек хәрефләрен сукырларча күчерү генә җитми, төрки телнең үзенчәлекле авазларын аныклап чагылдарган хәрефләр дә кирәк була. Менә ни өчен глаголицада кырык хәреф барлыкка килә. Билгеле булганча, славян телендә ул кадәр авазлар юк. "Беренче славян укытучылары" дигән ялган каян килеп чыккан соң? Эш шунда: әлеге ике изге агайның

тормышлары хакында язганда кайчандыр ялгышлык киткәнме, әллә юри шулай бутаганнармы, билгеле түгел. Башта моңа әһәмият бирмәгәннәр, аннары күнеккәннәр, тарихчылар исә моны тарихи факт итеп язмага кертеп җибәргәннәр. Кирилл һәм Мефодий турындагы "Житие"нең чиркәү-славян тәрҗемәсендә: "Херсонесте Кирилл урыстан урысча белем алды", — диелгән. Бөтен ясалма тарих әнә шул җөмләдән башланган. Кириллның урыс булмаганлыгы шушы ялган җөмләдән үк аерым-ачык күренеп тора. Хәер, моны православие язмалары да инкяр итми. Ул заманда Херсонесын — Корсунь дип атап йөрткәннәренә дә гаҗәпләнмибез. Иң яманы шул: изге ике туган турындагы грекча язылган оригиналда Кириллның кайда укуы хакында бер җөмлә дә юк!

Тикшерә торгач, бу да ачыкланды. Ялган тарихны язган авторлар оригиналдагы "сурский" дигән сүзне урысчага күчергәндә, "русский" дигән сүз белән алыштырып барганнар икән. Менә шуннан соң барысы да баштүбән әйләнгән дә инде .

Бераз гына сулыш алыйк әле. Тарихчы һәм бу хәлләрне тикшерүче Мурад Анджи ике туганны Бөек Болгар башкаласы Фанагориядә туганнар, ди. Димәк, ошбу ике изге туган христиан динен кабул иткән, гәрчә изге Кирилл исемен үләр алдыннан гына алса да, ә бит аның атасы биргән исеме Константин була — димәк, алар төрки болгарлары булганнар. Ә "сурский" сүзе, галим Л. Мюллер раслаганча — "сирийский"ны, бер сүз белән "сурияле" сүзен аңлаткан. Ул чорларда Сурия китапларына укымышлы туганнарның мөрәҗәгать итүе гадәти хәл булган, әлбәттә.

"Ул чакта әле урыс китапларының исе дә булмаган, — дип әйтә галим Мурад Анджи. — Чөнки славяннарның язулары булмаган. Язулары булмагач, китаплары кайдан булсын инде?! Славяннар, дөресрәге, Ауропада атап йөртелгәнчә — венедлар, археологларның табылмаларына караганда, язма дигән нәрсәне белмәгәннәр. Хәер, Толпез күле янында табылган борынгы славян идолларында язулар табыла. Ләкин нинди язулар соң алар? Рун язулары! Төрекләрдә һәм борынгы германлыларда булган язуга охшаш язмалар. "Беренче славян укытучылары" турындагы легенда ни Византия документлары белән, ни башка чыганаклар белән расланмый. Югарыдагы "мәгърифәтчелек" әкиятен, гәрчә бу чорда русьларның алфавитлары вә язмалары булмавын белсә дә Н. М. Карамзин да (Карамзин чыгышы белән Кырым татары була — ягъни Кара мәэзин оныгы) Нестордан сүзгә-сүз күчергән. Кызганычка каршы, хәтта ошбу зыялы да Русиядә хөкем сөргән гадәткә хилафлык кыла алмаган".

Күренә ки, кадерле укучыларым, Рәсәй тарихына ялган өстенә ялган өстәлә генә торган. Мин әнә шул тарихны укып үстем. Һәм, әлбәттә, бик күпләребез. Рәсәй тарихына ышанганнар бардыр, ышанмаганнар бардыр. Ышанасыз икән — ихтыярыгыз. Әмма мин ышанмыйм. Шуңа тарихи әсәрләр язарга керештем дә. Инде ике туган мәгърифәтченең чын йөзен ачкан Мурад Анджиның Кирилл белән Мифодийга карата әйткән соңгы җөмләләрен китерәм. "Кирилл белән Мифодийны "беренче славян укытучылары" ясап, урыс елъязмачылары Кириллны (төгәлрәк итеп әйтсәк, Константин картны) христианлаштыру миссиясе белән Киевкә җибәргәннәр. Үз заманының бу бөек вәкиле һәм аларның кылган эшләре хакында урысларныкыннан башка борынгы чыганакларда да язылган, әмма Кириллның Киевкә баруы турында ул язмаларда бер кәлимә сүз дә юк. Мәгәр урыс елъязмачылары моңа әһәмият биреп тормаганнар". Ягъни ялган ары таба да дәвам иткән.

"Кубрат хан" романын язган чорда миңа берничә тапкыр Ленинградка барырга туры килде. Бер баргач, тарихчы Лев Николаевич Гумилевны очраттым. Ул миңа эрмитажга керергә һәм запасникларда сакланган Кубрат хан хәзинәсен карарга киңәш итте. Ленинград язучылар союзыннан юллама алып, Лев Николаевич фатихасы белән эрмитажга киттем. Анда ул чакта директор булып, күптән түгел безгә олуг ханыбыз Кубратның хәзиналәрен күрсәтеп киткән Б. Б. Пиатровскийның атасы утыра иде. Тарихчы Гумилев фатихасы белән килдем дигәч, ул миңа гид бирде һәм мин моңа кадәр татар күзенә күрсәтелмәгән Кубрат хан хәзиналәрен төшеп карадым. Әнә шул хәзиналәрне күргәч, безнең бабаларыбызның мәгърифәтле булуларына тәмам инандым. Хәзиналәрне күреп-карап чыккач, мәрхүм галим

үзенең "Көнчыгыш мәдәниятеннән истәлекләр" дигән хезмәтен бүләк итте. Һәм әйтте: "Славяннар турында язган да булыр идем, язар язма истәлекләр тапмадым, — диде. Һәм тагын өстәде: "Кубрат хан хәзинәләрен славян вожагы хәзинәләре итеп күрергә телиләр, шуңлыктан берәүгә дә күрсәтә алмыйбыз. Әмма хәзинәнең славян вожагыныкы булуга бер генә дәлил дә юк". 1985 елда бу галимнең "Фән" нәшриятында басылып чыккан китабын мин дикъкат белән укып чыктым. Һәм инандым, ошбу олуг галим бөтен гомерен Көнчыгыш халыкларның мәдәни үсешен тикшерүгә һәм алар вәзгыятен ачыклауга сарыф иткән икән. Безнең бабаларыбыз хакында ул болай ди: "Кавем-кабиләләр туктаусыз күчеп йөрү сәбәпле — Һинд-Аурупа диалектларын йөртүче халыклар Көнчыгыш Урта Азия аша Аурупага үтеп кергәннәр, ә Көнчыгыш төрек, монгол, енисей, фин-угыр сүзләре Һинд-Аурупа диалектларын йөртүче халыкларга үтеп кергән... Ә соңрак Көнчыгыш-Иран диалектларын йөртүчеләр скиф-һун-сарматлар аша Аурупага үтеп керәләр".

Ләкин биредә хөрмәткә ия галим Аурупаның гадәти тарихчылары теориясенә иярә. Халыкларны "күчереп" йөртә. Скиф-һун, сарматларны "күчмә" халык дип күрә. Кавем-кабиләләр "туктаусыз күчеп йөрү сәбәпле", ди. Тик бит бар халык та күчеп йөрмәгән. Хак, күчмә скифләр дә, һуннар да, болгарлар да булган. Әмма алар белгән җирләреннән ерак китмәгәннәр. Һәр җирнең, һәр елга буеның, һәр төбәкнең иясе-хуҗасы булган. Шулай булгач, нигә соң әле алар каядыр баш алып күчеп китәргә тиешләр. Әйтик, таныш булмаган ят җирләргә?! Булмаган ул! Безгә мәгълүм халык бар — этрусклар. Римләннәргә күрше халык. Ә аларны төрки телдә сөйләшкәннәр дип гоман итәләр (чөнки руни белән этруск язмасын кушып, бүгенге латин графикасын төзиләр). Шуның өчен булса кирәк, латин хәрефләренең авазлары безнең татар теленә ятып тора. Аннары заманында Мәхмүд солтан римләннәр тәре явы артыннан тәре явы йөри башлагач, Рим императорына хат яза. Ул хатта мондый юллар бар: "Нигә сез үзегезгә кайчандыр кардәш булган халыкларга яу артыннан яу йөрисез?"

Ләкин инде бу чорда тәре яулары ниндидер кардәш милләтләр белән исәпләшеп тормый, чөнки диннең милләте юктыр.

Ни генә әйтсәк тә хакыйкать хакыйкать булып калачак. Б.Б.Пиатровский хаклы — халыклар аралашып, бер-берсенә тел-лөгатьләрен "өләшеп" йөргәннәр. Әмма теге йә бу сүзне алганда да һәр тел үзенең нигез ташын саклап калган, гәрчә үз казанында гына кайнамаса да.

Әйтик, "Русь изначальная" китабының соңгы сүзендә язучы галим В. Иванов: "Французларның арме — армия сүзе төркиләрнең "урма", "урмас" сүзенә тартым, ди. Ә "урмас" көч-куәтне аңлата, дип хәтта татар сүзенә аңлатма бирергә тырыша. Шул ук вакытта бу сүз төркиләрнең "өер" сүзенә дә бик якын, ди. "Берегү" сүзен бригада сүзенә тартып китерә. "Солдат" сүзе исә "сун" — "һун" — ат менгән һун сүзеннән кергән, ди.

Олжас Сөләйманов үзенең "Аз-И-Я китабында "бирак" — союз сүзенә нигез булган, дип яза. Брак сүзе дә шуннан, ди. Дунай буе болгарларында бу сүз бүген дә "пирак" рәвешендә әйтелә, ягъни берегү мәгънәсен аңлата.

М. З. Зәкиев (Татар теленең барлыкка килүе. — К., 1977) хезмәтендә: "Күп кенә галимнәр беренче төркиләрне сөннәр чорына да, сөннәрнең таралу чорына да туры китереп карыйлар. Бу карашка таянганда, чыннан да Урта Азиядән башка урыннарда, мәсәлән, Идел-Урал, Кече Азиядә, Төньяк Кавказда, Кара дингездән төньяктагы җирләргә кадәр төрки телдә сөйләшүче кабиләләр бөтенләй булмаган, сөннәрнең бу җирләргә күчеп килүләре төркиләрнең беренче дулкыны булган дип танырга туры килә. Ләкин төрки сөйләшүче кавем-кабиләләр монда элек-электән яшәмәгән булса, бу төбәкләрдә күп таралган скиф-сарматларны сөннәр (һуннар) гына чагыштырмача тиз төркиләштерә алырлар идеме икән?" — дигән фикер әйтә.

Хак фикер! М. З. Зәкиев скиф-сарматларны бер халык итеп күрә. Ә бит бу халык, галим үзе әйтмешли, чанлап та "гомум төрки" телдә сөйләшкән. Моны археологик материаллар да раслый. Аннары янә бернәрсәне онытмасак иде — кабилә дигән сүз инде күптән искерде. Тарихчыларга аны күптән чүплеккә чыгарып ташларга вакыт. Бигрәк тә скиф-һуннарга карата бу сүз ятышмый һәм яттыр. Чөнки борынгы сөннәрдәге һәм һуннардагы кебек төрки каһанлыгында

да һәммәсе дә гомуми хәрби-демократик союзга буйсынган. Ә хәрби-демократик союзга төрле диалектларда сөйләшсәләр дә — бер телдә сөйләшкән халыклар гына керә алган. Хәрби-демократик союзга кергән төркиләр башка телдә сөйләшкән халыклар белән бары тик дипломатик мөнәсәбәттә генә булганнар, анда да каһанлык аша гына.

Безгә шунысы да билгеле, тарих та моны исбат итә —безнең һун һәм болгар бабаларыбыз Рим һәм Византия империяләре белән тыгыз дипломатик элемтәдә торганнар. "Болгарларның бер кавеме булган утригурлар Кече Азия грек дәүләте белән сәүдә иткән, сәяси элемтәдә торган" (Г. Таһирҗанов).

Бу хәл, һичшиксез, прогрессив күренеш булган. Ләкин безнең бабаларыбыз бер греклар белән генә элемтәдә торганнар дию белән бер дә килешеп бетәсе килми. Безнең бабаларыбыз иң әүвәл үзләренең кардәш кавемнәре булган Көнчыгыш төркиләре белән береккән рәвештә тыгыз элемтәдә булганнар. Бу инде рухи үсешнең асыл билгеләреннән берседер. Күрше халыклар белән булган бәйләнешләр, аралашулар йогынтысында тереклек итү, әлбәттә, Урал-Кама буйларында көн күргән бабаларыбыз дәверендә дә дәвам иткән. Әйтик, Болгар Башкаласында грек, әрмән, рус халыклары яшәгән һәм аларның урам-базарларның булуы мәгълүм, анда зурмы-кечкенәме яһүд, мари, удмурт, мукшы-эрҗә, мордва халыкларының базарлары да булгандыр дигән фикер бар.

Кала-сала төзү, корал ясау, ат дирбияләре житештерү буенча да Идел буе болгарлары көнчыгыш ауропада үтә һәвәс халык булган. Тарихчылар билгеләп үткәнчә, 1230 елда кенәз Святослав бабасы салган иске чиркәүне җимертеп, аның урынына болгар осталарыннан таш чиркәү салдыра. Мисал итеп Успен соборы бинасын күрсәтергә була. Корал һәм ат дирбияләре ясау буенча болгарларга тиң булмый. Бер көнчыгыш тарихчысы: "Болгарлар сугышчан халык, урысларны үзләренең туплары белән генә куркытып торалар", — дип яза. Бу хәл Сәлим хан чорында була. Ә Сәлим хан рәсми рәвештә Болгар тәхетендә 1164 елларда утырган.

Кыскасы, болгарларның рухи мәдәнияте дә, аның бер өлешен тәшкил иткән әдәбияты да үз кысасында гына үсмәгән, күрше һәм диндәш халыклар вә илләр йогынтысында да булган. "Бабаларыбызның мәдәнияте чынлап та югары булган", — дип яза галим тарихчы Габдрахман Таһирҗанов үзенең "Тарихтан — әдәбиятка" дигән хезмәтендә (Казан, 1979 ).

Биләр шәһәрендә Болгар ханы хафизы Якуб Ногман "Тарихы Болгар" китабын яза. Бу хакта мөхтәрәм галимебез Шиһабетдин Мәрҗани дә искәреп үтә. Әмма ул китап мангул яулары чорында юкка чыккан булса кирәк, чөнки әлегә кадәр аның табылганы юк. Бәлкем ул китапның күчермәсен Татищев кебек урыс миссионерлары юк иткәннәрдер, чөнки ошбу гадел булмаган тарихчы мөселманнардан: "Мин сезнең тарихыгызны бастырып чыгарам", — дип ялганлап, кулына кергән һәр китап өчен алтын белән түләп, бик күп Болгар мәгърифәтчеләренең китапларын җыя һәм үзенә кирәк мәгълүматларны алып, яндыра бара.

Ниһаять, Идел буе болгар халкының югары мәдәниятле булуын раслый торган бөек чыганак — Кол Гали поэмасы "Кыйссаи Йосыф" безнең кулда. Бу әсәрне бөтен төрки дөньясы, бигрәк тә Идел-Кама-Җаек буйларында һәм төбәкләрендә яшәгән халыклар укыган булса кирәк. Ошбу зур бәяләмә алган әсәр галимнәр раславынча, шагыйрь Кол Гали тарафыннан XIII гасыр башларында, ягъни ил-дәүләтебезгә мангуллар килгәнче иҗат ителә.

Әгәр дә мәгәр Рәсәй галимнәре вә тарихчылары кулында шуңа охшаш әсәр табылса, алар бу хакта бөтен дөньяга шәрран салган булырлар иде, ә без татарларга бу поэманы совет чорында хәтта басарга да рөхсәт итмәделәр: ул гынамы, гарәп шрифты белән язылган китапларны җыеп, ул китапларны өйләрендә тоткан кешеләрне гаепләп, җыелган китапларны совет биналарын җылыту өчен котельныйларга яктылар. Бу хәлгә патша самодержавиесе дә барып җитмәгән иде.

Безнең Болгар дәүләтебез чынлап та зур ил-хөкүмәт булган. Шул чордагы урыс елъязмачылары бабаларыбызның башкаласы Болгарны тикмәгә генә Бөек Кала дип атамаганнардыр. Бу кала Көнчыгыш Ауропада, чынлап та, бердәнбер кала булган — зурлыгы, сәүдә юллары челтәрләренең күплеге һәм халык саны

белән дә. Хәтта мангуллар яулагач та биредә акча сугудан туктамыйлар. Ә соңра Батый хан, яубаш буларак яудан әйләнеп кайткач, нәкъ менә Болгар каласын башкаласы итмәк була. Әйтсәм әйтим инде, мангуллар баскынчылар буларак ничекләр генә кәпрәймәсеннәр, Болгарга килә-килүгә үк бабаларыбызның телен генә түгел, диннәрен дә кабул итәргә мәҗбүр булганнар һәм күп тә үтми үзләре дә болгар-кыпчак арасында эреп беткәннәр. Иллә "татар" дигән исемнәрен тагып калдырганнар. Хәер, монда да шаккатасы юк, чөнки галимебез Шиһабетдин Мәрҗани раславынча, мангул яугирләренең 80 проценты төркиләр була. Димәк, татар сүзе янә безнең борынгы көнчыгыш тарафларында яшәгән бабаларыбызныкы икән ләбаса! Шуның өчен, туганкайларым, татар исемен йөртүгә бер дә уфтанасы юк, паспортларыбызга "болгар" дип яздыруның да һич тә хаҗәте юктыр, чөнки "татар" сүзе шул ук төрки бабаларыбызныкы. Бу исем белән безгә гарьләнергә түгел, бәлки горурланырга кирәк — шул исем белән безне бөтен дөнья халкы белә, галимнәр һәм тарихчылар тарафыннан да бу исем бик күптән таныла килә һәм билгеле атама булып кала бирә. Без — татарлар — кайбер урыс язучылары әсәрләрендә сурәтләнгән кебек куркыныч халык түгел. Кунакчыл, хезмәт сөючән безнең халык. Ә бит Болгар чорында һәм бигрәк тә Алтын Урда дәверендә һәр урыс кешесе татар кызына өйләнү белән чиктән тыш горурланган һәм мактанган. Хәер, ул хәзер дә шулай ләбаса. Тик кызларыбыз бу милләт вәкиле алдында түбәнсенмәсеннәр, горур һәм гыйффәтле булып калсыннар иде. Балаларына исем куштыру — чукыну — чит динне кабул итү мәсьәләсендә дә, ата-аналары тоткан дингә тугры калып, теге якны да, бу якны да рәнҗетмичә һәм өстен санамыйча үз вәзгыятьләренә һәм вөҗданнарына тугры калсыннар иде. Ахыр чиктә, адәм баласына Ана белән күрше Аллаһыдан, диләр бит. Димәк, без татарлар да урысларга Аллаһыдан, урысларга да без — татарлар — Аллаһыдан насыйп ителгәнбез булып чыга. Үз халкыңның гына мәнфәгатен кайгыртып, күршең теләкләренә сукыр калып, күз йомып, хәтта аны кимсетеп, рәнҗетеп яшәсәң, ахыр чиктә, синең халкың да Аллаһы каһәренә тап булуы бар ич! Без татарлар, менә мең еллар була инде, урыслар белән күрше- шабра яшибез, шул исәптән урыс язучылары белән дә. Тик кайбер күршеләренә сукыр калган шовинист язучылар татарларны һаман бабалары тарафыннан яуланган, буйсындырылган, җирләре колония ителгән дип кабул итәләр. Шушы фикер сөрешеннән арына алмый инде XXI гасырга аяк басарга торалар. Ләкин заманалар нык кына үзгәрде ләбаса. Бүген, кичекмәстән, Русиягә федерациягә керәсе милләтләр мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Ашык-пошык, чиле-пешле табадан төшкән конституциядән арынырга һәм бар булган проблемаларны да гадел рәвештә ике як белән дә бертигез килешеп хәл итү зарур. Килешүдән ике як та канәгать калсын. Башкача эшләү янә каршылыкларга китерәчәк. Шунда, бары тик шунда гына Русиядә яшәүче барча халыкларга да бер-берсенә ихлас күңелдән ышану килер, чөнки безгә XXI гасырда да күрше-шабра булып яшисе ич әле!?

М. Зәкиев үзенең "Төрки-татар этногенезы" хезмәтендә бу хакта күзгә бәреп әйтә: "Татарларны татар-монгол яулары белән тинләп, **Рәсәй тарихчылары** аларны (ассызык минеке. — М. Х.) төрле яклап начар итеп күрсәтү татар балаларында "мин татар түгел", "минем татар буласым килми" дигән психологик халәт барлыкка китерде. Шәһәрләрдәге, Татарстаннан тыш регионнардагы татарларның шактые үзенең татар икәнен яшерә башлады, балаларын да рус, үзбәк, казакъ яисә әзәрбәйҗан дип яздыру гадәте барлыкка килде. Үзенең татар икәнен әйтергә кыенсыну Татарстаннан читтә яшәгән татарларда бигрәк тә көчәйде. Шуның аркасында татарның сан ягыннан үсеше шактый акырынайды. **Урысларның бу сәясәте татар-урыс халкы арасындагы дуслыкка балта белән чапкан беренче зыяны иде".** (Ассызык минеке. — М. Х.)

Ә җир шарында тереклек итүче бер генә халык та теге йә бу планетага күчеп китәргә җыенмый, күчеп китәргә җыенган хәлдә дә бу хәл тиз генә булмас кебек. Инде Аллаһы тарафыннна татар һәм рус язучыларына күрше-шабра булып яшәргә язган икән һәм безгә Аллаһы теләге белән бер ил-дәүләттә көн күрергә дучар ителгәнбез икән — сез инде, Русия язучылары, күршеләрегезнең телен, динен, гореф-гадәтен генә түгел, аларның ана телендә барган мәктәпләрен дә, урта һәм югары уку йортларын да сакларга, түрә-хакимнәрегездән саклатырга

тырышыгыз. Киресе булган хәлдә Русия таралыр һәм сез инде аны беркайчан да җыя алмассыз. Чөнки дөньядагы бер генә империяне дә кире җыя алмадылар, вакыты җитү белән ил түрәләре вә хакимнәре нәкъ менә язучы-зыялылары коткысы белән империяне үзләре үк эчке каршылыклар аша җимерделәр һәм ары таба аякланып китә алмастай иттеләр.

440 елларда яшәгән бөек күрәзәче Мишель Нострадамус 1999 — 2002 елларда кешелектә кан коюның өченче туфан калкуы булачак дип фаразлый, ә 2005 һәм 2035 елларда Алтын чор башланачак, дип гоман итә. Бигрәк тә 2002 елны үтә яман һәм хәтәр хәлләр елы дип фаразлый бөек күрәзәче: "...күктән утлы сөңгеләр явачак, ут өермәсе өч төн буена (димәк, хәтта кояш та күренмәячәк. — М. Х.) дәвам итәчәк. Күктән төшкән утлар белән бөтен калалар диярлек яндырылачак".

Күрәзә фаразлаган 2002 елга кул сузарлык кына ара калды. Күктән төшәсе утлар Русияне дә читләтеп үтмәс, чөнки атом-төш коралының иң күбесе, иң яманы Русиядә. Бөек күрәзәче раславынча һәм фаразлавынча, Җир шарына бары тик 2005 — 2035 елларда гына тынычлык киләчәк һәм Алтын чор урнашачак. Шул елларда гына: "Иң гадел закон туачак һәм тынычлык киләчәк. Тынычлык килер, берләшү һәм үзгәрешләр булыр", — ди күрәзәче Алтын чорны күз угында тотып.

Мин бу бөек күрәзәченең сүзләренә игътибар да итмәгән булыр идем. Ләкин ул Русиядә буласы революцияне дә, хәтта СССР империясенең бетәсен — елы, ае, көне белән диярлек тәгаенләп әйтә.

Күрәзәчене берьякка куеп, Русиядә чынлап та уңай якка үзгәрешләр башланды, дип әйтергә була булуын... Тик Русия зыялылары һаман бер җырны җырлыйлар — "бердәм һәм бүленмәс..." дип авыз суын корыталар. Күптән түгел Русия Себердә яулаучы Ермак баһадирга багышланган кино күрсәтте. Киноны экранга чыгарыр алдыннан бер хөрмәткә ия артист: "Баһадир Ермак Себергә ирек даулап барган", — дип ычкындырды. Нинди гаделсезлек! Кем туган илдән куган Ермак юлбасарны? Кем аңа Себер халкының канын коярга фатиха биргән?.. Шул ук Рәсәй патшасы түгелме?.. Ирек даулаучылар түгел, илбасарлар ич алар!

Күренә ки, Рәсәйдә тарихны бозып күрсәтү, язу һаман мең еллар элек башлангандагы кебек дәвам итә. Һәм Рәсәй хакимияте, һәм урыс зыялылары кайчан да булса яуланган халыклардан гафу үтенер, бабалары кылган гөнаһлары өчен тәүбә итәрләр дип өмет итәсе юк. Әмма барыбер заманалар үзгәрде ич, кешелек 2000 нче елга аяк басарга тора. Әйе, бербөтен Рәсәй шушы килеш озак тора алырмы, өстәлдән төшкән кыйммәтле ваза кебек челпәрәмә килеп ватылмасмы?.. Хәер, Рәсәйдәге милли сәясәт шул килеш калса, Тормыш агышы һәм Вакыт аны үзе таркатачак һәм аны нәкъ менә Рәсәйдәге эчке көчләр таркатачак. Рәсәйгә, федерацияне ныгыту һәм камилләштерү өчен, милләтара мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк һәм кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Тик бу четерекле мәсьәләне Рәсәй һаман да хәл итәргә ашыкмый. Ә бит Рәсәй-Русиягә күрәзәче Мишель Нострадамус әйткән "Алтын чорга" дөнья империяләре арасында беренче булып аяк басарга да һәм, шул җайдан, бөтен дөнья империяләренә үрнәк булырга да мөмкинлекләр бар. Моның өчен аңа кул астындагы халыкларга тулы ирек бирергә генә кирәк — килешеп яшәргә кирәк. Моны кылырга әле соң түгел. Соң түгел!

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Сәгыйть Хафизов**

# ӘДӘБИЯТТА БАЗАР ЗАМАНЫ

## Язучы "базарын" кемнәр төшерә?

Революция һәм әдәбият... Болар бер-берсеннән ерак төшенчәләр кебек, чөнки әсәрне революционер түгел, ә сүз, тойгылар мәҗнүне булып калган шагыйрь, язучы иҗат итә. Ул исә каләменә үзе хуҗа...

Әмма революция илгә яңа хаким, яңа хуҗалар китерә. Соңгы елларда да шулай булды. Боларның зәвыгы, уй-фикер дөньясы ничек? Рухи дөньяга карата нинди исәп-хисап тотып яшәргә җыеналар алар? Һәм шул ноктада әдәбият, язучы язмышы сәясәткә бәйле булып кала. Базарчылар — "яңа руслар"ның — турысын әйтергә кирәк, сәнгать, әдәбият белән әшнәлеге зурдан түгел. Һәм "яңа татарлар"ның да үз милли әдәбиятларына, иҗатчыларына булган мөнәсәбәтен узган ел журналда "Проза турында сөйләшү" ачык күрсәтте.

"Казан утлары"ның 1997 ел 1 санынннан бу әңгәмәне башлаган язучы Гариф Ахуновтан алып журналның азаккы санында чыгыш ясаган Зәки Зәйнуллинга кадәр дистәләрчә каләм әһелләре язучы хезмәтенең тәмам бәясе төшүгә, сан һәм кадер булмауга зарландылар. Татарстанда хәтта күрше җөмһүриятләргә, әйтик, Башкортстанга караганда да каләм хакы күп мәртәбәгә түбәнрәк икән. Әмма шул мәгълүматларга контраст төсендә Татарстан президенты Минтимер Шәймиевнең Яңа ел бәйрәме алдыннан үзәк "Маяк" радиостанциясе аша милләттәшләренә юллаган котлавы яңгырый. Җөмһүриятнең икътисадта төрле-төрле уңышлары бар, гектарыннан 37 шәр центнер ашлык та җыеп алганнар. Кама аркылы унбер чакрымлап озынлыкта гигант күпер сугып яталар икән. Ә Казан үзәгендә харәбәләрне ватып меннәрчә гаиләләрне яхшы фатирлар белән тәэмин иткәннәр...

Ходай бирсен, алга табан да сөенечле хәбәрләре белән шатландырып яшәсен Татарстан! Тик милләтнең йөзек кашы булган язучыларын ник зарлы иткән, үпкәләткән соң мөстәкыйль җөмһүрият?

Хакимнәрнең "бертуктаусыз чит илләргә йөрергә, катлы-катлы коттеджлар салырга акчалары бар икән, әдәбиятка да тапсыннар..." — диде сөйләшүдә катнашкан әдипләр.

Сизелә ки, Татарстанда бүген язучылар базары, рейтингы зурдан түгел. Хәтта түбән! Йә Алла, дөнья чынлап куласа икән! Ә бит әле кичә генә язучы, шагыйрь исемен йөрткән һәр зат пәйгамбәр кебек иде. Ул халык депутаты мандатын алып, мөнбәрләргә күтәрелде. Теге яки бу сәяси вакыйга чыкса, радио, гәзит-журнал аша башлап сүз әйтүче кеше дә язучы булды. Клуб-залларда гына түгел, сарай, кабинетларда да әдип кешене беләләр, олы-олы түрәләр дә сүзенә колак салалар иде. Ахыр чиктә куркалар да иде язучыдан, көче үлчәнмәгән дошман сыман булды ул. Шулай булмаса, дистәләгән, йөзләгән куштаннарны аңа каршы өсләтмәсләр иде. Һәм менә сиңа мә... Ельцин тәңкәләренеке кебек базар, бәя төшү...

Төп сәбәп — илгә яна хужалар килү һәм яна тәртипләр инүдә билгеле. "Туган партиябез, аталарча кайгыырткан хөкүмәтебез" юк инде хәзер. Һәрберебез үксез, язмыш иркенә ташланган ятимнәр хәлендә... Ә чынлап уйлаганда бередә ике сәбәпне калкытып кую дөрес булыр. Белүебезчә, сәясәтче юлы депутатлыктан башлана. Олы түрәләр дә хакимияткә таба иң беренче адымнарын шуннан ясыйлар бит. Сәвит заманында депутатлыкка башлыча "телчән" хезмәт ударниклары, зыялылар үтте, югары постларга да күбрәк "фәнни коммунизм" теориясен биш бармагы кебек белгән адәмнәр үрләде. Шулай, фирка теләге белән: идеология, сәнгать, әдәбият хобби гына түгел, бәлки башлык, түрәнең идеяви зирәклеген, хәтта булдыклылыгын раслаучы күрсәткечкә әйләнде. Хәтерләгез әле, СССРда республика һәм өлкәләрнең уңышларын сәнгать, әдәбият казанышлары белән дә җөпләлиләр иде бит. Авыр туфрагы җинел булсын, мәрхүмкәйнең: СССР — тоталитар, унитар, әмма гуманитар, хәтта лирик җәмгыять булган шул!

Яңа, базар заманында исә сәясәтнең ширма, кәмит уены гына түгел, бәлки кәсеп, бизнес икәненә төшенгәч, депутатлыкка прагматик-кырыс ирләр, ирдәүкә хатыннар ыргылды. Югары хакимияттә дә хәзер "лириклар" түгел, күбрәк "физиклар" утыра. Аларның күбесе өчен сәнгать һәм әдәбият — эч пошканны басу, күп дигәндә күңел ачу өлкәсе. Өскорманың иҗтимагый роле, тәрбияви-эстетик әһәмияте базарчылар тарафыннан тиешенчә бәяләнми. Югыйсә, китап, газет-журнал кебек изге әйберләр бизнес чарасына әйләнмәс, ә дингез артының җыен чернуха-порнухасы, буасын ерган ташкын сыман, безнең илгә ыргылмас иде.

Бу — әдип базары төшүенең беренче сәбәбе. Икенчесе —язучы халкының үзенә кайтып кала. Әйе, безнең язучылар үз базарларын үзләре төшерделәр. Горбачев "пешеп җитмәгән" демократизмы белән үзе утырган тәхетне үзе ватуы өстенә, ил күңеленә яман рух — мазохизм вәсвәсәсе кертте. "Ай үсәсен көн үсеп" демократ булып киткән аерым язучылар, дәрвишләр сыман үз-үзләрен кыйнап, үткәндәге әдәбиятны, каләмдәшләрен ничек кенә хурламадылар! Миргазиян Юныс сәвит заманындагы язучылардан партия ялчылары ясады, аларны мәетләр итеп күрде. Аяз Гыйләҗев шагыйрьләр шагыйре саналган Хәсән Туфанны таптап узды, Габдрахман Әпсәләмов кебек мәшһүр язучыларның да бер тиенлек кадерен калдырмады. Болардан соң да безнең байтак исемле һәм исемсез каләм ияләребез үзләренең рухи ахирәтләрен яманлау, мыскыллау белән шөгыльләнделәр.

Гомумән, пычрак итекләр киеп милли рухиятне таптау язучылар, журналистлар төркеменә мода булып кергән бугай. Әнә, "Идел" дә (1996 ел, 9 сан) интервью биргән Марсель Галигә карагыз. Татар әдәби иҗатына "калдык-постык талант кына килә. Укырдай әйбер тапмыйм. Җанга, аңга фикер бирә торган әйберләрне урыстан, ә бәлки Аурупа прозасыннан алганмындыр" — ди ул. Һәм милли әдәбиятны кимсетүне классика җирлегенә күчереп, Г. Ибраһимов, М. Гафури, К. Тинчурин иҗатларына бәя биреп уза: "Бу язучыларда мин эстетик зәвык булуга шикләнәм"... Шуннан Марсель Гали "татар акыллы булса", әлеге язучыларның аерым әсәрләрен чүплеккә ташларга тиеш, — дигән күрсәтмәсен биреп үтә.

Нәрсә әйтергә бу "акыллы татарга"? Язсын башта Марсель әлеге талантлардан да уздырып! "Кара йөзләр", "Татар хатыны ниләр күрми" кебек повестьлардан да көчлерәк, заманчарак әсәрләр иҗат итсен, эстетик зәвыгын күрсәтсен! Ә аннары ташланасын Вәлиләр Галидан башка да ташларлар.

Исмагыйль Шәрәфи мөхәррирлегендә чыккан "Татарстан яшьләре" ( 1997 ел, 7 сан) газитендә бик дустанә рәвештә яшь укучыга болай мөрәҗәгать итәләр: "Сез радиодан "Гөлҗамал"ны яки "Карурман"ны тыңлап утырганчы, магнитофон кабызып урыс яки чит ил эстрадасы җырларын тыңлауны юньлерәк эшкә саныйсыз. Шулай, һәр буынның үз зәвыгы"... Аңламадым, "урыс җырчыларының дүрт аяклы дусларын яратулары" хакындагы төксе мәгълүматка нигә кирәк икән мондый нечкә лирик чигенеш? Ләкин шунсы хак, татар радиосын, милли музыкасын шартлатып өзүче яшь буын зәвыгыннан бигрәк, "ашаган табакларына төкерүче" газитчеләр зәвыгы чекрәеп тора монда.

Кагыйдә буларак, татар әдәбияты, татар мәдәнияте хакында йөгәнсез, шөкәтсез сүзләрне "чит"тә йөргән яисә "чит"тәгеләргә мөкиббән киткән зыялыларыбыз ычкындыра. "Диңгез артында"гыларга, мәскәүләргә карап, поза-кыяфәт алырга телиләр безнекеләр. Хәер, заманчалык, алдынгылык безнең бик

күп әтрәгәләмнәрдә борын-борыннан аякны Мәскәүгә карап көйләүдә дип фараз итедә бугай. Ләкин мондый "инкубация"ле сәясәтнең татарга зыяннан башка нәрсә китергәне юк. Хәер, мондый татар үзенекенә генә түгел, халык утырган ботакка да балта чаба. Гомумән, демократлар тәнкыйте милли язучыга, милли әдәбиятка нинди абруй өсти? Иҗатка, идея-эстетик фикергә күпме файда китерә? Бу турыда житди уйланасы бар.

Әмма шунсы ачык: ташка басылган сүз ул кино, телевидение сурәте кебек, халыкта шаблон тудыра. Эчке халәтне, фикерләүне, зәвыкны билгели, теге яки бу хәл-күренешкә карата бәя тудыруда катнаша. Матбугат сүзенең психологиясен истә тотсаң, туксанынчы еллардагы мондый инкарь шаукымы һич тә милли әдәбият файдасына түгел!

Татар язучыларының Башкортстандагы каләмдәшләренә зуррак хөрмәт булуына гажәпләнү белдерүен беләбез. Ә сәбәбе белән кызыксыналармы икән? Әлбәттә, хөкүмәтнең, беренче чиратта президент Мортаза Рәхимовның, милли язучыларны иҗатка ныграк җәлеп итәргә тырышуы бу. Ә бәлки авыр, катлаулы әдип хезмәтен гаделрәк бәяләү нәтиҗәседер? Ләкин бу игелекле теләк юктан бар булмаган бит. Монда әдәби мохит үзе дә әдәбият абруен, язучы шәхесен күтәрә белә.

Башкортстанда яшәгән татар буларак, бик еш хыялымда чагыштыру, каршы куюлар үткәрәм. Каләмдәшләрен урынлы-урынсыз типкәләп мәсхәрә итүчеләр дә, кумир-остазлардан көлүчеләр дә, манкорт-нигилистлар да, нишләптер, юк монда. Ә бит башкортлар да шул ук "демократия", "плюрализм" заманында яшиләр. Әмма милләтпәрвәрлек көчлерәк аларда. Бергәләп укмашып милли мәнфәгатьләр өчен көрәшүне уртак максат иткәннәр алар. Бәлки шуңадыр, халык каршында да, рәсми даирәләр алдында да әдип затын зурлауга ирештеләр. Матбугат шаулый, кичәләр уза, хөкүмәт указлары пәйда була... Башкортстанда әдәбият культы, язучы культы бар. Нәкъ шуннан иҗатчыларны кадерләү, бәяләү башлана.

Чагыштырырга икән — чагыштырырга. Яңа ел ыгы-зыгылары белән мондагы гәзит-журнал редакцияләрендә дә игелекле шөгыль — лауреатлар билгеләү башлана. Аннары шул мактаулы исемгә лаек булганнарның зурлап сурәтләрен басып чыгаралар, матур итеп котлыйлар. Минем шәхсән "Казан утлары", "Идел" кебек журналларда да "иң яхшы хикәяче", "иң яхшы тәнкыйтьче" яисә "иң яхшы шагыйрь" исеменә лаек булган язучыларны күрәсем килә. Гәзитләрдәге талантлы журналистларны, публицистларны беләсем килә минем. Эш нидә соң? Гадәт юкмы... Соң булмаса, башла! Акча юкмы... Соң булмаса, тап!

Димәк, безнең язучы кавеменә дә җәмәгатьчелек, хакимият каршында бәя, абруй күтәрим дисә, хурлашу түгел, ә иң элек үз кадерен үзе кадерләргә өйрәнергә кирәк икән. Һөнәр бәясен күтәрү кирәк! Хәер, талант — хәерче түгел. Әдиплек — кәсеп түгел. Бүрек салып түрәләр каршында тезләнү дә, бугаз киереп акырулар да язучы кешене бизәми. Яхшы бәяне, абруйны язучы сокландыргыч әсәр иҗат итеп кенә казана, яулый ала.

Шулай итеп, һәр болгавыр заман кебек, хәзер дә өскорма әһәмияте, атап әйткәндә, әдәбиятның иҗтимагый роле, тормыштагы урыны, яшәү принциплары кебек зур мәсьәләләр турында уйлану хаҗәте көчәйгән икән. Ханнар каршында да, патшалар алдында да, диктотор-тиран күңелендә дә кирәклеге, зурлыгы, көчлелеге хакында аз гына да шик-шөбһә кузгатмаган әдип, әдәбият базар хакимнәре, президентлар заманында да, иншалла, каушап-югалып калмас. Чөнки сәяси система, җәмгыять үзенең сәнгатен, әдәбиятын тудырырлык һәм үстерерлек хәлгә килмәсә, таркала, җимерелә, юкка чыга. Бу — апокалипсис. Ул рухи бушлыктан, әхлак җуелудан, әдәп бетүдән башлана.

Әдәбият хакында хакимнәр, президентлар кайгыртсын!

## Прометей һәм Мөхәммәт

Иҗтимагый тетрәнүләр һәм әдәбият үзгәрешләре турында фикерләгәндә иң беренче чиратта кеше концепциясен күздә тотарга кирәк. Тарихта этап булып гәүдәләнүче һәр сәяси-мәдәни дәвер үз каршында ачык төсмерле кеше сурәтен булдырган. Төрле яссылыктагы фикерләүләр дәрәҗәсен,

әхлакый-этик кагыйдәләрне үзендә сендергән иҗтимагый кеше сурәте җәмгыять аңында гына эз салмаган, бәлки сәнгать һәм әдәбиятта да заманның идея-эстетик фикерләрен билгеләүдә хәлиткеч роль уйнаган. Мондый симбиоз борынгы әдәбиятыбызда, аеруча суфыйчылык лирикасында, мәгърифәтче язучылар иҗатында яисә совет чоры әсәрләрендә аеруча күзгә ачык бәрелә. Һәм никадәр генә болгавыр, чуалчык булып күренмәсен, базар икътисады дип аталган безнең заман да иҗтимагый аңга үзе табынган кеше сурәтен сендерергә тырыша.

Михаил Горбачев "Үз-үзеннән башла" лозунгысы белән бервакытта иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә яңа принциплар игълан итте. Болар:

— Хәбардарлык (гласность).
— Хөр фикерләү (плюрализм).
— Идеологик, сыйнфый чикләүләрдән арыну.
— Дәүләт монополизмыннан котылу.

Кеше яңа геополитик шартларда командачыл-административ, тоталитар яшәү тәртипләреннән котыла барып, азатлык, мөстәкыйльлек алырга, шәхси активлыкны үстерергә, кәсепчелек, иҗтиһадка кыйбла тотарга тиеш иде.

Бу катлаулы әверелештә, сәяси узаманнар гоманынча, гомумкешелек кыйммәтләрен, демократик казанышларны файдалану мөмкинлеге яшәде.

Кеше концепциясендәге тамырдан борылышны кыскача, образлы аңлатыйк дисәк, Максим Горькийга таяныйк. Ленин, большевиклар белән аймылышлы, хәтта әчелешле яшәгән дәверендә язган гаҗәеп акыллы "Несвоевременые мысли" китабының 157 битендә әдип әйткән: Гаделлек һәм Матурлыкка омтылыш юлында Кешелек ике бөек символ тудырды. Христос —шәфкатьлелек һәм кешелеклелекнең үлемсез идеясе вә янә Прометей — Аллалар дошманы һәм язмышка каршы күтәрелгән тәүге гыйсьянчы.

Тик искәртик, М. Горький ике символның бер бөек тойгыга кушылу көне килерен, барлык адәмнәрдә рух, җан кардәшлеге башланасын әйткән. Ай-һай, булырмы бу? Көн белән төнне яисә яшәү белән үлемне бергә кушу, коры хыял хәлендә яшәгән сыман, Христос белән Прометейны килештерү дә бары иллюзия түгелме? Тормышның капма-каршы башлангычлары рәвешендә, үзара көрәшеп, хәяткә туктаусыз ут өстәүчеләр итеп кузаллау дөресрәк аларны.

Марксистик-ленинчыл тәгълимат, эстетика нигезенә куелган совет әдәбияты идеал итеп Прометейны алды дисәк, ялгышабыз. Әле Октябрь зилзиләсе уйнаган бер чорда үзебезнең Такташ "Җир уллары трагедиясе"н язып, Аллага каршы фетнә күтәргән канлы гыйсьянчыларны данлады. Гали Хуҗиев "Россия" поэмасында Прометей белән Ленинны рухи тугандаш каһарманнар итеп күрсәтә:

Прометей башлап
Кешеләргә
Ут китергән — тормыш чаткысын;
Ә Ленин ул алып килде безгә
Ирек, бәхет, тормыш яктысын.

Болардан соңрак Мостай Кәримнең башкорт, татар сәхнәләрендә уйналган "Ташлама утны, Прометей!" трагедиясен карасак та, күрәш, кан теләүче гыйсьянчы геройларның идеал булып калуын күрер идек. Әлбәттә, бездә генә түгел, тирә-күршеләр әдәбиятында да шулай булды ул. Нәкъ менә шуңа күрә 1980 елда чыккан "История русской советской литературы" авторлары язып үтәләр: "Социалистик сәнгатьнең иң абруйлы геройларыннан берсе булып Прометей күтәрелде". Җөмләдән, Галина Серебряякованың "Прометей" трилогиясендә төп каһарман булып гыйсьянчылар атасы Карл Маркс үзе тасвирланган икән.

Әдәбиятта, һәркемгә утлы факел яисә комач әләм күтәреп, адәмнәр алдыннан йөрергә язмаган. Киресенчә, олы йөрәк, зур язмыш ияләре — аз, бик аз бу, гөнаһлы җирдә. Шуңа күрә бик җәелеп, таралып сөйләргә дә кирәкмидер. Прометейлар токымы, татлы кыйсса, легендалар сыман ук, аздыр, сирәктер. Әдәбият галиме әйтмешли, типиклыкка вәгъдә итмидер?

Әмма шулаймы икән?

Алайса совет әдәбиятының гадилек, типиклык җәһәтеннән дә күнелгә шик салмаслык берәр персонажын алыйк. Азат Ганиевның "Сүзсез җыр"

повестендагы татар кызы Хәят — нәкъ шундыйларның берсе. "Элегрәк кешеләр үлгәннән соң оҗмахта, һич югы тәмугта гына булса да яшәргә өмет иткәннәр. Ә мин өмет итмим. Чөнки моның кем тарафыннандыр уйлап чыгарылган матур әкият булуын ап-ачык аңлыйм. Котылгысыз үләсеңне белә торып ничек яшәргә кирәк?!" — дип дөньясының бер читен ача ул.

Әйе, Хәят кечкенә, гади кеше. Ләкин холкы, асылы белән Прометейдан кимме? Шул ук Аллага, кануннарга каршы фетнәлек, горурлык уты чәчү, фаҗигага тартылыш... Тагын үзенә кешеләрдән аерым сукмак салу өмете берләштерә татар кызы белән борынгы миф героен. Әйе, үткән чорның әдәби героена — зурмы ул, кечкенәме, — барыбер Прометей рухыннан кыйпылчык чәчрәгән иде. Тик аларның бер төрлесе җан аулады, әмер бирде, үзе Аллага әйләнде, ә икенчеләре аскетлар, коллар психологиясенә дучар ителеп, ялган мәнфәгатьләргә хезмәт итте.

Инде совет әдәбияты белән бергә Прометей рухы белән сугарылган геройлар мәйданнан китә. Алмашка икенче бөек символ — кешелеклек һәм шәфкатьлелек идеяләрен гәүдәләндергән пәйгамбәр Христос рухы калка. Хәер, славян, роман-герман халыклары тормышы өчен шулай бу, ә безнең кавем, мөселман өммәтеннән булган милләтләр олуг Мөхәммәткә һәм аның изге китабы Коръәнгә баш ора. Болар хәзер дини мәзһәб өчен генә түгел, ә рәсми, мәдәни-әдәби катламнар өчен дә олуг кәгъбә.

Әйтик, татарның җыр сәнгате, моң үзенчәлекләре турында уйланып Илшат Вәлиуллин, Коръән тәэсире, көче турында болай яза: "Татарлар өчен Коръән — олуг киңәшләр вә фәлсәфә китабы гына түгел, ул иң беренче чиратта үзенә Алла белән булган моңлы бәйләнешне индергән... Коръәннең моңлы мәкамендә бөтен асылыңны ахыргача ачып салып зарлану, ялвару, өметләнү, юану мөмкинлекләре ачыла". ("Идел", 1995, 10 сан).

Туксанынчы еллар башында ук Хатип Миңнегулов һәм Шәйхи Садретдинов тугызынчы класс өчен әдәбият дәреслегенә Мөхәммәт пәйгамбәр һәм "Коръән" турында тарихи фикерләрне яңартып матур-матур сүзләр яздылар. "Алар турыдан-туры укылудан тыш, татар әдәбиятының формалашуына һәм үсешенә дә зур йогынты ясаганнар", дип боларның әдәби кыйммәтен билгеләделәр.

Галимнәр хаклы: чынлап та, изге китаптан безнең кайсы гына әдибебезгә иман, нур иңмәгән! "Коръән" Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Риза Фәхретдинов, Тукай, Мәҗит Гафури, Гаяз Исхакый кебек төрки һәм татар әдәбиятларындагы олы әдипләрнең дөньяга карашларын билгеләгән, эстетик фикерләүләрен формалаштырган, зәвыкләренә эз салган. Ләкин "Коръән" һәм әдипләребез хакында бер яссылыктан гына чыгып фикерләргә дә ярамый. Алланың берлеген, зурлыгын тану белән беррәттән, аерым каләм ияләре "Коръән"не үзләренең тар мәнфәгатьләренә яраклаштырып шәрехләүче руханиларга каршы чыкканнар. Алар шәригать исеменнән торып шәхес ирекен чикләүче, халыкны томалаучы кадими, фанатик муллаларны нәфрәтләнеп фаш итүдән дә курыкмаганнар. Хәтта Гафури кебекләре ил өстендә золым-зөлмәт, иблис котырынуы башлангач, "Юктырсың ла, Алла, әгәр булсаң, риза булмас идең бу эшкә..." дип башлап, Хак Тәгаләгә бөек рәнҗешләрен җибәрергә дә җөрьәт иткәннәр.

Халкында иман зур булгач, әдәбиятында да дини идеяләрнең көчле һәм төрле-төрле булуы бик табигый. Тик аларны, совет заманындагы сыман, алласызлык, дәһрилек кысаларында караудан гына сакланырга кирәк. Язучы — гуманлы зат, ул һич тә имансыз, Алласыз була алмый. Һәм кара еллар аркылы әдәбиятыбызга янә "Коръән", иман нуры сирпелә. Шагыйрь әйтмешли, "Догаларның күңелемнән юк әле югалганы"... Чынлап та, хәзерге әдәбият догалы була бара: "Әнкәмнең догалары", "Догалы еллар", "Йөгез, бер дога"... Сүз, әлбәттә, исем-атамаларда гына түгел, ә герой-каһарманнарда, аларның эчке дөньяларына, холык фигыльләренә изге символ — пәйгамбәр рухы үтеп керүдә.

Әдәбияттагы моңдый уңай борылышны Г. Ахуновның "Идел кызы" романы, Р. Ханнановның Казан сәхнәсендә уңышлы уйналган "Алтын беләзек" пьесасы башлаган иде. Һәм шул юнәлештә иҗатны кыю дәвам итеп, гаҗәп отышлы тарихи хәятта Җ. Рәхимов ил, халык тормышына карата актив позициядә торган көчле, олпат рухани тибын ("Батырша") тудырды.

Бу романда безнең өчен гадәти булмаган каһарманны яңа идея-эстетик

эчтәлек белән сугаручы мөһим ике факт бар. Берсе Батыршаның халыкларны азатлыкка өндәп иҗат иткән атаклы тәхризнәмә-өндәмәсе язмышы. Һәм икенчесе Батыршаның тоткын булып Шлиссельбург крепостендә утырган чакта христиан рухание Степан Левацкий белән бәхәсе. Һәр ике вакыйгада без гыйсьянчы мулланы исламның кайнар "патриоты", дин һәм әхлак сакчысы, хәтта корал күтәреп сугышучы кыяфәтендә күрәбез. Килешегез, болар безгә ят тасвир, хәтта авторны кирәкмәгән мөселманлыкта, хәтта панисламизмда гаепләүчеләр дә табылыр. Ләкин язучы чор рухына турылыклы. Ут һәм кылыч белән куркытып төркиләрне чукындыручы урыс попларына каршы халык һәм ислам руханилары шулай кыю күтәрелгән. Милли тормышның сыналган үз асылын, гореф-гадәтләрен, рухын, телне саклап, чит-ят мәгыйшәт тәэсирен тибәрүдә дин алыштыргысыз роль уйный. Бу хакыйкатьне Батыршалар бөтен тулылыгы белән аңлаганнар. Һәм чын ислам асылын, тарихка кереп калган мулла образын тасвирлап, Ж. Рәхимов тарихи дөреслекне заман каршында кыю ачып салды.

Моннан соңгы колачлы проза әсәрләрендә гәүдәләнгән руханилар, аерым алганда, Ф. Латыйфиның Колшәрифе ("Хыянәт"), Ф. Яхинның Мөхәммәт пәйгамбәре ("Олуг пәйгамбәр"), С. Поварисовның Гыйрфан мулласы ("Яшьлек иртәсе") уңай, сокландыгыч геройлар булу белән беррәттән, укучыда чын, милли нигездәге идея-эстетик кичерешләр һәм уйланулар тудыруга сәләтле.

Әмма ерак, бик ерак торабыз әле без изге китаптан, чын иманнан...

Әйдәгез, мөселман өммәтендәгеләр буларак, бернечә милли басмага күз салыйк. "Татарстан яшьләре" гәзитенең (1997 ел, 4 декабрь саны) беренче битендә "Презервативларыгыз шартламасын!" атамасы чекрәеп тора. Һәм шуның янәшәсендә "нинди матур презерватив!" дип сокланган егет-җилән сурәте бар. Гәзитнең хәбәрчеләре Лилия Сөнгатуллина белән Нәзилә Сафиуллина яшьләр дискотекасыннан репортаж ясап, түбәндәгеләрне тасвирлыйлар: "Дискотекага кергән һәр кешегә кучтәнәч итеп презерватив... Һәм куркынычсыз секс турында белешмә китапчыгы таратып тордылар. Кызып-кызып биегәндә дә өскә презервативлар явып торды... Бу кичәдә караңгы почмакларда яратышып торучы "зәңгәрләр"не һәм "аллар"ны да күрергә була иде..."

Гәзитнең танылган журналисты Әлфия Самат шул ук декабрь саннарының берсендә, түрәләр белән оятсыз дөнья хакында сөйләшеп, кызык-кызык хәлләр яза: "Казанга килгәч, кунакханәгә урнашуга кызларның бәясен сорый башлыйсың. Алып киләләр. Былтыр бер төн өчен 150 мең сорыйлар иде..." Ә хәзер зөфәф кичәсе үткәргән түрәдән "1 төн өчен 3 млн. сум акчаны" каералар икән.

Ә инде шул ук декабрь аенда Алсу Мансурова тарафыннан "Интим" кибетеннән бирелгән репортаж укучының тәмам эротик тәкатен алырга мөмкин: ..."Менә мондые бар, ир-ат әгъзасы, зур, куркыныч, тамырларына хәтле бар. Чын кебек, кыскасы, шуңа эшләтә торган батареялар тыгасың да, күңел ачасың.."

Хәбәрче кыз күз күрмәгән, колак ишетмәгән нәмәрсәкәйләрне барлап, шуларны ничек эшләтү хакында күрсәтмәләр генә бирми, үзенчә фәлсәфә дә сата: "Интим сүзен икәүдән-икәү дип аңлау бүген бигүк дөрес түгелдер. Чөнки кайберәүләр өчен интим өчәүдән-өчәү, бишәүдән-бишәү, унаудан-унау булырга мөмкин. Андый секс та тормышыбызга үтеп керә, димәк".

Ләкин "интим" сүзен кешеләр башкача да аңлыйлар бит. Мәсәлән, "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" (1977) аны "үтә шәхси, яшерен" дип шәрехли. Әйе, кеше хайваннан шул ягы белән аерыла, аның иҗтимагый дөньясы белән бергә шәхси, яшерен дөньясы бар. Безнең бабай-әбиләр аны үзләренчә, "оят" төшенчәсе белән бәйләгәннәр. Һәм ул безнең мөселман халкы өчен үтә хәрәм нәрсә саналган. Ягъни, оятлы эшне үзең дә кылма, кешенең эчке дөньясына да тыкшынма!

Әшәке, әдәпсез сүздән, түбән, фахиш гамәлләрдән тыелу мөселман өммәтендәгеләр өчен канун булган. Ояла белүне бигрәк тә хатын-кызда зурлаганнар, "Оялчан хатын — шәһәр бәясе, оялчан ир — тәкә бәясе", дигәннәр.

Әмма без, хәзергеләр, борынгыларның изге нәсыйхәтеннән көләбез. Шул ук секс турында кайгырткан "Татарстан яшьләре" битләрендә һәм бүгенге әдәбиятның аерым әсәрләрендә шундый карашлар таратыла: янәсе, мескен татар хатыны эш камыты киеп, изелеп, басылып секс дигән татлы нәрсәне тоймый калган. Тәнендә ут-ялкын уйнап торып, булыр-булмас ир белән яшәгән, хисен

тыеп, чирләшкәгә әйләнгән... Әнә Наташа, Марусяларга карагыз, ир-ат тамырын тотып рәхәт алуны алар тышка чыгып йомыш-йомышлау кебек үк бер нәрсә итеп карыйлар...

Исемнәрен әйтмим, әмма безнең байтак "демократ" авторларга кызларыбызны, хатыннарны Европа стилендә сексуаль, ягъни хисле, тойгылы һәм женси азат, ирекле итеп күрергә теләү хас. Дон-жуаннар өчен бу начар хәл түгел. Ләкин кочыш-үбештән генә торамы дөнья? Имин гаилә корып, инсафлы балалар үстерәсе, тормыш итәсе дә бар бит әле... Фәйләсуфләр исә нәкъ шул яссылыкта хатын-кыз тотышыннан зур иҗтимагый мәгънәләр чыгаралар. Бабайлар исә "көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын", дигәннәр. Асылда исә һәркайсында бер хакыйкать ята. Женси хисләргә бирелеп, теләсә кемгә түшәк булырга ризалашкан хатын ирне дә, баланы да, гаиләне дә бәхетле итә алмый.

Кыскасы, әйтәсе килгән шул: секс-иблис рухи тормышыбызга уннан да, сулдан да янаган бер мәлдә әдипләребезгә, аңа капка ачу һәм уйнашчылык итү түгел, ә кешеләр күңелен шул иблистан арындыру, сафландыру гамәлен кылу шәригатьчәрәк булыр иде. Инде шәригатьне санга сукмасаң, аның кануннарына төкереп бирсәң, ахыр чиктә кеше язмышы, бала иминлеге хакында уйларга кирәк. Сабыйны бит ләкләк китерми... Нәрсәгә ишарәлим, аңлыйсыздыр? Ястык нәтиҗәләре турында да төрлесен уйларга бурычлыбыз. Әмма секс темасында каләм чарлаган авторлар нишләптер бу турыда дәшмиләр. Ә менә әлеге "баллы" темада бик тыйнак, хәтта оялчан булган Башкортстан гәзитләре аның әче җимешләре хакында бик еш язалар. Әйтик, мондагы "Кызыл таң" гәзите түбәндәгене яза:

"Кайчандыр мөэмин-мөселман өчен хурлык булып саналган гамәл — зинадан бала табу күренеше ят түгел хәзер безнең халыкларга. Ел да республикада 7 меңнән артык никахсыз бала туа һәм бу күрсәткеч арта бара. 1993 елда шундый балалар саны гомум күрсәткечнең 13,1 процентын тәшкил итсә, 1994 — тә 14,3, быелтыр 16,6 процентка җитте" ("Кызыл таң", II февраль, 1998 ел)

Татарстанда да хәлләр шәптән түгелдер. Арабызга үлем чәчеп СПИД килеп керүен дә искә алсак, гаилә өлкәсендә, интим мөнәсәбәтләрдә Мөхәммәт пәйгамбәрдән дә акыллырак юл табып булмаслыгына ышанырбыз шаять?

Мин Фоат Садриевнең "Таң җиле" романындагы Нуриасма, Хәдичә, Бәрия кебек хатын-кыз образларында интим дөньяга карата акыллы, кырыс һәм шәригатьчә мөнәсәбәт күрдем. Ләкин кызлар гыйффәтен, хатыннар тугрылыгын, аналар шәфкатен безнең әдәбиятта яңа сәнгать югарылыгына күтәреп ачасы да ачасы әле.

"Коръән"нән, иманнан ераклашуыбыз интим дөнья, оят гамәлләр тирәсендә генә күзгә ташланмый, әлбәттә. Сирәк-мирәк мөселман гадәтләрен искә төшерсәк, йолаларын үтәсәк тә, мәгыйшәтебез, рух һәм фикерләүләребез белән хак динебездән еракбыз шул без. Әле яңарак Зөлфәт Хәкимнең "Гөнаһ" романын укып чыктым. "Гөнаһ" — дини сүз, Алла каршында ярамаган гамәл кылып гаепле, языклы булуны аңлатканча, тәкъва тойгылы геройлар белән очрашырбыз, дип әсәргә өметләр зурдан иде. Ләкин роман минем үземә көткәнне бирмәде. Ничек диим икән? Безнең байтак урыслашкан татарлар үзләренең кемлекләрен белдерер урында "Алла бирся".. дигән гыйбарә ычкындыра башладылар. Гыйбарә, визит карточкасы сыман, кешенең милләтен, өммәтен ачып сала диләр бугай. З. Хәким романына да "Гөнаһ" атамасы шундый исәп беләнрәк чәпәлгән шикелле... Гөнаһ юк, гөнаһ турында сыкрану гына бар анда. Романның төп герое Фәиз, угрылык кылганда аның гаебе белән ахире Зәбир сазлыкка батып үлде, дип уйлый, сызлана, хәтта акылына көч килә... Автор үз героен да, укучысын да кичерешләр сазлыгына батырып байтак быкырдаткач, ниһаять серне ача: Зәбир исән, үлмәгән... Шулай итеп роман өн түгел, саташулы төш кенә булып чыкты.

Р. Мостафин, И. Нуруллин кебек усал тәнкыйтьчеләр заманы булса бу романны ике дә уйламыйча конъюнктур әсәр дип атарлар иде. Хәер, гәзит мәкаләсен хәтерләткән җөмләләр моны үзләре үк күрсәтеп торалар: "Илдә дә зур үзгәрешләр башланды. Михаил Горбачев җитәкчелегендә үзгәртеп кору дигән хәрәкәт кузгалды. Дөньяның асты-өскә килгәндәй булды...

Илдәге үзгәрешләр белән аның (Фәизнең — С.Х.) психикасы үзгәрүенең бер вакытта туры килүе кызык һәм куанычлы фал!"

Әйтергә мөмкин ки, Фәизнең чирләп терелүе — соңгы елларда барган гаугалы сәясәткә иллюстрация. Геройда бигрәк тә үзгәртеп кору атасының "үз-үзеңнән башла" лозунгысының чагылышы сизелә.

Теге яки бу сәяси идеягә иллюстрация ясау һәрчак язучыны кечәнүгә китерә. Әсәр каһарманнары бик еш фәлсәфәгә биреләләр, бәхәсләр коралар. "Кеше үтерүченең үтерергә хакы бар, — ди, мәсәлән, "Гөнаһ" романының персонажы психотерапевт Марат Шандаров — Дөресрәге, аның сайларга хакы бар: үтерергәме, юкмы?.. Әгәр вөҗдан үтерергә куша икән — кеше үтерә һәм беркемнең дә ул үтерүченең хөкем итәргә хакы юк..."

Гиппократ анты биргән кеше — табиб ничек мондый җәллад фикерләве дәрәҗәсенә төшкән — бу язучы намусында кала. Хәер, җәллад авызына салсаң да, куркыныч бу сүзләр. Китап өчен куркыныч! Вөҗданны хәзер искә-санга алучы бармы, булырмы, әмма "үтерергә ярый" дигәнең канга сендереп әллә никадәр исәр башлар адәм җанын кыярга әзер торырга мөмкиннәр. Зөлфәт Хәким "демократиясе" шулай кешене чебен урынына да күрмәс дәрәҗәгә житкән микәнни?.. Безнекеләр сугышта, гарасат эчендә дошман канын коюга да сак килгәннәр. "Мин гуманист", — дип атый Ф. Кәрим окопта язган бер шигырен. Лирик герой хис кешесе, ярата ул кошлар сайравын, дөньяны сөя һәм җирдә кеше каны агуга каршы... "Мин — гуманист", — дидем, үзем менә Бу кешенең гомерен бетердем..."

Солдат җан кыюны акларлык сәбәп эзли, ниһаять, таба:

> Юк, кеше гомерен бетермәдем,
> Сабыйларның яшен суыручы,
> Бәхет бакчаларын корытучы
> Иң әшәке кортны үтердем.

Тын, аяз күкле заманда кеше үтерүне акларлык нинди сәбәпләр бар? Рухи, әдәби чыганакларыбыз, Коръән-Кәрим "үтермә", "кеше үтерү — хәрәм", дип канун куйганда каян килә язучыга дәһрилек?

"Поселокка психология, философия буенча кызыклы китаплар алып килеп сата башладылар. Күбесе чит телләрдән тәрҗемә: Ницше, Шопенгауэр, Кант, Шпинглер, Фрейд, Кафкалар һ.б. бик күп төрле, аның (Фәизнең — С.Х.) күңелен тиз арада яулаган авторларның хезмәтләре сусаган җан иясенә бер йотым су сыман булды".

"Гөнаһ" авторы үзе белмәсә, әлбәттә, гаребнең бу мәшһүрләрен Фәиз дә белмәс иде. Боларны Зөлфәт Хәким, белү генә түгел, алар белән женләнә һәм әсәрендәге фәлсәфә дә шулардан килә дип фараз итәргә кирәк. Ярату-яратмау, кумирлар табу, ияру — зәвык эше. Әмма әйтергә кирәк, кешедәге кыргый инстинктларны, явыз башлангычларны котыртып үстереп, адәмнән иблис ясарга сәләтле Фрейд, Ницше, Шопенгауэрлар һич тә Мөхәммәт өммәтеннән булган затлар түгел. Киресенчә, пәйгамбәребезгә дошманнар — Алласызлар болар. Үз вакытында Гитлер һәм аның фанатик төркеме Ницше рухын үзләштереп, ярты Европаны канга батырды, үзебезгә күпме фаҗига китерде Кеше үтерүне аклаган фәйләсүфларга иярсәк, без Алласыз, денсез калу гына түгел, бәлки фашистларга әйләнүебез дә бар... Тәүбә, тәүбә!

Әйе, гөнаһ гамәл янәшәсендә тәүбә булырга тиеш. Тәлгат Галиуллинның "Тәүбә" романы да кадим, әмма нык шул канунга корылырга тиеш иде. Әгәр әсәр каһарманы яман эшеннән кайтып, ходайдан, кешеләрдән, вөҗданыннан ярлыкау сорамаса, аны "Тәүбә" дип атаудан ни мәгънә соң?

Романның төп герое Сәет Сакманов туксанынчы еллар прозасының әдәби ачышы буларак, шактый зур яңгыраш алды һәм үзенә карата тәнкыйтьне икегә бүлде. Берәүләр криминал җинаятьләр эчендә кайнаган мафиячел геройны каушап һәм нәфрәтләнеп каршыладылар, игенчеләр, киресенчә, аны заманның яңа кешесе, типиклыкка дәгъва иткән милли каһарман дип бәяләделәр. Тик Сәетне икегә бүлү аны яхшы һәм начарга аеру нәтиҗәсе түгел иде, бәхәс аңа карата симпатия һәм антипатия белдерүгә генә кайтып калды. Асылда миңа калса, һәркем килешә — болгавыр заманның чын герое бу. Иҗтиһад та, мәкер дә, кәсепчелек тә, ихласлык та, мәрхәмәт тә, явызлык та бергә укмашкан Сакмановта. Бу кешедән фәрештә дә, иблис тә ясарга мөмкин. Заманнан, мохиттән тора хикмәт. Хәрәм мал өчен

тарткалаш, астыртын көрәш заманы, кызганычка каршы, түбән башлангычларны көчәйтә ирдә. Һәм ул жинаять юлына баса, үтерешләр китә. Дошманнары кыйммәт түләтәләр Сакмановтан, ул өзелеп яраткан Зөлфиясен югалта...

Ниһаять, тәүбәгә килергә вакыт, жанны дәваларга вакыт!

Әсәр үзенең бөтен корылышы, фәлсәфи-әхлакый пафосы белән тәүбә мизгеленә котә иде. Тик тәүбә итү булмый, тәүбәгә бары ишарә генә ясала. Харис Әшрәфжанов тәнкыйтендә язылганча: "Юк шул, бер явызлык, үжәтлек, байлык туплау юлына баскан адәм баласы туктый алмый, идарәсен югалткан машина төсле, тау астына таба тәгәри дә тәгәри". ("Ватаным Татарстан", 5 декабрь, 1997 ел)

Сәет Сакманов турында романны да, күп серияле чит ил мелодрамалары кебек, дилогия, трилогия итеп үстерергә була. Тик мәгънәсе нидә бу криминал эпопеяның? Һәм тукран тәүбәсенең рухани дөньяда бәясе күпме?

Күренә ки, демократлар прозасында чын гөнаһ та, ихлас тәүбә дә юк әле. Мөхәммәт өммәтеннән булсалар да, халкыбыз кебек, әдипләребезгә дә, "Коръән" рухы, "иман нуры" житешми, изгеләрчә фикерләү юк. Һәм без әлегә рухыбыз белән метис халык. Нишлисең, колакта һәрдаим чиркәү чаңнары, ят догалар мәкаме торса, күз алдыннан зәңгәр эфир, таштагы сүзләр булып туктаусыз секс, эротик рәшәләр дулкыны чапса, ә хаятең алдау-йолдау, хыянәт һәм үтерешләр белән тулса, чын мөселман булып калу кыен шул. Ләкин безнең алда башка хак юл юк... Дәһрилек, кяферлек — тәмуг куркынычыннан бигрәк, әүвәл Кеше дигән бөек асылны жую, рухи һәм әхлакый таркалу ямьсезлеге ул.

## Иман иң элек рухи тормышыбыз өчен кирәк.

Әдәбиятның бер канаты — дин, икенчесе — миллият.

Әйе,әдәбиятның бер канатын дин тәшкил итсә, икенче канаты белән ул миллияткә таяна. Әмма миллият тә, дин кебек үк сүз сәнгатенең борынгыдан килгән асыл сыйфаты булса да, бүген гыйльми яктан иң зур "ак тап"ларның берсен тәшкил итә икән. Нинди генә күренешләрне тикшереп, нинди генә мәсьәләне яктыртмаганнар безнең филолог-галимнәр. Әмма миллилеккә кагылучы булмаган. Һич булмаса белешмә табыйм дип, А. Әхмәдуллин төзегән "Әдәбият белеме сүзлеге"н (1990) кулыма алдым. Әмма монда да миллилек хакында фикер очратып булмады. Китапханә киштәләрендә Мансур Хәсәновның "Интернационализмның жанлы традицияләре" (1980) исемле саллы китабы күзгә чалынгач, өмет кузгалды. Чөнки интернационализм хакында авыз ачкач, миллилек турында да сүз әйтү фарыз. Нигә дисәң, беренчесе икенчесеннән башка була алмый бит. Тик бу автордан да көткәнне алып булмады.

Хәзер, мөгаен, инде беркемдә дә шик калмагандыр. Коммунизм жиме белән алдап мәкерле рус шовинизмы үз империясендәге халыкларның миллиятен ауларга, рухи һәм мәдәни асылын юк итәргә жыенган булган. Ярый әле, мең шөкер, замана кырку үзгәреп куйды. Миллият янә Мөхәммәдьяр яисә Тукайлар заманындагы төсле, ижатның мөһим принцибы буларак, әсәрләрнең кыйммәтен билгеләүче төп сыйфатка әверелде. Ләкин хәзер "милли" эпитетын орден, медаль яисә партком грамоталары сыман уңга, сулга юмарт өләшсәк тә, аның асылына һаман ныклап төшенмибез бугай. Шәхсән мин "Имән чикләвеге" ("Шәһри Казан" 1990 ел) язмасында Аяз Гыйләжевның Тукайдан соң танылган милли әдипләрнең берсе итеп Мөдәррис Әгъләмовны атавын, ә Х. Туфан, М. Жәлил, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Г. Афзал кебек киң танылган каләм ияләрен читләтүен күреп аптырап калдым.

М. Әгъләмов кимсенмәсен — талантлы шагыйрь ул. Ләкин, турысын әйтергә кирәк, "Мөдәррис Әгъләмов — милли байракны авыр юлларда, караңгы елларда кулыннан төшермәгән шагыйребез. Ул ижатын тутыкмас корал итеп, татарларда милли аңны уята килә... Телебез, денебез сагында торучы... Ул татарны татар килеш саклап калырга тырышты" кебек төче мәдхияләрнең бу мәгълүм шагыйрьгә багышлануы сәеррәк. Сәяси зирәклек, диссидентларга якынлыгы белән яулыймы Әгъләмов мәшһүр демократ күңелен? Алайса ник аның янәшәсендә тоталитар режим, шовинизм белән көрәшеп халык күңеленә үрләгән Айдар

Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Әхмәтҗанов кебек язучыларыбыз да урын алмый?

Бәлки М. Әгъләмовка милли холык, гореф-гадәтне бирү, халык тормышының үткән мәсьәләләрен кыю ачу маһирлыгы хастыр? Әмма бу юлда да ул ялгызы гына түгел. Повесть, романнары белән халык күңелендә тамырланган Мөхәммәт Мәһдиевне кая куябыз? Яисә Зөлфәт бу юлда Мөдәрристән кимме?..

Гадәттә милләт әдибе дигәндә без халыкның төрле катламы тарафыннан да танылып, бүтән милләт вәкилләре дә кабул итәрлек дәрәҗәгә күтәрелгән олы, зур колачлы каләм иясен күздә тотабыз. Әмма А. Гыйләҗев язмасыннан ук шагыйрь даирәсенең нинди икәнлеге күренеп тора: "М. Әгъләмовны яшьтәшләре чит итмәделәр. Ул... әдәбият, сәнгать тирәсендә сакланып кала алган бер оя татарлар арасында ныклы урынын тапты".

Күренә ки, татар халкы, милләте мөнәсәбәтендә А. Гыйләҗевның берәүләрне күтәреп, икенчеләрне төшерүендә, хәтта хурлауда нинди дә булса ныклы иҗтимагый гыйльми нигез ятмый, ә авторның үз, шәхси зәвыгы төп сәбәпне үти. Әлбәттә, "Имән чикләвеге" язмасындагы татар язучыларына булган фикер-бәяләрне җитди кабул итәргә ярамый. Безнең карашыбызча, бигрәк тә тоталитар режим чорында, халык каршында танылган талантлы язучыларны "арбадан" төртеп төшерергә тырышулар зур хата. Әдәбиятта миллилек уртак табактагы шулпа өресе түгел, аны теләсә кемгә этә дә, шудыра да алмыйсың. Беренчедән, бу һичшиксез — халыкның холык-фигылен, йола-гадәтләрен, тарихын ышандырырлык итеп гәүдәләндерү. Икенчедән, заманның кайгы-хәсрәтен, шатлыгын, рухын халыкча нечкәләп сиземләү һәм сурәтләү. Өченчедән, тойгыларны аерым төркем белән генә бәйләмичә, милләтне тәшкил иткән барлык катламнарның уртак мәнфәгатьләрен чагылдыруга ирешү. Һәм, ниһаять, зур, тәэсирле талант көче, сәнгатьчә осталык белән иртәме-соңмы ил каршында танылу.

Аяз Гыйләҗев мәкаләсендә "Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов кебекләрнең кынысыннан корыч кылыч түгел, озын вә ялганга шомарган тел килеп чыга иде", — дип татар прозасы осталарына ничаклы авыр сүзләр юнәлтелмәсен, болар — безнең милли язучыларыбыз. "Имән чикләвеге" авторы "Туфанның төрмәгә ябылганчы һәм аннан соңгы иҗат үрнәкләре бер чакта да халкыбызның авыр язмышын ачуга хезмәт итмәделәр" — дигәненә карамастан, Туфан да, Моабит тоткыны Муса Җәлил дә татар халкының мәхәббәтен казанган шагыйрьләр, милләт әдипләре булып кала. Чөнки алардагы миллият асылын һәртөрле сәяси антипатияләр дә, иҗатта очрарга мөмкин булган аерым кимчелекләр җыелмасы да юкка чыгара алмый. Аяз Гыйләҗев һәм башка демократлар төркеме безнең әдәбиятка Солженицын, Синявский сыман диссидентлар өлге-шаблонын китереп такмасыннар. Татар язучылары үзләренең милли характерлары, мәгыйшәт үзенчәлекләре белән ил, замана уллары булып яшәп, тарихи иҗтимагый-психологик шартларга актив мөнәсәбәт тотып иҗат иттеләр. Һәм аларны бәяләүдә дә анык заман, шартлар, язучы активлыгы күздә тотылырга тиеш.

Әйтик, Габдрахман Әпсәләмов зур иҗатка аяк баскан сугыш беткән елларда сталинизмның хөр фикергә яңа һөҗүм дулкыны башлану белән бергә, татар халкы, аның мәдәният һәм әдәбиятына өстәмә каршылыклар тудырыла. Аеруча 1944 елгы "Татарстан партия оешмасында идеология эшләренең торышы"... дигән фирка карары әдипләрнең ис-акылын җуя. Кулуарларда Кырым татарларының хыянәтләре турында нәфрәтле сүзләр янәшәсендә мондагы татарлар арасында да сатлык җаннар күплеге хакында сөйләкләр йөри. Шуларның берсе Муса Җәлил, имеш... Гомумән, татар исеме үк күпләрнең саруын кайната, геналардагы, кандагы дошманлыкны кабарта...

Мондый чакта татарны ничек сурәтләргә мөмкин? Әлбәттә, батыр итеп, матур итеп һәм уртак Ватанга тугрылыклы итеп кенә... Г. Әпсәләмовның үз халкының соклангыч, хәтта героик уларын, кызларын сурәтләгән романнары бер-бер артлы дөнья күрә башлый: "Алтын йолдыз", "Газинур", "Сүнмәс утлар"ы, "Ак чәчәкләр"... Язучының таланты аларны милли әдәбият кысаларында гына калдырмый, рус мохитына, хәтта дөнья мәйданына алып чыга. Аның татары

меңнәрчә, миллионнарча күңелләрне дулкынландыра, милләткә карата уңай хис, зәвык уята.

Әле дә бүгенгедәй хәтерлим, төш алдыннан, мәктәпкә китәр чак җиткәч, Әпсәләмовның "Сүнмәс утлар" романын радиодан укыйлар. Әни мичтән алып аш сосып бирә, ләкин аш гаме юк. Дөньяны онытып радио тыңлыйм. Менә ничәнче көн инде рус хәяте, рус исемнәреннән башканы белмәгән Мәскәү радиосы Сөләймән абзый, Иштуган, Хәсән Мортазин һәм башка дистәләрчә татар кешеләрен атап, татар тормышы турында хикәят кыла. Барысы да ниндидер могҗиза төсле. СССР каласы Мәскәү татар язучысының әсәрен укытач, ул язучы пәйгамбәр төследер тоела. Аның өчен, әдәбиятыбыз өчен, татар өчен күңелдә туктаусыз горурлык елдырамы йөгерә...

Әпсәләмов әсәрләре шулай күпме милләттәштә татар өчен сөенеч уятмаган?! Ә бит бу язучы, үзләрен милләт әдибе итеп танытырга теләгән байтак каләм ияләреннән аермалы буларак, татар дип төчеләнми, халыкка куштанланмый, пәйгамбәр рәвешенә кереп, милләткә вәгазь дә укымый, юлкыйбла күрсәтергә дә алынмый. Аның милләткә булган мәхәббәте, зур ихтирамы, оста художникларга хас булганча, әсәр тукымасына, иҗат принципларына сеңдерелгән.

Игътибар итәсезме икән, безнең совет заманындагы әдипләребез, хәтта Октябрьдан соңгы Г. Ибраһимов, Ш. Камал, татарны икегә бүлеп сугыштырырга, канга, былчыракка батырырга яраттылар. Соңгысының "Ут" драмасында аскет большевик Рәүф идея коткысына бирелеп хәтта яраткан хатыны Галияне буып үтерә. Бу — инде сыйнфый күзлектән чыгып тасвирлау принцибына баш ию иде. Г. Әпсәләмов романнары исә башлыча уңай геройлар галереясын тәшкил итә. Киреләре бармак белән генә санарлык: Кәшиф, Сәлим, Янгура, Хәсән Мортазин... Тик сыйнфый дошманнар түгел болар, ә мәкер, золым, культ символлары. Гуманист язучы милләтне әтәчләр хәленә китереп сугыштыру, ямьсезләү, каралту түгел, ә аны гримлау белән мавыкты, татарны ул гамәлдәгедән дә матуррак, сөйкемлерәк итеп күрергә тырышты.

Аның Газинуры шундый, "Алтын Йолдыз"дагы Галим Урманов, Мөнирә, Ләлә, Хафиз, Һаҗәр, Наил шулай сурәтләнә. Язучы бизәге кунганга профессор Әбүзәр абзый Таһиров, "Ике башлы" Сөләйман абзый, Гөлшаһидә туташ та чамасыз сокландыгычлар. Бизәү генә түгел, әдип хәтта аларны пьедесталга бастырудан да курыкмый... Шул сыйфатны истә тотканда, Г. Әпсәләмов романнарын, хаклы рәвештә, "романтик романнар" дип атарга да мөмкин. Г.Бәшировның "Намус" М. Әмирнең "Саф күңел" романнары да әлеге төркемне тәшкил итә ала. "Романтик роман" дигәндә, әлбәттә, бизәкләрне куерту, сыйфатларны күпертүгә корылган Горький романтикасы түгел, ә Европа әдәбиятлары тарихына бәйле романтизм күздә тотыла. Бу мәсләктәге язучылар тормыш дөреслегенә иярү, аны сурәтләүдән бигрәк, үзләренең шәхси дөньяларында, хыялда туган хәятне тасвирлау белән мавыгалар. Чөнки күңелдәге нәзакатьле зәвык тышкы дөнья белән килешми, ярашмый, ниндидер үҗәтлеккә бирелеп үз галәмен тудыра. Г. Әпсәләмов һәм аның каләмдәшләренең әсәрләрендәге дөнья бары тик мөстәкыйль фикерле художниклар кора алган тылсымлы дөнья ул. Берәүләр хәзер бу дөньяны ялган, социализмны идеаллаштыру, фиркагә куштанлану галәмәтләре, дип бәяли. Әмма, безнеңчә "романтик романнар" — мәгълүм чор татар әдәбиятының олы казанышы. Бердән, мондый әсәрләр рационализм, схематиклык, калыплашудан интеккән социалистик реализм әдәбиятына яңа сулыш, форма китерсә, икенчедән, алар тоталитар режим астында йомылган кешене азатлык, көрәш, киләчәккә ышаныч, матурлык идеяләре белән рухландыруга сәләтле иделәр. Димәк ки, бу төр иҗат та халыкны, милләтне, рухи коллыктан коткаруда мәгълүм роль уйнаган.

А. Гыйләҗевның "Ялганга шомарган тел", дип Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов стилен хурлап бәяләве үтә берьяклы. Рус язучысы, шулай ук, демократ Юрий Нагибин әйтә: "Язучыдан да зуррак ялганчы юк"... Шагыйрәнә ялганны инкарь итсәк, без хәтта Г. Тукайны да, борынгы шагыйрь Кол Галине дә хурлап, гомумән, әдәбиятның зур бер кыйсьмен чүплеккә ташларга мәҗбүр булыр идек. Әдәбият, хәтта кырыс реализм да күзгедәгечә тормыш дөреслеген-

нән генә гыйбарәт түгел, бәлки анда сәнгатьчә дәреслек тә хаклы урын ала. Һәм сүз сәнгате — заман өчен никадәр актуаль булмасын — коммунистларны каргау, социализмны хурлау яисә базарны яклаудан гына тормый. Шулай ук, диссидентлык идеяләре белән генә дә чикләнә алмый ул. Милли әдәбият милләтнең үзе кебек үк күп тойгылы, ишле аһәнле, төрле зәвыклы. Үзендәге бар талантны, бөтен казанышларны бергә туплаганда гына ота һәм үсә ала милли әдәбият. Шулай итеп, "Имән чикләвеге" авторының "Мөдәррисне чынлап торып үз арабызга алмасак — йә, кем булабыз инде без?!" дигән соравына "Ә ни өчен Мөдәррисне генә алырга тиешбез? Һади Такташ та, Хәсән Туфан да, Г. Әпсәләмов һәм Г. Бәширов та, Җәлил дә һәм татар булган һәр талант, гуманист язучы да милләткә бик кыйммәт, барысын да алабыз!" — дип әйтәсе килә.

Мәртәбәле әдип белән шактый бәхәсләштек бугай. Әмма миллият мәсьәләләрендә каләм чарлаучылар, Аллага шөкер, хәзер байтак инде. Шагыйрьләребезнең берсе Гәрәй Рәхим: "Татар ашыкмый гүргә — ул оптимист гомергә!" дисә дә, бүгенге матбагада төшенке сүзләрне татар хакында бик еш язалар: "Безнең халкыбыз бик борынгы", "Үзара өзгәләшүләр һәм таркаулык "татарлык"ка әйләнеп бара... "Татар берсен берсе ашый"... Ә "Идел" журналында (1995, 10 сан) "Татар декаденсы" исемле мәкалә белән катнашкан яшь галим Илшат Хәлиуллин татарга хәтта инкыйраз — бетү юрый. Хәер, ул язганнарга карасак, без беткәнбез дә инде: "Чөнки безнең рухи байлыкларыбыз да, унай якларыбыз да, шул ук вакытта тышкы дөньядагы ярлылыгыбыз, кимчелекләребез дә — татар декадентлыгының биниһая зур кайтавазы... Декадентлык билгеләре татарда тулып ята".

Шундый язмаларны укыйм да, уйлап куям: Гаяз бабай үзенең "Ике йөз елдан соң инкыйраз"ы белән безнең халыкны нык шүрләткән икән... Хәтерлисез булыр, егерменче гасыр ишегең ачар-ачмас язган әсәрендә ул Казан татарларының соңгы варисы Җәгъфәрнең Болгар хәрабәләре арасында япаялгыз калып җан тәслим кылуын хикәяли. Һәм язучы безгә кинаяләп әйтә, әгәр зыялы һәм узаманнар милләтне әйдәрлек гайрәттән, акылдан мәхрүм булып, үзара ызгыш-талашка бирелсә, халыкны исә хорафат һәм милли йомылу, гамьсезлек басса, татарны инкыйраз көтә...

Һәм менә инкыйраз хакында, йөз ел үтмәс борын ук сөйли, хафалана да башлаганнар икән. Хәлиуллин, әйткәнемчә, татар тормышында кай тарафка борылмасын, декаденс — бетәшү күрә. Татар моңы — бетәшү, мәчет манаралары тәбәнәк — бетәшү, асыл ирләр, хатын-кызлар җитми — бетәшү...

Хәтта ул милли әдәбиятның аерым әсәрләрен санап, иҗатта да бетәшү галәмәтләре күрә. Анынча, "Әйтелмәгән васыять" (Ә. Еники), "Торналар төшкән җирдә" (М. Мәһдиев), "Болын" (Ф.Бәйрәмова) — болар татар декаденсына караган әсәрләр. Дөнья яртылаш кире кагыла... Яхшырак, сафрак дөньяларга ымсыну идеясе дә ачык күренә".

Нишлисең, күрергә теләгән кеше күрә инде. Кояшта да тап күрүчеләр бар. Ходай һәркемгә күз, зиһен, уй биргән. Хәер, бу уй Хәлиуллинның үзенеке түгел. "Кешеләрнең, бетәшүен, ахыр чиктә инкыйразга йөз тотуларын һәм бу күренешнең аерым билгеләрен алман фәлсәфәчесе Фридрих Ницше "декаденс" дип атый"... Һаман шул Алласыз, кансыз Ницше! Безнең Зөлфәт Хәкимне әсир иткән Ницше тозагына Хәлиуллин да килеп капкан бит! Тәфсилләү кирәкми. Шунсын гына әйтим, үзенең бер журнал мәкаләсендә Рафаэль Сибат язган: "Татар өчен Азия медиумы белән Европа прагматлыгыннан торган симбиоз әдәби концепция һәм фәлсәфә кирәк!!" Башта бу чамасыз "гыйлемлек"тән кычкырып көлдем. Аңыша торгач, уйлап куйдым, Бушның тавык ботларын кимереп, Һинд дөгесе ашап, цейлон әфлисуны белән сыйлану гына җитмәгән иде, инде милли әдәбиятыбызда Шәрык белән Гареб кушылмасыннан туган гибрид геройлар үрчетергә җыенабызмы? Һәм менә Хәлиуллин тәнкыйтьче Сибат хыялланган симбиоз фәлсәфәне укмаштырып та куйган. Ул бер ягы белән дәһри Ницшегә ияреп "гөнаһлы" фәлсәфә кора, ә икенче ягы белән мөэмин мөселман кыяфәте алып, догага чума...

Мине шәхсән Хәлиуллин фәлсәфәсе, бетәшү идеясе куркытмый. Куркытканы башка: без — зыялылар иҗатка сәләтне җуеп цивилизацияләр ташлаган

концепцияләр, фәлсәфәләр чүплегендә казына башлыйбыз, ялтыравык идеяләрдән ниндидер симбиозлар корабыз һәм милли фикерләү казанышы ясап боларны калын-калын журналларыбызда дөньяга чыгарабыз икән — бетәшү хакында берниндн дә фәлсәфә кирәкми, без — беткән халык. Мондый гамәлләр белән матбаганы, әдәбият һәм сәнгатьне пычратуыбыз гына житми, үзебездәге төшенке, черек, инкыйраз идеяләреннән оештырган бомбалар ташлап, милләтнең рухын җимерәбез. Мондый халыкка чит милләтчеләр һөҗүме, шовинистлар, миссионерлар сәясәте дә кирәкми. Милләт өметсезлек һәм агониягә бирелеп үзен-үзе өзгәли. Аны инкыйраз, бетәшү идеяләре тарката.

"Безнең милләт үләнме, әллә йоклаганмы?" Габдулла Тукайның бу соравы җитмеш еллап коммунистик гафләткә булган халык өчен тагын да урынлырак икән шул. Татар милләте һаман да сау һәм сәламәт икән, ул иң элек эчке коткыдан аралану чарасын күрер. Һәм бу — иң элек зыялылар, каләм әһелләре өчен кирәк!

Безнең милләт чынлап та бик борынгы, картмы ул? Вакытлар бар иде, халык үзенең чыбык очы тарих төпкеленә тирәнрәк үткән саен, ныграк, көчлерәк, акыллырак сизәргә тиеш сыман иде. Ләкин таш булып таш җимерелә, кыя уела... Этнос та мәңгелек түгел. Табигатьтәге һәр нәрсә кебек, аның да формалашу, үсү, чәчәк ату һәм таркалу фасыллары бар. Л. Гумилевның пассионарлык теориясе буенча сыйфат сикерешләре 150 шәр ел саен ясала килә. Милли гамьнәр дә исәп-хисапка бәйле икән, картаерга ашыкмау хәерлерәк. Һәм чынлап та без "Татар декаденсының XVI гасырга нигезләнгән булуын хәтергә төшергән" Хәлиуллин белән килешмәс идек. Димәк, аныңча, Явыз Иван тарафыннан җиңелгән Казан ханлыгы — татарның бетүгә борылуы. "Идегәй", "Чура батыр" кебек халык дастаннары безгә татарлык турында күп нәрсә сөйли", ди Хәлиуллин. Һәм тагын да ераграк дәверләргә күз ташлап яза: "Үткәндәге татарлар көч һәм бөеклек белән" мавыкканнар. Авторның шундый ишарәләреннән хәзерге татар этносын турыдан-туры Алтын Урда, Болгар, хәтта татар-монгол эпопеяләре белән бәйләү омтылышы ятканын танымау мөмкин түгел.

Искәртәсе килә, безнең халык мирас итеп алган "татар" сүз-атамасы чиксез киң, төпсез бит. Кайдадыр "Татар бугазы" бар. Кайчандыр бөтен Себер киңлекләрендә яшәгән халыкны "татар", "хәтта илне "Татария" дип атаганнар. Л. Толстой, Ю. Лермонтов кебек рус язучыларының әсәрләрендә Кавказдагы байтак җирле халык татар итеп тасвирланган. Рус шовинистлары да үзләренең дошманнарын теге яки бу кавемгә аерып мәшәкатьләнмәгәннәр, "Татар-басурман"!.. дип кенә сөрән салганнар. Мондый мөнәсәбәт хәтта Марина Цветаева, Анна Ахматова шигырьләренә дә үтеп кергән.

Инде шул буталчык, четерекле тарих галәмәтләрен барысын үзебезгә җыйыйкмы? Барысы өчен кеп, янып йөреп, картайыйкмы?

Этногенез ыру, кабилә, кавем, халык, милләт кебек төшенчәләр белән эш итә. Хәзерге тарихчылар сыман этнос категореясен куллану гына аз, чөнки эволюция ачылмый. Әмма шунысы бәхәссез, Русия татарының милләт булып оешуы бик якын дәвергә — XIX — гасырның икенче яртысына карый. Иҗтимагый тарихи, сәяси һәм мәдәни шартлар тәэсирендә гомум төркичелек, гомум мөселманчылык агымыннан татар үзенә аерым юл-мәсләк ала, милләт буларак формалаша. Г. Ибраһимов язганча, җиде кабилә — "Казан татары, мишәр, нугай, алатыр, типтәр, Төмән һәм Касим татарлары бер милләт рәвешендә әдәби, мәдәни бер коллектив" буларак оешалар. Безнең мөстәкыйль, үз мәгыйшәтебезне Каюм Насыйри, Мәрҗани, Курсави, Акмулла, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Муса Акъегет һәм тагын дистәләрчә гаярь, милләтпәрвәр зыялыларыбыз башлап җибәрә. Болар Г. Ибраһимов әйткәнчә, "мөселман урынына татар йөртә, ихтыяҗ итеп татар тормышындагы эшләр хакында сөйләргә" керешәләр. XX гасырлар башында Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирханнар буыны исә милләтне яңа үргә күтәрә, прогрессив идеяләр белән сугара һәм мөһим сыйфатлар белән баетып халыкны туплый...

Без — яшь әле! Көчле, иҗтиһадлы, һиммәтле милләт! Инкыйраз, бетәшү куркынычы түгел, ә оешу, берләшү, һәм якты, зур омтылышлар белән яшәү идеяләре кирәк халыкка. Күңел хөрлеге, иҗат дәрте аеруча милләт узаманы

булган зыялыларыбызга, язучыларга зарур. Күпләр фирка идеологиясеннән котылдык, ирекккә чыктык дип сөенеп, гомумән иҗтимагый идеяләргә дошманлык чәчәләр. Юк, дөрес караш түгел бу. Таза, тормышчан идеология рухи тормышның, әдәбият, сәнгатьнең ныклы нигезен, яшәүчән көчен тәшкил итә. Кая барабыз? Нәрсә корабыз? Нинди идеалга табынабыз без?

Язучы кеше шундый җитди сорауларга җавап тапканда гына халыкны дулкынландырырлык әсәрләр иҗат итә ала. Безнең әдипләр шул дәрәҗәдәме?

## Йомгак урынына

Дини тойгы үсү, миллият көчәю белән бергә хәзерге әдәбиятның тагын бер оешу үзәгенә игътибар итәргә кирәк. Бу — серлелек. Әдәбият гомумән серле дөнья. Тормыш хакында, мөнәсәбәтләр турында, тойгы-кичерешләр өлкәсендә укучыларга ачкан серләр тезмәсеннән тора ул. Синең сердәшең — язучы, аның китабы. Тик тыңлый бел, аңла син аны һәм дөрес файдалан гына син ул җиткергән серләрдән! Ләкин серлелек кайчакта табигатьтәге, тормыштагы үзлекләре ачылмаган, танып беленмәгән, аңлашылмаган күренешләр, тылсым хәлләре, мистика буларак, үзе теге яки бу әсәрнең сүрәтләү темасына әверелә яки алар реаль хәлләр тезмәсендә тасвирланып, вакыйга ачышына көтелмәгән борылыш китерәләр. Серлелек дигәндә без менә шуны күздә тотабыз. Һәм борынгыдан башлап Октябрь инкыйлабына кадәр булган татар әдәбияты аңа искиткеч бай иде. Тик сәвит заманы, коммунистик материализм милли әдәбиятта һәртөрле сер, тылсым галәмәтләрен чикләргә тырышты, аларны хорафәт дип атады. Һәм бик күпләр тора-бара җен-шайтанга, ырым-юрауга гына түгел, хәтта сөйләгән сүзләренә үк ышанмый башладылар. Чөнки җисем культы башланды. Хәятта тик молекула, атом, протон, нейтрон, электрон хакимлеге генә калды сыман. Атеизм кешеләрнең җанын, рухын корытып, алардан сөяк һәм иттән торган, әмер һәм күрсәтмәләргә карышусыз буйсынган роботлар ясарга җыенды.

Янә сөенергә туры килә, ярый әле дөнья куласасы әйләнеп китте... Җансыз, рухсыз кеше, тере булса да, мәет бит ул. Мөселман юкка гына исемнәргә "җан" өстәмәгән: Галимҗан, Сәетҗан, Тимерҗан, Зөһрәҗан... Нәкъ менә үз җаныбыз безне бер-беребездән аерылып торган затлар, шәхесләр итә. Ә җанга серләр һәм тылсым кирәк, могҗизалар көтә ул... Борынгы шагыйребез Әхмәт Уразаев-Курмашиның халкыбызны елаткан "Таһир илә Зөһрә кыйссасы"нда Таһир илдән ерак Мәрдин төрмәсендә җиде ел мәхбүс булып ята. Зинданнан коткаруын, Зөһрәсе белән кавыштыруын сорап, Аллага ялвара ул. Ниһаять егет янына Хозыр-Ильяс галәйһиссәлам килә. "Углым, еглама вә гамь чикмә", — дип юата һәм аны төрмәдән коткарып, атка утыртып мәгъшукасы янына озата ул.

Безнең һәрберебез, хәтта денсез дә авыр, өметсез чакта бөтен асылы, җаны белән Аллага сыгына һәм үзенең Хозыр-Ильясын өметләнеп көтә... Г. Тукай да бит юкка гына: "Күктә ниләр булмас дисең, ... күк бит ул!" димәгән. Галәм чиксез, андагы хәят адәм акылына гына сыеп бетәрлек түгел, ни сөйләсәләр, шул булырга мөмкин. Чөнки сүздә булган —акылда була, акылда булган — гамәлдән килә. Һәм янә гамәлдә булган, акылга күчә. Дөрес мантыйкмы бу, яшәргә лаекмы? Дөрес һәм яшәүгә лаек икән, димәк, һәр тылсымга, һәр могҗизага да өмет бар. Шулай итеп, тирәбездә көн күргән багучылар, күрәзәчеләр, сихерчеләр им-томчылар кебек үк, әдәбиятта да чынны сер белән кушып иҗат итүчеләр булырга хаклы. Әйткәнемчә, серлелек — яңа әдәбиятның бер юнәлеше. Һәм аңа аеруча проза бай. Әйтик, Мәхмүт Хәсәновның "Язгы ажаган" романының төп каһарманнарыннан берсе булган Гази, җир кышкы йокыдан уянмас борын, ажаган балкышын күргән. Им-томчы Мәгыйшә карчык "Ай-һай, балакай, андый кяфер сүзләрне авызыңнан җил алсын, берук. Яз башында нинди ажаган булсын, хәзер оныт ул турыда", — дип үз ырымын кулланса да, көчсез булып чыга. Язгы ажаганга тап булган кеше өлешенә тигәнне Гази дә кичерә, гомере буена зур афәтләрдән, иләмсез газап-михнәтләрдән газап чигә.

Хәер, туры акыл өчен әсәрдәге язгы ажаган — сталинизм, тоталитар режим символы ул. Бер Гази генә түгел, Иргали, Гөлүсә, Һади һәм романның башка каһарманнары да каргалган заманның авыр язмышлы затлары булып чыгалар. Җентекләп укысак, без Ф. Бәйрәмованың "Күл балыгы", Р. Мөхәммәдиевнең "Кенәри — читлек кошы", Г. Кашаповның "Убырут", Ә. Гаффарның "Олы юлның тузаны", А. Хәлимнең "Өч аяклы ат", Р. Хәмидинең "Китәм инде", А. Гыйләҗевның "Яра" һәм башка күләмле әсәрләрдә серлелекнең, тылсымның кызыклы гәүдәләнешләрен күрер идек.

Әмма бездә тылсымлы прозаның иң кызыклы вәкиле булып Нәбирә Гыйматдинова танылды. Тәнкыйтьчеләребездән Хәнәфи Бадыйков "Н. Гыйматдинова сер, тылсым, халык йолалары, ырымнары, магия һәм башка төрле күренешләрнең яшерен катламнарын үтеп кереп гаҗәп мавыктыргыч, һич көтелмәгәнчә тасвирлап бирә алуы белән игътибарны җәлеп итә", — дип язып әдибәнең иҗатындагы мөһим сыйфатны дөрес билгеләп үтә. Нәбирәнең "Сихерче", "Күке төкереге", "Бүре каны", "Болан" кебек повестьлары татар әдәбиятына кызыклы яңалыклар китерделәр.

Бездә серлелек белән бәйле иҗатның зур мөмкинлекләре бар. Бу ышаныч халык фольклоры, мифологик фикерләү һәм әдәбият казанышларына нигезләнә.

Шулай итеп, күчеш чоры татар әдәбиятының аерым сыйфатлары, бигрәк тә, мөһим оешу үзәкләренә бәйле уйланулар бер ноктага төбәлә. Җитмеш еллап коммунистик басым астында милли мәнфәгатьләр, милли рухтан читләштерелгән әдәбият янә үзенең асылына кайта, язмышын милләт белән бәйли. Ә милләткә әдәбияттан да ныграк, көчлерәк йогынты ясаучы куәт юк. Дөрес, бүгенге иҗатны камил диюдән еракбыз. Ул әле һаман анык сурәтле, әхлакый, этик билгеләнешле заман героен бирә алмый. Социалистик этапка бәйләнешле тискәре персонажлар да уйландыру, чын тойгылар тәрбияләүдән бигрәк, схемага, шаблонга корылалар. "Үткәннәр белән көлә-көлә саубуллашу"да сәнгатьчә камиллектән ерак әле... Тик түзик, сабыр итик. Әдәбиятыбыз бәгырь яраларыннан арынсын, үзендә көч тупласын, рухы белән яңарсын. Һәм Тукайлар дөрләткән утны караңгы елларда да М.Галәү, Ә.Еники, Ф.Кәрими, Х.Туфан, С.Хәким, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Ш. Хөсәенов, Г.Афзаллар аркылы саклап килгән әдәбият аны тагын яңа бер көч белән үрләтеп җибәрер.

... Халык өчен бүгенге авыр, хәтта фаҗигале бөек күчеш дәвере, шөкер, тоташ үкенеч һәм аһ-зарлардан гына тормый, сөремле күк арасыннан балкып-балкып куйган кояш сыман, аерым юану, сөенечләрдән дә өлеш чыгара. Ходай үзе шаһит, иманлы зат тирә-юнен яңгыратып азанын әйтә, догасын укый. Моңлыга исә күңел тарткан җырын, аһәңен көйләргә була, иҗтиһадлыга да кәсеп ирке бар бит. Халык җаны тарткалашлар эчендә богау-зынҗырлардан арына, хөрриятькә чыга. Күчешнең сөенечле чагылышлары халык рухының көзгесе булган әдәбиятта да ачык күренә. Тар, зыянлы һәм һәлакәтле фирка-идеясенә, Мәскәү Кремленә яраклашып түгел, ә татар халкының уй-фикер йөртүенә, зәвыгына нигезләнеп сурәтләнгән әсәрләр бирерлек хак юлда ул хәзер.

*Уфа.*

## Әбүнәчеләребез игътибарына!

**Шушы елның 13 июленнән 31 августына кадәр, 1999 елның беренче яртысы (гыйнвар — июнь айлары) өчен, "Казан утлары" журналына льготалы подписка игълан ителә. Язылу бәясе —1998 елның икенче яртыеллыгындагы кебек — 6 айга нибары 18 сум. Бәяләр күтәрелгәнче, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз, кадерле дуслар!**

Флера
Ганиева

# ШАГЫЙРЬ ГОМЕРЕ — АККОШЛАР ЮЛЫ

## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИНГА 50 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН

Нигә мультфильмнар карарга яратам икән дип үземә гаҗәпләнеп йөри идем, аның серен бер мультфильм үзе үк тасвирлап бирде. Зоопаркта кечкенә ат — пони үзенең кечкенә арбасына күккә кадәр өеп балалар төйи дә, аларны түгәрәк буйлап әйләндереп-тартып йөри. Читтәрәк шәп бер генерал менә дигән атларны бертигез, дөрес итеп атлап йөрергә өйрәтә. Янәшә әнә шундый ике хәрәкәт бара, ике дөнья яши. Балаларның куанычы күкләргә ашкан, алар чиксез бәхетле. Ә пони теге шәп атлар кебек булырга кызыга. Кич житә, зоопарк тынып, бушап кала. Йокымсырап торган пони янына әлеге генерал килә. Пони аңа зур атлар кебек дөрес, шәп итеп йөреп күрсәтмәкче була. Юк, генералга анысы кирәкми. Ул кечкенә арбаны күрсәтә һәм шуна утырып түгәрәк әйләнә дә бик канәгать булып китеп бара.

Менә шул халәт — ат тартып барган арбага утырып баргандагы, балачактагы рәхәтлекне кабат тою — кирәк икән кешегә. Бу халәт безне тормыш ваклыкларыннан арындырып, күңелләребезне сафландырып тора.

Шуңа күрә зур әдәбият янәшәсендә бер дә туйдырмый һәм картаймый торган могжизалы дөнья — балалар әдәбияты яшәү зарурый. Үз әдәбиятын укып үскән бала, олыгайгач та, матурлык хисен, хыяллана белү сәләтен югалтмыйча яши.

Роберт Миннуллин — балалар шагыйрe. Балаларны чынлап куандырырлык, бәхетле итәрлек, балачакның серле бер дөнья икәнен тоярлык итеп язучылар күп түгел. Шуңа күрә дә алар игътибар үзәгендә. Балаларның да, олыларның да!

Мәктәп дәреслекләрен төзегәндә программаларга һәм дәреслекләргә нинди әсәрләрне кертергә, сайлап алырга дип уйланганда, киңәшкәндә, әлбәттә, балалар әдәбиятыннан үрнәкләрне алырга, әлбәттә, Шәүкәт Галиев, Ләбибә Ихсанова, Фәнис Яруллин әсәрләрен алырга дидек. Балалар белән шигърият телендә ин табигый һәм үз булып сөйләшүче шагыйрьләрдән берсе булганга, үзенчәлекле булып аерылып торганга Роберт Миннуллин ижаты да мәктәп дәреслекләрендә өйрәнелә башлады.

Балалар әдәбияты турында, поэзия турында үз белгечләре, галимнәр язып, фикер алышып торалар. Роберт ижаты да күп өйрәнелгән. Мин аның шигырьләрен яратып укучы буларак, мәктәп балаларына һәм студентларга аның ижаты турында сөйләп торучы укытучы буларак фикерләрем белән уртаклашам.

Беренче фикер, әлбәттә, Робертның балалар поэзиясе турында. Аның шигырьләрен укыганда мин үземне нәкъ теге мультфильмдагы генерал итеп тоям, башка укучыларга да бу хис-кичерешләр таныштыр дип ышанам. Чөнки балачактан аерыласы килмәү теләге һәркемнең канында, серле бер катлам булып аңында яши. Шигырь — бер очкын, шул теләк кабынып китә, шигырь — бер тамчы, шул теләк-хис чишмә булып челтерәп ага башлый. Һәм син кәгазьдән көймә ясыйсың да, шул чишмәнең жемелдәп торган дулкынына ияреп агып китәсең. Синдәге тәвәккәллек, ышаныч, өмет! Барысы да алда әле, яна әле, кызык әле! Дөньяга син хужа, офыклар чиксез, гомер-яшәү дә чиксез!

Укучы булып үз күңелемне, хисләремне анализлап карыйм: чынбарлык белән хыялны тигезләп куйганмын, мин гадел, дөрес дөньяда яшим, тулы хокуклы булып яшим, иң әһәмиятлесе: рухым-хыялларым чикләнмәгән. Дөрес, әти-әни, олылар вакыт-вакыт (кайчак артыграк та) "Ярамый!" дип кисәтәләр. Анысы бит олылар дөньясыннан торып әйтелә аның. Акыл белән уйласаң, дөрестер ул сүз,

тынларга кирәктер аны. Әмма мин әлегә хис-теләк-хыял йомгагы булганга үз дөньяма үзем хуҗа. Минем иң якын сердәшләрем — табигать, тереклек. Хәер, табигатьтә җансыз нәрсә юктыр да ул. Менә кайда ул хөрлек, иркенлек! Мин — шул чиксезлекнең бер бөртеге дә, хыялымда —хуҗасы да.

Бу хыял дөньясы бер үк вакытта чынбарлык та: иң беренче мин үзем бар, әти-әни бар, олылар бар, дуслар бар, мин басып торган җир бар һәм тагын бик күп нәрсәләр чыннан да бар! Минем шул чынбарлыкка тулы хакым бар!

Менә шулай хыялландырган героен шагыйрь иплəп кенә күтәреп җиргә төшерә тора. Артык югары күтәрелеп китсәң дә, җиргә төшәсе бар, егылып төшүең бар, имгәнүең бар. Балачактан да аерыласы булыр, олылар дөньясына баланы хәзер әзерләргә кирәк. Тормышның авырлыгыннан куркытмыйча, кешеләрдән һәм яшәүдән биздермичә!

Роберт шигъриятендәге иң кирәкле, әһәмиятле матурлык, фәлсәфи матурлык шунда — үз тәҗрибәсен, олы кешеләрнең зур тормыштагы тәҗрибәләрен җыеп ул бу байлыкны бала тәҗрибәсенә әйләндерә, аңлаешлы итә белә. Бу инде — сирәк була торган талант.

Табигый яңгырамаса, ягъни үз телендә язылмаса, бала андагы хисләрне (димәк фикерне дә!) кабул итми, үз ачышы-табышы-хәзинәсе итеп күнеленә салып куймый. Шигырьләрдә бала үзе җавап эзләп, үзенчә уйланып йөргән, олыларны аптыраткан, күп вакыт аларга әйтеп тә тормаган мең дә бер сорауга җаваплар бар. Җавап эчендә тагын әллә никадәр сорау да бар. Барысы да бала логикасына корылган. Алтын ачкыч, дөнья хикмәтләрен аңлата, ача торган ачкыч — нәкъ менә шушы логика. Беренче карашка гади тоелган фикер сөрешендә абстракт дәрәҗәдән, фәнни катлаулылыктан аерылып торган чын сәнгатьчә фәлсәфә бар, һәр нәтиҗәнең сәбәбен аңлаткан, һәр сәбәпнең нәтиҗәсенә барып җиткән психологизм бар.

Курс һәм диплом эшләрендә студентлар белән без үзебез өчен дә гаҗәеп кызыклы фикер сөрешен, инде онытылып өлгергән яки безгә таныш та булмаган ачышлар, сәнгать алымнары табабыз. Роберт Миңнуллинның балалар өчен язылган шигырьләрен анализлау — булачак укытучылар, филологлар өчен үзе бер иҗат лабораториясе. Фикерләрне исбатлау өчен, мәкалә мәйданы сыйдырган кадәр генә, берничә шигырен искә төшерәсе килә.

Һәркемгә ипи кирәк!
Һәм көн дә ипи кирәк!

Ипи космонавтка да, очучыга да, игенчегә дә һәм... иген игүдән качучыга да кирәк. Тизрәк үсеп җитү өчен һәр балага да кирәк.

Шуңа да игенчене
Хөрмәт итәргә кирәк!

Ә менә иген игүдән качучыны, эшләми тик ятучыны хөрмәт итеп буламы? Ул үзе эш яраткан кешеләрне хөрмәт итә беләме? Үзен-үзе хөрмәт итә аламы? Бу сораулар гап-гади сүзләрдән чигелгән шигырь-шкатулка эченә салып куелган "проблемалар" инде. Бу сораулар атап әйтелмәсә дә, күңеле белән бала аларны сиземләп үтә. Янындагы берәр өлкән кеше аларны искәртеп куйса, акылы белән үзләштереп тә өлгерә. Әйтелеп бетмәгән, әмма шигырьгә салып куелган нәтиҗәләр шигырьнең серле матурлыгын, авторның осталыгын — ягъни поэтиканы чагылдыралар.

"Җәйнең яшел аты". Яшел ат буламени дигән мәгънәсез сорау башка да килми. Җәе яшел булгач, аның аты ничек яшел булмасын ди! Өстәвенә җәй ничек аттан башка була алсын ди?! Җәйне бит күреп өлгерергә кирәк. Зур атка әллә ничә кеше тезелеп утырып чапсаң да таманга килә әле. Уеннан туеп өлгергәнче кич җиткән кебек (бу чагыштыру шигырьдә "кычкырып" әйтелми) җәйне күреп бетереп өлгергәнче аның чигенә килеп җителгән икән бит! Их, атым да арымады, туктап ял итмәде ичмаса, җәйнең матурлыкларын күреп бетереп булмады.

Бигрәк җитез барганбыз,
Сизмичә дә калганбыз —
Атым белән бергә без
Көзгә килеп кергәнбез.

Ә күзнең аты сары төстә. Ана күчеп утыру өчен башка шигырь кирәк.

Бала бу шигырьне укыды да, ары таба чапты, уйнарга чыгып чапты. Ә минем күңел — генерал — моңланып алды: ах, җәй аша гынамы, гомер аша да шулай талпына-талпына чапканмын, кире дә борып булмаган, туктатып та булмаган ул атны. Әмма бит ул балачак булды, мин тагын бер шул яшел атка атландым, ялт кына бала чакка кайтып килдем.

Роберт Миңнуллин шигырьләре гел рифмалардан гына тора кебек. Охшаш яңгырашлы авазлар куанышып көлешкән балалар кебек җитәкләшеп-тезелешеп торалар. Үзләре бер дә тик тормыйлар, туктаусыз хәрәкәттә. Сүзләр гади, кыска, җиңел аңлашыла, агылып кына торалар. Шигырьләренең герое шәп: барысын да булдыра ала, барысына да өлгерә, ул әле гел беренче булыр иде, барысын да шаккатырыр иде, олылар гына ирек бирми.

Мин иң усал җанварларны
Өйрәтүче булыр идем,
Сезне шаккатырыр идем,
Арысланнар арасында
Курыкмыйча торыр идем.
Арысланнар кирәк миңа,
Юлбарыслар кирәк миңа.

Хикмәт шунда, тоткарлык шунда:

Зурлар хәйләләшә генә,
Алар мине белмиләр лә —
Мин курыкмыйм бернидән дә!
Үзләре куркалар алар —
Шуңа алып бирмиләр дә.

Баланың батырлыгы да, зурларның ерткыч җанварлардан куркуы да хак. Бу — балачак дөреслеге, бу — бала логикасы. Балачак дөньясы гомумән романтикадан тора: һәр бала — герой, хыялый, иң шәп профессияләрне генә сайлаячак. Хыялның да, кичерешләрнең дә иң югары дәрәҗәсе. Роберт бала янәшәсендәге олыларга да мөрәҗәгать итә: бала кичерешләре чикләрне белми, аның соклануы да, ярату-яратмавы да , барлык мөнәсәбәтләре дә хәлиткеч дәрәҗәдә үзе өчен әһәмиятле. Аның күңел кыллары белән сак булырга кирәк. Кызгана икән — ул фидакярләрчә кызганыч, җанын бирердәй булып кызгана.

"Әни, мин көчек күрдем!" шигырендәге герой әнисенә таш күңелләрне эретерлек итеп ялына, өзгәләнеп ялына. Шигырь кабатлаулардан тора: юл саен диярлек малай "әни!" дип эндәшә, көчекнең хәлен шулай сурәтли — кабатлаулар градация дулкынын тудыра.

Әни, туңганга микән,
Ул бик дерелди иде.
Салкын тисә ул анда,
Тышта терелми инде.
Нишләр инде ул анда,
Берьялгызы урамда?
Ул елыйдыр әле дә,
Дерелдидер тәне дә.
Иртәгә үк үләчәк,
Калдырсаң бу хәлендә.
Әнием, шул көчекне
Алып керик әле, ә?!

Бу — гаҗәеп драматик яңгырашлы шигырь. Кемдер ташлап калдырган этне бары сабый җаны гына шул дәрәҗәдә аңлап кызгана. Ә мин җаны өзгәләнгән шул малайның кичерешләренә буйсынам, иярәм, аның белән берьялгызы урамда туңып, дерелдәп утырып калган көчекне коткарырга телим.

Соңгы ике елда Робертның балалар өчен китаплары затлы эшләнештә, күз явын алырлык матур, сыйфатлы булып басылды. Шуларның берсе — "Кояш алмасы" ике телдә: шигырьнең үз телендәгесе һәм русчасы янәшә куеп басылган.

Тәрҗемәләр әйбәт, әлбәттә, чөнки тәрҗемәчеләр үзләре дә шагыйрьләр. Әмма алар бөтенләй башка шигырь, үз шигырьләрен язганнар. Әлеге шигырьне генә алсак та, зеңгелдәп торган кызгану хисе, өзелергә торган кылның чыңлавы тәрҗемә шигырьдә юк, киеренкелек юк, кичереш юк. Чөнки вакыйганы — фаҗигане бала түгел, ә шул баланың сөйләгәнен карап торучы яза. Өстәвенә ул бозып үзгәртелгән — көчек әрсезләнеп малайга ияреп кайткан да, ишек артында көтеп утыра, бары тик ишекне генә ачасы.

Мне он как другу поверил...
Мама, сейчас он за дверью!
Может быть, мы позовем
Славного песика в дом?!

Бөтен хикмәт тә шунда, чынлыкта кечкенә герой олылар дөньясындагы битарафлык, алдау-хыянәт алдында калган. Нәрсә эшләр аның әнисе? Көчекне коткару турында гына сүз бармый бит, баласындагы шушы олы хәзинәне — кызгана белү хисен — саклап кала белерме? Бала күңеле җәрәхәтләнсә, мәрхәмәтсезгә әйләнәчәк бит.

Роберт Миңнуллин үгет-нәсихәтсез генә, ипләп кенә зур белем, зур кагыйдәләр, яшәү тәртибе турында хыял иясе — сабый телендә сөйләп тора һәм олыларны да аңлаган кешегә аңларлык итеп искәртә бара: бала күңеленә карата саксызлык, ваемсызлык — ул зур тормышта зур фаҗигаләргә китерә.

Икенче фикерем — Роберт Миңнуллинның лирикасы турында. Балалар өчен генә язса да автор образын күз алдына китереп булыр иде, әле ул шул дәрәҗәдә үк — олы поэзия шагыйре дә. Аның иҗаты ике канатлы, кайсы әһәмиятлерәк, югарырак дип сорау кую урынсыздыр. Минемчә, Роберт һәр икесендә үзен бердәй тыныч, ышанычлы һәм бәхетле итеп хис итә. Күп кенә шигырьләрен балаларныкымы, олылар өченме дип аерып та булмый.

Мәйданның кыл уртасына
Яшь малай башлап чыга.
Башлап чыккан малай гына
Мәйданны ташлап чыга.

Җиңе белән сөртә яшен —
Хәле түгел җиңелдән.

Беренче кат көрәшкән ул,
Беренче кат җиңелгән.

Кысыла аның тешләре,
Йодрыклары төйнәлә.
Кысылсын әйдә, төйнәлсен —
Ул җиңәргә өйрәнә.

Лирика да, балалар шигърияте дә — Робертның үзе турында. Балачак аның күңелендә бөтен килеш, җимерелмичә сакланып калган һәм аның хәзерге кичерешләренә килеп ялганган. Хәзер — олы шигырьләрендә — ул нинди? Тормышның үзе кебек кайнап, үзгәреп торамы? Чуармы аның йөрәге, сабырмы?

Шигърият турында сөйләү, аны прозага әйләндерү —"сандугач менә шулай сайрый" дип сөйләп күрсәтү белән бер. Шулай да, Роберт шигырьләрен укыганда күңелгә тула торган моңның сәбәпләрен — бу сабыр һәм моңлы шагыйрьнең серен аңлыйсы килә. Чишмә суы кебек тыныч-тыйнак шигырьләр. Хикмәт шул чишмәнең үзендәдер бәлки? Җирнең ничәнче катыннан, нинди катламнар аша үтеп күтәрелгән ул? Күзгә күренмичә кайлардан бирле, күпме юл үткән?

Җавапларны шигырьләрендәге эчкерсез самимилектән, әйткән һәм әйтеп бетермәгән мәгънәләрдән эзлим. Барлык шагыйрьләр дә моңлы, һәрберсе үзенчә моңлы. Аның төсе яшел дип күз алдына китерсәк тә, төсмерләрен һәм моңның сәбәпләрен табып, барлап бетерү мөмкин түгел.

Шигъриятнең дә тылсымы аңлап-аңлатып бетереп булмаудадыр, мөгаен. Шулай да бу моң уйландыра, хыялландыра һәм мин күз алдына китерәм.

Тал бишектә биш бала үскән. Үсеп җиткәч, болар таралышачак бит, туган өйләреннән, җирләреннән аерылачаклар бит. Биш баланың берсе генә, баш бала гына шагыйрь булып киткән. Әнкәсенең сагышларына иң якын торгангадыр; аерылу-таралу-сибелүләрнең котылгысызлыгын күңеле алдан ук сизеп торгангадыр, йөрәгенә җыеп торгангадыр...

Үзең теләп аерылуда никадәрле үкенеч бар — моң чыганагы, сәбәбе — йомгакның бер җебе шушыдыр. Татарстаннан читтә туып-үсеп, Казанга — шигърият

башкаласына килгән әдипләрдә, шагыйрьләрдә сөйгәненнән аерылган аккошлар моңы бар. Сөн, Илеш, Агыйдел, Базы, Хан тавы, туган йорт, нигез, авыл, әтисе утырткан алмагачлар, ишек алдында үскән әрем һәм тагын бик күп кадерле төшенчәләр. Алар инде Робертныкы гына түгел, уртак байлык, матурлыкка әйләнде. Шулар турында туктаусыз сөйләп ул сагышлана һәм сагышын баса. Энеләре белән сөйләшә:

Таралды ла нигез, уртак нигез.
Башлап киттем аннан мин үзем...
Уртак нигез мең кат өзәр әле
Безнең үзәкләрне анлагач...
Безнең кебек шаулап үссен анда
Кече туганыбыз — алмагач!

“Аерма мине моннан!” дип туган жиренә эндәшә, туктаусыз аның белән серләшә:

Үзем җүләр!
Сине ташлап
Китмәскә кирәк булган.
Ул чакта әле, күрәсең,
Миндә таш йөрәк булган.

Каһәрлим, тиргим, кичермим
Синнән киткән чагымны.
Шул кирәк миңа, шул кирәк —
Елат, сызлат җанымны!...

Сызландыр, зинһар, сагындыр —
Шәфкатьле бул син.
Амин!



*Роберт Миңнуллин үзенең остазлары Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев белән.*

Робертның шигырьләре яшьлекнең үзе кебек, табигатьнең үзе кебек моңсу. Табигать, ел фасыллары белән туктаусыз очрашып һәм аерылышып торганга моңсу инде ул. Яшьлекнең моңын алдагы билгесезлек, шуны алдан күрәсе, беләсе килү тудырадыр. Яшь шагыйрьләр бер үк вакытта шуңа күрә кыю-тәвәккәл һәм кыюсыз-моңсу булалардыр. Бәлки алар таза, яшь тәннәре буйлап ургылып аккан кан агышын сизгән-тоеп торган кебек, киләчәктәге тормыш-гомерләрен дә алдан ук үз йөрәкләре аша үткәрә торалардыр. Гомер чикләрен үз йөрәкләренә сыйдыра алалардыр, йөрәкләре шул киеренкелектән әрни-сызланадыр?

Бу шыпырт-тыныч йөргән егет үз кадерен үзе белеп йөри.

Күпләр чиртте йөрәк кылын —
Көй чыгара
Алмадылар.
Озак уйный алмасларын
Үзләре үк
Аңладылар.
Ул кылда уйнау өчен бит
Паганини
Булу кирәк!

Ә андыйлар ятмый тулып,
Аны уйнар
Куллар сирәк.
Яратам дисең, аны бит
Теләсә кем
Әйтә ала.
Йөрәгемдә бер генә кыл —
Уйный алсаң,
Уйнап кара!

Әйе, күп кенә шагыйрьләр ашкынып, әллә ничә гомергә житәрлек кичерешләр давылында яшиләр. Дөрес эшлиләрдер — аларның табигате шундыйдыр. Ничек яшәү дөрес, ничек яшәү жиңел, кирәкме ул жиңеллек шагыйрьгә — болар мәңгелек сораулар. Роберт үз жаны белән шул турыда сөйләшә.

Нигә моңаябыз әле?
Гомерләр үткәнгәме?
Ерактагы сөйгәннәрне
Тилмереп көткәнгәме?..

Балачакның сандугачлы
Бакчалары буш инде...
Сагынырга, моңаерга
Безгә генә куш инде,
Безгә генә куш инде.

Сагына белү, шул хиснең сүрелмәве — моң йомгагының тагын бер жебе. Үз шигъриятен генә түгел, бөтен укучылары күңелен моңга күмгән "Әнкәй" шигыре, дөресрәге бу шигырьләр циклы, сагынуның менә дигән үрнәге бит! Ничек шулай гади һәм кабатланмаслык итеп әйтеп була. Бер карасаң гадәти күренеш: үз өйләренә кунакка кайткан бер гаилә балалары; аларга дип саклап торган, әле генә кар базыннан чыккан нигъмәтләр; казан астына ягылган һәм мич янында балаларын тыныч-сабыр гына көйләп йөргән әнкәй! ( Бу шигырьдән соң Робертның анасы турында бары тик "әнкәй" дип кенә әйтеп була!) Авылда туып-үскән һәркем өчен таныш һәм әйтеп бетергесез кадерле күренеш. Фәлсәфә дә бар — әниләр олыгайган, картайган саен югалтуга-аерылуга (мәңгелек!) якынаялар. Котылгысыз бу, хакыйкать бу. Ул — сүз белән әйтелмәгән, йөрәк белән аңлап-тоелып торган моң. Без үзебез исә ничә яшьтә булсак та, әниләр янында балага әйләнергә, иркәләнергә яратабыз шул.

Роберт шигырьләреннән моңның төп сәбәпчеләреннән булган мәхәббәт тарихын эзлим. Һәм мөгаен аның үзен дә тилмертә-газаплый торган үзенчәлек күрәм кебек. Ул бит үзен баштан ук бер сөю, бер кешегә булган мәхәббәт белән бәйләп куйган. Сабырлык, түземлекне күкләр аңа шушы тугрылыгы өчен биргәндер!

Кайгыммы син, бәхетемме?
Бәлки хатам, ялгышым?
Ни булса да булган инде,
Синдә — бөтен язмышым.

Беләм йөрәкләрнең бергә
Типкәнен, тибәчәген.
Бердәнбер үткәнем бит син,
Бердәнбер киләчәгем!

Мәхәббәт бит — кешедән дә, шагыйрьләрдән дә өстен бер хис. Йөгәнли алганмы шул Пегас кебек үк иярләп булмый торган хыялый һәм бик реаль серне? Робертның лирикасы — мәхәббәт лирикасын гына — җыйсаң да мон дәрьясы хасил булыр иде. Гүзәллеккә гашыйк булмый ничек түзәргә кирәк?! Әмма түзәргә кирәк. "Яратудан ташып түгелгәндә" дә, "Мәхәббәттән йөрәктә җәрәхәтләр" ясалганда да, "мәхәббәт урынына газапка юлыкканда да".

Еллар үткәч тә ул "Син!"гә ("Кларага") элекке сүзләрне кабатлый.

Мин сиңа күз яше генә,
Әрнү генәдер инде.
Нишлисең сөю-сөелү
Әрнү белән бер инде!

Көчәйгән саен мәхәббәт,
Әрнүләр арта бара.
Безнең йөрәкләр тулыдыр
Әрнүдән калган яра.

Кичер бу газаплар өчен
Әллә миңа рәхәтме?!
Тик беребез дә теләми
Башкача мәхәббәтне.

Моң йомгагында зур дөньядан килгән гамь-борчулар торган саен — шагыйрь олыгайган саен — күбрәк урын ала, шигырьләрнең яңгырашына яңа әрнүләр, капма-каршылыктан торган хис-кичерешләр килеп урала.

Йодрыклар чыкты кесәдән,
Бүген һәркем гайрәтле!
Буташтырып бетерделәр
Яман белән әйбәтне.

Илләр, телләр, халыклар язмышы шагыйрь күңелендәге интим дөньяны читкәрәк күчереп куйды. Робертның иҗтимагый тормышта актив катнашуы да роль уйнамый калмагандыр. "Татар өмете" (Казан, 1998) китабына җыелган шигырьләр — бүгенге көн, мәйдан, чор авазы.

Мәңгелек марафон кебек —
Кешелек, алга барыш!
Ул шулай мең гасырларга
Сузыла алган ярыш.

Егылсаң да, яңадан тор!
Абынсаң, алга талпын!
Старт бер алынган инде,
Туктау юк сиңа, халкым!

Тукайдан башлап һәр зур шагыйрь халык язмышын күзәткән, шул язмышта үз урыны, бәясе турында уйланган, халкының һәм үзенең хакын раслаган. Бу — бүген дә шулай! Бу — Роберт поэзиясендә дә шулай.

Минем өченче фикер — Роберт Миңнуллинның үзе турында. Гел очрашып тормасак та, бер-беребезне 70 нче еллардан бирле беләбез. Арада ниндидер рухи якынлык бар: мин аның иҗатын өйрәнеп-күзәтеп торам, хәлен белешеп куям. Дүрт туганына абый була белгән Роберт миңа җылы-ягымлы итеп "Флера апа" дип дәшә. Энесе Ким, сеңлесе Люция минем күз алдында укыганга күрә дә Робертның дөньясы миңа якын, кадерле.

Шулай да без гел аралашып, еш очрашып яшәмибез, озаклап сөйләшеп утырырга да вакыт таба алган юк. Аннан соң ул үзе турында сөйләгәнне тыңларга уңайсызлана да әле, шунда ук күзләрен түбән төшерә, сүзне икенчегә бора.

Кеше буларак: тормыштагы үзен тотышын, шагыйрьлеген исәпкә алмыйчарак бәяләгәндәге сыйфатларын, холкын-фигылен әйтергә кирәк булса, мин барыбер төп байлыгы, матурлыгы — аның сабырлыгы, түземлелеге дияр идем. Шулай

яшәве аңа авыр да, җиңел дәдер — анысын үзе беләдер. Һәрхәлдә ул үзенә төшкән авырлыкны егетләрчә, ирләрчә үзе күтәрә. Дулап, зарланып, ярдәм сорап, яклаучы эзләп йөрми.

Аның кешеләр белән мөнәсәбәтләрендә сирпелеп кенә торган (әбиләр чуагының мәрхәмәтле кояшы кебек!) юмор бар. Бу аның балаларга мөнәсәбәтеннән күчкән сыйфаты ахрысы. Менә ул сине тыңлый, игътибар белән, сабыр гына тыңлый. Үзе "әйе, әйе" ди, "шулай-шулай" ди; гел башын кагып, синең сүзеңне җөпләп-килешеп тора. Сөйләү кызулыгыңны киметеп, "ник үзе сүзгә катнашмый әле, тыңлап кына тора" дип игътибар итсәң, ул "әйе,шулай"ларның әллә ничә төрле интонациясе бар икәнен тоя башлыйсың. Сиңа теләктәш һәм сине хуплый ул; "сөйлә-сөйлә, мин тыңлыйм, фикеремне әйтергә ашыкмыйм, уйлыйм әле" ди аның интонациясе; "Сөйлә инде булмаганны, мин ышана дип уйлыйсыңдыр инде" дигән мәгънәне дә салып куя. Әмма барыбер аның белән сөйләшүе рәхәт — ул мәрхәмәтле тыңлаучы, сөйләүченең шулай уйларга, сөйләргә хакы бар бит дип, сиңа хәер-хак булып тыңлаучы. Әлбәттә сүзенә, кешесенә караптыр инде.

Бу сыйфатыннан күбебез файдалана, аның игътибарын, вакытын ала торганбыздыр, аңа кызыклы булмаган дөнья кадәр сүзне тыңларга мәҗбүр итәбездер. Сабырлыкка да терәк кирәк, үзеңне саклый торган чикләр-киртәләр кирәк. Якыннары зарлана торган кирелегән мин шундый "чик сакчысы" итеп, табигать биргән сыйфат дип күрәм.

Ниһаять, менә аның яше турында әйтергә чират җитте. 50 яшь — егет чак ул дип юатуга Роберт мохтаҗ түгел. Әмма аның сабыр йөрәген дә юатырга, куандырырга бик кирәк һәм бик вакыт. Аңа бирелгән дәрәҗәле исемнәрне мин дә, аның укучылары да куанып кабатлыйбыз; ул үзе дә бу бүләк-исем-дәрәҗәләрнең кадерен аңлыйдыр. Исемнәр чынлап та зур бит: Муса Җәлил, Ганс Христиан Андерсен, Абдулла Алиш һәм Габдулла Тукай.

Бик моңаеп-моңсуланып киткән чагында минем "Роберт, исемең янына тезелгән исемнәргә кара әле!" дип эндәшәсем килә; 50 яшьне үтеп киткән кеше буларак, алдагы дистә елларның үз матурлыгы, көче-егәре һәм моңнары бар икәнлегенә аны ышандырасым килә.

Хәер, аның күз алдында сүзләрдән күп мәртәбә көчлерәк булган үрнәкләр бар. Кечкенә генә чигенеш. Татарстан телевидениесендә эшләгәндә Роберт балалар өчен бик матур "Шигъри тәлгәшләр" һәм зур шәхесләргә багышланган тапшырулар оештырган, үзе алып барган иде. Гомәр ага Бәширов өендә, гаиләсендә сөйләшеп утыруларның матурлыгы — үзе бер сәнгать иде. Татар прозасында "Туган ягым — яшел бишек" кадәр сандугачлы бишек башка юктыр. Кем язган ул әсәрне?! 7 яшьтәге 70 яшьлек Гомәр — Гомәр ага Бәширов язган. Балачагы аның гомерен шулай матур итеп озатып килгәнгә күрә ул шулай бәхетле, мәрхәмәтле гомер кичерә.

50 яшь! Шагыйрьнең елларын саныйсы килми. Тезелеп очкан кыр казларын санарга ярамаган кебек, ниндидер бер саклык чаралары күрәсе, уйлап табасы килә, шагыйрьнең йөрәген яралардан аралыйсы килә.

Укучыларыңның, сине яраткан-аңлаган, хөрмәт иткән, ярдәмгә әзер торган кешеләрнең изге теләкләре, әнкәңнең догаларына кушылып, Сине яклап торсын!

Бу сүзләргә Роберт үзе алдан ук җавап биреп куйган:

Мин һаман шул шагыйрь бер җан,
Мин һаман шул хыялый.
Минем күңелгә һаман да
Сандугачлар оялый.

*Академик Мирфатих Зәкиевкә 70 яшь*

# ОСТАЗЫБЫЗ, ДУСТЫБЫЗ

Мирфатих Зәкиевне мин 1954 елдан бирле, ягъни 40 елдан артык беләм. Шул гомер безне остазның үз шәкертенә карата кечелекле һәм шәкертнең үз остазына булган ихтирамлы дуслыгы берләштерә.

Мин аның, әле яшь фәннәр кандидатының, беренче мәртәбә дәрес биргәнен күрдем. Без ул чакта 4 курс студентлары, ә ул тәүге кат дәрескә керә. Каушадымы ул, югалып калмадымы, — хәзер тәгаен хәтерләмим. Әмма аны үз итүебез һәм гадилеге, төпле белеме өчен яратып калуыбыз истә. Ә бит без атаклы Латиф Җәләй дәресләрен үткән кешеләр идек инде...

Ул мине кайчан үз итте, кайчан алар — яшь укытучылар һәм аспирантлардан торган төркем — мине үз араларына алды, моны бүген төгәл генә әйтүе кыен. Бездә марксизм-ленинизм буенча шулай ук яшь икенче бер кандидат дәресләр алып бара иде. Рәфикъ Нәфигов, бүгенге академик. Шулай ук студентларны тиң күрә торган, кечелекле, кызыклы шәхес. Ул — Уральскидан (Җаектан) килгән егет, татарча әйбәт үк белми, ләкин аның татарлыкка омтылышы гаять көчле. Мин якыннанрак танышканда бу ике шәхес үзара бик дус, алар тирәсенә бердәм төркем дә оешкан иде инде: Фәрит Хатипов, Мансур Хәсәнов, Хәлиф Курбатов, Нил Юзиев — бүгенге академиклар, профессорлар. Һәркөнне, китапханә залларында утырып арганнан соң, кичке якта сәгать унга кадәр (22 сәгатьтә радиодан кичке хәбәрләрне тыңлыйсы бар!) урамны иңләп сөйләшеп йөрүләр — бер гадәт... Маршрут — ул вакыттагы Ленин урамы буйлап Кремльгә кадәр һәм кирегә, университет бинасына хәтле... Сөйләшү темалары киң: яңа укыганнар белән бүлешү, дөнья, ил һәм милләт хәлләре хакындагы мөсахәбәләрдән башлап, кызлар һәм бу бәйрәмне кайда, ничек үткәрергә, кемнәрне арага кертергә кебек сүзләргә кадәр... Төркемнең "идеологлары" икәү: гомуми мәсьәләләр һәм дөнья хәлләре буенча — Р. Нәфигов, милли мәдәният, тормыш мәсьәләләре буенча — М. Зәкиев. Мин ялларны, күңел ачуларны ничек оештыру һәм уздыру буенча адъютант кебегрәк идем булса кирәк. "Хрущев җепшеклеге" еллары, милли аң көчәя барган вакыт... Беркадәр иркенлек алган демократия шартларында без төрле-төрле, хәтта электәрәк тыелган мәсьәләләрне дә шактый иркен тикшерә, фикерләр алыша идек. Татарга карата монарчы булган карашларның дәвам итүе безне рәнҗетә... Шуның белән бергә безнең бу төркем коры зарланып йөрүчеләрдән генә дә тормый. Бер генә мисал.

1956 елның язында Казан дәүләт университетындагы татар бүлеген ябалар, аны пединститутта гына калдыралар икән, дигән хәбәр таралды. Табигый ки, яшьләрне мондый ният бик борчыды һәм ярсытты. Шунда ук бу хәлгә түзеп тормаска, Н. С. Хрущевның үзенә хат язарга дигән фикер туды. Хатның караламасын Нурихан Фәттах язды. Аның бу нөсхәсен Лобачевский бакчасында укуыбыз, аерым формулировкалар буенча бәхәсләшүләр истә калган. Кыскасы, хат камилрәк хәлгә китерелде, саллы дәлилләр белән Татарстанда гомумән милли сәясәтнең дөрес алып барылмавы турында әйтелде. Төркемдәгеләрдән тыш киңрәк җәмәгатьчелекне тарту өчен хатка күбрәк кул куйдыру Н. Фәттах белән миңа тапшырылды. Бер сүзсез кул куючылар, шүрләп калып баш тартучылар да булды. Хәтерлим, нәшрият бүлмәләрендә йөргәндә шунда хезмәт итүче, иҗатында күтәрелеп килүче бер яшь шагыйрьнең кул куюдан баш тартуы безне бик рәнҗеткән иде...

Хатның тәэсире булдымы икән, КДУ да татар бүлеге ябылмый калды. Әмма безне, хатка кул куючыларның барысын да, партия өлкә комитетының мәдәният бүлегенә җыеп "бик һәйбәтләп" сөйләшкәннәр, татарларны кысу

юклыгын, киресенчә, безгә иркенлекләр мул бирелгән булуны "яхшылап аңлатканнар" иде.

Безнең бу "хатабыз" алдагы язмышларыбызда алай артык сизелде дип әйтә алмыйм. Шулай да бөтенләй дә эзсез узды, дисәң дә дөрес үк булмас. Мәсәлән, Р.И.Нәфиговны шул чорларда киң таралган хәрәкәткә кушылырга — шәһәрдән колхоз җитәкчеләре итеп җибәрү эшенә тартырга, Казаннан ераккарак олактырырга тырышып кат-кат басым ясалды. Кул куючылар арасында аспирантка Ләлә Зарипова дигән бер туташ та бар иде. Берничә елдан соң аны комсомолның өлкә комитетына секретарь итеп сайлату мәсьәләсе килеп чыга. Шул вакытта анар "теге хат" исенә төшерелә. Мин, университет тәмамлагач, аспирантурага керергә гариза биргән идем. Якуб ага Агишев, яраткан укытучыбыз, сер итеп кенә миңа әйтте: "Аспирантура бүлегенә: ә беләсезме, ул бит күмәк хатка кул куйган кеше, укырга алырга ярамый, — дип шалтыратканнар. — Син, иң яхшысы, гаризаңны кире ал да, Казаннан тай, сиңа рәтле тормыш күрсәтмәсләр", — диде. Мин шулай эшләдем дә. Җае да чыкты, Тобол пединститутына укытырга китеп бардым.

Ләкин төркемнең мондый эшләре моның белән генә бетмәгән икән. Әле моннан соң да бер күмәк хат оештырыла. Монысы — опера һәм балет театрына Муса Җәлил исемен бирү турындагы үтенеч-хат...

Мин Казанга әйләнеп кайткач та остазым белән очрашулар дәвам итте. Әмма инде бу дуслык икенчерәк рух алды. Кичәге ялгызаклар бүген барыбыз да башлы-күзле булганбыз. Инде гаилә дуслары булып яши башладык.

Шәхес асылда сугыш кырында һәм хезмәттә сынала. Ләкин аның сынала торган тагын бер өлкәсе бар, бу — дуслык.

> "Дус" сүзе бары бер иҗекле генә...
> Ә мәгънәсе — чиксез һәм тирән, —

дип яза Р.Фәйзуллин. Әйе, кеше дуслыкта да сынала. Бу сынауны да һәркем уңышлы уза алмый. Шуның аркасында без яшьлектәге һәм кичәге күпме дусларыбызны җуябыз.

Шөкер, безнең — остаз белән шәкертнең — дуслыгы сынауларны уңышлы



*Мирфатих Зәкиев (уңда) һәм Азат Әхмәдуллин. 1997 ел.*

узарлык нык булып чыкты. Хатыннарыбызның холыклары туры килеп, берсен-берсе хөрмәт итешүе дә аны ныгытты, ничәмә еллар саклап тотарга ярдәм итә. Бергәләп туган якларга кайтып йөрүләр, Балтыйк дингезе буенда ял итү, театрларга йөрү, спектакльләр, концертлар турында мөсәхәбә кылулар, туган көннәрне уздырулар — һәммәсе безгә рухи байлык өсти, канәгатьлек бирә. Без атналар, хәтта айлар буе, үз эш-хезмәтебезгә батып, аралашмаска, хәтта телефон аша хәл белешмәскә дә мөмкин. Аның каравы очрашу-күрешүләр шулкадәр сагындырган, аралашу ләззәтлерәк була.

Мин дустым һәм остазымны хезмәт баскычының төрле басмаларында күрдем. Әмма шәхес буларак та, дус төсендә дә ул тамчы да үзгәрмәде, үзе булып — гади һәм гадәти, эчкерсез һәм киң күңелле булып кала бирде. Кафедра мөдире, пединститутта проректор һәм озак еллар буе ректор, Татарстан Югары Советы рәисе, Г. Ибраһимов исемендәге институтның директоры, Татарстан Фәннәр академиясенең оештыручыларыннан һәм җитәкчеләреннән берсе — бу баскычлар һәм дәрәҗәләр аның менәзен (характерын) дә, үз-үзен тотышын, кешеләргә мөнәсәбәтен дә үзгәртмәде-бозмады. Алар аның миңа һәм гаиләмә булган дуслык җепләренә дә аз гына да зыян салмады.

Шәхси тормышында Мирфатих Зәкиев — җыйнак, эшчән, тәртипле, һәрвакыт ачык-тигез мөнәсәбәттәге кеше. Соңгы елларга кадәр ул авырып урын өстендә ятуны белмәде. Физик эштән тайчанмады, алай гына да түгел: ул физик эштән тәм таба, ләззәт ала. Дача йортымы, мунча салумы, машина ремонтлаумы, үз хезмәтләрен машинкада басумы (ул машинка тузып-искергәч, аның тышлыгын дермонтин белән тышлап куюмы), фатирын ремонтлаумы — һәммәсен үзе эшләде һәм эшли. Бу яктан ул дус-ишләр арасында үрнәк. Минем хатын да еш кына аны миңа: әнә, Мирфатих! дип үрнәк итеп куя. Әйе, эштә батыр ул, "булмый", дип тормый. Бер генә мисал. Хәзерге Пушкин урамында педагогика университетының ике гомуми торагы төзелү тарихын хәтерлим. Ул биналар Кабан күленең Академия театрына каршы ягындагы "долгострой" белән бер вакытта төзелә башлаган иде. Характерлы бер деталь: субайларны каккач, аның җир өстендәге артык өлешләрен кисеп ташлау проблемасы килеп баса. Төзүчеләр аптырашта, — техника юк, кайчан була әле?! Шул вакытта ректор артык өлешләрне кувалда чүкечләр белән бәреп ватуны тәкъдим итә, берничәсен үзе ватып та күрсәтә. Кабан күле янындагы бина һаман төзелеп бетә алмый әле; ә КПДУ тулай торaклары, аның ул вакыттагы ректорына һәйкәл булып, инде дистә еллар утыралар. Ничәмә мең студентлар — кичәге авыл балалары — аларны икенче туган йортлары итте.

Хәер, Мирфатих дусның аптырап-гаҗиз булып калуын бер мәртәбә күрергә туры килде миңа. Күптән инде, әле балалар кечкенә вакытта без — өч гаилә — Мари урманнарына гөмбәгә барган идек. Зур, адаштыргыч урманнар... Балаларны гына күз уңында тотып без Лена белән Гөлҗиһанның бик эчкә кереп китүен абайламый калганбыз. Чабышып эзләнүләр, кычкыру-чакырулар, файда бирмәде. Җитмәсә, минем машина ачкычы багажникта бикләнеп калган; ни ишекләрне ачып, ни машинаны кабызып булмый. Минем мәсьәләне Мирфатих дус җиңел хәл итте. Башыма да килмәгән тәкъдим ясый: "Рөхсәт ит, багажник йозагына каты итеп тибеп карыйм, ачылырга тиеш", ди бу. Чыннан да, типкәч, багажник ачылды. Ә менә ике ханымның озак табылмавы аны тәмам пошаманга төшерде, каушады, борчылды. Ләкин ул гасабилануын балаларга сиздермәскә тырышты. Бәхеткә, Лена ханымнар табылдылар...

Көндәлек тормышта Мирфатих гаилә әгъзаларына да, дусларга һәм башка кунакларга да тигез мөгамаләдә, дидем. Ләкин бу аңар кирәк дип тапканда кырыс һәм турыдан ярып әйтергә һич тә комачауламый. Мондый вакытта ул кәнфитләнеп тормый инде. Ләкин аңар моның өчен үпкәли алмыйсың, чөнки ул үзе үпкәли дә, кер саклый да белми. Музыка ярата. Үзе тальян гармунда уйный, яратып һәм әйбәт уйный. Кеше уйнаганын да — баяндамы, пианинодамы, скрипкадамы — бирелеп тыңлый. Җырларга һәвәс, бигрәк тә үзе уйнаганда җырласалар, ләззәтләнә, дәртләнә.

Безнең төркемнән ул иң беренче булып өйләнде, беренче булып уллы булды. Хәтерлим, мин Тоболдан кайтып өйләнгәч, без бер компания булып

(Мирфатих, Рәфикъ, хатыны Разия белән Мансур, Нил) хатыным Фираяларның алты сутыйлы бакчаларында кунак булдык. Кунарга шырпы тартмасы кебек кенә өйнең тавык кетәклеге кадәр генә чормасында бер рәт булып тезелешеп яттык. Истәлекләр булды, мәзәкләр сөйләнде. Ләкин ни турында гына сүз бармасын, яшь эти Мирфатих сөйләшүгә үзенең кечкенә улы Рөстәмне китереп кыстырды, үзенең әти булуы белән горурланып безне көлдереп тә, туйдырып та бетерде. Аның тыныч-салмак һәм сагышлы тавыш белән: “Менә аны кочагыңа аласың да, менә болай итеп кысасың... сез әле аның тәмен-ләззәтен белмисез... кая ул сезгә...” дигән сүзләрен без әле дә көлешеп искә алабыз...

Мирфатихны без яшь чакта ук логик фикерләү көче өчен хөрмәт итә идек. Логик эзлеклелек һәм иҗади хезмәт дәрте аны фән юлыннан чагыштырмача тиз үстерде. Ул вакытыннан алда кандидатлык диссертациясен яклады, ә тугыз елдан инде фән докторы булды. Татар теле белгече буларак тиз арада галимнәрнең иң алдынгы сафларына чыкты, бөтен союзда, бигрәк тә төрки телләре галимнәре арасында киң танылды. Хәзер инде менә ничә дистә ел бу өлкәдә ул иң зур абруй һәм оештыручы дип санала. Ләкин тынгысыз эзләнүче буларак тел өлкәсе белән генә чикләнмәде, татарның чуалып-буталып беткән тарихын, килеп чыгышын тел материаллары җирлегендә тикшерү эшенә алынды һәм монда да өр-яңа концепция булдырды. Бу концепция рус һәм көнбатыш тарихчыларына сукырларча ияргә торган галим-голяма тарафыннан кабул ителеп бетмәсә дә, логик бөтенлеге һәм ачыклыгы белән күпләрне үзенә җәлеп итә, көннән-көн тарафдарларын арттыра бара. Ә бит бу концепцияне М. Зәкиев меңәрләгән чыганакләр, китаплар укып-өйрәнеп һәм татар теленең үз закончалыклары ноктасыннан чыгып төзеде. Гаять киң эрудиция, белем тирәнлеге белән бергә күп хезмәт вакыты да сорый торган эш ул.

Мирфатихның эш стиленә сокланам мин. Иртәнге сәгать биштә инде ул — эш өстәле артында. Рәсми эш урынына киткәнче ул инде дөнья кадәр эш эшләгән була: укый, яза, шул сәгатьләрне физик күнегүләр, гаилә мәшәкатьләре белән бәйләп алып бара. Кичен, хезмәт урыныннан кайткач, кыска вакытлы ялдан соң ул — тагын өстәл артында. Көйләнгән машина кебек. Бу ритмның төгәл саклануына аңар Лена ханым зур ярдәм күрсәтә.

Минем үземә берәр рәсми хат язар өчен дә әллә никадәр вакыт һәм үземне моңа алдан көйләү кирәк була. Дустым мине бервакыт бу яктан да таң калдырды. Үзләрендә нинди дер уңай белән сыйланып утырганда, сүз ияргә сүз чыгып, минем (ул вакытта Г. Ибраһимов исемендәге институт дирекциясе вәкиле буларак) әдәбият буенча хәзерләнә торган зур бер конференция эше өчен Төрекмәнстандагы тел-әдәбият институты белән бәйләнешләрем җитәрлек булмавы турында әйтелде. “Ә, аның директоры — минем яхшы таныш, мин аның докторлыгын яклаганда оппонент булган идем, кире какмас, әйдә, хат язабыз”, — диде хуҗа һәм шунда ук хатны язып та бирде. Атна-ун көннән төрекмәннәрдән уңай җавап килгән иде инде...

Менә шундый җәһәтлек һәм тәвәккәллек, эшне һәр барчасыннан алда кую — М. Зәкиевнең гадәти эш алымы. Шунсыз, билгеле инде, ул кадәр фәнни хезмәтләрне иҗат итү мөмкин дә булмас иде. Аларны тулаем алып караганда зур бер коллектив түгел, ә бары бер кеше башкарганына ышануы да кыен...

Шундый бәхетле дуслыкны мин һәркемгә телим.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН,**
Казан дәүләт университетының
татар әдәбияты кафедрасы мөдире.

Китап күзәту

# САБАН ТУЙЛАРЫНДА — ХАЛКЫБЫЗ АСЫЛЫ

Татар бүген, егерменче гасыр азагында, мәңгелектән килүче Вакытның яңа чоры дип йөртелгән чорның ике меңенче өлеше түгәрәкләнеп килгәндә, уйлана:

— Без кемнәр булганбыз? Бүгенгә кемнәр булып килеп життек, турырак әйткәндә, без кемнәргә әвереддек, үзебез булудан туктап барабыз түгелме? Асылыбызны ачыклыйк, үзебезне табыйк...

Бер без генә түгел, башка халыклар да шундый гамь белән яши.

Һичшиксез, милли кыйбла табылырга тиеш. Бәхәссез, аның нигезендә милли үзлегебез, милли асылыбыз ятарга тиеш.




Дамир Шәрәфетдинов үзенең "Сабан туе" исемле китабын "халкыбызның яшәеше" дип шәрехләгән. Китап дәүләтебезнең ике телендә: татарча һәм урысча язылган. Урысча әйтелештә: "Сабантуй — образ жизни народа". Татарча өлеше үзебез һәм якын төрки туганнар өчен булса, урыс теле аркылы татар халкының яшәеше хакында башкаларга да сөйләп бирелә.

Асылның, үзлеген-үзгәлеген, үзенчәлеген-барлыгын — нәрсә ул? Ул — гореф-гадәтен, йола-бәйрәмнәрен, гамәл-шөгыльләрен, гыйлем-һөнәр эстәү һәм эшхезмәт тәртибен, дәрәҗән... Шуларда синең барлыгың, үзгәлеген, үзгәңнен ныклыгы...

Китап шул хакта. Ничек яшәвебез хакында. Менә аның эчтәлеге:

— Халык бәйрәмнәре.
— Борынгы йоланың яшьлеге.
— Гасырлар кайтавазы.
— Сабан туеннан — Бөтендөнья уеннарына.
— Сабан туе киләчәккә атлый.

Милли йолаларыбыз турында языла килгән. Бик борынгыдан ук. Төрки бабаларыбыз дөньяда күрекле булганнар. Үзләре дә язганнар, аларны күргән, белгән халыкларның вәкилләре дә язып калдырганнар.

Шулай да гасырлардан килгән тарихыбызның эзлекле, тәфсилле, томнарга тупланган язмасы әлегә юк. Әмма ул тарих бар. Татар бугазыннан алып, Гибралтар бугазына, Ерак Шәрыктан Ерак Гарепкә, халыкча әйтсәк, Мәшрикътән Мәгърибкәчә төрки-татар катнашмаган вакыйга, гореф-гадәт, эш-гамәл юк кебек. Безнең тарих кытай, япон, монгол, һинд, урыс, грек, гарәп, фарсы, испан, итальян, француз, герман сәүдәгәрләре, сәяхәтчеләре, рухани-сәясәтчеләре, хөкемдарлары, елъязмачы-язучылары, тарихчылары, телчеләре һ.б. әһелләре тарафыннан теркәлгән. Без шуларны эзлибез, таба торабыз, тарих итеп яза киләбез.

Д. Шәрәфетдинов китабы да шул бай мираска таяна, шуннан тамырланып, үсеп чыга, аны гыйльми эшкәртеп, шул нигездә, шул корылмага яңа ташбүрәнәләр өсти, тамыр-үсентеләрнең гасырларда үсешен-яңарышын күзәтә, бүгенге дәрәҗәсен барлый, киләчәген планлаштыра.

Бу китапның язылу тарихы гыйбрәтле. Автор — белеме, хезмәт юлы, шөгыльләре белән — филолог-мөгаллим, журналист-язучы, архивчы-галим, көрәшче-батыр, спортчы-судья. Ул үзе дә Сабан туе мәйданыннан.

Миңа шулай тоела: бер мәлне ул үзенә: "Бу бәйрәм кайчан барлыкка килгән, кайдан, кемнәрдән килә? Нигә кирәк булган? Мәйдан уртасында басып торучы мин — кем?" — дигәнрәк уйлар-сораулар биргәндер.

Инде менә шундый ук сорауларны Көн, Заман, Киләчәк үзе куя. Кызыксыну мәҗбүрияткә әверелә. Гомер буе эзләнгән-язылганнарны халыкка җиткерү бурычы туа. Бу китап — кеше табигатенең эзләнүе, ихтыяҗы җимеше. Иҗади, тырыш шәхеснең максатчан, үҗәтлек белән еллар дәвамында хезмәт куюы нәтиҗәсе.

Авторның халәте — милләт халәте.

Авторның җегәре — милләт җегәре.

Ирексездән гасыр башыннан билгеле бер тарихи сөйләшү, тарихи барлау искә төшә.

1921 елның март ае. Татарстан Республикасына әле бер яшь тә тулмаган. Татарстан делегациясе Совет хөкүмәте башлыгы Владимир Ильич Ульянов белән очраша. Якташлар очрашуы була бу.

— Әйтегез әле, безнең татар әдәбияты белән эш ничек тора? Әлеге... ни атлы соң... Мулла улы... Пушкин, Лермонтов әсәрләрен үз туган теленә тәрҗемә иткән... Габдулла, Габдулла..., — дип исенә төшерергә тырыша Ленин.

— Тукаев! — дип әйтеп куйдым, дип яза истәлек авторы Владимир Бахметьев.

— Шагыйрьнең эшен лаеклы дәвам иттерүчеләр бармы соң? —дип төпченә ил җитәкчесе. Бахметьев берничә яшь татар язучысының исемен әйтә.

— Димәк, базда дары бетмәгән әле! — ди Ленин, елмаеп, канәгать булып.

Совет чоры кешеләренә бу бик билгеле факт. Мин аны 1975 елда Равил Фәйзуллин төзеп чыгарган "Тукайга чәчәкләр" дигән җыентыктан китердем.

Ул көннәрдән соң сигез дистәгә якын ел узган. Без бүген дә Татарстан дәүләтен төзү мәшәкатьләре белән мәшгуль. Алда торган бурычлар шулар ук:

— Татар телен дәүләт теленә әверелдерү;

— Ата-баба горефе белән яшәүгә кайту;

— Милләт буларак сакланып калу...

"Сабан туе" китабын язган Дамир Шәрәфетдинов өчен ул дистә еллар өзек ара түгел. Ул үз гомеренең дүрт дистә еллары буена туган халкының яшәү рәвеше белән яши, шул яшәешне саф килеш дәвам итүне хаклап мәкаләләр яза, җыентыклар чыгара.

"Сабан туе" китабы Бөтендөнья татар конгрессының II корылтаена чыгып өлгерде. Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүнең 7 еллыгына чыгарылды. Авторның туган җиренең, иленең борчу-мәшәкатьләре белән яшәве, аларны яңа заманга, киләчәккә яраклы итеп чишә баруда шәхси өлеше, катнашуының бер чагылышы булды бу китап.

Татар — дөньякүләм халык. Безнең татарлыгыбыз татарча сөйләшүебездә, татарча яшәү рәвешебездә. Америка татары белән Австралия татары, Сахалин белән Донбасс татары — кыскасы, төрле кыйтгаларның төрле төбәкләрендә көн күрүче татар халкының бер үк йолаларны тотып, бер үк бәйрәмнәрдә бәйрәмләшеп, бер рух, бер дәрт, бер моң, бер җыр белән яшәвендә.

Сабан туебыз кайда да сабан туе. Китапта шундыйрак аталган аерым бүлек бар хәтта: "Сабан туе — ул Киевтә дә сабан туе". Сабан туе — татарның үзенә бер төрле корылтае ул, бер-берене таныта, таныштыра, берләштерә торган корылтай.

Дамир Шәрәфетдинов болай яза: "Традицияләр һәм йолаларның тәрбияви әһәмияте безнең республика шартларында бүген, Татарстанның яңа Конституциясендә ныгытылган дәүләт суверенитеты турындагы Декларациясен эзлекле рәвештә тормышка ашыру дәвамында, халкыбызның рухи яңаруы барганда аеруча арта.

Гореф-гадәтләр һәм йолалар суверенитет идеяләрен тирәнтен аңлауга һәм үзләштерүгә, аларны уй һәм гамәлләребезгә әверелдерүгә, туган республикабызда бара торган һәр нәрсәгә катнашабыз барлыгын тоюдан горурлык тәрбияләргә булыша.

Бездә хәзер бәйрәм көннәре һәм истәлекле көннәр турында дәүләт кануннары бар. Бу — аларның кайберләренә дәүләт статусы бирелде дигән сүз. Шактый кызыклы күренеш. Кайберләренә генә. Алар — дәүләт тарафыннан халыкка тәкъдим ителгән бәйрәмнәр. Арада халыклашып өлгергән бәйрәмнәр дә бар. Корбан, Раштуа бәйрәмнәре кебек. Борынгыдан килгән үз бәйрәмнәренә халык иң зур статусны — халык статусын биргән. Алар халык кануннары буенча туа, үзгәрә..."

Гореф-гадәтләр, йолалар ничек канунлаша, үзләренә генә хас, халык иҗатына хас бөтенлекне нинди тамырлардан ала? Дамир Шәрәфетдинов бәйрәмнәребезнең ничек оештырылуы, ничек үтүе турында авылдан-авылга күчеп, иркенләп, илһамланып яза. Әйтик, өр-яңа бәйрәмебез — Республика көне — 30 август тантаналары турында ул: "Татарстан Республикасы игълан ителгән көн халкыбызның иң матур, иң истәлекле бәйрәменә әверелде. Мондый феноменның сере нәрсәдә? Барыннан да элек — аның идея эчтәлегендә ", — дип яза һәм фикерен раслап санап китә: беренчедән, икенчедән, өченчедән...

Кеше, халык, милләт рухының төп хасияте — азатлыкка, хөрлеккә омтылу. Аның гасырлар дәвамында канунлашып килгән барлык йолалары, бәйрәмнәре рухының азатлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Республика көне — Татарстан улларының, кызларының, гасырлар дәвамында бергә яшәгән бар халыкларының рухына туры килгән баш бәйрәме.

"... Тарихны ничек булган, шулай кабул итәргә кирәк", — дип искәртә автор. Ә тарихи факт шундый: Иван Грозный тарафыннан 1552 елда Казан ханлыгы басып алынгач, Октябрьгә кадәр Россия патшасы титулында "Казан патшасы" дигән сүзләр сакланып килде. Һәм бу — патша таҗының символик бер атрибуты гына да түгел иде. "1552 елда Казан ханлыгы руслар тарафыннан басып алынганнан соң, аның халкы — хәзерге татарлар — өч ярым гасыр дәвамында патша хакимиятенең даими рәвештә эзәрлекләвеннән торган авыр юл үтте..." Тырнаклар эчендәге соңгы җөмлә Т. Дәүләтшинның 1974 елда Лондонда чыккан "Советский Татарстан" исемле китабыннан алынган.

"Октябрь инкыйлабы тарафыннан уятылган һәм демократик Россия белән бергә чын, нык һәм ышанычлы федерация төзергә теләүче элек изелгән халыкларның мөстәкыйльлеккә туктаусыз хәрәкәтен беркем дә туктата алмаячак. Заманның таләбе һәм йөзе шундый", — дигән нәтиҗә ясый Дамир Шәрәфетдинов.

Кемгә нинди уйлар киләдер, авторның тарихи йолаларыбызның тууын, бәйрәмнәргә әверелүен тасвирлаган язмаларын укыганда минем үземә шундыйрак фикер дә килде:

— Бездә октябрь ае башында Хәтер көннәрен уздыру бар. Бу әле башлангыч хәлендә, һаман энтузиазм рәвешендә бара. Аны рәсми төстә уздыруны даулап йөрү дә бар. 7 ноябрь (25 октябрь) татар халкы өчен азатлык яулаучыларны искә алу көне түгелмени? 1552 елның 2 октябреннән эстафета шунда сузыла. Әле безнең Җиңү көнебез — 9 май да бар. Монысы да Ватан азатлыгын саклап һәлак булганнарны хәтерләү көне бит. 25 октябрь Россия Президенты Указы белән федерациякүләм истәлек көненә әверелдерелгән. Файдаланыйк булмаса, татар россиякүләм халык ич. Хәтер көненә бар дөньядан Казан Кремленә генә җыелырга димәгән. Кайда татар, шунда Хәтер көне (бәлки Янарыш көнедер) үткәрелсә, дөресрәк тә, тәэсирлерәк тә булмасмы?

Гореф-гадәт, йола дигәндә ниндидер искелардән калган нәрсәләр күз алдына килә. Чөнки озак вакытлар йолалар онытылып торды, яналары урнаштырылды. Хәзер онытылып торганнары кире әйләнеп кайта, кичәге-бүгенге бәйрәмнәребез яңа эчтәлек ала. Бу хакта "Сабан туе" китабында тәфсилләп сөйләнә. Казан, Азнакай, Әлмәт, Алабуга, Чистай... Авыллар, шәһәрләр... Һәрберсендә ниндидер яңалык, үзенчәлек... Ә бәйрәмнәребез — бер, бердәм... Җиңүнең 50 еллыгын уздыру, мәсәлән, "тормыш рәвешебезгә патриотик йола-гадәтләрне кертә баруга этәргеч булды", "... бәйрәм үзе чын мәгънәсендә бөтенхалык тантанасы һәм

сагыш, һәм кайгы бергә катнашкан тирән дулкынландыргыч йола булып әверелде" дигән нәтиҗә ясала.

Өстән игълан итеп кертелгән бәйрәм генә түгел идеме соң Җиңү бәйрәме? Сугыш — һәр халыкның, һәр гаиләнең, һәр кешенең җелегенә үткән, балаларыбызның канына күчкән зур фаҗига. Шуңа бәйле һәр истәлек-хатирә, һәр эш-гамәлебез гадәтебезгә әверелә, йола төсен ала. Халык үз тарихыннан, үз милли гадәтләреннән килгән әхлакый нормаларын шул йолага туплый. Аның мәҗүси, дини, дөньяви яшәеш күнекмәләре рәсми бәйрәмнең эчтәлеген билгели, шул бер йолада канунлаша.

Бу бәйрәм Указ, Декрет, Карар белән генә түгел, шул фаҗигане кичергән, сугыш афәтен җиңгән халык җаныннан алып игълан ителгән.

Бәйрәм, гореф-гадәт, йола, дибез. Шулар белән яшибез дә. Ә нинди йолаларыбызны беләбез икән? "Сабан туе" китабын укып, үзебезне тикшерә алабыз: дәүләткүләм бәйрәмнәр, календарь йолалар, гаилә йолалары. Әйтик, календарь йолалар: язгы-җәйге, көзге-кышкы гореф-гадәтләр һәм йолалар. Әти-бабаларыбызның яшәү рәвешендә барлыкка килгән, гасырлар дәвамында чарланган, камилләшкән, тормыш алып бару, нәсел-ыруны үстерү-ишәйтү, көн күрү, табигать шартларына ярашу кебек яшәү кануннарыбыз. Алар сынау узганнар, күңелгә якыннар.

Мин — совет чоры кешесе, татар авылы баласымын, китапны үземне сынап укыдым, әйтәм: юкка үзебезне битәрлибез, гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз, бәйрәмнәребез үзебез белән, күңелләребездә, көнкүрешебездә икән. Бозны да озаттык, карга туйлары да уздырдык, яңгыр боткасы да пешердек, каз һәм тула өмәләрен дә күрдек, аулак өйләргә дә йөрдек.

Яшьләребез белмиме? Аның каруы, алар бабалары белмәгәнне беләләр. Белгәннәре гел начардан гына да тормый. Дамир Шәрәфетдинов китабы кебек китаплар яшьләр өчен — ата-бабалар тәҗрибәсе, гасырлар буе күп буыннар камилләштергән рухи-әхлакый кануннар. Әлеге китап үзенә бер төрле сүзлек-белешмә, билгеле бер күләмдә энциклопедиябез була ала.

Автор: "Киләчәккә юнәлгән халык традицияләре, яңа әхлакый һәм сәнгатьчә эчтәлек белән байый барып, халыкның яшәү рәвешен тәшкил итәләр. Алар мөһим тәрбия чарасы булып торалар. Бу җәһәттән Сабан туебыз аерым игътибарга лаек", — дип яза.

Күпгасырлы, бай традицияле, шул ук вакытта мәңге яшь милли бәйрәмебез ул Сабан туе!



Безнен Сабан туебыз халкыбыз гореф-гадәтләреннән, йолаларыннан, традицияләреннән, ышануларыннан, мәҗүси һәм дини карашларыннан, мәңгелек көнкүреш тәҗрибәсеннән үрелеп барлыкка килгән, китапча итеп әйтсәк, квинтэссенция, бер феномен. Бәйрәм дию генә аның өчен таррак. Туй атамасына да сыешмый ул. Әйе, бүген дә ул — йола. Табигатьнең яшьлеге, уянуы, язгы кыр эшләре белән бәйле йола. Шул ук вакытта ул —уңыш бәйрәме, хезмәт туе да. Ул җир куенына салынган орлыклардан мул уңыш үсүен теләүгә, Күктән, Кояштан, Җилдән-Янгырдан мәрхәмәт сорауларга бәйләнешле гореф-йолаларны да эченә ала кебек.

Ә ат чабышлары? Баш батырны тәкә биреп зурлау? Колга очындагы әтәч? Иң соңгы килгән атка бүләк бирү? Нәзер аты?

Мондый йолалар һичшиксез борынгыдан, аларда — әби-бабаларыбыз рухы. Сабан туенда катнашу, сабан туе рухы белән яшәү — ата-бабаларыбыз рухына, мәңгелеккә, тамырларыбызга кушылу ул.

Һәрберебез сабан туенда булган, катнашкан, күргән, кичергән... Сабан туйларыбыз безнең, китаптагыча итеп әйтсәк, хезмәт мәйданы, дуслык мәйданы, спорт һәм сәламәтлек бәйрәме, сәнгать бәйрәме, рухи сафлану көне. Автор сабан туйларыбызны иләк аша или, аларга Олимпия уеннары биеклегеннән күз сала, күршеләр, чит-ят халыклар хөкеменә куя. Гасырлар сынавы аша үткәрә. Иң мөһиме — үз халкыбызның мөнәсәбәте аша тикшерә. Сабан туйсыз авыл булмаска тиешле. Оештыручысы — халык үзе: житәкчесе-хадиме, хакиме, бае-ярлысы, көрәшчесе-тренеры, музыканты-язучысы, ат караучысы-көтүчесе, сәүдәгәре, әзергәбәзере, кыскасы, яше-карты...

Бу — безнең халыкыбыз турындагы китап. Каһарманнары, балаларыбыздан алып картларга кадәр, үзебез: туган табигатебез, мал-туарыбыз; авылларыбызшәһәрләребез; көрәшчеләр, узышчылар, авырлык күтәрүче пәһлеваннар, зирәкләр, булдыклылар-уңганнар, һөнәрлеләр, житезләр, жыр-бию осталары, шагыйрьләречәчәннәре...

Монда җиңүгә омтылыш, тәртиплелек, көндәшкә хөрмәт, ярышу-тартышу әхлагы, үзе ярыш — үзе уен, димәк, уены-чыны бергә... Хәрәкәттәге халык... Сабан туе — үзе бер дәүләт тормышы кебек ул: хакимияте, кагыйдәләре, казыйлары, каһарманнары һәм гавамы, тәртип сакчылары белән...

"Һәм, әлбәттә инде, — дип дәвам итә автор, — Сабан туе безнен язучыларыбыз, рәссамнарыбыз, композиторларыбызның илһам чыганагы булып әверелде. Ул Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Еники, Н. Фәттах, М. Мәһдиев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим Р. Мөхәммәдиев, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Р. Миннуллин, Р. Вәлиев һәм башка татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗатында чагылыш таба.

"Сабан туе" — үзенең икенче симфониясен Н. Җиһанов шулай дип атады. Бу темага Ш. Шәрифуллин симфониясен, Ф. Әхмәтов, З. Хәбибуллин шул исемдәге әсәрләрен багышладылар. Сабан туе рәссамнарыбыздан Б. Урманче, Л. Фәттахов, Т. Хаҗиәхмәтов, И. Әхмәдиев, И. Колмогорцева, Н. Адылов һәм башкаларның иҗатларында урын алды. Мәсәлән, белгечләр Лотфулла Фәттаховның "Сабан туе" әсәрен сугыштан соңгы татар рәсем сәнгатендә иң күренеклеләр рәтенә куялар".

Җитмешенче еллар азагында, торгынлык һәм милли нигилизм чорында рәссамнар югалган кыйммәтләр, халык көнкүрешенең үлеп барган матурлыгы, үзлекне юксыну турында фәлсәфи уйларын чагылдырдылар. Әйтик, А. Абзгильдинның "Капчык киеп йөгерү", Б. Урманченың "Сабан туе", В. Федоровның "Сабан туе" дигән сюжетларында сабан туе күренешләре, күңел ачу тамашалары булудан бигрәк, уйларга сала, моңсулык иңдерә. Ш. Шәйдуллинның "Сабан туе"нда милли колоритлы кешеләр арасындагы курайчы малай образы аша, элеккеге рәсемнәрдәгедән аермалы буларак, беренче мәртәбә мәдәнилек —рухилык, милли мирас, бабаларыбыз дөньясының гүзәллеге мәсьәләләре куела. Ә инде сиксәненче еллар уртасында "милли жанлану"дан башлап сабан туе сюжетлары халыкның рухи уянуы һәм иҗтимагый гайрәте турында сөйлиләр. Рәсемнәрдә билләрен сөлге белән буган, идеаллаштырылган Алыплар калка, иярләрендә нәфис батырлар утырган нечкә сыйраклы атлар басып килә, халык көйләре

"яңгырап тора", — кыскасы, тамаша үлемсез баһадир — халык, аның үткәне һәм бүгенгесе турында шагыйрәнә миф-риваятькә әверелә. (Р. Вахитов. "Болгар җире турында сюита". Триптих"). Ә Р. Заһидуллинның "Сабан туе" һәм Ә. Мәҗитовның "Бәйрәм" дигән әсәрләрендә үзенең суверенитетын һәм кешелек хокукларын яклауга күтәрелгән татар халкының көч-куәте, "мәйдан энергиясе" ташкыны агыла.

Сабан туе — безнең визит карточкабыз да. Ул күршеләрне дә, ерактан кунакларны да, илчеләрне дә үзенә кабул итә, күңелләре булганчы кочагында тота. Сабан туенда бер булган, бәйрәм иткән кеше аңа карата битараф кала алмый. Ул һәркемне бердәй әсир итә. Бу бәйрәмебез турында, гомумән, татарның гореф-гадәтләре, йолалары хакында сүзе-фикере булганнарга, шул исәптән, алардан кер эзләгәннәргә дә китапта урын бирелә. Без бит киң дөньяда үзебезгә лаеклы урыныбызны даулыйбыз, "дөнья һәм без" — бүген актуаль тема... Дөнья күзгесендә без нинди булып күренәбез? Китапны язган Дамир Шәрәфетдиновның үз хезмәтенә куйган таләпләренең берсе шул сораура да җавап табу кебек. Бу кадәресе үзе генә дә — зур һәм үтә кирәкле хезмәт.



Китапка "Сүз башы" язган профессор Булат Солтанбәков шундый истәлеге белән уртаклаша: "Танылган француз политологы, журналист һәм язучы Кенизи Мурад, Каенлыкта узган Казан сабан туенда булганнан соң, соклануын шундый сүзләр белән белдерде: "Сабан туе — могҗиза ул! Сез бу бәйрәмдә катнашучыларга һәм аның кунакларына карагыз әле, алар көндәлек мәшәкатьләрен, бөтен проблемаларын өйләрендә калдырганнар. Мин аларның йөзләрендә искиткеч шатлык, күңел көрлеге һәм миһербанлык күрдем", — диде.

Ә соңрак, без Парижда очрашкан вакытта, ул милли бәйрәмнәребезне искә алып, фикерен тагын да ачыклый төште. Аның уенча, сабан туе, җәдитчелек — исламдагы дөньяви мәгърифәтчелек хәрәкәте — кебек үк, татар халкының гомумкешелек кыйммәтләре хәзинәсенә керткән лаеклы өлеше ул... Үзенең шәҗәрәсендә Мөхәммәт пәйгамбәр һәм төрек солтаннары токымы геннары кушылган кешенең, Шәрык белгеченең шундый бәясе белән килешми мөмкин түгел".

Белгеч бәясенә без, әлбәттә, кушылабыз. Сабан туен бер бәйрәм генә итеп күргәч, белгән кеше өчен бу — кешелек хәзинәләренә безнең бер өлешебез. Ә сабан туйларына җаны-тәне белән береккән, татар мәдәнияте турында белем-мәгълүматлы китап авторының фикере киңрәк, төгәлрәк: "Сабан туе — татар халкы яшәешенең мәңгелек Вакытның бер фасылында табигать-анабыз кочагында гәүдәләнеше ул".

Тормыш — театр, анда һәр кеше үзенең ролен башкара дигән фикер дә бар. Әмма бу фикердә эчке бәйләнештән формаль охшату күбрәк сыман. Ә сабан туебыз бит — тормышның рәвеше, без

шулай яшибез: хезмәт итәбез, ярышабыз, җинәбез-җиңеләбез, бүләкләнәбез-бүләксез калабыз, ымсынабыз-югалтабыз, уйныйбыз-көләбез... Сабан туе мәйданы —Ил-Ватан мәйданы, тамашачылары — халкыбыз.

Әйтик, без — атлы халык, сабан туебызда без атта; без мал-туарлы халык — сабан туебызда баш батырга бүләгебез —тәкә; без һөнәрле халык — сабан туебызда кызларыбыз чиккән бүләк сөлгеләрне эләктерер өчен генә дә һөнәрләренне, зирәклегеңне, житезлегеңне, батырлыгыңны һәм башка булдыклыкларыңны күрсәтәсең.

Сабан туйларында хезмәткә мәдхия. Атка мәдхия. Батырлыкка, баһадирлыкка мәдхия. Җыр-биюгә, уен-көлкегә мәдхия. Болар бар да халыкның үзенә мәдхия булып берләшә.

Могҗиза — без үзебез, гомумкешелек хәзинәсендә кыйммәтле бер өлеш — татар халкы.

Дамир Шәрәфетдинов төрле яклап шуны раслый.

Нәкъ менә шуна күрә сабан туебызны саклау — татарның үзен саклау. Нәкъ менә шунлыктан сабан туебызга һәр яктан игътибар зур: тугандашлар ягыннан да, безне өнәмәүчеләрдән дә, дөнья сәясәтен билгеләүчеләр тарафыннан да.

Без хәзер үзебезнең җегәрлегебезне барлыйбыз, әйтәбез: безне тел яшәтә, безне дин яшәтә, безне моң яшәтә! — дибез.

Дөрес булып күренсә дә, бик үк төгәл фикер түгел шикелле. Беләбез: бер үк халыкның берничә дине була ала. Ә теле, моңы, сабан туе — бер, уртак. Ул идеологияләрне, диннәрне дә үзенә сыйдыра, үз эченә ала.

Китапта Казан галиме Карл Фукс — безнең халыкны хөрмәт иткән һәм бик матур истәлек-язмалар калдырган кеше язмасыннан өзек китерелә. Галим авыл сабан туен сурәтли, шуннан бер җөмләгә игътибар итик әле: "...Берничә курайчы (татар музыкантлары) үзләре ясаган скрипкәләрдә бию көйләрен уйныйлар иде, биергә аларда ирләргә генә рөхсәт ителә, хатын-кызлар исә көймәле арбалардан (кибиткалардан) карап торалар"...

Нибары 150 ел элек булган сабан туе күренеше. XX гасыр, татарның яңарыш гасыры, хатын-кызларыбызны да уятты, кузгатып җибәрде, иҗади тормышка кайтарды. Әйе, кайтарды. Алар хөр, азат булган гасырлар ераграк тарихта калган. Мәйданга хатын-кыз кайтуы сабан туйларын ямьләндереп, җанландырып, көрәш-ярыш рухын көчәйтеп җибәрде.

1912 ел сабан туен күргән берәү менә ничек дип язып калдырган: "...халык шундый күп булуга карамастан, сабанда салмыш яки, гомумән дә, тәртипсезләнүче кешене бик сирәк очратырга мөмкин. Тәртип үрнәк булырлык, күңел ачучыларның үзләре тарафыннан бик бирелеп саклана. Бу очракта татарларны бары тик мактарга гына мөмкин, алар үз ялларын акыл белән үткәрәләр".

Хәзерге заман язмаларына күз салсак та, шул ук фикер теркәлгән: сабан туе мәйданы — эчкечеләр өчен түгел! Мәсәлән, мәскәүле кунакларыбыздан Н. Молчанов "Труд" газетында Балтач район сабан туеннан язмасында: "Соңгы вакытта кемнендер "җинел" кулыннан сабан туе дип шау-шулы эчешләрне атый башладылар. Дөресен әйткәндә, халык белән кумәк күңел ачуларның ин аекларыннан булган бәйрәм өчен кимсенеп куясың", — дип язган (13 июнь, 1985 ел). Аек яшәү рәвешен тормышка ашыруга күп көч куйган академик Ф. Углов та үзенең "Иллюзияләр әсирлегендә" дигән китабында КамАЗда сабан туйларының хәмерсез үтүен әйтә: "Сабан туенда бер грамм да исерткеч эчемлек юк", — ди.

Елмаеп укыйбызмы әлеге юлларны? Канәгатьлектән елмаюыбыз булсын.

Әнә бит сабан туйларыбызны кимсетергә әзерләр дә бар. Үзебез төшермик, үзебезне үзебез пычратмыйк. Дөньяда безнең данымыз шундый. Сабан туебыз үзен ямьсезләүчеләрне кабул итми.

Татарны өнәмәүчеләр сабан туеның аның тормышында нинди урын тотканын бик шәп аңлыйлар. Чит-ятлардан аны кабул итмәүчеләр һәрвакыт табыла торыр, чөнки башка дин, ырым, ышану, күңел, көй... Бу — аңлашыла.

Сабан туеның җанын саклау — ул татарны мөстәкыйль халык итеп саклау. Беренче чиратта төрки дөньяда, ислам дөньясында!

Укучыны китап шундый фикергә китерә. Дамир Шәрәфетдинов, бетәбезме — калабызмы дип, Габдулла Тукайча әйтсәк, милләтебезнең баш очында ясин чыгып утырмый, аның ният-өметләре ерак бабаларыныкыдай: сабан туе мәйданыннан бөтендөнья мәйданына чыгу. Китапта махсус бүлек бар: "Сабан туеннан — Бөтендөнья уеннарына" диелгән. Сабан туе уеннарыннан — Олимпия уеннарына була инде бу. Белмәүчеләр үзалдына елмаеп куяр: "Хыяллану — файдалы шәйдер", — дияр. Белүчеләр белә: сабан туе батырлары күптән инде Олимпия биеклекләрен алдылар. Китапта шундый фоторәсем бар: җиңүчеләр пьедесталының иң югары баскычында яшь бер татар егете басып тора. Рәсем астыннан укыйбыз: "Татар сабан туе батырларыннан беренче булып 1952 елда Хельсинкида XV Олимпия уеннарында грек-рим көрәше буенча чемпион булуга ирешкән Шәзам Сафин". Беренчесе, әмма соңгысы түгел. Безнең хәзер сабан туе уеннарын гыйльми нигездә өйрәнүче галимнәребез, тренерларыбыз бар. Олимпия чемпионнары Ш. Сафин, Ш. Хисаметдиновларның, дөнья чемпионы Ф. Мостафинның, Европа чемпионнары М. Тажетдинов, К. Фәткуллин, Х.Бикташев, Р. Насыйбулловларның, дөнья беренчелеге бүләкләре иясе Л. Сәлимуллин һәм Н. Гәрәевләрнең, СССР чемпионы Х. Тимашевның, Россия чемпионнары Ә. Шәйхетдинов, Р. Шәрәфетдинов, И. Яруллиннарның, халыкара класслы спорт осталары Н. Измайлов, Р. Камалов, И. Мөхәрләмов һәм башка бик күпләрнең күренекле казанышларын беләбез. Унбер тапкыр СССР чемпионы, биш тапкыр Европа чемпионы, өч тапкыр дөнья чемпионы, Олимпия уеннарында көмеш медаль алган Минзәлә егете Виталий Кузнецовны да зур спорт мәйданына сабан туе чыгарды. "Сабан туеннан башладык" — бик күп илкүләм, дөньякүләм батырлар шулай дип әйтә алырлар иде...

Язучылар журналында ассызыклап үтү урынлы булыр: татар журналистлары һәм публицистлары безнең батырларыбыз һәм аларның остазлары, аеруча Татарстаннан читтә яшәүчеләре алдында бик зур бурычлы. Шул уңайдан Дамир Шәрәфетдинов искә алып үтә: "...Җитмешенче елларда бер китап төзергә омтылыш ясаган идем. Әмма ләкин омтылышым кайбер каләмдәшләребез күңеленә ятмады. Күренекле татар чемпионнары һәм Татарстан җирендә җитлеккән, илебезнең башка якларында яшәүче башка милләт вәкилләре турындагы язмаларым өчен язучыларның еллык җыелышында, "интернационализмны һөнәргә әйләндереп", озак еллар дәвамында шушы төшемле эш белән шөгыльләнүче берәү миңа "милләтче" ярлыгы таккан иде. Шуның артыннан, ул елларда гадәткә кергәнчә, КПСС өлкә комитетына әләкләр яуды һәм катгый төстә "юл куймаска" дигәгә ирешелде. Олимпияче якташларыбыз турындагы белешмә дүрт елдан соң гына дөнья күрә алды. ("Җир шары алкышлый". Хикәяләр һәм очерклар — төзүчесе Д. Шәрәфетдинов. 1976 ел. Илдарханов И. Г. "Олимп тавына ничек менәргә?", 1980 ел)

Андый тыюлар артта калган һәм Казаныбыз капкалары бар дөнья татарлары өчен киң итеп ачылган бүгенге заманда бу игелекле тема дәвам иттерелер һәм үстерелер дип, автор ышанып кала. Бу — аның тәкъдиме.

Ә менә мондый тәкъдимгә ничек карарсыз? Алда без сабан туе уеннарының төп төрләре: көрәш, авырлык күтәрү, йөгереш-узыш һәм башка кайберләре бөтендөнья уеннары төрендә һәм дәрәҗәсендә икәнлеген күреп үттек. Төрки халыкларның милли көрәш төрләре белән безнең көрәшебез охшашлыгы, алардагы уртаклыклар аеруча зур икән бит. Ни өчен, әйтик, күренекле татар тарихчысы һәм шул ук вакытта шактый билгеле сабан туе батыры Шиһабетдин Мәрҗани бүләге игълан итеп (сүз уңаеннан, күренекле тарихчыбыз Һади Атласиның да Буа сабан туйларында оттыру белмәс батыр булганлыгын әйтеп үтик), билгә сөлге салып көрәш буенча халыкара ярышлар оештырмаска ди?! Аларда катнашырга, үзеннән-үзе билгеле инде, барысы өчен дә ярарлык кагыйдәләрне алдан ук килештереп, якындагы чит илләрдән, шулай ук ерактагыларыннан да, мәсәлән, Япониядән, Кытайдан, Кореядан, Төркиядән, Ираннан, Әфганстаннан, Пакыстаннан, Гыйрактан һәм башкалардан командалар чакырырга мөмкин булыр иде. Билгә сөлге салып көрәшү — дөнья халыкларының байтагында таралган спорт төре.

Әле Татар иҗтимагый үзәгенең II корылтаенда ук Дамир Шәрәфетдинов тарафыннан барлык кыйтгалардан татар вәкилләрен чакырып, милли спорт төрләре

буенча Бөтендөнья уеннары оештыру тәкъдим итеlә, бу тәкъдим беркетмәгә дә кертелә. Мондый тәҗрибә башка халыкларда бар икән. Әйтик, Литвада, Чувашстанда. Безнең уеннарыбыз бары тик сабан туе уеннарыннан гына тора алыр иде. Галим Б. Солтанбәковның әлеге ярышларны "Идегәй уеннары" дип атарга кирәк, дигән тәкъдиме дә игътибарга лаек. Һәм бу уеннарны (бәлки, без аны җыен яки мәйдан дип атарбыз) Татарстан Республикасы төзелү көненә туры китерергә мөмкин булыр иде.

Шәп булыр иде!

Китап авторының тагын бер тәкъдиме шундый: "...татар халкының ел фасылларына караган бәйрәмнәре, аның уеннар фольклоры әле һаман аз өйрәнелгән өлкә булып кала килә. Күп кенә уртаклык һәм аермалыклары булган "кече" һәм "зур" сабан туйларын үткәрүдәге уңай тәҗрибәне фикерләү таләп итеlә. Халык хәтереннән сакланып калган хәзинәләрен, күпгасырлы бәйрәмнең төп элементлары булып торучы риваятьләрен, фольклор һәм тел һәйкәлләрен бөртекләп, тамчылап җитди анализлау зарури. Мәсәлән, "Идегәй" дастаныннан:

Алтысында ат менде,
Җидесендә җәя тартып,
Җиде тотам ук атты.
Сигез — тугыз булганда,
Сигез тукмак сындырып,
Туң тимергә кул орды.
Унга җитте — ул булды,
Ул ни дисә шул булды,
Чүлгә чыгып басканда
Чүл ярылып юл булды,
Тауга чыгып басканда
Тау сыгылып уй булды.
Унберендә бер булды,
Уйныксыз чичән ул булды.
Уникегә җиткәндә
Алпамыштай ир булды... —

дигән юлларны укыганда санап кителгән сынау-сыналулар тәгаен җыеннар, сабан туйлары һәм башка йола, бәйрәм мәйданнарында булгандыр, дип уйлап куясың. Халкыбызның "Дутан батыр" дигән әкиятендә әйтелгәнчә: "Туй булгач, күп халык җыелырга кирәк, мәйдан җыярга, атлар ярышырга, көрәшчеләр көрәшергә кирәк".

Шулай икән, милли тәрбия чараларын тарихи планда өйрәнү, максатчан этнографик тикшеренү ысулларын киң куллану, инде тупланган этнография, археология, фольклорга караган һәм башка материалларны фәнни әйләнешкә кертү буенча әле башланмаган эш өелеп тора.

Безнең карашка, заман Татарстан Фәннәр Академиясе Тарих институты каршында гыйльми үзәк яки лаборатория төзүне таләп итә. Гыйльми эшләрне матди яктан тәэмин итеп торырдай "Сабан туе фонды" оештырып җибәрергә дә булыр иде.

Китапта без гасырлар авазын ишетәбез. Автор гасырлардан килгән тарихи чыганаклар, мәгълүм галимнәрнең хезмәтләре белән эш итә, аларның төрлесе белән очраша. Тамырларыбызны эзләп, ул халкыбызның тарихи хәтеренә мөрәҗәгать итә. Сабан туеның тарихын ачыклау — халкыбызның тарихын, шәҗәрәсен ачыклау. Сабан туе өчен көрәш бара. Тарихыбызны бозулар белән көрәш бу. Соңгы меңъеллыкта фикерләрен калдырган галимнәр, язучылар: Ибне Фадлан, Йосыф Баласагуни, М. Кашгари, Әбү Хәмид Әл-Гарнатый, Сәйф Сараи, П. Рычков, В. Радлов, К. Фукс, М. Солтангалиев, Н. Семенов, М. Артамонов, Р. Нәфигов, Я. Ханбиков, Н. Фәттах, М. Госманов, Я. Абдуллин, Р. Уразманова, И. Таһиров, Э. Галиев, Н. Колчин, М. Сәхәбетдинов һәм башкалар бар. Без сабан туебызның тарихы, гасырлар дәвамында үсеше, янарышы, баюы-югалтулары хакында фикерләр, мәгълүмат белән танышабыз. Китапның бер сыйфаты: фикерләшү, бәхәсләшү, дөреслекне табарга тырышу. Бу очракта, сабан туена

кагыйшлы рәвештә ул — гүзәллекне, камиллекне эзләү.

Дамир Шәрәфетдинов ачынып яза: "Сабан туеның программасын камилләштерү, баету, тагын да нәфисрәк, гүзәлрәк итәргә кирәк дигән булып, аны, "бөтенләй дә интермилли бәйрәмгә" әйләндерергә маташулар булды. Һәм сабан туе үзенең кыйммәтле халыкчан җанын югалта, төссезләнә башлаган иде инде. Әмма рухи яңарыш заманы мондый бер чиктән икенчесенә ташлануларны кискен кире какты. Һәм сабан туе кабат үзенең борынгы, кабатланмас бизәкләренә төренде...

Бары тик халкыбызның җаны, аның күмәк рухи хәтере белән тудырылган йолабызның барлык өлешләренә һәм сыйфатларына, беренче чиратта, спортка караган төрләренә хөрмәтле мөнәсәбәт булганда гына, ялган бәйрәм иҗат итүчелеккә бирелмәгәндә генә, сабан туйларыбызны уңышлы үткәреп булачагына исәп тотарга мөмкин..."

"Сабан туе" китабы зур-калын түгел. Анда нибары 100 битләп текст: очерклар, язмалар, йола-бәйрәмнәрдән репортажлар. Шунда ук гомумләштерүләр, гыйльми йомгаклар. Йомгак, нәтиҗә, ирешелгәннәр — нигез. Шул нигездә хәл ителәсе проблемаларыбыз. Барысы да бер проблемага туплана:

— Татар булып, халык булып киләчәккә барасы да барасы иде...

Бу китап — яшәүчеләр китабы. Яшәү рәвеше китабы! Аңарда татар зарланмый, кимсенми, дөньясын шаулатып, дөнья уртасында яши. Һәр эшле кешенеке кебек, безнең халыкның да эшләре тулып ята.

Китап эшкә өйрәтә, спортчыларны, хакимиятне, галимнәрне, шагыйрьләрне — барыбызны да эшкә җигә. Ярдәмгә 40 тан артык кушымта-кулланмалар да тәкъдим ителә.

Китапның йомгак бүлеге "Сабан туе киләчәккә атлый" дип атала. Китапны укыган кеше күңелендә: "Сабан туйлы халык —татар үзе киләчәккә атлый", — дигән фикер урнаша. Әйе, татар халкының үз асылын югалтканы да юк...

Бу китапны сез дә үзегездә булдырырсыз, укырсыз, фикерләрегезне уртага салырсыз.

Сабан туенда очрашуларга кадәр...

**Хәмзә ЗАРИПОВ**

## Киләсе санда укыгыз:

"Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, миңа быел Хаҗ сәфәре кылу бәхете насыйп булды. Хаҗдан алган тәэсирләрем шул хәтле тетрәндергеч һәм көчле булды ки, мин әле шушы көнгә хәтле бу зур бәхетнең миңа насыйп булуына ышанып та бетә алмыйм. Анда күргәннәрне, анда кичергәннәрне язарга сүзләр җитми, шул хәтле илаһи һәм дәһшәтле манзараларны тасвирларга сүзләр көчсез, бәндә көчсез, каләм көчсез... Кәгъбәтулла өстендә яңгыраган төнге азан авазлары, миллионлаган мөселманнарның, кәфенлеккә уралган әрвахлар сурәтендә Аллаһ йорты янына җыйналулары, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә укылган намазлар, Пәйгамбәребез рухын саклаган кара мәрмәр таулар... Бу күренешләр, бу авазлар, бу тәэсирләр гомеремнең ахырына кадәр мине озата барырлар, мәңге онытылмаслар, мәңге җуелмаслар..."

*Бу өзек язучы һәм җәмәгать эшлеклесе **Фәүзия Бәйрәмованың "Тәгәри китте йомгагым..."** исемле язмасыннан алынды. Динебез хакында тирән уйланулар белән сугарылган бу әсәр тулысы белән журналның 9 һәм 10 саннарында дөнья күрәчәк.*

\. . .

Əj Idel — jort, Idel jort!
Idel bujь imin jort!
Atam kijəy bulgan jort —
Ielep təgzim qьlgan jort, —
Anam kilen bulgan jort —
Ielep səlam birgən jort,
Kendegemne kiskən jort,
Kerem — koņьm jugan jort,
Bi ə saugan sөtle jort,
Qьmьz eckən qotlь jort,
Idel Çajьq arasь
Jьlqь belən tulgan jort,
Qazan — Bolgar arasь
Qala belən tulgan jort.

*("Idegəj" dastanьnnan.)*

## Gabdulla Tuqaj

### Yz — yzemə.

Telim bulьrga min insane gali,
Teli kyņlem təgali bittəwali.

Kyņle berlən søjəm bəxten tatarnьņ,
Kyrergə çanlьlьq waqtьn tatarnьņ.

Tatar bəxte өcen min çan atarmьn:
Tatar bit min, yzem də cьn tatarmьn.

Xisapsьz kyp minem millətkə wəgdəm,
Qьrьlmasmь "wawъ", wallahe əgləm?

## Dərdmənd

\. . .

Atam — anam jortь өcen
Bulsa meņ çanьm fida,
Tugan yskən çirem өcen
Soņ tamcь qanьm fida.

## Ildar Juzief

### Bez tatarlar — Saq—Soqlar

Kem ikənne əjtsen bəjet:
Bez — qargalgan xalьqlar:
Tərle jaqlarga ocqanbьz
Bez — tatarlar — Saq—Soqlar.
Ənkəbez dəres qargagan,
Citləp ytkən şatlьqlar.
Telengənbez, bylengənbez
Bez — tatarlar — Saq—Soqlar.
Təxettən tartьp təşerde
Xəsetleklər, waqlьqlar.
Ber çirdə jəşi almadьq
Bez—tatarlar — Saq—Soqlar.
Barьr julda — ьşanьcsьz
Juldaşlar wə sazlьqlar.
Baltalarga totьnmadьq...
Bez—tatarlar — Saq—soqlar.
Ykensə də, Ənkəbezdə —
Tugan teldə xaqlьqlar.
Gafu sorьjq Ənkəbezdən
Bez—tatarlar — Saq—Soqlar.
Əmma çanda isən əle
Aqlьqlar wə saflьqlar.
Kiek buldьq, bəjek buldьq
Bez—tatarlar — Saq—Soqlar.
Bəjek bulsaq ta bojьq bez,
Kiler ber kən şatlьqlar:
Anga kilep kawъşьrbьz
Bez—tatarlar — Saq—Soqlar!

## Ravil Fəjzullin

* * *

Dənja — əle gel qojaşlь.
Jazmьş — şəfqət tutaşь.
In tatlь təşemdəgennən
əndəge cьnьm jaxşь.
Min — bəxettən jaqtьrtucь
joldьz astьnda tugan.
Qajgьm da minem aq təstə —
ərekmim qurqьtudan.
Tik ber qurqu: bəxetemne
Il belən jugaltudan.

## Renat Xaris

### Çir — mində

Tuƣan çiremdə jəşim min.
Dimim altьn, dimim kɵmeş —
Ruxьm imin.
Min tuƣan çiremdə jəşim.
Tuƣan çirdən — jьlmajuьm,
Tuƣan çirdən — kyz jəşem.

Jəşim min tuƣan çiremdə.
Anda minem syz ezem də,
Qajnap tamƣan tirem də.
Tuƣan çiremdə
Min — çirdə,
Çir — mində.

## Rədif Ƣataş

...

Jə, nicek? Taƣьn qalqьnьp ber synyme?!
Şulmь bu? Aqtьq talpьnu — yzeme?
Xalqьm, inde çiŋygə bit bu adьm?! —
Juqsa, jatlar jazƣan xɵkem — ylemme?

Ə nindi kɵc julnь bygen kirtəli?
Şatlansaq, kisətə çannь: irtə, di,
Nindi fəlsəfə qullanьr səjəsət?!
Taƣьn ƣajepme millətkə məxəbbət?!

Jarsьp aƣa tьjьlƣan taşqьn—sular,
Inde daulьj yz julьn milli çьrlar,
Waqьtьn kətkən xalqьmda kypme kɵc!
Ylməgənbez, əle bajtaq dərman bar.

Əmma nigə waq—təjək bəxəs, ьzƣьş,
Acьlsьn çanda ikence saf sulьş!
Moŋarcь "gɵnaһ" sanalƣan izge uj —
Xalqьŋnь səjudən tusьn һərber eş!

Nicek? Kemder: irtə, dime? Soŋ dime?
Təmam synərgə, kynərgə ɵndime?!
Tьŋlama, qaumem, manqortnь, xainnь,
Jandьr, fakel it soŋƣь qat çanьŋnь!

...Yzeŋ xəl it, xalqьm, yz jazmьşьŋnь!

# МӘҢГЕЛӘШКӘН МИЗГЕЛЛӘР



Мидхәт Шакиржанов... Бу исемне әйтүгә, безнең күз алдына, менә шушы сурәттәгечә, нурлы елмаеп, олпат ир-ат — заманыбыз фотоелъязмачысы килеп баса. Чын мәгънәсендә, мизгелләрне мәңгеләштерүче Тылсымчы ул! Республикабызның төп газетасы "Ватаным Татарстан"да 38 ел эшләве дәверендә генә дә барлыгы 45 меңләп (!) фоторәсеме дөнья күргән Мидхәт аганың. Ә башка газета-журналларда (шул исәптән, безнең "Казан утлары"нда!) республикабыздан читтәге матбугат басмаларында һәм үзәктә басылганнарын да өстәсәң, рәсемнәр диңгезе хасыйл була.

Тынгысыз фоторәссам үз гомерендә Кояш чыгышы иле — Япониядә, Мисырда, Грециядә, Төркиядә, Болгариядә, элекке союздаш республикаларда һәм Россия Федерациясенең күп кенә төбәкләрендә була, Татарстанның барлык районнарын, шәһәр-авылларын инли...

Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт Фәйзелхак улы Шакиржанов — әдәбият-сәнгать әһелләренең һәм журналистларның да якын дусты, арка таянычы. Аның язучыларга, артистларга, композиторларга, рәссамнарга багышланган меңләгән фоторәсемнәре — бәһа биргесез олы хәзинә. Алар үткән белән бүгенгене, бүгенге белән киләчәкне тоташтыручы хикмәтле күпер вазифасын үтиләр.

Бүген без укучыларыбыз игътибарына Мидхәт ага архивындагы кайбер фоторәсемнәрне тәкъдим итәбез.



***Беренче мизгел.*** *"Казан утлары" журналының баш мөхәррире, шул ук вакытта СССР Язучылар союзы секретарьларенең берсе дә булган фронтовик әдип Зәки Нури (сулда), үзенең каләмдәшләре Гөлшат Зәйнашева, Сафа Сабиров, Шамил Рәкыйпов һәм Нәби Дәүли белән бергә, Казан елга портында Уфадан килүче "Тукай" теплоходын каршылый. Билгеле булганча, безнең әдипләр бу теплоходка шефлык иткәннәр (1975 елның мае).*



***Икенче мизгел.** Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары. Беренче рәттә (сулдан уңга) — композиторлар Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Г. Камал театры артисткасы Шәхсәнәм Әсфәндиярова, шагыйрь Хәсән Туфан, композитор Александр Ключарев, икенче рәттә — рәссам Эрнст Гельмс, нәфис сүз остасы Айрат Арсланов, Г.Камал театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов, рәссам Николай Кузнецов һәм Г. Камал театры артисты Шәүкәт Биктимеров. (1971 елның 30 декабре)*



***Өченче мизгел.** Туган̄даш Башкортстанның Яңавыл районы — татар дөньясын данлаучы олуг шәхесләрне тудырган төбәк. Атаклы язучы-галим, Г. Тукай премиясе лауреаты Нурихан Фәттах белән күренекле рәссам-график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Зарипов — әнә шундый затлардан (1978 елның 3 ноябре).*



**Дүртенче мизгел.** *Вакытсыз арабыздан киткән талантлы каләмдәшебез — "Казан утлары" журналында озак еллар эшләгән шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов. Татарстан Җөмһүриятенең азатлыгын һәм бәйсезлеген яклап, мәйданнарда халык алдында ялкынлы шигырьләре белән күп мәртәбәләр чыгыш ясады. Аның шигърияте бүген дә алгы сафта, көрәшчеләр сафында ( 1992 елның 11 мае).*



**Бишенче мизгел.** *Яшьтәшләр — 1941 елда туган өч дус — Казан дәүләт педагогия университетының әдәбият кафедрасы мөдире, язучы-галим, югары категорияле диктор Фоат Галимуллин (сулдан-беренче) , Кукмара районының "Яңа тормыш" арендачылар берлеге рәисе, Татарстанның атказанган агрономы Рәфыйк Рәуфов, Татарстанның халык артисты Мингол Галиев (1996 ел).*

**Редакциядән**: *быел 27 августта Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы Мидхәт ага Шакирҗановка 70 яшь тула. Без өлкән фоторәссамны юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз, аңа нык*л*ы саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез!*

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ — АБРУЙЛЫЛАР ИСЕМЛЕГЕНДӘ

Социалогик эзләнүләр үзеге һәм матбугат чаралары ярдәмендә җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү соңгы елларда гадәткә керде. "Независимая газета" үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәсендә, иң абруйлы утыз дәүләт эшлеклесе исемлегенә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев тә керде. Ул әлеге исемлектә өченче урында тора.

### КАРДӘШЛЕККӘ ЧИКЛӘР ЮК

Татарстан Республикасы башкаласында Кабарда-Балкар Республикасы Президенты В. Коков җитәкчелегендәге делегация булып китте. Делегация составына КБР Хөкүмәте Рәисе Х. Чеченов, парламентның Вәкилләр Советы Рәисе И. Бочелов һ.б. рәсми кешеләр бар иде. Ерактан килгән кунакларны ТР Президенты М. Шәймиев кабул итте.

21 июньдә Казан Кремлендә Татарстан һәм Кабарда-Балкар Республикалары арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы Килешүгә кул куелды.

### ӘЛМӘТТӘ ТАНТАНА

20 июньдә Татарстан нефте башкаласы Әлмәттә олы вакыйга — Мөселманнарның дини, мәдәни-мәгърифәт үзәген ачу тантанасы булды. Әлеге комплекс, Җөмһүриятебезнең Диния нәзарәте башлангычы белән, "Татнефть" акционерлык җәмгыяте акчасына җиткерелде.

Үзәкне ачу тантанасында Татарстан Республикасының Министр Кабинеты Рәисе урынбасары Илгиз Хәйруллин, Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Госман хәзрәт Исхакый, "Татнефть"нең генераль директоры Ринат Галиев, "Хәзинә" газетасының баш мөхәррире, язучы Нур Әхмәдиев һ.б. чыгыш ясады.

Әлеге мәһабәт корылмаларны төзүдә зур тырышлык күрсәткәне өчен, халык тәкъдиме белән, үзәккә Ринат Галиев исеме бирелде.

### ХӘТЕРЛЕ ХАЛЫК ҮЛМӘС

22 июньдә, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларыбызны искә алу көнендә, Казан милли мәдәният үзәгендә беренче мәртәбә 23 томлы "Хәтер китабы" белән таныштыру булды. Билгеле булганча, әлеге томнарга Җөмһүриятебез шәһәр-авылларыннан сугышка китеп һәлак булган 340 меңнән артык кеше турында кыйммәтле мәгълүматлар бирелгән.

Әлеге томнарны халыкка ТР Министрлар Кабинеты каршындагы "Хәтер китабы" редакциясенең баш мөхәррире А. Иванов тәгъдим итте.

### АЛТЫН УРДАГА БАГЫШЛАП

23-25 июнь көннәрендә "Казан" милли мәдәният үзәгендә "Җучи Улусы (Алтын Урда) тарихи чыганаклары. Калкадан Хаҗитарханга кадәр (1223-1556)" дип исемләнгән халыкара семинар үткәрелде. Аның эшендә Россия, АКШ, Алмания, Япония, Венгрия, Төркия, Кытай, Монголия һ.б. мәмләкәтләрдән килгән күренекле шәрекъ белеме галимнәре катнашты.

Семинарда 30 дан артык доклад һәм чыгыш тыңланды. АКШ галиме Шамил Юлайның әле яңа гына Алтын Урда тарихына багышлап чыгарылган китабы семинарда катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Автор әлеге куәтле дәүләтнең чума авыруыннан соң юкка чыгуын дәлилли. Шәрекъ институтының Санкт-Петербург филиалы директоры Е. Кычанов, Тайваньнан яшь галим Чхао Чху-Ченг чыгышлары да яңача фикерләү белән аерылып тордылар.

### ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — ТАТАР МӘГАРИФЕ

Казанда "Россия Федерациясенең татарлар күпләп яши торган төбәкләрендә татар мәгарифен үстерү проблемалары һәм перспективалары" дигән темага төбәкара фәнни-гамәли конференция булды. Анда Татарстан Мәгариф министры Ф. Харисов, КДУның татар теле кафедрасы мөдире, профессор Ф. Сафиуллина, ТР халык депутаты, язучы Т. Миннуллин һ.б. чыгыш ясады.

Конференция эшендә Мәскәү, Семипалатинск, Самара, Чиләбе, Уфа шәһәрләреннән, Свердловск, Ульяновск, Пермь өлкәләреннән, Удмуртия, Коми республикаларыннан килгән татар теле укытучылары һәм мәгариф хезмәткәрләре катнашты.

## КҮЧМӘ УТЫРЫШ ҮТКӘРЕЛДЕ

Казакъстанның Семипалатинск шәһәрендә Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитеты бюросының күчмә утырышы үткәрелде. Утырышны Башкарма комитет рәисе — академик Индус Таһиров алып барды.

Татарстан кунаклары әлеге шәһәрдә үткән беренче халыкара Сабантуйда да катнаштылар. Зөһрә Сәхәбиева, Мирсәет Сөнгатуллин, Рамил Курамшин кебек танылган артистларыбызның чыгышларын тамашачылар яратып кабул иттеләр.

## ТАТАРСТАН ЧУАШ УЛЫН ЗУРЛЫЙ

Тәтеш районының Кошки авылында чуаш халкының күренекле мәгърифәтчесе Иван Яковлевнең музее ачылды. Билгеле булганча, шушы елның апрелендә аның тууына 150 ел тулу тантаналары үткәрелгән иде.

Әлеге мәдәният үзәген тергезүдә Татарстан Мәдәният министрлыгы, ТР ның Берләштерелгән дәүләт музее, Чувашстан Милли музее зур көч куйды.

## ТАИСның БИШ ЕЛЛЫГЫ

Моннан биш ел элек "Татар интеллектуаль милек агентлыгы" (ТАИС) оешкан иде. Бу оешмага авторлык хокукларын саклау, шул юнәлештә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, гамәлдәге законнарның үтәлүенә күзәтчелек итү вазифалары йөкләнде. Кыска гына вакыт эчендә ТАИС (җитәкчесе — язучы Рәфкать Кәрами) авторларны һәм аларның варисларын теркәп, аларга тиешле гонорарны түләү, консультацияләр белән ярдәм итү кебек мөһим эшләрне башкарды.

Оешманың биш еллыгы уңаеннан, Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында җыелыш булып, авторларның хокукларын киләчәктә тагын да ныграк яклау буенча эшлекле сөйләшү үткәрелде. Җыелышта, язучылар белән бергә, композиторлар, рәссамнәр дә чыгыш ясады.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ САФЫНА

Татарстан Язучылар берлегенең 22 июньдә үткәрелгән идарә утырышында тагын 6 кешене берлеккә әгъза итеп кабул итү булды. Бәхетлеләр арасында Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе профессоры, шагыйрь Рифат Җамал (Корбанов), танылган публицист-галим Мәхмүт Әхмәтҗанов, шагыйрә һәм тәрҗемәче Флера Тарханова, драматург Гафур Каюмов, прозаиклардан — "Казан утлары" журналының җаваплы сәркатибе Алмаз Гыймадиев, Чаллыдан Ирек Диндаров бар.

## ТУГАНЛЫКНЫ НЫГЫТУ ЮЛЫНДА

Язучы Тәүфикъ Әйди туган әдәбиятыбызның халыкара багланышларын ныгыту максатында Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәгестан илләрендә булып кайтты. Ул анда Язучылар Берлекләре җитәкчеләре, күренекле җәмәгать эшлеклеләре, бу илләрдә чыгучы төрле газета-журналларның мөхәррирләре белән очрашты.

Т. Әйди Алматы, Бишкәк, Ташкент шәһәрләрендә татар диаспорасы җәмгыятьләре эше белән дә танышты, милләттәшләребез алдында чыгышлар ясады. Әдип җирле радио һәм матбугатка мәдәни багланышларга кагылган интервьюлар бирде.

## ШОСТАКОВИЧ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

Татарстан Композиторлар берлеге идарәсе рәисе, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Рәшит Кәлимуллин, халыкара фестивальләрдә зур яңгыраш тапкан музыкаль әсәрләре өчен, Россия Композиторлар берлегенең Д. М. Шостакович исемендәге премиясенә лаек булды. Аңа әлеге зур бүләкне РФ Композиторлар берлеге идарәсе рәисе, Россиянең халык артисты, якташыбыз В. Казенин тапшырды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, ветеринария медицинасының иң мөһим юнәлешләрендә эшчәнлек алып баруда һәм авыл хуҗалыгы кадрлары әзерләүдәге уңышлары өчен, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе профессоры, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Рифат Җамал** улы **Корбановка** "Татарстанның атказанган фән эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә**: Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев туграсы — рәссам-каллиграф **Нәҗип Нәкъкаш** (Н. Исмәгыйлов) эше.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Рәмзия МӨХӘММӘДОВА. **Татар халык киемнәре.** — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 224 б. Тиражы — 5000 данә.




Төрле җирләргә таралып яшәгән халкыбызның кием сәнгате гаять үзенчәлекле. Автор тарихи мирас булып калган шул хәзинәне озак еллар дәвамында ныклап өйрәнеп, бар булганын бергә туплап, укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итә. Бу альбом-китап этнографик байлыгыбыз турында кызыксынган кешеләргә шактый мул мәгълүмат бирер, ә инде сәнгать әһелләренә һәм модельерларга милли кием үрнәкләре әзерләүдә ярдәме тияр.

Китап-альбомның авторы — Рәмзия Гыйният кызы Мөхәммәдова — тарих фәннәре кандидаты. Аның авторлыгында һәм автордашлыгында татар халкының традицион мәдәнияте һәм көнкүрешенә багышланган байтак фәнни хезмәтләр һәм мәкаләләр дөнья күрде.

Китапның төп тексты татар һәм рус телләрендә басылган, шулай ук инглиз телендә сөземтә-рюземе бирелгән.

Флүс ЛАТЫЙФИ. **Уяну**: *публицистик язмалар, очерклар, парчалар.* — Казан: "Сәләт" китапханәсе, 1998. — 211 бит. Тиражы — 3000 данә.





Халкыбыз мөстәкыйль Казан дәүләтендә яшәгән чордагы мавыктыргыч вакыйгаларны сурәтләгән мәгълүм "Хыянәт" романы, күпсанлы повестьлар, хикәяләр авторы, танылган язучы, публицист Флүс Латыйфиның бу китабына халык, ил язмышы, туган тел, гомумән, татар халкының бүгенге дөньядагы урыны турында җитди уйланулар белән сугарылган мәкаләләре, очерклары тупланган.

"Мин бик еш халкыбыз язмышы, телебез язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакында уйланам. Халкыбызны дөньяның алга киткән милләтләре сафында күрәсем, туган телебезнең киң күкрәктән дөнья эфирында яңгыраганын ишетәсем килә..." ди автор. Китапта басылган әсәрләр нәкъ менә шул теләкне тормышка ашыру нияте белән язылганнар да инде.

Китапның ахырында язучының моңа кадәр басылып чыккан китапларының библиографиясе дә бирелгән.

Индекс 73210



Язучы Солтан Шәмси

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)